ISSN 0206–4189
Индекс 73210 12+

# Казан утлары

4.2015



№4 (1110) 2015

# БУ САНДА:



**Ягъсуф ШӘФЫЙКОВ**
**«Рейхстагка Җиңү Байрагын беренче булып кем кадаган?»**

«30 апрельдә штурм вакытында Заһитов Рейхстагка беренче булып бәреп керде... Яраланган өлкән сержант Заһитов, сержант Минин белән бергә Рейхстаг башнясына күтәрелеп, беренче Җиңү Байрагын кададылар.
Рейхстагны штурмлауда күрсәткән тәвәккәллеге, батырлыгы һәм кыюлыгы өчен иптәш Заһитов Советлар Союзы Герое исеменә лаек».

104

# КИЛӘСЕ САНДА:

**Бөек Ватан сугышы.**
**XXI гасырдан караш.**



«Бөек Җиңүгә 70 ел тула. Бөек Ватан сугышы – тарихыбызның иң фаҗигале вакыйгасы. 1941-1945 – үткән гасырның иң дәһшәтле еллары. Тарих фәнендә бу сугышка объектив бәя бирелдеме? Аңа карата бүгенге караш нинди? 70 ел үткәннән соң, бу коточкыч афәт турында галимнәр, язучылар ни уйлый?
Бөек Җиңү елъязмасын дәвам иттерү максаты белән без аларны «Казан утлары» журналы редакциясенә — «түгәрәк өстәл»гә чакырдык».

www.kazanutlary.ru

# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

## Бу санда

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Зиннур МАНСУРОВ. Ямьнән аерылмый бер гамь дә. *Шигырьләр.* ....3
Солтан ШӘМСИ. Ата белән ханбикә. *Тарихи хикәя.* ....9
Факил САФИН. Тын суларга карап. *Сонет-такыя.* ....21
Әлфия СИТДЫЙКОВА. Жырга-моңга тулы елларым. *Шигырьләр.* ....51
Фәнил ГЫЙЛӘҖЕВ. «Уян, милләт!» диеп көйли татар. *Шигырьләр.* ....79
Рөстәм ЗАРИПОВ. Үзгә юлда. *Хикәя.* ....82
Рамил ВӘЛИЕВ. Җанны айкый сагыш бураны. *Шигырьләр.* ....145

ДРАМА ӘСӘРЛӘРЕ

Данил САЛИХОВ. Баязит. *Драма.* ....27

КЫСКА БӘЯННАР КОНКУРСЫ

Нәжип ӘМИНОВ. Себер кунагы. *Бәян.* ....54

СӘНГАТЬ

Насретдин хуҗа булган илдә. *(Фәрит БИКЧӘНТӘЕВ белән Рабит БАТУЛЛА әңгәмәсе).* ....91
Мөхәммәтгали АРСЛАНОВ. Хуш, Хуҗа Насретдин! ....97
*100нче бит:* Рабит БАТУЛЛА. Тукай-Тукай, дибез... ....100

ПУБЛИЦИСТИКА

Ягъсуф ШӘФЫЙКОВ. Рейхстагка Җиңү Байрагын беренче булып кем кадаган? ....104

ФӘН

Илида БӘШИРОВА. Тукай төрек телендә язганмы?.. ....110

ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ИСЕМЕНДӘГЕ ДӘҮЛӘТ ПРЕМИЯСЕНӘ КАНДИДАТЛАР

Рәфкать ШАҺИЕВ. Клара Булатованың «күзге чор» иҗатында фәлсәфи сыйфатлар. ....121
БАТУЛЛА. Укалы иҗат. ....126
Равил РАХМАНИ. Нәниләрнең үз шагыйре. ....129

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Нурфия ЮСУПОВА. Шигърият дөньясы: 2014 ел. ....132

ЮБИЛЕЙЛАР

Мөдәррис ВӘЛИЕВ. Каләм җиле *(Роберт Әхмәтҗановның тууына 80 ел).* ....140
Роберт ӘХМӘТҖАНОВ. Шигырь иле. *Шигырьләр.* ....142

ХӘТЕР

Әлфия ШАМОВА. Сезнең язмыш сугыш уты белән үрелгән. ....147
Әнәс ХӘСӘН. Безнең язмыш. *Истәлекләр.* ....153
Рафикъ ЮНЫС. «Әхмәт Гали, Гөлчәчәк Гали...» ....173

*Шаян сәхифә*
Уены-чыны бергә. *Сәхифәне Марсель ГАЛИЕВ әзерләде.* ....181

АК ҖИЛКӘН

Хикәя яза аласызмы? *(Әлфия Арсланова, Алинә Юнысова, Гөлшат Зәйни).* ....184

Мәкаль өмәсе. ....189
«Казан утлары» архивыннан. ....102
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ....190

ТМ татмедиа

Гамәлгә куючы — «Татмедиа» акционерлык җәмгыяте

*БАШ МӨХӘРРИР —*

**Илфак Мирза улы ИБРАҺИМОВ**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Нурия Беломоина**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Дания Заһидуллина**
**Дамир Исхаков**
**Рафис Корбан**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Вакыйф Нуриев**
*(җаваплы сәркатип)*
**Айрат Сибагатуллин**
**Энгель Фәттахов**
**Равил Фәйзуллин**
**Рамил Ханнанов**
*(баш мөхәррир урынбасары)*
**Рәфикъ Юныс**

---

*Мөхәррирләр:* **Айгөл Әхмәтгалиева, Гөлзадә Бәйрәмова, Фәнил Гыйләҗев, Камил Кәримов, Ләйсән Солтанова, Рәфикъ Юныс.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Наил Кадыйров.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Гөлнара Галиева** (баш бухгалтер).

---

✉✉: Редакция һәм нәшер адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Баш мөхәррир — 222-05-50 (өст. 1618).*
*Баш мөхәррир урынбасары — 222-09-83 (өст. 1612).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге — 222-09-83 (өст. 1616).*
*Исәп-хисап бүлеге — 222-09-80 (өст. 1267).*
**Факс** — (843) *222-09-83 (өст. 1612).*

**E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

---

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 31.03.2015, график буенча 31.03.2015.
Офсет ысулы белән басылды. Кәгазь форматы 70Х108$^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ О-860. Тираж 4004.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2011 елның 23 мартында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-44362.
Индекс: 73210 (физик затлар өчен), 16262 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

---

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2015 ел



Зиннур
Мансуров

# ЯМЬНӘН АЕРЫЛМЫЙ БЕР ГАМЬ ДӘ

## Каләм

*Бездә әдәбият бар!.. Милләт хәлен тетрәнгән куллар белән язып бирү бу... Нигә... гыйбрәт алмыйсыз?*

Г.Тукай

Язмышыннан җәберсенеп зарланучы
кавемнәргә кат-кат хәйран калам мин.
Өзгәләнеп үзгәртергә азапланмыйк —
ирексезләп булмый тәкъдир каләмен.

Күкләр барсын унлы-суллы теркәп тора,
фани затка тагын нәрсә кала соң?
Хәләл чикне кысан тояр милләт хәлен
гыйбрәт итеп яза гына аласың.

Өмет белән сиңа бага газиз өммәт,
фәрештәләр өзеп бирә кавырсын.
Тәгълим кылыйк тәкъдир хакын ихлас санлап —
кәлам-сүздә калеб тибеп, кан йөрсен!

Сыктанулар гакылыңны сыегайтыр,
кәгазь җебер, күздән акса әр яше.
Карганмагыз кырыс хөкем карарына,
язар өчен анда бар... юл арасы.

Китап сүзен фәтва диеп белмәс бәндә
мәхлук төсле җанын асрар аң-мисез.
Язылмады азмы язмыш ялгышлары —
узганнардан нигә сабак алмыйсыз?..

Галәмнәрнең келәймәле кәлимәсе
иманлыга якын да ул, ерак та.
...Кыелудан йолып калыр каләмемне
мәшхәргәчә чәнчеп куйдым йөрәккә.

---

Зиннур МАНСУРОВ (1949) — *Татарстанның халык шагыйре, публицист; «Кул бирәм», «Күңел сәфәре», «Җәрәхәтле йөрәк җылырак», «Күңелдә фидаи яшәсә» һ.б. китаплар авторы. Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты. Казанда яши.*

## Милләтпәрвәр

Әллә бөтен дөнья гаме минем өскә ишелә?!
Уйларымнан бушанырга теләү хисе еш килә.

Чыңлап торган авыр башны тыкмак булам инешкә —
олы исәп төпкә китәр, вагы калкыр иң өскә...

Барсын өеп бирә күкләр колы күргән бер иргә;
жанга тансык борчуларны күмеп барам бәгырьгә.

Әйдә, дөнья, гамьнәреңне күңелемә уя тор!
Мәрткә китсәм, хафаларым җилтерәтеп уятыр...

Сызлануны чикләр өчен сынап карыйм мең имне,
газиз ваем, тукран кебек, чукып тора миемне.

Шул уй килә бисмиллалы һәрбер изге башламда,
тынычланып, Хак Тәгалә хозурына бассам да...

Намазлыкта ихлас оеп, тәкбир-сүзне мул әйттем,
һәрчак, миннән ярдәм сорап, дәшә сыман милләтем.

Онытыла алмавымны кичерсәңче, Аллаһым —
халкын сөйгән хәлифәнең хәл-халәтен аңларсың.

## Төер

Күңелдәге ташып түгелгәндә,
төер килә тамак төбенә.
Рухны изгән авыр уйлар көчен
куар өчен җитми төн генә.

Нәсел каны аша сеңгән аңа
элгәрләрнең гомер ачысы...
Йөрәк итен шулай чукып туймый
озын гаҗизлекнең ач кошы.

Яшен ташы төсле утлы төер
үзәгенә җыйган барсын да.
Ауган дәүләт гаме, ярчык сыман,
әйләнгәләп куя башында.

Авыртуга кемнәр әврелдерә
газиз ана теле нигъмәтен?
Чарасыздан бәгырь сызланганда,
үз-үземне аяп, ни әйтим?!

Тәүге сөю хакы сыкрап ала
тамак төбендәге төердә.
Юшкын булып утыра барган гамьнәр
ачы гына түгел, тере дә.

Насыйп зәһәр тагын күпме өтәр —
алда һәммәсенә түзәсе.

Мәҗрух җанга шифа өстәп тора
сабый чакның керсез күз яше.

Күнелдәге ташып түгелгәндә,
төер килә тамак төбенә...

## Яшәү яклы нисбәт

*Монаконың милли оркестры музыкантлары
илнең кораллы көчләре гаскәриләреннән күбрәк.*

Күңелледер: илдә аһәңсазлар
яугирләрдән күбрәк булганда.
Моң-мәкамле гомер мәгънәлерәк,
ямьнән аерылмый бер гамь дә.

Җиһан буйлап хөкем сөргән чакта
үтерүнең камил сәнгате,
яшәү яклы көчнең кадре арта,
үсә бәрәкәтле сан хакы.

Адәм җаны гелән тетрәп куя
актарылган янар тау ише.
Гыйбрәтледер: туплар гөрелтесен
күмеп китсә орган тавышы.

Шаулы җирнең төрле гүзәл көйдә
өнен тыңламаган мизгел юк.
Хушландыра күкләр кайтавазы,
аң-зиһенгә сала изгелек.

Уклар җитә — барып тияр өчен
күңелләрдә сайрар соң кошка.
Шатлык катыш матәм маршын уйнап,
ясин чыксаң икән сугышка.

Хозурлыктыр: илдә аһәңсазлар
яугирләрдән күбрәк булганда...

## Батырша

Хисап тотам, әни, синең алда:
соңгы фидаидай кыланмыйм;
җәрәхәтле йөрәк ямауларын
имләгәндә шөкер кылам мин.

Сызланудан артык ыңгырашсам,
сиздер — миңа җитә ярты ым.
Яра санау оят, яшен үзе
теккән чакта күкнең ертыгын.

Вәгъдә бирәм, әни, Коръән тотып:
ирлек намусыма кер кунмас;
бәгырь итен уйган тишек аша
халкым мескен булып күренмәс!..

## Зиратның арткы капкасы

Әллә нинди авыр дулкын тышау сала,
бу капкадан салмак атлап кер генә.
Адәм заты ахыр чиктә күпме серне
фанилыктан алып китә гүренә.

Монда яңгыр ил-көн яше булып ява,
юып тора каеннарның акшарын.
Күктән тынлык инәр чакта мөмкин түгел
ишетмәскә каберләрнең аh-зарын.

Орынганда канлы үлән яфрагына
сынымката, зынҗырлана кулым да...
Яхшылары яман белән аралашкан —
төрле серләр инри җирнең куйнында.

Беришеннән якты балкыш бөркеләдер,
кайсысыннан саркып ята үч-кинә.
Хакыйкатьнең хәтта үзе ыңгыраша,
таш бастырып куйган кебек өстенә.

Миңа нидер хәбәр иткән килбәт белән
хозурымда ике песнәк чыркылдый.
Монда вакыт, туфрак сибеп, табу салган —
әрвахларның ләхетеннән сер чыкмый.

Яшрен хәлләр, берчак калкып, телгә килсә,
ап-ак чәч тә үрә торыр, баш китәр...
Күпме кабер, күккә карап, аh-ваh килә,
Хөкем көне барсын-барсын фаш итәр.

## Мәктәп белән уйнау

Хисап тота дәүләт чынын әйтеп,
кайчак сөйли шактый күпертеп.
Мактанмаслык түгел: мәктәпләрне
сала кебек үзе күп итеп.

Нинди мәгънә яңа йортның эче
ерак торса төзек булудан.
Әллә ничә төрле уйлар килә
ислах турындагы бу уйдан.

Мондый тәгълим ак-пакь бала затын
бер зур итсә, ун кат хур итә:
башта аны — «баба Яга» белән,
сонра... ЕГЭ[1] белән куркыта.

Ана сөте аша иңгән хаклык
әлмисактан бирле уң ласа...
Төрмәләрне күпләп кормагаек,
илең мәктәп белән уйнаса.

[1] ЕГЭ — единый государственный экзамен.

## Дулкынлану белән көрәшмим

Әгәр җанга насыйп сынау борчу салса,
дулкынлану белән һич тә көрәшмим, —
шашкын йөрәк яңа ыргым алыр мәлдә
эчтән янам, әмма тыштан көләч мин.

Башны имим, билне бөкмим, тез дә чүкмим —
сезнең алда кылыч кыймас сын тора.
Гомер буе хикмәт җыяр салкын акыл
кайнар канга сабырлыгын сеңдерә.

Хәлне сыкса мәгъруур рухны туры тоту,
яраларга туфрак сипкәч көч кергән.
Яңа сынау борчыр чакта тыныч калам —
безнең токым инде күпне кичергән.

## Тәҗрибә

*На этом собаку съел...*
Урыс халык әйтеме

Утырасың төсле тәхетеңдә,
өстә зиннәтләнгән таҗ яна.
Синең белән һәркем киңәш тота,
гамәлеңдә сиңа таяна.

Сынау үткән сабак аша гына
гаҗиз җанга тансык түл иңә...
Килештермим шуны: кылтаюың
чыга кайчак татлы телеңә.

Хафалыйдыр мондый һавалану —
хәтта сөйләмеңнән ку аны!
Нигә кирәк безгә кыеп алу
бер атуда ике куянны?

Ерак китә алыр микән бәндә
гел-гел... кисеп елан аягын?!

Һәрбер инсан күрер өчен туа
тәҗрибәнең бары ак ягын.

Масаюлар нигә? Дан-дәрәҗәң
тоеламы әллә аз булып?
Кыяматкә син дә барачаксың,
гамәл дәфтәреңә язылып.

Эреләнеп киткән шәкертләрең
гафу сорасыннар эттән дә.
Мондый вәкарь йөктәй изеп торыр
сират күпереннән үткәндә...

Утырасың төсле тәхетеңдә,
үзең горур, үзең ягымлы.
Күрәсебез килми күрәчәктә
күләгәле кара ягыңны.

## Бакыйлык

Зирәклек яшендә күңелгә
очраклы уелган тапларны
эчендә бөялгән яшь алмас.
Гомеренең уртасын үткәндә
тәкрарлап сөйләнде аксакал:
«Яшәлгән кадәрле яшәлмәс...»

Һичнинди гөнаһ та кылмаган
бер көнлек күбәләк күзендә
рух өрер чаткыдай чык яна...
Болында хушланган затларга
искәртте пәйгамбәр чәчәге:
«Җаныңның гомерен чикләмә!..»

# Ялгану

*Әнкәй үлгән көннең истәлеге*

Ять-яшь башым ташка орыр мәлдә
әллә ничә төрле уй кордым;
аннан кулны селтәп, озак кына...
кендегемә карап утырдым.

Күзне йомсам, бөтен аңны биләп,
әнкәй тулгак тоткан төн бага.
Ике бәгырь җебен пычак өзгәч,
ни соң бәйли мине дөньяга?

Күкләр тыны сеңгән кендек бавы
вәйран булып ята кайларда?..
Тәкъдир сузган тәүге ярдәм кулы
бик салкын да иде, кайнар да.

Ялгышмыйча кая ялганырга —
ташып тора юкса көч тәндә.
Жуя төсле инсан кирәк җайны
җиһан карынына кучкәндә.

Файда бирмәс, еллар аша сорап,
кендек әбиемә дәшү дә.
Тамчы каным тамган ап-ак биләү
агып киткән инде ташуда.

Бергә-бермен гел-гел тибәрергә
әзер торган тормыш алдында.
Оча вакыт! Тоту кыен хәтта
чабып барган атның ялын да.

Тармакланган яшен тамырына
үрелә-үрелә япан кыр кичтем...
Кичерсәнче, әнкәй, көферләнеп,
ахры, акланырга керештем.

Мин болай да насыйп җаным белән
инде мәңгелеккә береккән.
Авыр чакта, Аллам, гаҗиз башка
уйлап алыр форсат бир икән —
йөз сорауга җавап бер икән.



Солтан Шәмси

# АТА БЕЛӘН ХАНБИКӘ

ТАРИХИ ХИКӘЯ

Әшрәф Баба өеннән Сөембикә нык дулкынланып, хәтта ниндидер күңел очынуы белән чыгып китте. Зыялы картның сөйләгәннәре аңа шундый көчле тәэсир итте, менә ул хәзер Сарайчык урамыннан атлый, ә күзләре йорт-каралтыларны, коймаларны, сирәк-мирәк очраган кешеләрне дә күрми сыман. Башында бер-берсен узышып, хәтта бер-берсен бастырып китеп уйлар, уйлар йөгерешә. Гүя ул яңа дөньяга аяк баскан, гүя аның алдында ниндидер офыклар ачылып киткән дә ул таныш булмаган җиргә килеп кергән. Картның нугай кауменең борынгы тарихын, Эмба, Җаек буендагы далаларга Аму-Дәрья, Бохара якларыннан урау юллар узып күчеп килүен, мәҗүсилектән аерылып, ислам динен тота башлавын сөйләве, рәсүлебез Мөхәммәд пәйгамбәр хәдисләрен тәрҗемә итеп аңлатып утырулары Сөембикәнең күзен ачты. Картны тыңлый-тыңлый, ул үзен бөтенләй икенче кешедәй хис итә башлады. Монарчы күпме нәрсәләрне белми яшәгән икән...

Ул бит ундүрт яшендә, туган иленнән аерылып, татар мәркәзе Казанга килен булып төште. Көтмәгәндә Казан ханбикәсенә әверелде. Кыз чагында, Сарайчыкта атасы Йосыф мирза йортында яшәгәндә, нигездә дин сабагы алды, җәй житкәч, туганнары белән иркен җәйләүләргә чыгып китте, үз халкының матур җырларын, риваятьләрен тыңлап үсте. Тик риваять чын тарих түгел шул. Ә аның, ханбикә исемен йөрткән затның, үз халкының чын тарихын бик беләсе килә иде. Моны белмәү аңа килешми генә түгел, ә зарури икәнне ул инде күптән төшенде. Шул хакта еш уйлана иде. Әмма ватаны ерак, ул унөч ел Казан ханбикәсе сыйфатында татар мәркәзендә яшәде. Шундагы катлаулы тормыш эчендә кайнады.

Менә көтмәгәндә вазгыять үзгәрде дә куйды. Ире Сафагәрәй хан Нугай Урдасы башкаласы Сарайчыкка кайтып төшәргә мәҗбүр булды. Казанда шушы кыш башында Сафагәрәйгә каршы фетнә кузгалды. Ханның иминлегенә куркыныч яный башлады. Аларга бөтен гаиләләре белән Казанны ташлап чыгарга туры килде. Шулай Сафагәрәй тәхетен югалтты. Хәзерге көндә менә атасы Йосыф мирза йортында яшәп торалар. Сафагәрәе нугай гаскәре белән барып, Казанда тәхетен кайтарып алмакчы. Шул хакта сөйләшүләр алып бара. Сөембикә

---

Солтан ШӘМСИ (1946) – *прозаик, тәрҗемәче. Милли тарихыбызны яктырткан «Җәяүле буран», «Еллар эзе», «Низаглы йортта», «Күк капусы ачылса» һәм башка фәнни-популяр китаплар авторы. Язучылар берлегенең Ф.Хөсни һәм А.Алиш исемендәге премияләре лауреаты. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Казанда яши.*

Сафагәрәйнең тәхетне кайтарып алачагына бөтен күңеле белән ышана, бу хакта бер шиге дә юк. Ул моңа вакытлы бер кыенлык дип кенә карый.

Сөембикә дә, Сафагәрәй белән Сарайчыкка кайткан башка хатыннары да монда күпме торасыларын белми. Менә бүген зыялы карт Әшрәф Баба янында булып, күпме яңа нәрсәләр ишетте. Башларың әйләнерлек. Ул әле атасыннан да күп нәрсәләр сорашачак. Туган җиренә кайту форсатыннан тулысынча файдаланып калырга тырышачак.

Атасы Йосыф мирза йортына килеп җитәрәк ул, ниһаять, үзен кулга алды. Тәбәнәк капка баганасына тотынып бераз уйланып торды. Өйгә ул тынычланып, берни булмагандай кайтып керергә тиеш. Сөембикә сораштыручыларга артыгын сөйләмәскә булды. Әшрәф Баба сөйләгәннәр сер булып калырга тиеш иде. Ул күңел дөньясын кемгә дә булса ачарга җыенмый, ни кичергәннәрен сөйләсә, дөрес аңламыйча, аңа сәерсенеп карый башлаулары да бар.

Сөембикә өйгә елмаеп-көлеп, шат йөз белән килеп керде. Биредә төшке ашка әзерләнәләр иде. Әнисе Акбикә ханым, башка хатын-кызлар янәшә куелган тәбәнәк ике өстәл тирәсендә кайнашалар. Өйдәгеләргә Сафагәрәй хатыннары да килеп кушылгач, бер өстәл генә тар була башлаган иде. Шуңа күрә ике өстәлне кушып тәгам җыю гадәткә кереп китте. Барысы да урнашып беткәч, иң соңыннан өстәл башындагы күн мендәргә Йосыф мирза үзе килеп утырды. Кулларын күтәреп бисмилла әйткәч, өстәлгә тезелгән нигъмәтләргә керештеләр. Монда вак итеп туралган сарык ите шулпасында ачы камырдан пешерелгән хинкал, нугай пилмәне касык бөрек, бавырсак, токмачлы аш, тары боткасы, киптерелгән сайгак ите һәм башка нугай ризыклары бар иде.

Сафагәрәй хан белән өлкән хатыны Фатыйманы атасы Шәех Мамай биләргә кичә кунакка алып киттеләр. Анда куна калганнар, төшке ашка әле кайтып җитмәгәннәр иде.

Тәгам җыеп утырганда, сүз артыннан сүз чыгып, Йосыф мирза Сөембикәдән сорап куйды:

— Син, кызым, бүген Әшрәф Баба янына барып кайткансың икән. Ничек соң, Әшрәф Баба исән-саумы?

— Аллага шөкер, атаем, әлегә саулыгына зарланмый.

— Ниләр сөйли соң?

— Ул миңа Мөхәммәд пәйгамбәр хәдисләрен тәрҗемә итеп утырды. Бик укымышлы карт икән.

— Укымышлы гына түгел, ул бездә бердәнбер, — дип өстәде Йосыф мирза. — Бохараның үзендә дә аның белән тиңләшерлек кеше юк, диләр. Берәр моназарада катнашса, дин әһелләрен гел җиңеп чыга икән, зиһене, сөйләү осталыгы искиткеч дип сөйлиләр.

— Шуңа күрә аны яратып бетермиләр, ахры.

— Нишләп алай дисең? — дип сорап куйды Йосыф мирза.

— Үз сүзеннән чыгып әйтүем. Бохарада фәкыйһләр белән дини мәсьәләләр буенча сүз кузгаткан идем, килешмәделәр. Дошманга әйләндем, ди.

— Булыр, булыр, бик туры сүзле затлардан ул.

Өстәл янындагылар ата белән кыз арасында барган сөйләшүне игътибар белән тыңлап утырдылар. Сафагәрәй ханның башка хатыннары Сөембикәнең шулай иркен фикер йөртүенә көнләшеп тә куйдылар. Хәер, Сөембикә үз өендә, үз атасы белән сөйләшә. Бу табигый. Кемнән тартынып торсын соң ул. Әмма барыбер көнләшү дигән нәрсә күңелләрендә төер булып утырып калды.

Сөембикәнең анасы Акбикә ханым табындагыларны гел кыстап, әле бер, әле икенче ризыкны тәкъдим итеп торды:

— Менә монысыннан авыз итегез, — дия-дия, күбрәк Сафагәрәй хан хатыннарын сыйларга тырышты. Ни дисән дә, алар үз өйләрендә түгел, инде күпме

көннәр үтүгә карамастан, әле һаман кунаклар санала. Аларга аерым ихтирам, хөрмәт кирәк. Дөресен генә әйткәндә, Йосыф мирза йортында алар үз кеше булып, җәелеп яшәп китә алмадылар, үзләрен ничектер кысынкылыкта яшәгәндәй хис итәләр иде. Түземсезлек белән Казанга кайтып китү көнен көтәләр, Сөембикә дә аларның бу халәтен ничек үзгәртергә белми иде. Ул туган йортында, атасы-анасы, ир һәм кыз туганнары арасында үзен бик иркен тота, еш кына карынында үсә башлаган баласы турында уйлый һәм язмышына тагын бер сөенеп куя.

Ашап-эчү тәмамланганнан соң, хатын-кызлар табындагы нигъмәтләрне җыя башладылар. Йосыф мирза да киенеп ишегалдына чыгарга җыенып тора иде. Шулвакыт Сөембикә аның янына килде:

— Атаем, минем синең белән сөйләшәсе сүзем бар иде. Кайчан вакытың булыр икән? — дип сорады.

Йосыф мирза кызына игътибар белән карап алды. Монарчы Сөембикә бөтен мәсьәләләрне анасы белән хәл итеп килде. Бу Йосыф мирза өчен яңалык иде. Димәк, гади сүз түгел, дип уйлап алды ул һәм Сөембикәгә:

— Кызым, хәзер минем ашыгыч эшләрем бар. Иртәгә иркенләп сөйләшербез, яме, — диде дә тышкы ишеккә юнәлде.

Иртәгесен Йосыф мирза Сөембикәне эш бүлмәсенә үзе чакырып алды. Каршысына утыртты да, ягымлы караш ташлап:

— Йә, кызым, миңа нинди сүзең бар иде? — дип, урынына җайлашып утырды һәм аны тыңларга әзерләнде.

Сөембикә сүзне нәрсәдән башларга икән дип беравык уйланып торды да:

— Атаем, кичә Әшрәф Баба белән сөйләшкәндә, ул мангыт бабаларыбызны, Мангыт Йортын телгә алып узды. Без бит нугай халкы саналабыз, ә илебез Нугай Урдасы дип атала. Без ничек башта мангытлар булып, аннан нугайларга әвереллек соң? Бу ничек килеп чыкты?

Кызының соравы гади сораулардан түгел иде, Йосыф мирза аңа гаҗәпсенеп карап куйды. Менә нинди сораулар кызыксындыра икән аның ханбикә кызын.

— Кайдан килә мондый сораулар синең хатын-кыз башыңа, кызым? Шактый катлаулы сорау бирдең бит әле син. Аңа бер-ике сүз белән генә җавап таба торган түгел, — диде ул, тагын да аптырый төшеп.

— Халкыбызның тарихын беләсем килә, атаем. Казанда миңа еш кына зыялылар, галим-голяма белән аралашырга туры килә. Үз халкыңның тарихын рәтләп белмәү, бер яктан, ят булса, икенче яктан, ханбикә дәрәҗәсендәге затка киңрәк фикер йөртергә ирек бирми.

Йосыф мирза уйга чумып ханбикә кызына карап торды. Ул аны беренче кат күргәндәй булды. Үзгәргән, бик нык үзгәргән икән аның сөекле кызы бу елларда. Ә ул аңа элеккечә һаман баласытып карый.

— Кызым, бу сорауга җавап бирү өчен, безгә мәшһүр Алтын Урда мәмләкәте тарихына мөрәҗәгать итәргә туры киләчәк. Алтын Урданың уң һәм сул кулга бүленгәнен сиңа сөйләп торасы юктыр. Син аны беләсең. Уң кулга кергән далалар Иделдән уң якта җәелеп ятсалар, сул кулга Иделдән сул якта, кояш чыгышында урнашкан җирләр кергән. Мәмләкәтнең сул кулына кергән җирләрне икенче төрле Күк Урда дип атап йөрткәннәр. Менә шул Күк Урдада элегрәк заманда Ырыс хан углы Тимер Мәлик хан хөкем сөргән. Ханның иң тәҗрибәле һәм ышанычлы киңәшчесе Балтачык би булган. Ә Балтачык бине кем дип беләсең, кызым? — дип сорап куйды Йосыф мирза.

— Белмим шул, атаем. Беренче ишетүем.

— Белмибез шул тарихны, белмибез. Нугайларда чынлап торып тарих белән кызыксынучылар әлегә юк дәрәҗәсендә. Ярар, әйтсәм әйтим инде: Балтачык би Идегәй бабабызның атасы булган бит. Менә хәлләр ничек тора. Зирәк зат буларак, ханнарда киңәшче сыйфатында хезмәт иткән ул... Ә хәзер тарихи

манзара киңрәк күз алдына килеп бассын өчен, көньякка, Сыр-Дәрья белән Аму-Дәрья елгалары арасында урнашкан Мавараеннәһер дәүләтенә күз салыйк. Мавараеннәһердә Аксак Тимер атлы көчле һәм гаярь әмир хөкем сөргән, ара-тирә Күк Урда калаларына хөҗүм итеп торган. Ул элегрәк Күк Урдада хакимлек иткән Ырыс ханнан качып килеп сыенган Туктамыш атлы угланны да үз сәясәтендә бик оста файдаланган. Туктамыш углан ханнар нәселеннән булганга, Аксак Тимер аңа гаскәр биреп, Күк Урда җирләренә яуга йөрткән. Бераздан хәтта хан дәрәҗәсенә күтәргән. Кул астында үзен үстергән, үзен тәхеткә утырткан тыңлаучан хан булуның нинди отышлы нәрсә икәнен Аксак Тимер яхшы аңлаган. Шуңа күрә Туктамышка гел ярдәм итеп торган.

Йосыф мирза урыныннан торды, кулларын биләндә кушырып, бүлмә буенча йөренә башлады. Күрәсең, йөренеп сөйләү аңа җиңелрәк иде булса кирәк. Ул сүзен дәвам итте:

— Әйтергә онытканмын, бу вакытта Идегәй бабабыз да Туктамыш хан белән яуларга йөргән. Ә атасы Балтачык би каршы якта, Тимер Мәлик ханда хезмәт иткән. Шулай вакыйгалар агышы ата белән улны капма-каршы якка куйган... Күк Урда калалары өчен барган бәрелешләрнең берсендә Аксак Тимер әмерен үтәп йөргән Туктамыш хан җиңүгә ирешә, хәтта Тимер Мәлик ханны да, аның киңәшчесе Балтачык бине дә әсирлеккә төшерә.

— Идегәй бабабыз атасы Балтачык бине коткарып кала алганмы соң? — дип сорады Сөембикә.

— Юк шул, кызым, коткарып кала алмаган. Бөтен фаҗига да шунда. Ул бит әле бу вакытта Туктамыш ханның бер нөгәре генә булган.

— Үтергәннәрмени Балтачык бине? — дип, хәвеф белән сорап куйды Сөембикә.

— Бу хәл болай була, кызым. Туктамыш хан Тимер Мәлик ханда хезмәт иткән Балтачык бинең зур акыл иясе, дәүләт эшләрендә үтә дә тәҗрибәле, идарә эшләрендә файдалы зат булуын белә, аны үз ягына аударырга тырыша. Ул болай ди: «Әгәр дә мине үзеннең ханың дип танып, бигать бирсәң, ягъни ант итсәң, гомереңне саклап калу гына түгел, чал башыңнан бер чәч бөртеге дә төшмәс. Бу очракта мин сине үземнең якын кешем итеп идарә эшләренә билгеләрмен», — дип ышандыра Туктамыш хан. Беләсеңме, моңа каршы Балтачык би аңа ни дип җавап биргән: «Тимер Мәлик хан исән чакта мин абруйлы әмир булып яшәдем. Хәзер кулларым бәйле булмаса, сине ханым тәхетендә күргән бу күзләремне чокып чыгарыр идем. Әгәр дә миңа изгелек кыласың килсә, башымны чабып өзәргә боер, башымны — ханым башына, гәүдәмне аның гәүдәсенә каплап куярга куш. Аның асыл гәүдәсе болай кадерсез килеш ятарга тиеш түгел», — ди. Ягъни тугры йөрәкле Балтачык би хыянәт юлына басмаячагын Туктамыш ханның йөзенә бәреп әйтә. Әлбәттә, бу Балтачык бинең соңгы сүзләре була. Ул шунда ук кылычтан үткәрелә.

Бу вакыйга Сөембикәне тәмам тетрәтте. Ул, кулларын күкрәгенә кушырып:

— Моны хәтта күз алдына китерүе дә куркыныч, — дип калтыранып куйды. — Атасының үтерелүен күреп тору ничек авыр булгандыр Идегәй бабабызга. Йөрәге ничек түзде икән?..

— Әйе, кызым, Идегәй бабабызга үз гомерендә бик күпне күрергә туры килгән. И-и, аны сөйли башласаң...

— Әшрәф Баба әйтә, Идегәй бабабыз — Мангыт Йортына нигез салган зат ул, ди.

— Дөрес әйтә Әшрәф Баба. Идегәй бабабызның халкыбыз өчен кылган изгелекләре санап бетергесез. Халык шуңа күрә аны онытмый, аның турында дастаннар чыгара.

— Атаем, Идегәй бабабызның Алтын Урда мәмләкәтендә бик зур дәрәҗәләргә ирешүе билгеле. Бу ничек булган соң? Шул хакта сөйләгез әле.

Йосыф мирза кабат үз урынына барып утырды. Тәрәзә яктысына карап байтак уйланып торды:

— Кызым, бу хәлләргә барып җиткәнче әле бик күп вакыйгаларга тукталып узарга кирәк. Әйтеп торам бит, Идегәй бабабызның тормышы бик катлаулы булган, дип. Анда көтелмәгән борылышлар күп. Барысын да искә төшерү җиңел эш түгел. Син мине ашыктырма, яме.

— Гафу ит, атаем, — диде Сөембикә һәм тыныч кына тыңларга әзерләнде.

Йосыф мирза карашын тәрәзәдән кызына күчерде дә дәвам итте:

— Атасы Балтачык би үтерелгәннән соң да Идегәй бабабыз Туктамыш ханда хезмәттә кала. Ниләр кичергәнен бер үзе генә белгәндер. Әмма тормыш итәргә, яшәргә кирәк. Күктә — Аллаһ, җирдә — хан, дигәндәй, кайвакытта адәм баласына, тешен кысып булса да, тормыш шартларына яраклашырга туры килә. Әйтергә кирәк, Идегәй бабабыз батыр йөрәкле, искиткеч сәләтле, үтә сизгер, зирәк һәм тапкыр телле, төскә-биткә чибәр кеше булган. Ул кешеләр белән бик тиз уртак тел таба белгән. Шушы сәләтләре аркасында Туктамыш хан хезмәтендә ул тиз күтәрелгән, хан аңа җаваплы эшләр йөкли башлаган... Әйе, Туктамыш хан Күк Урдада байтак еллар сугышлар алып бара, анда төп көчкә, Күк Урданың иң көчле ханына әверелә. Әлбәттә, аңа Аксак Тимер дә ярдәм итеп тора, чөнки ул күп эшләрен фәкать үз канаты астында үскән Туктамыш хан кулы белән башкара. Туктамыш хан аның кулында бер коралга әверелә.

Күк Урдада тәмам ныгып җиткәч, ә бу шактый елларга сузыла, Туктамыш хан күп көч белән Идел буена, Алтын Урданың мәркәзе Сарай каласын яуларга килә. Әлбәттә инде, бу елларда Идегәй бабабыз да аның белән көрәшләрдә катнаша. Ахыр чиктә, Алтын Урдада барган эчке низаглардан файдаланып, Туктамыш хан Сарай ханнарының алтын тәхетенә утырырга ирешә. Шулай итеп, кайчандыр Аксак Тимер йомышында йөргән углан Алтын Урданың абруйлы ханына әверелә. Аксак Тимер оясында канат ярган кошчык бөркеткә әйләнә. Идегәй бабабызга да тәхет тирәсендә дәрәҗәле урын табыла. Өстәвенә Туктамыш ханның кызына өйләнеп, аның ышанычлы кешесенә әверелә. Хан кадерле киявенә мәмләкәтнең сул кул гаскәре белән идарә итүне тапшыра. Менә шулай Идегәй бабабыз мәмләкәттә зур гаскәр белән идарә итүче абруйлы зат булып китә. Бер караганда, шундый биеклеккә күтәрелгәнсең икән, тормыш-яшәешнең рәхәтен күреп, аннан ләззәт табып яшә дә яшә, ләкин Идегәй бабабыз башкарак кеше булган шул. Тарих шуны күрсәтә.

***

Йосыф мирза тагын уйга калды. Терсәге белән өстәлгә таянып, башын читкә борыбрак беравык тын гына утырды. Ул Идегәй бабасының моннан соң үткән катлаулы тормышы турында уйлый иде. Аны кызына сөйләргәме, юкмы — шул хакта уйлый иде ул. Бик тирәнгә кереп кителмәсме, кызына боларны белү кирәкме, дип, алда ни сөйләячәген хәл итеп утыра иде. Ниһаять, ул бер карарга килде: барысын да сөйләп бирәчәк, аның кызы гади кыз түгел — Казан ханбикәсе, катлаулы сәясәт дөньясында яши, ул барысын да белергә тиеш. Бәлки, бу вакыйгалардан берәр гыйбрәт алыр, кирәге чыгып куяр.

— Кызым, мин сиңа әйтергә онытканмын. Күк Урдада Туктамыш хан тарафыннан үтертелгән Тимер Мәлик ханның Тимер Котлык атлы улы кала бит. Тимер Мәлик хан Идегәй бабабызның апасына өйләнгән була. Тимер Котлык шул никахтан туган бала инде. Кыскасы, бу баланы Идегәй бабабыз бик ярата, аңа җил-давыл тидермичә, күз карасы кебек саклый. Беренчедән, ул аның туганы, икенчедән, хан улы.

— Атаем, гафу ит, тагын бер сорау бирмичә булдыра алмыйм, — диде Сөембикә.

— Нинди сорау, кызым?

— Туктамыш хан Идегәй бабабызның атасы Балтачык бине дә, яшь

углан Тимер Котлыкның атасы Тимер Мәлик ханны да җәзага тартучы бит? Сөйләгәннәреңнән шул килеп чыга...

— Фәкать шулай, кызым. Бу соравыңны биреп, син минем эшне шактый җиңеләйттең бит әле, — дип сокланып Сөембикәгә карап куйды Йосыф мирза. — Чыннан да, алар икесе дә Туктамыш хан әмере белән үтерелә. Менә шуннан чыгып үзең уйлап кара — Идегәй бабабыз белән Тимер Котлык углан аталарын үтерткән Туктамыш ханга карата алар нинди мөнәсәбәттә булганнар. Шик юк, алар бу фаҗигане һич тә онытмаганнар. Әлбәттә, үз мөнәсәбәтләрен тыштан белдерә алмаганнар. Бу — хәтәр нәрсә. Ә эчтән алар Туктамыш ханга карата үч саклаганнардыр, дип уйларга кирәк. Монысы шик калдырмый. Әйтергә кирәк, Идегәй бабабыз хан нәселеннән булган Тимер Котлыкка зур өметләр баглап яши. Бераз үскәч, аны бит Алтын Урда тәхетенә дә чыгарып булачак. Берәү дә каршы сүз әйтә алмаячак. Тимер Котлык — хан углы, теләсә нинди тәхеттә утырырга хакы бар. Һәм Идегәй бабабыз Туктамыш ханны тәхеттән төшерү өчен үз тирәсенә әкренләп фикердәшләр тупларга керешә. Өстәвенә бу вакытта Туктамыш хан берничә җиргә яу йөреп, аннан җиңелеп кайта. Сарай аксөякләре аның булдыксызлыгын күрәләр, канәгатьсез кешеләр арта, ханның абруе төшә башлый.

Мин инде әйткән идем, Идегәй бабабыз Тимер Котлыкны күз карасы кебек саклый, дип. Зирәк һәм барысын алдан уйлап эш итүче зат буларак, Идегәй бабабыз Туктамыш ханга каршы астыртын фетнә оештыра башлагач, Тимер Котлык угланны җил-давыл тимәслек, куркыныч янамаслык җиргә — Мавараеннәһергә Аксак Тимер тарафына озата. Бу эш, әгәр дә фетнә ачыланитә калса, Тимер Котлык углан хәвеф-хәтәрсез, имин җирдә яшәсен өчен эшләнә. Адәм баласы ничек кенә акыллы-зирәк булмасын, язмышның кайсы якка борыласын алдан белә алмый. Бу очракта да шулай килеп чыга. Үзен тәхеттән төшерү өчен фетнә әзерләнгәнне Туктамыш хан ничектер белеп ала һәм анда катнашучыларны җәзага тартырга әзерләнә. Бу хәлне Идегәй бабабызга җиткерәләр һәм ул, башын саклап калу өчен, төн караңгысында ат белән Сарай каласыннан качып китә. Кая барып сыенган дип уйлыйсың аны, кызым? — дип елмаеп сорап куйды Йосыф мирза. Сөембикә җавап бирмәгәч, үзе дәвам итте. — Әлбәттә, аның бердәнбер барып сыеныр урыны — Мавараеннәһер, ягъни Аксак Тимер дәүләте була. Ул бит егет чагында Туктамыш белән Аксак Тимердә хезмәттә була. Һәм Мавараеннәһер идарәчесе аның булдыклы, кулыннан эш килә торган гаярь ир икәнен яхшы белә. Хәер, ул хакта әйткән идем инде.

Аксак Тимер Идегәй бабабызны бик яхшы кабул итә. Күз алдыңа китер: Туктамыш ханнан качып китеп, Алтын Урда мәмләкәтенең шундый абруйлы гаскәр башлыгы синең якка чыксын әле. Бу бит гадәттән тыш хәл, Аксак Тимернең дәрәҗәсен күтәрә торган зур вакыйга. Әлбәттә, Идегәй бабабызга хезмәт итәр өчен анда бөтен шартлар тудырыла. Ул Аксак Тимернең якын кешесенә әверелә. Һәм байтак еллар Мавараеннәһердә яши.

— Ә хатыны? Ул бит Туктамыш ханның кызына өйләнгән иде, — дип сорап куйды Сөембикә.

Йосыф мирза кеткелдәп көлеп җибәрде:

— И-и кызым, шундый гаярь затка анда хатын табылмагандыр дип уйлыйсыңмы?

Сөембикә үзенең беркатлы сорау бирүеннән уңайсызланып, кызарып чыкты.

Йосыф мирза сүзен дәвам итте:

— Еллар уза тора, Сарай каласында хан тәхетендә утырган Туктамыш ханның үстергән, күтәрелергә бөтен мөмкинлекләрне тудырган, байлык, гаскәр биргән, ахыр чиктә Күк Урдада хан итеп күтәрткән остазы Аксак Тимергә карата мөнәсәбәте акрынлап үзгәрә башлый. Ул химаячесенең биләмәләренә яу йөргәли, аның хатларына тупас итеп җавап бирә, остазының изгелекләрен

онытып, тәкәбберлек, минминлек юлына баса. Тәхет тирәсендәгеләр аны Аксак Тимергә каршы даими котыртып торалар. Син гомерен буе ана баш иеп яшәргә тиешмени? Син — бөек хан, ә ул бер кечкенә дәүләтнен әмире генә, дип анын минминлеген үстереп торалар. Аксак Тимер башта анын дорфалыкларын, үзенә карата тупаслык күрсәтүләрен гафу итеп килә, әмма ахыр чиктә анын да түземе төкәнә, ул артык масаеп киткән Туктамышны акылга утыртырга карар кыла. Алтын Урдага каршы зур яу әзерләргә керешә. Идегәй бабабыз да бу эштән читтә калмый, Аксак Тимернен ышанычлы гаскәр башлыгы буларак, яуны оештыруда зур тырышлык күрсәтә. Анын да кем ярдәмендә мондый биеклеккә күтәрелүен онытkан, үзенен ни кылганын, ни сөйләгәнен белмәгән, тәмам масайган Туктамыш ханнан үч аласы килә. Ул бит анын күз алдында газиз атасы Балтачык бинен башын чаптырган адәм. Ничек гафу итмәк кирәк?! Алачак ул Туктамыш ханнан үчен, Аксак Тимер кулы белән Туктамышны мәсхәрә хәленә калдырачак. Әгәр шуны эшләмәсә, исеме Идегәй мирза булмасын... Менә шундый уйлар белән яшәгән булса кирәк безнең Идегәй бабабыз, кызым...

Йосыф мирза сөйләүдән туктады. Беравык сокланып кызы Сөембикәгә карап торды. Нинди гүзәл анын кызы, Казан ханбикәсе дәрәҗәсенә ирешә бит анын баласы. Ничек килешеп тора ана Казаннан алып кайткан затлы киемнәр, алкалар, беләзекләр, асылташлар белән бизәлгән муен каптырмалары. Анын кызы да бит тәхет тирәсендә катлаулы һәм хәтәр вазгыятьтә яши. Күпме акыл, зирәклек, саклык кирәк тәхет тирәсендә үзенне саклап калу өчен. Шуна күрә ул Сөембикә кызына Идегәй бабасы тормышын бөтен вaклыклары белән сөйләп чыгарга булды. Бәлки, кызы бу сөйләшүдән үзенә гыйбрәт алыр.

— Кызым, үткән хәлләрне мин сина махсус сөйләп утырам, — дип дәвам итте сүзен Йосыф мирза. — Гыйбрәт өчен. Кайвакытта хакимнәр арасындагы мөнәсәбәтләр мәмләкәтнен язмышына шундый нык тәэсир итә, тәхет тирәсендәге затларга һәрбер сүзен үлчәп-уйлап сөйләргә туры килә. Мәмләкәтләр язмышы адәмнәр язмышы кебек ул, чөнки мәмләкәтләр белән ханнар, корольләр, императорлар идарә итә. Ә алар барысы да адәм балалары.

— Рәхмәт, атаем. Сине тынлаганда, үзем дә Казан хәлләрен искә төшереп утырдым. Мина еш кына Сафагәрәйне теге яки бу гамәленнән үгет белән тыеп калырга туры килә. Артык гайрәтле, кызу канлы ул, хөкемен тиз чыгара, кайвакытта ахырын уйлап житкерми.

— Алайса, син анын саклаучы фәрештәсе кебек инде, кызым. Акыллы бул, сак һәм сабыр бул. Хәтәр гамәлләрдән саклый күр иренне, — дип, Йосыф мирза кызына ягымлы елмаеп куйды.

— Аксак Тимернен Идел буена явын бик дәһшәтле вакыйга булган дип сөйлиләр бит, атаем.

— Әйе, кызым, Аксак Тимернен Идел буена яу белән килүе Алтын Урда мәмләкәте өчен чын фажигагә әверелә. Аны Кондырча сугышы[1] дип атыйлар, чөнки төп бәрелеш Кондырча суы буенда була.

— Анда Идегәй бабабыз да катнашканмы?

— Катнашмыйча, ул бит Аксак Тимернен ышанычлы әмире сыйфатында орышкан. Аксак Тимергә ярдәме зур булган.

— Мангытлар да бу сугышта орышканмы?

— Әлбәттә. Тик мангытлар Алтын Урданын сул кул халкы саналганга, алар Туктамыш хан ягында булган.

— Менә бит ничек килеп чыккан: Идегәй бабабыз Аксак Тимер ягында, ә анын ыруы — мангытлар каршы якта орышкан.

— Әйтеп торам бит, Идегәй бабабызнын тормышы бик катлаулы булган, дип.

[1] Кондырча суы буендагы сугыш 1391 елнын 18 июнендә була.

Тик монда аның бер гамәлен һич тә искә алып үтмичә булмый. Сугышның бик каты буласын, күп кеше кырыласын белеп торган Идегәй бабабыз, әле сугыш хәрәкәтләре башланганчы ук, Туктамыш хан ягындагы мангытларга яшерен генә үз кешесен җибәреп, аларга сугышның кызган чагында Туктамыш хан гаскәрен ташлап китәргә киңәш иткән. Ул аларга сугыш барган җирдән мөмкин кадәр ераграк урынга, ачык далага китеп югалырга кушкан. Хыянәт иткән өчен Туктамыш хан мангытларны эзәрлекли алмасын өчен, даими күченеп йөрергә, эз югалтырга, бер җирдә бер көннән артык кунмаска, дошман эзләп таба алмасын өчен, даланың кеше яшәми торган аулаграк җирләрендә йөрергә киңәш иткән. Идегәй бабабыз мангытларга бөтенләй кирәк булмаган бу зур сугышта үз ыруын имгәнүдән саклап калган. Менә шулай мангытлар далада бертуктаусыз күченеп йөреп, сугыштан читтә торып калалар, бер зыян да күрмиләр.

Кондырча сугышы Аксак Тимернең тулы җиңүе белән тәмамлана. Сугыш хәрәкәтләре туктала, тынычлык урнаша. Туктамыш хан каядыр Болгар җирләренә качып китә. Сугыш нәтиҗәсендә Иделнең сул ягындагы җирләрдә тормыш тәмам сүнә. Туктамыш хан ягындагы татарлардан торган Алтын Урда гаскәре кайсы кая таралып бетә. Җиңүчеләр туган илләре Мавараеннәһергә кайтып китәр алдыннан ял итәләр, яралыларны дәвалыйлар, бер үк вакытта Идел буендагы авыллардан әсир итеп алып китү өчен, яшь егетләрне-кызларны Аксак Тимер урдасына куып китерәләр, терлек-туарны җыялар, нәрсә талап булса, шуны талап үз ватаннары Манараеннәһергә алып китәргә әзерләнәләр.

Сөембикә, атасы сөйләгәннәрне тыңлый-тыңлый, Идегәй бабасы турында уйланды. Катлаулы шәхес булган икән аның Идегәй бабасы. Туктамыш хан белән аралары бозылышу аркасында ана, байтак еллар үз ватаны Идел буе, Җаек далаларыннан аерылып, чит җирдә яшәргә, Аксак Тимергә хезмәт итәргә туры килгән, анда ул зур дәрәҗәгә ирешкән. Һәм менә Аксак Тимер ягында шушы канкойгыч орышта катнашкан, аның ярдәме белән күптәнге дошманы Туктамыш ханнан үч алган, үз сүзен сүз иткән. Әмма ни бәрабәренә, нинди бәягә... Шушы коточкыч сугышта Алтын Урда халкы булган меңнәрчә Идел буе татарларының гомере өзелгән. Казан ханбикәсе буларак, ана хәзер татар язмышы да бик якын. Татар язмышы аның тормышы, язмышы, бүгенгесе белән бәйле, ул моны күңеленә тирән алып кичерде. Әйе, катлаулы шәхес булган икән аның данлыклы Идегәй бабасы. Шушы хакта уйланганда, Сөембикә үзен нигәдер гаебе бар кеше сыман хис итте. Ул бит нугай кызы, Идегәй бабасының Аксак Тимерне үгетләп Идел буена яу белән китерүендә үзенең дә гаебе бар сыман тойды, ләкин бу уйларын үзеннән куарга тырышты. Идегәй бабасы үз ыруы мангытлар өчен дә тырышкан бит. Аларны һәлакәттән саклап калуга ирешкән.

Туктап бераз тын алганнан соң, Йосыф мирза сүзен дәвам итте:

— Сугыш хәрәкәтләре тәмамланганнан соң, бер кызыклы вакыйга була, — диде ул. — Идегәй бабабыз, Тимер Котлык углан һәм тагын берничә ханзадә Аксак Тимергә шундый тәкъдим белән мөрәҗәгать итәләр. Алар үз ыруларын җиһангир карамагына алып килергә теләк белдерәләр. Шул сәбәпле җиһангирдан гаскәрдән аерылып китеп торырга рөхсәт сорыйлар. Ә Идегәй бабабыз өстәп әйтә: «Без, мангытлар, сугыш барышында Туктамыш ханга хыянәт иттек. Моның өчен ул безне кайчан да булса эзләп табачак һәм үч алачак. Шуна күрә ыруымны синең хозурына китереп, саклап калырга телим», — ди. Аксак Тимер Идегәй бабабызның да, Тимер Котлык белән башка ханзадәләрнең дә тәкъдимен бик хуплап кабул итә. Һәм аларның барысына да гаскәрдән китеп торырга рөхсәт итә, хәтта юлда аларны туктатмасыннар өчен, махсус ярлыклар да яздырып тапшыра.

Идегәй бабабыз, Тимер Котлык углан һәм ханзадәләр үз ыруларына китеп баралар. Анда ыруларын җиһангир карамагына алып килү өчен әзерлиләр. Тимер Котлык та, Идегәй бабабызның яшерен ниятен белмичә, үз ыруын

Сәмәрканд әмире карамагына алып килергә җыена. Әмма Идегәй бабабыз ана болай ди: «Менә син ыруынны Сәмәрканд әмиренә китереп тапшырырга җыенып йөрисен. Уйлап кара әле, ыруынны анда алып китеп тапшырудан сиңа ни файда? Аксак Тимер бит аларны Сәмәрканд якларына озатачак, төрле җирләргә таратып бетерәчәк. Ә син үзең элеккечә анын нөгәре булып калачаксың. Синең гомер буе Аксак Тимер нөгәре булып йөрисен киләме? Аңлыйсынмы, эшләр кая бара?!.»

Шушы сөйләшүдән соң яшь Тимер Котлык ыруын Сәмәрканд әмиренә китереп тапшырудан баш тарта, ялгышып ыруына нинди авыр язмыш әзерләвен аңлап ала. Чыннан да, килмешәк-илбасар Аксак Тимер күчерелгән халыкнын кадерен белмәячәк бит, аны кайсын кая таратып, ыруны әрәм итеп бетерәчәк.

Тимер Котлык ырудашларын җыя да: «Аксак Тимер сезне кылычтан үткәрергә җыена. Бала-чагаларыгызны, туган-тумачаларыгызны төрле җирләргә таратып бетерәчәк», — ди. Билгеле, мондый хәтәр сүзләрне ишеткән халык куркуга кала, урыныннан кузгалмаска була һәм карар кыла: «Без синен белән калабыз, ә Аксак Тимерне танымыйбыз», — дип җавап бирә.

Тимер Котлык, агасы Идегәй бабабыз киңәшен тотып, халыкка даими күченеп, эз югалтып йөрергә куша. Аерылып киткән ханзадәләрдән Аксак Тимер янына берсе генә кире әйләнеп кайта.

Шушы эше белән Идегәй бабабыз Тимер Котлык угланны Аксак Тимер кулыннан тартып ала. Тимер Котлык углан Идегәй бабабызның үзенә бик кирәк була шул. Беренчедән, ул аны якын туганы, апасының улы булганга саклаcа, гел үз янында тотса, икенчедән, ул хан углы Тимер Котлыкны киләчәктә үстерергә, күтәрергә уйлый. Ул күп сугышлар, көрәшләр давылы аша үтеп, ахыр чиктә аны барыбер Сарайдагы алтын тәхеткә утыртачак. Ул аны Алтын Урданың ханы итеп билгеләячәк әле. Әмма мона хәтле әле бик зур юл үтәсе бар. Тирән сер булып бу ният әле анын күңелендә генә яши. Ләкин Идегәй бабабызның һәр адымы, һәр кылган гамәле шушы ниятне тормышка ашыруга багышлана. Тик ана хәтле зур сынаулар үтәсе, күп көрәшләрдә җинеп чыгасы бар. Идегәй бабабыз үзенең яшерен ниятен Тимер Котлыкка ачып салгандырмы, юктырмы — анысы билгесез. Әмма Тимер Котлыкның Алтын Урда ханы сыйфатында Сарай тәхетендә утыруы бөек мәмләкәт тарихы белән азмы-күпме кызыксынган һәркемгә билгеле. Димәк, Идегәй бабабыз яшерен ниятен тормышка ашыруга ирешкән. Тимер Котлыкны хан тәхетенә утырткач, Идегәй бабабыз Алтын Урданың хәрби көчләрен үз кулына ала, ул бәкләрбәк дәрәҗәсенә ирешә, һәм мәмләкәттә ханнан кала икенче затка әверелә. Кабатлап әйтәм, кызым, әле бу көннәргә барып житкәнче, ана бик күп көрәшләр аша узарга туры киләчәк.

Йосыф мирза тамак кыргалап алды. Аннан Сөембикәгә:

— Бар әле, кызым, әйт, эчәргә берәр нәрсә кертсеннәр. Нигәдер тамагым кипте, — диде.

Сөембикә тиз генә урыныннан торды, бүлмәдән чыгып китте. Озак та үтмәде, Сөембикә үзе, җиз табак тотып, бүлмәгә килеп керде. Табакка ак фарфор чәйнек, ике касә, Бохара җимешләре салынган чынаяк савыт, ике бал кашыгы куелган иде. Табакны атасы алдынарак этәреп, Сөембикә бер касәгә куе чәй агызды, җимешләр салды да Йосыф мирзага сузды:

— Рәхмәт, кызым, — диде Йосыф мирза, касәгә үрелеп.

— Күп сөйләден, атаем, тамагын шуңа кипкәндер.

Йосыф мирза, чәй йотып, елмаеп куйды.

— Үз гомеремдә бу кадәрле сөйләгәнем юк иде.

— Атаем, син боларны кайдан белеп бетердең соң? — дип кызыксынды Сөембикә. — Күптәнге хәлләр бит.

— И-и кызым, Идегәй бабабызның тормышын халык үз хәтерендә саклый

бит. Ул буыннан буынга тапшырылып килә. Дөрес, вакыт дигән нәрсә үзенекен итә. Кайбер нәрсәләр онытыла.

— Атаем, син шундый төгәл итеп сөйләп чыктың. Шаккатмалы...

Йосыф мирза канәгать елмаеп куйды:

— Мин дә бу хәлләрне белеп житкерми идем. Әшрәф Бабаң ярдәм итте. Ул барыбыздан да күбрәк белә. Юкка гына аны бездә халыкның хәтер сакчысы дип атамыйлар.

— Ул тарихны теркәп барамыни?

— Анысын белмим, кызым. Бәлки, теркидер. Бездә әле тарих язу гадәткә кереп китмәгән шул.

— Атаем, Кондырча сугышыннан соң Идегәй бабабыз үз ыруыбыз мангытларга кайтып киткән иде. Шуннан соң ул нишләгән? Бу билгелеме?

— Билгеле, кызым. Иң мәшһүр эшләрен ул Кондырча сугышыннан соң башкара. — Чәй эчкәч, Йосыф мирзаның йөзе алсуланып китте, ана хәл кереп, сүзен дәвам итте. — Сугыш хәрәкәтләре тукталгач, ил тынычлана. Аксак Тимер дә, гаскәренә бераз ял биргәч, җыелган байлыклары белән үз иленә кайтып китә. Далаларда тынычлык урнаша. Бу вакытта Идегәй бабабыз бик мөһим бер эш башкара. Ул мангыт мирзаларын җыя да корылтай кебек бер җыен уздыра. Бәлки, бу чыннан да корылтай булгандыр. Анысы билгеле түгел. Шул җыенда мангыт мирзалары киләчәктә ничек яшәргә дигән мәсьәләне уртага салып тикшерәләр. Араларында Идегәй бабабыз иң абруйлы, тәҗрибәле, иң зирәк мирзалардан саналганга, җыенда аның белән янәшә куярлык бер мирза да табылмый. Корылтайда дилбегә аның кулында була. Шулвакыт Идегәй бабабыз сугыштан соң Алтын Урда хөкүмәтенең шактый хәлсез булуыннан файдаланып калырга, аннан аерылып чыгып, үзебезгә Мангыт Йорты дип аталган ырулар берләшмәсе төзәргә тәкъдим итә. Бу дәүләт яралгысы сыманрак бер нәрсә була инде. Мирзалар әлеге тәкъдимне күтәреп алалар һәм Мангыт Йортының бие итеп Идегәй бабабызны сайлап куялар. Ул хәзер мирза түгел, Мангыт Йорты белән идарә итүче би исемен йөртә. Бу хәл, үзең әйткәнчә, Кондырча сугышыннан соң була. Шушы көннән мангытлар Иделнең сул ягында җәелеп яткан далаларны үз җирләре саный башлыйлар. Ул җирләрдәге бердәнбер кала — Сарайчык аларның башкаласына әйләнә. Мангыт Йортының идарә эшләре шунда алып барыла.

— Атаем, бу вакытта Туктамыш хан кайларда йөри? — дип, Сөембикә Кондырча сугышында җиңелгән ханны искә төшерде.

— Сорауны бик вакытында бирдең әле, кызым. Хәзер синең төп соравыңа җавап бирер вакыт житте. Син бит без ничек башта — мангытлар, аннан нугайлар булып киткәнбез, дип сораган идең, шулаймы?

— Әйе, әткәй, — диде Сөембикә. Аның өчен бу төп сорау иде. Теге көнне Әшрәф Баба янында да аның башында бу сорау калыккан иде, тик сөйләшү болай да озакка китте дип, ул аны картка бирергә кыенсынды.

— Аксак Тимер ил корыткыч гаскәре белән Мавараеннәһергә юнәлгәч, Туктамыш хан да качып йөргән жиреннән Сарайга әйләнеп кайта. Әйтергә кирәк, Аксак Тимер бу явында Сарай шәһәренә кадәр барып житми, шәһәр зыян күрмичә, жимерелмичә кала. Туктамыш хан кабат тәхеткә утыра. Җиңелсә дә, аның хан дәрәҗәсен берәү дә тартып алмый, ул элеккечә Алтын Урда ханы буларак идарә итәргә керешә. Сугыштан зур зыян күрсә дә, мәмләкәттә тормыш акрынлап җанлана. Җанлануын җанлана, ләкин сугыштан соң Туктамыш хан биләмәләре бермә-бер тарая. Иделнең сул ягындагы далалар Идегәй бабабыз оештырган Мангыт Йорты биләмәләре санала башлый. Эш шунда: дала батырлары арасында Идегәй бабабызның абруе шундый зур була ки, Туктамыш хан аңа каршы берни кыла алмый. Кондырча сугышыннан соң аны берәү дә көчле вә гайрәтле хаким хәлендә кабул итми. Шушы вазгыятьтән файдаланып,

Идегәй бабабыз Туктамыш ханга үзара килешү төзергә тәкъдим итә. Ягъни мәсәлән, шушы килешү нигезендә Туктамыш хан Иделнең сул ягындагы буш далалардан баш тартып, аларны Идегәй бабабыз карамагындагы җирләр дип санарга мәҗбүр була. Моннан тыш Мангыт Йорты ягына чыккан ыруларга, шулай ук фәкыйрь-фокраларга, тол хатыннарга, ятимнәргә, хәлсез, малсыз кешеләргә Туктамыш хан салымнар салмаячак, дип тә өстәлә бу килешүдә.

— Тәхеттә утырган Туктамыш хан шул килешүгә нишанын сукканмы? — дип гаҗәпкә калып сорады Сөембикә.

— Ханга Идегәй бабабыз таләпләре белән килешергә туры килгән шул, кызым. Ул аның нинди көчкә ия Мангыт Йорты хакиме икәнен яхшы белгән. Әгәр дә риза булмаса, ишле мангыт гаскәре аның өстенә ябырыласын ул аңлаган, кызым. Сугыштан соң Алтын Урда шактый хәлсезләнгән була.

— Алайса, Идегәй бабабыз шушы килешү нигезендә Иделдән алып Жаекка, Жаектан алып Эмба елгаларына хәтле сузылган далаларга хуҗа булуга ирешкән. Шулаймы, атаем? — диде Сөембикә, соклануын яшермичә.

— Һәм бу килешүнең иң әһәмиятле ягы шунда: халык, Идегәй бабабыз белән Туктамыш хан арасында шундый килешү төзелүне белеп алгач, төрле салымнардан котылу өчен, Иделнең сул ягына агыла башлый. Шулай Мангыт Йортында халык күпкә арта, Мангыт Йорты бик нык көчәеп китә. — Йосыф мирза кызы каршына килеп басты да, хәйләкәр елмаеп: — Хәзер мин сиңа бер сорау бирәм. Ничек җавап тотарсың икән?

— Нинди сорау, атаем? — дип, кызыксынды Сөембикә.

— Иделнең сул ягындагы җирләргә күчеп утырган халык ул кемнәр була инде, кызым?

Сөембикә берара уйланып торды. Ул Алтын Урдада бу вакытта нинди халык яшәвен күз алдына китерде һәм башында елтырап киткән фикердән елмаеп куйды.

— Соң, Алтын Урда халкы инде, атаем. Татарлар, тагын кем булсын.

— Сөбханалла, кызым, күз тимәсен үзеңә, — диде Йосыф мирза, кызының җавабыннан бик канәгать калып, аннан дәвам итте: — Алтын Урда татарлары мангытлар яшәгән далаларга күчеп утыргач, тора-бара Мангыт Йорты зурая, ишле һәм көчле Нугай Урдасына әверелә. Моның өчен Идегәй бабабыздан соң идарә иткән көчле биләр зур тырышлык күрсәткән. Шуннан соң анда яшәгән халыкны нугайлар дип атап йөртә башлыйлар.

Сөембикә моңа каршы:

— Бохара, Сәмәрканд якларыннан Казанга килгән сәүдәгәрләр Казан халкын да нугай дип йөртәләр. Нигә алай икән, атаем?

— И-и кызым, гасырлар буе бу ике халык даими аралашып яшәп, кушылып, туганлашып беткән инде. Казан Йортында да күпме нугай авыллары бар. Әнә, Казан артындагы Алат каласына да нугай мирзалары хуҗа. Күрәсең, Мавераэннәһердәге халык нугай белән татарны бер халык дип карыйдыр.

Йосыф мирза, бер сүз дә әйтмичә, бүлмә почмагында торган яшел сандыкка таба атлады. Бу төрле эш кәгазьләре, сәүдә эшләренә караган исәп-хисап кенәгәләре саклана торган сандык иде. Йосыф мирза сандыкны ачты, аннан тышкы ягы матур итеп уеп бизәлгән затлы агач тартма алды. Шуны тоткан килеш Сөембикә янына килде, тартманы өстәлгә куйды һәм ачып җибәрде. Тартма эченнән кадерләп төреп куелган, шактый саргайгая төшкән бер ярлык алды да аны сак кына сүтәргә тотынды. Сөембикә, атасының ни эшләргә җыенганын аңлап җиткермичә, аның хәрәкәтләрен күзәтә иде.

— Менә, кызым, Туктамыш ханның Идегәй бабабыз белән төзегән килешү ярлыгы. Без нугайлар аны күз карасы кебек саклыйбыз. Күрәсеңме, язу астына дүртпочмаклы хан нишаны басылган. Нугай Урдасы җирләрен билгеләүче бик

кадерле ярлык бу, — дип, Йосыф мирза ярлыкны Сөембикәгә сузды. Сөембикә аны саклык белән кулына алды, Алтын Урда заманында язылган юлларга күз салды. Ярлык гарәп хәрефләре белән укырлык итеп язылган иде. Ул ярлык башындагы беренче сүзләргә күз салды. Ул: «Минем Туктамыш хан сүзем...» дип башлана иде. Сөембикә ярлыкны акрын гына укырга кереште. Ара-тирә эш кәгазьләрендә генә кулланыла торган аңлашылып бетмәгән махсус сүзләргә дә килеп төртелгәләде. Шулай да аның эчтәлеген ул яхшы ачты. Сүз атасы сөйләгән килешү хакында бара иде. Аның моңарчы Сафагәрәй яздырган ярлыкларны укыганы булса да, бу бөтенләй башка ярлык. Кәгазе саргая төшкән, астына дүрт почмаклы хан нишаны бастырылган бу ярлык үзенең борынгылыгы беләнме, анда Идегәй бабасы телгә алынгангамы — аңа бөтенләй башкача тәэсир итте. Ул бит кулында Нугай Урдасының яшәү даирәсен билгеләүче тарихи ярлыкны тотып тора. Ярлык аның Ватанын гәүдәләндерә сыман иде.

Укып чыккач та Сөембикә аны берара кулында тотып торды, үзенең дулкынлануын сиздермәскә тырышты. Аннан ярлыкны атасына сузды. Йосыф мирза аның халәтен күреп торды, тик бер сүз дә әйтмәде, ярлыкны элеккечә саклык белән генә төреп, агач тартма эченә салды:

— Менә, кызым, безнең Нугай Урдасы шушы ярлыктан башлана. Аңа Идегәй бабабыз нигез салган дип юкка гына әйтелми. Ул шушы бәһасез ярлык белән раслана, — диде Йосыф мирза һәм тартманы кире бүлмә почмагындагы яшел сандыкка илтеп салып куйды.

Аннан кире Сөембикә янына килде, аның иңенә кулын салды. Сөембикә атасы каршында утырып торуны яхшысынмыйча, аягына торып басты, ләкин Йосыф мирзаның йөзенә күтәрелеп карарга кыймады. Ә атасы:

— Кызым, анаең шатлыклы хәбәр әйтеп, мине бик нык сөендерде бит әле...

Сөембикә оялудан кызарып китте, ул инде сүз нәрсә турында барачагын аңлаган иде. Йосыф мирза аның иягеннән тотып, башын күтәрә төште дә:

— Сөембикә кызым, син балага узгансың икән бит... Бу безнең өчен шундый шатлык, шундый шатлык... Син әле моның мәгънәсен үзең дә аңлап житкермисең. — Йосыф мирза кызын кочагына алды, жиңелчә генә күкрәгенә кысты. — Әгәр дә ир бала таба калсаң, кызым, беләсеңме ул кем булачак?

Сөембикә, аңлап житкермичә, атасының бәхетле йөзенә бакты:

— Кем булачак, атаем?

— И-и кызым, шуны да аңламыйсыңмы?.. Минем оныгым бит атае Сафагәрәй ханнан соң Казан Йорты тәхетенә утырачак. Аңлыйсыңмы, Казан ханы булачак!

Сөембикәнең чыннан да әле бу хакта уйлаганы юк иде. Ул бары тик балага узу шатлыгы белән генә яши. Аның уйлары күбрәк Сафагәрәй язмышы тирәсендә әйләнә, ул кайта-кайта Казанны исенә төшерә, иренең тәхетне ничек кайтарып алачагы турында борчыла иде.

— Ә кыз туса, атаем?

Йосыф мирза уйга калды, бераз дәшми торганнан соң:

— Аллаһы боерса, ир бала туар. Шулай дип телә, кызым. Без дә анаең белән шул теләктә булырбыз.

— Рәхмәт, атаем. Бүген син миңа бик күп нәрсәләр сөйләдең, күп нәрсәләргә күзләремне ачтың. Мин инде бөтенләй башка Сөембикәгә әверелеп барам шикелле.

— Бик әйбәт, кызым. Файдасы тисен. Син үзеңнең нинди нәсел дәвамчысы икәнеңне белеп яшәргә тиешсең. — Ул кызын беләгеннән алды да: — Ярар, кызым, төш вакыты житте. Анаең табын янында көтә торгандыр, — дип, Сөембикәне бүлмәдән алып чыгып китте.



Факил
Сафин

# ТЫН СУЛАРГА КАРАП

СОНЕТ-ТАКЫЯ

## Таҗ–сонет

Тын суларга карап көрсендем,
Кипкән камыш кисәк сискәнде.
Жил кабызды тузгак сусәнне.
Кабынды да янә ул сүнде...

Төн кочакка алды, мин сеңдем,
Йолдызлармы ерак, ул шәмме?..
Карт өянке моны искәрде.
Кайнардан да кайнар җирсенү...

Мин тынлыкка сыенам тагын да,
Җаным эзли, юк син янымда.
Яктылыкка үрелә күзләрем.

Ак каурыйлар елга ярында,
Ни сер килә офык шавында? —
Ишеталмый калдым сүзләрен...

I

Тын суларга карап көрсендем.
Каршы ярга йөзә ак мамык.
Бер күренеп, тагын югалып,
Китсенме ул, кире килсенме?..

Суда сурәт йөзә — бу синме!
Киләм дигән иде — юк та юк...
Ә килсә ул? Булырмы таныл?
Сулар елый үксеп, мин сиздем...

Факил САФИН (1954) — *шагыйрь, прозаик; «Саташып аткан таң» роман-трилогиясе, «Биек тауның башларында», «Былбыл оясы» һ. б. китаплар авторы. Татарстан Язучылар берлегенең Г.Исхакый исемендәге әдәби бүләк иясе. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Чаллыда яши.*

Май гөлләрен алып кулыма,
Чыгар идем тагын юлыңа,
Еллар аша кире йөгереп.

Кушылырсың сыман жырыма.
Сыенды да суның ярына,
Ап-ак мамык алды тибрәнеп...

II

Кипкән камыш кисәк сискәнде.
Кояш нуры сызыла тын суда.
Бар гомерем — көмеш тамчыда,
Битем буйлап йөгереп үткән дә...

Жилнең битен камыш үпкәндә,
Хисләремне ала камчылап.
Нигә алар шундый ярсулар?..
Көзнең жаны ялкын икән лә...

Күтәрелә ялкын биеккә,
Кайнар да ул, салкын кебек тә —
Галәм өчен мизгел, шул бары...

Күңелләрем әле гел биктә,
Ачылмасмы көзне күреп тә? —
Уйландыра менә шулары...

III

Жил кабызды тузгак сусәнне.
Адарынып гомер кичкәнне,
Ике офык — чиккән чикләрне,
Сизмичә дә калдым үткәнне.

Мин теләмим инде бүтәнне,
Хыял, омтылышлар — кичәге,
Яктырырга! Шулмы исәбем? —
Шаулап үткән һәрбер уй ямьле.

Нечкәдән дә нечкә бу көннәр,
Тән сулышы аңа бөркелгән,
Төш күрәсе килә уяуда.

Киләчәкне күпләр күрсеннәр,
Бүгенгедән, әйдә, көлсеннәр.
Буялыр ул кайсы буяуга?..

IV

Кабынды да янә ул сүнде...
Көлдә тәгәрәттек бәрәңге,
Кызарынып янды өрәңге,
Балачакта моны кем күрде?..

Изү ачык иде — җил өрде.
Шукланды да язмыш, бөтерде,
Дулкыннарны куып китерде.
Әрем тәме — җанга ул өлге.

Гомер буйлап үткән чагында,
Тәрәзәгә чирткән чаганга,
Күз төшереп ал син, онытма.

Җыелсалар бергә табынга,
Юксынсалар сине тагын да,
Син бар әле, бар син бу йортта...

V

Төн кочакка алды, мин сеңдем.
Ялгыз таган җилдә чайкала.
Тын сулар да ага — яр кала.
Калалмадык ярда, дисеңме?..

Пышылдыймын синең исемне,
Йолдыз сүнсә, күктә ай кала.
Йөрәк түрендә үк саклanган
Син — сурәте якты хисемнең.

Хәтерлиме безне ул таган?..
Чытырманнан чыкты яшь болан.
Нигә ялгыз — әллә адашкан?..

Ерак ярда тагын мин калам,
Җаным әрни, тирән ул ярам.
Көз моңлана алтын сагыштан.

VI

Йолдызлармы ерак, ул — шәмме?
Офык эри җилләр чатында.
Еллар кичеп, менә кайттым да...
Бер тавыш юк өйнең эчендә.

Иртәсе дә шулай, киче дә.
Киләчәкне алда көткәндә,
Кайтып кердем тагын үткәнгә,
Сыенып торам салкын мичәнә.

Койма буйлап үскән кычыткан,
Каршыларга бары ул чыккан.
Тәгәрәдем ишегалдына.

Алмагачны әнә җил еккан,
Чишмә эзен күптән югалткан,
Кошлары да сәлам алмыйлар...

## VII

Карт өянке моны искәрде. —
Без дәверне кудык, йөгердек,
И сөендек! — Дидек, өлгердек!
Язмыш күперләрен сүткәнбез.

Җилләр каршы, һәрчак тискәре.
Күпме юллар үттем — бер белмим,
Дөрләп яналмадым, сер бирмим —
Ниләр җыйдым, барлыйм биштәрне.

Кош тоткандай йөри дус-ишләр,
Шәһәрләрдә җырлы, дип кичләр:
«Озак торды атым, чапмады...»

Бер карасаң — тулы бу биштәр,
Бер карасаң — тишек һәр төштән —
Мунча төтенен дә тапмадым...

## VIII

Кайнардан да кайнар җирсенү.
Болыннарда йөрим төшемдә,
Һәр чәчкәсе анның исемдә.
Кочак җәя миңа Җир-сылу!

Туган якта изге җилкенү.
Кошлары да читтә көйсезләр,
Йортлылар да анда өйсезләр.
Кирәк булган, ахры, бер күрү.

Эзли кеше бәхет дагасын.
Җуя барып әнкәм догасын,
Сурлы көнгә кайтып барыш ла!..

Балачагым — күзем карасы,
Ахыргача бергә барасы,
Серкә очырыр юлда арышлар.

## IX

Мин тынлыкка сыенам тагын да.
Һәрбер мизгел бүлеп куелган.
Каршылыклар кичтем юлымда.
Җанга минем саксыз кагылма!

Күрү тиеш кара, агын да.
Язмыш эзе тирән уелган,
Чыктык күптән арзан уеннан,
Гөлләр үсә шигырь багымда.

Хак диделәр, нахак булды ул.
Салкын булып җанга тулды ул,
Яшәү дигәннәре катмарлы.

Сөю булып бәхет кунды ул,
Игелектә безнен унды юл.
Чапсын, чапсын, тыймыйк атларны!

X

Жаным эзли, юк син янымда.
Мәктәп елларымнын кояшы,
Тан чыклары түгел — күз яше! —
Тик саф хистән сөю кабына.

Истә йөртәм барысын, барын да!
Алсу алмам, яшьлек сердәшем,
Кайтарырга иде бер дәшеп,
Сагышларын хәтта сагынам.

Ул чакларнын тансык моннары,
Йөрәгемдә берчак тынмады.
Учак яктык — күккә үрләде.

Көтәм, диден... Никтер сонладым.
Югалткачтын гына анладым,
Йолдызлардан эзлим эзләрен...

XI

Яктылыкка үрелә күзләрем.
Ялгыз торна кайткан күленә,
Сөенгән дә сыман күренә,
Дулкын какса, ялгыз түзәрме?..

Тавышлары жанны өзәрлек...
Офыкларнын ерак түренә
Дулкын-дулкын сагыш түгелә,
Сагыш — дингез, кораб йөзәрлек.

Мәхәббәткә юллар бик озын,
Югалтулар мизгел, ут-сызым.
Яшеннәре яши йөрәктә.

Ташулары тына һәр язнын.
Көзгә кереп барам мин ялгыз,
Сары яфрак оча тирәктән...

XII

Ак каурыйлар елга ярында.
Урман өсләрендә жил шаулый.
Кем югалткан — бары ул анлый,
Китмәс көзләр мина сарыла.

Төшә кояш, бишкә ярыла.
Үләннәрдә инде сут калмый.
Тын суларны сүрән ут ялмый,
Ут шәүләсе күктә чагыла.

Мин, күрәсең, тынлык баласы,
Бер җиргә дә килми барасым,
Тын суларда җаным коена.

Их, шушында мәңге каласы!
Урман өсләп җилләр шауласын,
Көзге урман җилгә сыена...

## XIII

Ни сер бар ул офык шавында?
Кубарылган болыт һавада.
Яңгырлары үксеп явалар,
Күшеккән, күр, Торна тавы да.

Актарыла алтын агымда,
Тирә-якны болыт камаган.
Көтәр әмәл, чара калмаган,
Дөнья көзнең алтын авында.

Барысына да кирәк түләргә,
Безнең эзне яфрак күмәр лә...
Китмим диеп, кемне алдыйсың?

Сөенергә кирәк, көләргә,
Санасыннар, әйдә, җүләргә,
Тормыш гади — бик соң аңлыйсың...

## XIV

Ишеталмый калдым сүзләрен.
Көтәләрдер — шуңа юрадым.
Яшьлек урамнарын урадым,
Тик күрмәдем таныш йөзләрне.

Мин күрмәдем таныш күзләрне,
Тупыллардан кат-кат сорадым,
Ә аларда — яфрак бураны,
Маналмадым мин дә бүзләрне...

Тын суларда йөзә ак мамык.
Ярда булмас, булмас шул калып.
Кызылланып яна чаганнар.

Мин дөньяга карыйм сокланып,
Әйләнешне танып, таң калып —
Җилдә тирбәлешә таганнар...



Данил
Салихов

# БАЯЗИТ

ДРАМА

*Ике пәрдәдә, бер картинада*

**Катнашалар:**

Баязит – олпат язучы.
Ислам – Баязитның өлкән улы. Алтын беләзекле чынаяк.
Хисам – Баязитның төпчек улы. Көмеш беләзекле чынаяк.
Хәтирә – Баязитның хатыны. Көяле шәл.
Кәримә – социаль-көнкүреш хезмәтеннән.
Фәрук – ак бабай.
Табиб
Лилия – Баязитның «Агыйдел» хикәясендәге төп образы.
Мифтахетдин – Баязитның «Бүре» романындагы төп герое.
Пәри
Миңнулла – Баязитның «Кукуруз» драмасындагы басу каравылчысы.
Яшь язучы
Түрә

*Вакыйга бүгенге көннәрдә Баязит яши торган биек түшәмле фатирның эш бүлмәсендә бара.*

## БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

### Беренче картина

*Баязит фатирының эш бүлмәсе. Ул иске генә герман машинкасында язып утыра.*

Баязит. Кәримә, сеңлем, син биредәме? Кәримә...

*Эчке бүлмәдән Кәримәнең тавышы ишетелә.*

Кәримә. Кая булыйм...
Баязит. Бирегә кер әле!

*Кәримә керә.*

Данил САЛИХОВ (1958) — *драматург; «Узып барышлый», «Гыйләҗ тәрәзәләре», «Таш сандык» һ.б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстан Язучылар берлегенең Г. Исхакый исемендәге әдәби бүләк иясе. Казанда яши.*

Кәримә. Пычагыма китимме? Миннән гайре кемең бар?

Баязит. Сенлем, нигәдер туңып киттем. Җилкәмә шәл генә япмассыңмы?

Кәримә. Хәзер. Ходаем, машинкасына кәгазь куярга да оныта. Нәрсә язган буладыр инде.

Баязит. Онытмадым. Кәгазьнең мина хәзер кирәге юк. Әнә, моңарчы язганнарым да китап киштәсендә җаныма тынгы бирмиләр. Үткәннәрдән качасым килә минем, сенлем, үткәннәрдән. Шушының төймәләренә бармакларым тисә, дөньямны онытып торам.

Кәримә. Күзем чыкмаган. *(Стенадагы китап киштәсенә күрсәтеп.)* Әнә, бер киштә язып тутыргансың. Боларның барысын да үзең генә яздыңмы, Баязит Әсһәдуллович?

Баязит. Белмим. Үземне дә шул сорау борчый.

Кәримә. Борчылма. Үлгәннәрдер инде.

Баязит. Кем?

Кәримә. Шул инде. Үзең дә сиксәннең теге ягына чыктың бит.

*Китап киштәсенең китапсыз урыныннан чәче-башы тузган, җимерек йөзле Пәринең башы күренә.*

Пәри. Үтерми торыгыз! Мин әле анда барырга ашыкмыйм.

Баязит. Син икәнсең әле. Үтерерсең аны. *(Китап киштәсенә күрсәтеп.)* Әнә, киштә ярыгыннан карап тора.

Кәримә *(гаҗәпсенеп)*. Кем?

Баязит. Әле ул мине каберемә кадәр озата барачак.

Кәримә. Кем?

Баязит. Әнә ич, Пәрием. *(Пәригә.)* Төш, әйдә. Нәрсә киштә ярыгыннан гына карап торасың?

Пәри. Төшмим. Син мине, мин сине күрәсебез килми.

Баязит. Шулай, сенлем. Чын язучы бер генә әсәрен дә үзе генә яза алмый. Пәрие белән яза. Язуын яздым. Кайберләрен Пәриемә карышып яздым. Менә шулар миңа хәзер тынгы бирми.

Кәримә. Шулайдыр шул. Җене булмаган кешегә бу кадәр китапны ничек язмак кирәк.

Баязит *(үз-үзенә)*. Пәри башка, җен башка.

Кәримә. Ярый әле, Баязит Әсһәдуллович, бәхетегезгә, безнең кебекләр бар. Синең бу китапларыңны укымаган булсам, мин дә яныннан километр ярымнан урап уза идем. *(Үз-үзенә мыңгырдап.)* Утырган була.

Баязит. Башкалар урап уздылар дисең инде?

Кәримә. Урап кына узу түгел, китап укымыйча да югарыга үрмәләделәр. Үрмәләделәр генә түгел, аякларын бөкләп менеп утырдылар. Нигә? Әнә, бар да берәрсеннән сора. «Минем китапларымны укыдыңмы?» — дип сора. Меннән өчесе җавап бирә алса, рәхмәт әйтерсең. Үз гомерләренә берәр китап укып чыгалар да, кергән-чыкканга шуннан берәр җөмләне кабатлап, синнән, миннән акыллырак булып утыралар. Шулвакыт син тирәнгәрәк керсән, сәгатьләренә карый башлыйлар. Кинәшмәгә ашыгалар. Ә менә мин укыдым. Укыганга күрә намусым синең яннан җибәрми. Баязит Әсһәдуллович, бу иске шәленне күптән чүплеккә чыгарып ыргытырга вакыт.

Баязит. Кирәкми. Өйрәндегез бар искене чүплеккә чыгарып ыргытырга.

Кәримә. Без түгел. Без искене саклаганга, бәлки шушы хәлдә калганбыздыр да. Баязит Әсһәдуллович, ачулансаң ачулан, мин бу шәленне чүплеккә чыгарып ыргытам.

Баязит. Кирәкми. Мин бөтенләйгә бу җирдән киткәч, ләхеттәге җәсәдемә капларсыз. Без анда, берегезгә дә комачауламыйча, тыныч кына ятарбыз. Ә хәзер ул көяле шәлне минем нафталинлы җилкәмә сал.

*Баязитның җилкәсенә шәл сала.*

Баязит. Рәхмәт. *(Иңсәсендәге шәлен ике кулы белән тотып.)*

Менә бу шәл дә минем үткәнемнең, яшьлегемнең гүзәл мизгеле. Хәтирә апаң истәлеге. Ә син шуны чүплеккә ыргытмакчы буласың. Узганыңны саклау — хәтереңне янарту ул. Узганнарны онытып киләчәккә барып булмый.

Кәримә. Тузган бит, Баязит Әсһәдуллович, тузган.

Баязит. Шәл тузган, күңелдәге хатирәләр тузмаган. Картая барган саен, көннән-көн көчәяләр генә.

Кәримә. Бир алайса, кадерле әйберең булгач, бераз тишек-тошыкларын ямаштырып бирим.

Баязит. Үткәннәрне ямап булмый. Алар күңелемдәге хатирәм калдырган төзәтеп булмаслык яралар. Мин соңгы адымнарымны, соңгы минутларымны шушы шәл белән атлыйм. Кагылган, сугылган чакларымда ул минем таянычым, кыйналганда яклаучым, өшегән, туңган чакларымда җылытучым, ялгыз калган чакларымда юатучым, минем белән тормыш сукмагыннан авыр йөк тартып баручы юлдашым. Ә син чыгарып ташлыйк дисең. Ул яшәргә хаклы! Ул бары тик минем белән генә китә ала. Ул бары тик минем җаным тәнемнән аерылып, хыялларым, уй-фикерләрем мине ташлап киткәннән соң гына бу җиһаннан китә ала. Күкрәгемдә йөрәгем типкәндә ул әле яшь.

Кәримә *(үз-үзенә)*. Яшь үзенекен итә картның. Моннан ярты гасыр элек үлгән хатынының көяле шәле белән саташа.

Баязит. Баязит саташа дисең инде. Баязит саташмый, Баязит хыяллана. Әдипне хыяллары ташлап киткәннән соң гына әдип саташа.

Кәримә. Шулай, бик тә шулай, Баязит Әсһәдуллович. Арабыздан киткәннәр рухы безне яшәтә. Мин теге бүлмәгә чыгыйм әле. Ялгызыңны гына калдырсам, ачуланмыйсыңмы?

Баязит. Ә мин ялгыз түгел. *(Шәлен күкрәгенә кысып.)* Мин Хәтирәм белән.

Кәримә *(гаҗәпсенеп)*. Алай икән...

*Чыгып китә. Серле музыка. Ут сүнә. Ут янганда шәл урынында яшь кенә Хәтирә, Баязитын кресло артыннан кочаклаган да...*

Хәтирә. Баязит, Баязитым минем. Мине синнән аермакчы булалармы?

Баязит. Малакасослар диген. Мине Хәтирәмнән аерып, нинди шатлык кичермәкче буладыр.

Хәтирә. Бәлки сиңа гыйшык тотадыр?

Баязит. Сиксәннең теге ягына чыктым, күңелдәге Хәтирәне сызып ташлап булмый.

Хәтирә. Үзең миннән аерыла алмыйсың, ә үзең минем янга күчмисең.

Баязит. Китәр идем. Төшләремдә чакырасың да, җитәкләшеп кенә киттек дигәндә, йокымнан уятып көлә-көлә китеп югаласың. Калдырып киткән шәлең дә, тузып, дөньялыктан китеп бара. Хыялым белән шуңа җан өрәм дә, аның белән сөйләшеп, туйганчы күңелемне юатам.

Хәтирә. Без киткәч, җиһан матурлангандыр, ташлап китәсең килмидер.

Баязит. Утыз бишең тулыр-тулмас ике малай калдырып ташлап киттең дә, җиһанга кайтасың килеп, төшләремә керәсең.

Хәтирә. Бөтен дөнья чәчәктәдер. Икмәк иседер. Минем өянкем тирәякка ишетелерлек итеп шаулыйдыр.

Баязит. Юк, шауламый. Җил искән саен шыгырдый. Өянкең картайды инде. Җил-давыллар ботакларын сындырды. Корып бара өянкең.

Хәтирә. Тамыры нык булсын.

Баязит. Дөньясы без уйлаганча бармый. Көтмәгәндә җил-давыл чыга да дөньясының астын өскә китерә. Без буган ярны, давыллап килеп, гарасат суы юа. Ярыбыз җимерелеп, өянкеңнең тамырлары актарыла.

Хәтирә. Борчылма. Ул тамырлардан яшь үсентеләр шытып чыгар.

Баязит. Алар безнең ярны сакламас... Аларның үз ярлары.

Хәтирә. Бәлки синең гаебең юктыр. Син шыткан җир бәлки уңдырышсыз булгандыр.

Баязит. Уңдырышсыз җир булгач, нигә шытарга иде?

Хәтирә. Бәлки аңа син гаепле түгелдер. Ул җиргә орлыгын салган Әсһәдулла карт, синең атаң гаепледер.

Баязит. Нигә үсәргә иде? Ябалдашыма ике бишек асарлык та хәлемнән килмәгәч, нигә дөнья бутарга иде? Ике сабыемны сакларлык та көчемнән килмәгәч, нигә аларга җан өрергә?! Минем әткәй, Әсһәдулла карт, мине уңдырышлы җиргә тудырды. Тугач та анам иренемә күкрәк сөте тидерде, атам түшәменә бишек асты. Үсә төшкәч, алдыма икмәк куйды. Ә мин аны кулак диеп сөргенгә сөрдем.

Хәтирә. Син үзең турында гына түгел, башкаларның да өсталләрендә икмәкләре булуын теләдең. Һәр йортның түшәмендә тирбәлгән бишек күрәсең килде.

Баязит. Ялгышым кайда?

Пәри *(китап киштәсеннән башын чыгарып)*. Тирбәлгән бишектә елак бала, тирбәлмәгән бишектә батыр ята.

Баязит. Син иленә елак балалар тудырдың диясең киләме?

Пәри. Синең илең юк!

Баязит. Димәк, җиремә?

Пәри. Иле юкның — җире юк!

Баязит. Бар, бар минем җирем! Минем ата-бабам калдырган үз җирем бар.

Пәри. Кайда?! Бәрәңге бакчасындамы? Юк, юк синең җирең! Ул да синеке түгел! Ясак түләтәләр.

Баязит. Кит, кит, мәлгунь, күземнән югал.

Пәри. Бик теләп китәр идем дә булдыра алмыйм. Мин — синең душаңдагы Пәриең.

Баязит. Ялварып сорыйм. Бер генә минутка булса да ялгызымны гына Хәтирәм белән калдыр.

Пәри. Үз-үзеннән качып булмый. Ходайдан сорап кара. Бәлки ул ярдәм итәр. Безне Хәтирәң белән Ходай илчесе Газраил генә бергә итә алса.

Баязит *(Пәрие булып)*. Алса! Харап икән. Син нәрсә, әллә анда да миңа ияреп бармакчы буласыңмы? Юк инде, Пәрием, гафу ит. Син бу юлы оттырдың. Анда барганда, Газраил бабаң безне бер-беребездән аерыр.

Пәри. Каян беләсен? Безнең анда барып караган юк бит әле.

Баязит. Шулай дисенме?.. Ул дөнья бардыр дисеңме?

Пәри. Каян белим. Ул дөньяның барлыгын белсәк, син дә китап язып азапланмаган булыр идең.

Баязит. Миңа да үз Пәрием белән тарткалашып, ызгышып утырасы булмас иде. Нинди хөррият! Адәм баласы тыныч күңел белән Пәрисез генә яшәр иде дә яшәр иде. Кызык. Пәрисез адәм баласы.

Пәри. Аяныч. Адәм баласы теге дөньяның барлыгын-юклыгын белми, китап яза. Шул китаплары аша башкалар күңеленә үтеп кереп, алар күңелендә дә Пәри тәрбияләмәкче була. Зиһене җитми, Пәрие белән сугышып, үз-үзен кимерә, ашый.

Баязит. Ялгышасың, Пәрием. Зиһене булып та Пәрие куркак була.

Пәри. Димәк, син — зиһенле, мин — куркак! Юк инде, хуҗам. Зиһен белән Пәри бергә йөри.

Баязит. Пәрием булгач, зиһенем булгач, ә ни өчен мин куркып калдым? Син Пәриемә каршы бардым.

Пәри. Мин синең белән көрәшмәдем түгел, көрәштем. Ике улыңны, Ислам белән Хисамыңны югалттырдым. Хәтирәңне. Атаң белән анаңа каршы бардырттым.

Баязит. Шуның белән нәрсә кырдым? Нишләдем мин?

Пәри. Көрәштең.

Баязит. Яшәдемме мин? Мин аларны җиңә алдыммы? Бәлки аларның Пәри түгел, җеннәре бардыр? Бәлки минем Пәрием аларның җеннәреннән шүрләп калгандыр.

Пәри. Алай димә, Баязит, алай

димә. Кемнең женен кемнең Пәрие жингәнен киләчәк күрсәтер.

Б а я з и т. Хәтирәм җәсәденең кай тарафларда җирләнгәнен дә белә алмадым. Каберенә барып бер уч туфрак кына да салалмадым.

П ә р и. Синнән соң килгәннәр салыр.

Б а я з и т. Кемнәр сине җир куенына салды? Бармы андый бәндә? Минем өчен ерак сәфәр китеп, Себер сазлыгында батып калдыңмы? Әллә берәр явызның кулыннан үттеңме?..

П ә р и. Бәлки ул исәндер?

Б а я з и т. Соңгы көннәремне яшим.

П ә р и. Көннәрдән бер көнне ике улыңны ияртеп кайтып керер.

Б а я з и т. Мин мәңгелеккә китеп югалгачмы?

П ә р и. Каберенә чәчәкләр салырлар.

Б а я з и т. Салырлармы? Син шуңа ышанасыңмы, Пәрием?

П ә р и. Нәрсә өчен яздың? Кабереӊ өстендә билчән үсәрлек булгач, кем өчен яшәдең, кем өчен иҗат иттең?

Х ә т и р ә. Безнең өчен.

Б а я з и т. Көннәрдән бер көнне өемдә кайтып керерсең дә, мин сиңа нәрсә дип җавап бирермен? Менә сиңа шәлең. *(Кулларына ике чынаякны алып.)* Менә улларыңнан ядкәр булып калган чынаякларны сакладым диярменме? Юлларыма ник очрадың?

Х ә т и р ә. Мәңге яшәр өчен.

Б а я з и т. Җуләрем. Әнә, күрәсең, Пәрием миңа тынгы бирми. Башканыкы булсаң, бәлки әле яшәр идең дә яшәр идең.

Х ә т и р ә. Пәриенә рәхмәт әйт. Ул мине мәңгелек итте.

П ә р и. Котәрсең аннан рәхмәт. Соңгы вакытларда ул миннән котылмакчы була. Мин Пәрие булмасам, үзенең Фәрук карты кебек әллә кайчан бауга менә иде инде ул. *(Күнеле тулып.)* Рәхмәт, Хәтирә, рәхмәт!

Х ә т и р ә. Баязит, син миңа яңа җан өрдең. Син мине маяк итеп киләчәккә калдырдың. Җиргә яңа хатирәләр тудырдың.

Б а я з и т. Мин бу җирдән киткәч, сиңа, минем Хәтирәмә якты караш калырмы? Менә нәрсә борчый мине.

Х ә т и р ә. Җуләрем син минем. Әгәр мин синең кайтканыңны көтеп, колач җәеп каршы алып, синең белән озак, озын гомер итеп, бергә картайган булсам, сине эзләп, синең арттан ерак Себергә сәфәр чыгып, шунда ятып калмаган булсам, яңа Хәтирәләр тумас иде.

Б а я з и т. Минем хыялларым, язганнарым тормышка аштымы соң, аштымы? Минем авазымны ишетүчеләр булдымы? Әллә ямьсез, мәгънәсез кайтаваз булып үземә генә әйләнеп кайттымы?.. Менә нәрсә борчый мине.

Х ә т и р ә. Ана җавапны киштәдәге китапларыңнан эзлә, Баязит.

Б а я з и т. Кулдан-кулга йөреп тузып, таушалып, өтәчке хәлендә калганнармы дисеңме? Ә син китмә. Хыялымда гына булса да матур хатирә булып кал.

Х ә т и р ә. Булмый, Баязит, булмый. Миңа китәргә вакыт.

Б а я з и т. Аңлыйм... Адәм баласы мәңгегә килмәгән кебек, хыяллар да мәңгелек түгел. Алар да, вакыты җиткәч, адәм баласын ташлап китәләр дисеңме?..

П ә р и. Китәләр, хуҗам, китәләр.

Б а я з и т. Адәм баласы гомеренең соңгы сәгатьләрендә, соңгы минутларында күнелендә уелып калган хатирәләре белән яши дисеңме?.. Хатирәсен югалткан адәм баласын нәрсә көтә?

П ә р и. Җуләрләр йорты.

Б а я з и т. Ә минем сине югалтасым килми, Хәтирә. Соңгы минутларыма кадәр хыялымда гына булса да озата бар мине, Хәтирәм!

Х ә т и р ә. Ашыкма, Баязит, китәргә ашыкма. Хыялларыңны тормышка ашырыр өчен, хыялыңда тудырганнар җир өстеннән озак атласын өчен, синең җиһанда калуың кирәк, Баязит.

Баязит. Бергә йөргән сукмакларга әрем үсте, чишмәсе корыды. Чишмә буенда соңгы тапкыр без сузган моң гына кайтаваз булып һаман да колагымда чыңлый.

Хәтирә. Ул моңны киләчәк буын, яшьләр күңелендә чыңлатасың килсә, сина жырларга да жырларга.

Баязит. Мина сиксән!

Хәтирә. Син — гасыр илчесе, син — әдип, синең сазың гасырлардан-гасырларга ишетелеп торырга тиеш, Баязит. Жырла, жырла, Баязит. Йөрәгең тибүдән туктаганчы- син жырларга тиеш, Баязит.

Баязит *(жыр суза).*

Гомерләр узды, чишмәләр кипте,
Инеш буеннан сайрар кош китте.
Яшьлектә уелып күңелдә калган
Утлап йөрүче атлар да бетте.
Халкым күңленнән моңнар да китте.

Хәтирә *(жырга кушыла).*

Нигә моң бетте, кая ул китте?
Авыл йортында, әби йортында,
Чыра башында сыңар ут калды.
Менә бетәм, дип, менә сүнәм, дип,
Ул гына жырлый, ул гына елый.

*Ут сүнә.*

Баязит *(үзәк өзгеч ялварулы тавыш белән).* Китмә! Хәтирәм, китмә!..

*Көчле музыка. Ут янганда ишек катында Кәримә белән ак халатлы Табиб басып торалар. Баязит шәлне сабый бала кебек куенына кыскан да, үз-үзенә сөйләнә.*

Баязит. Китмә, китмә син, Хәтирәм... Бер ялгызымны калдырып китмә. Хыялында гына булса да Хәтирәсен терелткән Баязит, Хәтирәсез нишләр соң?

Кәримә. Үз-үзеңне юкка бетерәсең, Баязит Әсһәдуллович. Мин бирედә бит, мин.

Пәри. Ул китсә, башкаларын чакырабыз. Әнә алар, синекеләр, бер киштә.

Баязит. Кирәкми, кирәкми, чакыра күрмә! Зинһар, чакыра күрмә. Миңа ял кирәк. Бер генә минут, бер генә сәгать булса да адәм баласына, миңа ял кирәк. *(Салмак кына өзеп-өзеп, сулкылдый-сулкылдый, жыр башлый).*

Чыра башында сыңар ут калды.
Менә бетәм, дип, менә сүнәм, дип,
Ул гына жырлый, ул гына елый.

Кәримә *(Табибка).* Менә шушы кешене акыллы дип буламы?

Табиб *(Кәримәгә).* Бу күренешләр еш кабатланамы?

Баязит *(жырлавыннан туктап).* Еш! *(Жырын ижекләп, көйсез).*

Чыра башында сыңар ут калды.
Менә бетәм, дип, менә сүнәм, дип,
Ул гына жырлый, ул гына елый.

Табиб *(Кәримәгә).* Сырхауханәдә ятканы бармы?

Баязит *(жырлавыннан туктап).* Бар.

Табиб. Кайсы больницада?

Баязит. Сез уйлаган сырхауханәгә иртәрәк әле миңа.

Табиб. Ә мин кайсы сырхауханә турында сүз алып барам?

Баязит. Күпләр өчен без жүләрләр булып күренәбездер.

Табиб. Баязит Әсһәдуллович, сезгә ял кирәк.

Баязит. Аңлыйм. Сезнең тынычлыкны бозмаска әдипкә ял кирәк. Әйе, әйе, аңлыйм, адәм баласына ял итәр өчен уйламаска, баш ватмаска кирәк. Минем кебекләрнең күз йомулары кирәк. Тынычлык кирәк сезгә, тынычлык. Арыдым. Бик теләп китәр идем. Сезне тынычлыкта калдырырга теләгем зур. Тик нишлим?! *(Китап киштәсенә күрсәтеп.)* Әнә тегеләр тынгы бирми миңа.

Табиб. Кемнәр?

*Китап киштәсеннән Пәри башын чыгарып.*

Пәри. Мин, Пәрие!

Баязит. Әнә, тегеләр!

Кәримә *(Табибка).* Күрәсен, саташа. Ул гел шулай. Үзенен китаплары белән саташа.

Баязит. Саташмыйм, сөйләшәм. Озакламый Мифтахетдинем сикереп төшәр дә, каршыма утырып, йодрыгы белән өстәлгә сугар. Минем белән кызып-кызып бәхәскә керер. Миннуллам, орденын ялтыратып, кукуруз басуыннан кайтыр. Әнә китап киштәсенең ярыгыннан Пәрием карап тора. Сезнен чыгып китканегезне генә көтеп йөри ул.

Пәри. Йөрмим. Нишләп йөрим. Синен душанда утырам.

Баязит. Душамда гына түгел, желегемдә утырасын.

Кәримә. Сезгә ял кирәк, Баязит Әсһәдуллович. Бераз гына тынычланырга.

Табиб. Әз генә күзегезне йомарга.

Баязит. Юк, булмый. Алар мина күземне йомарга ирек бирмиләр. Мин аларны гомерем буе сезнен арагыздан, халык арасыннан эзләдем. Сезнен белән бәхәсләшер өчен эзләдем.

Табиб. Юк, юк, без сине жуләргә санамыйбыз. Сиңа бары тик ял гына кирәк.

Баязит. Сонардын син, Табиб, сонардын... Хәзер сон, сон инде. Элегрәк, элегрәк кайда иден син?! Мин дөньяга үземнен гарип-горабаларымны, алданган, имгәнгән аксактуксакларымны, рәнжетелгәннәремне тудырганда, син кайда иден? Мина дәва юк. Мина дәва — бәхәс. Мина сездән бернәрсә дә кирәкми. Бары тик бер-беребезне анлау гына кирәк. Син — тән ярасын, ә мин жан ярасын дәвалыйм. Тән ярасына дәва бар, жан ярасына дәва бар микән?

Табиб. Бар. Вакыт.

Баязит. Вакыт дисен инде. Сиксән елдан артык сәгать чылбыры тартам. Сиксән елдан артык сәгать тукмагы күтәрә-күтәрә, дөньяны үзгәртмәкче булам. Сиксән елдан артык сәгать күкесе атылып чыга да бер үк саннарны кабатлый. Чүплектә абзый нәрсәдер эзли. Әнә, минем дустым, Пәрием китап киштәсенен ярыгыннан карый. Ана бәхәс кирәк, ана синен китап укуын кирәк. Ана чүплектәге абзыйнын язмышы тынгы бирми.

Кәримә. Саташа, мескен. *(Табибка.)* Алып китегез, алып китегез сез аны. Алай-болай тилереп, тәрәзәдән сикерсә, сезгә дә, мина да рәхмәт укымаслар. Жүләр булса да, язучы дигән зур исеме бар.

Баязит. Тән ярасын дәвалар өчен, жан ярасын дәваларга кирәк.

Кәримә. Зинһар, зинһар, дим, алып китеп дәвалагыз.

Табиб. Булдыралмыйм.

Кәримә. Әллә йогышлы?

Табиб. Юк!

Баязит. Рәхмәт, рәхмәт, яшь иптәш. Күзгә карап, чын хакыйкатьне ачканын өчен рәхмәт.

Пәри *(Баязитка).* Юк! Ул хаклы түгел!

Баязит. Шулайдыр. Шулайдыр, Табиб. Үзем дә шуна шикләнәм. Чирем йогышлы булса, газапларым, азапларым, баш өянәкләрем киштәләрдә тузанга чумып ятып калмаслар иде. Көнем — көн, төнем — төн, чирем чир булмагандыр...

Табиб. Ярый, Баязит Әсһәдуллович, хушыгыз.

Пәри. Хушлашырга ашыкмыйсынмы, Табиб? Баязитны жирләргә иртәрәк түгелме?

Кәримә *(Табибка).* Ә мина нишләргә?

Табиб. Сезгә көтәргә!

Кәримә. Нәрсәне?

Пәри. Баязитнын жир өстеннән чирләрне озатканын.

*Табиб чыгып китә.*

Кәримә *(үз-үзенә).* Әллә мин,

әллә болар дивана?! *(Баязитка.)* Кирәк әйберең юкмы?

Баязит. Кирәк. Үземне генә калдыруыгыз кирәк. Пәрием килде.

Кәримә. Ярый. Рәхәтлән шул Пәриең белән. *(Чыгып китә.)*

Баязит *(китап киштәсенә карап)*. Нәрсә, киштә ярыгыннан гына карап торасың? Төш, әйдә.

Пәри. Жинел генә төшәрсең, бар. Калын-калын романнарың, повесть, хикәяләрең арасына кысылып гомерем узды. Мине тынлаган булсаң, менә хәзер чирем йогышлымы, йогышсызмы дип аптырап утырмас идең?

*Таушалып ертылып беткән киемнән Пәри чыга.*

Баязит. Бер дә кысылып ятканга охшамагансың әле. Кайтып кергәнең юк. Көн димисең, төн димисең, җаныма тынгы бирмисең. Бүгенгедән — узганнарга, узганнардан бүгенгегә өстерисең. Эт талаган кыяфәткә кергәнсең.

Пәри. Нигә? Әллә ошамыймы? Син шул сорауга җавап эзлисең түгелме соң? Яшең житкәч сиксәнгә, Пәриең арта ул.

Баязит. Мина Пәриемнең өтәчке хәлендә калуы кирәкми, миңа китапларымның синең хәлдә калулары кирәк. Бар әле, бар, күңелемне болгатып торма. Юлыңда бул.

Пәри. Юк инде, хуҗам. Бергә башладык, бергә бетерәбез.

Баязит. Нәрсә? Мине каберемә кадәр озатып бармакчы буласыңмы әллә?

Пәри. Кабатланырга яратмыйм. Әйттем бит инде. Нишлим? Сиңа хыянәт итә алмыйм. Бергә икән, бергә, азагына кадәр бергә.

Баязит. Син имгәктән котылу юк икән.

Пәри. Үзең гаепле. Атаң, морза Әсһәдулла абзый сүзләренә колак салган булсаң, менә хәзер тыныч кына гомер кичергән булыр идең. Бәлки ике улың, хатының да янәшәңдә булырлар иде.

Баязит. Кызганам мин сине, Пәриемне.

Пәри. Нигә?

Баязит. Сүзеңнең ата-анасы юк. Ул чагында мин сине, Пәриемне тыңлап, атама каршы төшеп, аны иленнән, туган нигезеннән кудырдым. Ә хәзер син килеп миңа киресен сөйлисең!

Пәри. Ул чагында төштең, ә соңыннан?..

Баязит. Нәрсә? Ялгышларымны искә төшерергә дип килдеңмени? Алай бик акыллы булгач, әйт, ялгышым кайда?

Пәри. Бәрәнге кыздырган кайнар таба астында яткан романнарыңда.

Баязит. Явыз син! Мәрхәмәтсез син!

Пәри. Ул вакытта алар сүзен тыңлап, алар кубызына биемәгән булсаң, менә хәзер син үз Пәриеңә бу мыскыллы сүзләрне әйтмәгән булыр идең. Әнә теге романнарың да кайнар таба астында корымга батып, калҗаеп ятмаслар иде. Тегендә киштәдә тузанга батып ятканнары да сиңа рәнҗемәсләр иде.

Баязит. Аларны әйтәсең... Кем белә, бәлки алар үз сәгатьләрен көтеп яталардыр.

Пәри. Дыр, дыр... Дөньясы бит бытыр!

Баязит. Мин дә бу дөньяга яшәр өчен килдем. Сине тыңлап, нинди рәхәт күрдем? Синең белән саташып гомерем узды.

Пәри. Ялгыштың син, хуҗам. Ай, ялгыштың.

Баязит. Нигә?

Пәри. Гомерең буе мине тыңлаган булсаң, мин бит сине үлемсез итә идем. Үз Пәриеңә каршы килгәнең өчен, гомер буе рәхәт күрмәдең.

Баязит. Пәриеңә буйсынмаган өчен, итәгеңә утыртып балалар сөялмәдең, хәләленне куеныңда назлый алмадың, дисеңме?!

Пәри. Әнә, «Кукуруз» повес-

тендагы Миннулланың кукуруз басуыннан чыгалмый адашып йөри.

Баязит. Авырткан жиремә тоз сипмә. Аңа син гаепле. Аларны тудырганда, син Пәрием кая идең? Нигә каршы төшмәдең? Менә хәзер киштә ярыгыннан карап ятмас идең. Мин дә күптән күзләремне йомган булыр идем.

Пәри. Алай димә, хуҗам, алай димә...

Баязит. Менә хәзер ят шулар белән якага-яка килеп, сугышып, тарткалашып.

Пәри. Болай да синең тудырган һәр имгәгенә кендек әбисе булдым инде.

Баязит. Киштәдә тузан жыеп ятарлык булгач, кендекләрен төптәнрәк кисәргә кирәк иде. Югал күземнән, югал, диләр сиңа!

Пәри. Баш өсте, хуҗам.

*Пәри киштәгә менеп кунаклый.*

Баязит *(ике кулын югарыга күтәреп).* Ярабби бер Ходам, гомеремдә беренче тапкыр сиңа ялварам. Әгәр булсаң, зинһар, коткар мине, коткар мине бу Пәридән.

Пәри *(киштә өстеннән).* Син — бывший коммунист! Ул сине ишетми.

*Сәхнә артыннан Миннулланың жыры ишетелә.*

Миннулла.

Көне буе карга кудым
Кукуруз басуыннан.
Хөршидә, әй, Мөршидә,
Ярап булмый бу кызларның,
Бу кызларның берсенә.

*Күкрәгенә Алтын Йолдыз ордены таккан, кулына мылтык тоткан Миннулла керә дә, Баязитның өскә күтәрелгән кулларын күреп, гаҗәпсенеп.*

Ярап булмый бу кызларның,
Бу кыз... лар...

*Жыры өзелә.*

Миннулла. Баязит Әсһәдуллович, нишлисең син?

Пәри *(Миннуллага).* Мәхәббәтсез! Сөймим мин сине. Бакча карачкысы.

Миннулла. Сөйкемсез сөягегез булдым инде. Минем аркада Никитадан Дәүләт премиясе алганнарын онытканнар. *(Мылтыгы белән Баязитка төртеп ала.)* Нишлисең син?

Баязит. Бүлдермә. Ходайдан синең кукуруз басуына яңгыр яудыруын сорыйм. Күрмисеңмени, корылык. Жир өстен тиле бәрән үләне басты.

Пәри *(Миннуллага).* Билчән!

Миннулла. Син, Баязит Әсһәдуллович, сүзеңне чамалап сөйлә. Хәзер ике дә уйламый атам! *(Мылтыгын тери.)* Сөргендә йөргәннәреңне онытма. Иптәш Хрущёвның кукурузлары Ходай ярдәменнән башка да үсә. Авызыңнан жил алсын. Әнә, яна гына басуның аргы башыннан күк айгыры белән колхозның партоешма секретаре иптәш Байсаров узып китте.

Пәри. Бу ата. Менә шушындыйлар ата да инде. Бу ата. Имгәк бит бу. Син тудырган имгәк.

Баязит *(укуыннан туктап).* Узса! Анда минем ни эшем бар.

Миннулла. Ходайдан ялварып утырганыңны күрсә, райкомга чакыртып, кабер тактаңны, тактасын тактасына аерып, жиргә салып, сөргенгә сөрелгән атаңны исенә төшереп, жиденче бабаңны таптыра ул сиңа.

Баязит. Төкерәм мин синең Байсаровыңа!

Миннулла. Нишләп әле ул минем Байсаровым булсын. Ул синең Байсаровың!

Пәри. Ха... ха... ха... Син тудырган Байсаров!

Миннулла. Коммунистлар партиясенең тугры улы, «Якты юл» колхозының партоешма секретаре Байсаров!

Пәри. Якты юллар, партоешмалар артта калды инде, Миннулла. Син

генә ул кукуруз басуыннан карга куып гомеренне заяга уздырасын.

Миңнулла. Уздырмый нишлим? *(Еламсырап.)* Үзен бит, үзен, миннән басу каравылчысы ясадың.

Пәри. Өстәвенә — герой соц. труда!

Миңнулла. Молодец! *(Орденын жине белән сөртеп.)* Китеп кара, орденлы башын белән.

Пәри. Сезнең хәзер потыгыз бер тиен.

Баязит. Анламадылар, анламадылар мине. Мин аны гыйбрәт өчен таккан идем. Ә алар анламадылар. Үзләре ярыша-ярыша күкрәкләренә шуларны тага башладылар.

Пәри. Әйттем бит мин сиңа, үзләре тагачаклар дип.

Баязит. Кем уйлаган шулай бер катлы булырлар дип.

Миңнулла. Алай димә әле син, Баязит туган, алай димә... Такkансың икән, күпсенмә. Минем үземә бик ошый ул.

Пәри. Хәтта килешеп тә тора.

Миңнулла *(орденын кадерләп сөртеп).* Менә минем уң як күршенеке дә, сул як күршенеке дә юк. Көнләшүләреннән шартлыйлар.

Пәри. Ә синеке бар. Колхозның басу каравылчысы Миңнулла Хакимгәрәевнеке бар да...

Миңнулла. Райком секретаре Сәлимгәрәевнеке генә бар. Рәхмәт сиңа, иптәш Баязит Әсһәдуллович, рәхмәт. Миннән кеше ясадың. Стой!

*Миңнулла кө тмәгәндә күккә атып жибәрә. Куркудан Баязит идәнгә ава.*

Баязит. Нишлисең?

Миңнулла. Нишлим, нишлим, карга атам.

Баязит. Үз башыма. Тәмам йөрәксез калдыра бу мине.

Миңнулла. Колакка карга тавышы ишетелде. Борчылма. Патроны да, каргасы да жәлке түгел, кукуруз жәлке бит, кукуруз!. Фу... Дары исе чыкты.

Баязит. Дивана! Дары исе генә түгел, куркудан әллә нинди исләр чыгарырсың монда.

Пәри. Синең герой!

Баязит *(Пәриенә).* Кысылма! *(Үз алдына мыгырданып.)* Бу Миңнулладан курыккан кебек берсеннән-бер болай курыкмыйм.

Пәри. Миңнулла, хәзер Рәсәйдә каргалар да, чыпчыклар да калмады, птичий грипп дип, дума депутатлары атып бетерде.

Миңнулла. Бетерерсең карганы. Миннән гайре кем ата аларны? Баязит Әсһәдуллович, ну теге язучыны әйтәм әле. Кем соң әле ул, аты коргыры?

Пәри. Кайсы язучы?

Миңнулла. Теге инде, теге... «Көне буе карга кудым кукуруз басуыннан»ны язган язучы...

Баязит. Белмим, белмим.

Миңнулла. Беләсең инде. Кем соң әле ул, аты коргыры? Аңа Дәүләт премиясе бирдегезме әле, юкмы? Ну язып та куйган бит малай. Кирәк бит, ә, кирәк бит.

Көне буе карга кудым
Кукуруз басуыннан.

Ә көе, көе нинди!..

*(Жырлый.)*

Көне буе карга кудым
Кукуруз басуыннан.
Хөршидә, әй, Мөршидә,
Ярап булмый бу кызларның,
Бу кызларның берсенә.

Прәме көенә сүзләре килешеп, мәтәлчек атып тора инде. Прәме, мәтәлчек атып тора. Син — язучы, синең сүзең үтә, жырчысы герой соц.труда булганда, авторлары гына исемсез йөрмәсеннәр инде, Баязит Әсһәдуллович. Әйт үзләренә, бирсеннәр. Башка милләтләргә үрнәк булыйк.

Пәри. Булдыралмыйбыз туган, булдыралмыйбыз. Үзебезнекен дә кая куярга белмибез.

Баязит *(Пәригә).* Шуңа күрә күзләремне йомалмый азапланам. *(Миннуллага.)* Бөтен хатам да шунда. Кемнәрнеңдер буш сүзләренә ышанып, сине тудырганым өчен дә әнә теге киштә өстендә утырган җанымны кимерә.

Миңнулла. Харап икән. Мине тудырып, сиңа нинди зыян? Синекен кимим, синекен ашамыйм, синең өлешеңә кермим.

Баязит. Тынычлап җан бирергә бирмисең. Җанымны, бәгъремне игәүләп, үткән юлымны барлап торасың.

Миңнулла. Күпсенмә, күпсенмә син, Баязит Әсһәдуллович. Син язмасаң, бүтәннәр язган булыр иде. Заставили бы. Сезнең халык — өйрәнгән халык. Сезгә Колыма — курорт, ачлык — ураза. Вәт!

Баязит. Кит син, кит! Алла хакы өчен кит!

Миңнулла. Син Алланы еш исеңә төшерә башлагансың әле. Яңадан бу илдә революция ясарга туры килмәгәе.

Баязит. Хәтер бишегемнән югал.

Миңнулла. Синең хәтер бишегеңдә этем калганмыни миңа? Мин — герой труда! Мин халык күңелендә сакланам.

Баязит. Үтерә бу мине. Мин дә бит адәм баласы. Минем дә бит ялгышырга хакым бар.

Миңнулла. Китәм. Нигә китмәскә? Болай да озакладым. Үз теләгем белән килмәдем. Үзе чакыра, үзе куа.

Баязит. Мин сине чакырып китермәдем. Сине Пәрием чакырып китерде.

Миңнулла. Анда минем эшем юк. Пәриеңме, җеңеңме, үзеңме, денеңме. Мин бер нәрсәне беләм: Орденны миңа син бирдең. Китәм. Син биргән орденны ялтыратып, кукуруз басуына карга атырга китәм. Сагынгач чакыр. Син — минсез, мин синсез торалмыйбыз. Әлегә сау булып тор.

*Җырлый-җырлый чыгып китә.*

Көне буе карга кудым
Кукуруз басуыннан.
Хөршидә, әй, Мөршидә,
Ярап булмый бу кызларның,
Бу кызларның берсенә.

Пәри *(шаркылдап көлеп).* Сүзләре көенә мәтәлчек атып тора диме?!

Баязит. Бик кызык инде. Хуҗан үләлми тилмерә, ә син минем язмаларым өстендә ясин чыгасың.

Пәри. Нәрсә, елыйммыни? Син үлсәң, мин дә үләм. Ә миңа үләргә ярамый. Пәриләләр җир өстеннән китсә, җирдәгеләргә яшәү, ай, авыр булачак, ай, авыр булачак. Ахырзаман житәчәк. Фәрук картны гына исеңә төшер.

Баязит. Фәрук картка нәрсә булган?

*Сәхнәдә ап-ак сакаллы ак бабай — Фәрук карт пәйда була.*

Фәрук карт. Нәрсә булган, нәрсә булган. Нәрсә булганын белмисең инде. Авылның ак бабаен, мине, Фәрук картны, авылыннан шәһәргә җибәреп, авылымны таркатып, Пәриемне үтерттең!

Баязит. Сине мин түгел, Пәрием үтертте.

Пәри. Гыйбрәт өчен. Башкаларга сабак булсын өчен.

Фәрук карт. Авыл халкын ата-ана нигезеннән аерып, чит-ят җирләрдә туфрак итү кирәкмәс иде, Баязит. Сагынудан, саргаюдан ташлап киткән авылымның кара мунчасына кайтартып, бауга меңгезмәскә иде.

Баязит. Мин Пәриемә каршы килә алмадым. Тукта әле. Нигә әле син миннән сорау аласың? Кем соң син?

Фәрук карт. Беләсең ич инде. Үзең тудырган «Фәрук сандугачы» хикәяңдәге авылның ак бабае — Фәрук бит мин.

Баязит. Нигә мин баш ватам? Нигә мин үз-үземне битәрлим? Монарчы бер генә кешенең дә килеп, нигә син Фәрук картны үз мунчасында бауга астың дип сораганы булмады.

Фәрук карт. Пәриең чакырып китерде. Син тараткан нигездә ятып калган ата-бабаларымның рухы, читят җирләрдә таралып-чәчелеп беткән балаларым, оныкларымның күз яше чакырып китерде.

Баязит. Нигә, мин сине, Фәрук картны, корбан итеп, хаклы түгел идеммени? Нигә, мин халкымның телен, гореф-гадәтләрен, йолаларын саклап калмакчы түгел идеммени?

Пәри. Авылдан ерак түгел генә шәһәр төзетепме?

Баязит. Шәһәрне мин төземәдем. Аңлыйсыңмы, мин төземәдем. Шәһәрне башкалар төзеде.

Фәрук карт. Ә син кул кушырып карап тордың. Пәриенә каршы килеп. Пәриең күпме әйтте сиңа каршы төшик, шәһәр төзетеп, табигатьне боздырып, телне, авылларны бетертәбез, дип.

Пәри. Әйе. Нигә мине, Пәриеңне эшкә җикмәдең? Мин Пәриең сиңа әйтеп тордым. Шәһәр теленне, милләтенне йотачак, дип.

Баязит. Мин аларга, сандугач тирәгеннән аерылып, чит-ят җирләрдә сайрый алмый, тирәгенә кайтып җан бирә, димәкче идем.

Фәрук карт. Аңлаталдыңмы соң?

Баязит. Кызганычка каршы, аңламадылар шул, аңламадылар...

Пәри. Кендек каннары тамган туган җирләреннән аерып, уенчыкка кызыккан сабый балалар кебек, шәһәрнең якты, такыр урамнарына, буш хыялларга алдап җибәрдең дә...

Фәрук карт. Сагынып-саргаеп, чит-ят җирләрдә туфрак булдык.

Пәри. Авыллар бетте...

Фәрук карт. Тел кипте...

Пәри. Милләт үлде. Абзый читтән карап көлеп торды.

Фәрук карт. Таралган авылымның җимерек мунчасында Пәрием генә дә яшәп калалмады. Телемне, гореф-гадәтләремне сука белән тигезләделәр.

Баязит. Ялгышым кайда? Бәлки миңа үз Пәриемнең дә муенына шул кара мунчада элмәк саласы булгандыр.

Пәри. Еллар узгач, син ул турыда уйламадың түгел, уйладың. Кара мунчаны эзләп тә бардың.

Баязит. Мин ул мунчада Пәрием белән күп тарткалаштым, җиңә алмадым. Юк, юк, мин сине, Фәрук картны, үз нигезенә кайтарып, сагынудан бауга менгереп ялгышмадым. Ул минем ялгышым түгел, ул минем табышым иде.

Фәрук карт. Мин яшәргә хаклы идем. Мин үз нәселемнең дәвамын күрергә телим. Миннән соң килгән халкымның үз илендә, үз җирендә, үз сандугачымның үзебезнең телдә сайравын телим. (*Әкрен генә, салмак кына җыр суза).*

Тал-тирәктә, инешемдә
Сандугачым җыр суза.
Моңы таныш, сазы таныш,
Йөрәгем тибешендә.

Тал-тирәктә, инешемдә
Суларың кибеп бара.
Милләтеңә ясин чыгып,
Козгыннар аваз сала.

Тал-тирәктә, инешемдә,
Башкалар оя кора.
Синең җырың тыңлар өчен,
Милләтең үлеп бара.

Баязит. Шулай шул. Нигезен ташлап киткәннәрнең үз сандугачлары булалмый. Нигезен ташлап киткәннәр — килмешәкләр! Килмешәк үз гореф-гадәтләре, үз дине, үз кыйбласы белән яши алмый. Иртәме-соңмы күпчелеккә буйсына. Башта утрау булып яши, бистә була, урам кора, бала тудыра, күршесенә кыз бирә, малай өйләндерә — туй итә, намазлыгын җәеп, кыйбласына бага. Ят тел белән итәгеннән оныгы килеп тарткач, укыган догасыннан бүленеп, аңа борыла. Телен оныткан оныгына алар теле белән җавап бирә. Милләт бетә. Намазлыкта бабаң милләтенә ясин чыга.

Күпме генә тырышса да, ул үз артыннан оныкларын ияртә алмый. Сагынып, саргаеп, үз-үзенә хөкем чыгара. Кабер ташы ава, койма җимерелә, ул урында билчән үсә.

Сагынасызмы, дип сорыйсыз,
Сагынмаган кая ул,

— дип язды минем бер каләмдәш дустым. Син бит минем күңелемдә яшәүче, җанымны, вөҗданымны кимерүче милләтемнең ак бабае.

Фәрук карт. Миңа авыр, ай авыр. Авылымны киредән торгыз.

Баязит. Булмый, дустым, булмый. Таркату җиңел, торгызу авыр.

Фәрук карт. Авылдашларымны сагынам.

Баязит. Аларның күбесе, якты дөньяны калдырып, гүр ияләре булдылар.

Фәрук карт. Балаларым, оныкларым исән. Син — әдип. Оныкларымның, балаларымның Пәриләрен уят.

Баязит. Көчем житәрме?

Пәри. Мине, Пәриеңне эшкә җик.

Баязит. Өлгерерменме, Пәрием?

Пәри. Өлгергәнчә яз.

Баязит. Аяусыз син, язмыш.

Фәрук карт. Ә син яз, яз! Пәриеңне уятырлык итеп яз. Пәриләләр генә дөньяны үзгәртә ала.

Баязит. Кил әле, Фәрук бабай, ак бабай, кил әле, яныма утыр. *(Фәрук картка уң кулын сала.)* Бу дөньяда Пәриле адәм баласына яшәүләре айһай авыр. Менә өстәлдә ике чынаяк. Алтын билбаулысы — минем өлкән улым Ислам. Сәрхуш булып урамда үлде. Ә монысы, көмеш билбаулысы — кече улым Хисам. 23 яшендә үз подъездында атып үтерелде. Аларның үлеменә минем Пәрием гаепле. Минем җилкәмдә көяле шәл. Хәбәрсез югалган Хәтирәм шәле.

Пәри. Юк, юк, хатирәләрнең хәбәрсез югалырга хакы юк. Хатирәләрнең эзсез калырга хакы юк.

Баязит. Ул хатирәләр кайтаваз булып киләчәк буынга кайтырмы? Минем күңелемдә уелып калган җанымны, бәгъремне аңлаучылар табылырмы? Киләчәк минем романнарымдагы, хикәяләремдәге ялгышларымны аңлармы? Мин шуларга җавап эзлим. Әйт әле, ак бабай, Баязит бәхетлеме? Элек байны талап, хәерче хәерче калса, хәзер хәерчене хәерче талап, бай булмадымы?

Фәрук карт. Ә син яз, яз син, Баязит.

Баязит. Нәрсә хакында?

Пәри. Озакламый байны бай талар, дип яз.

Баязит. Куркам, куркам, ак бабай. Тагын күпме башлар харап китәр.

Пәри. Алайса, башкалар кебек, миннән котыл.

Баязит. Мин — сине, син мине сагыныребыз бит, Пәрием.

Пәри. Мин — Пәри. Мин сагына да, саргая да, ярата да белмим.

Баязит. Алдашма. Телисеңме, мин хәзер сине үзем белән алып китәм?

Пәри. Көчең житми. Сиңа китәргә мин Пәриен ирек бирмәячәкмен.

Баязит. Үз-үзеңә зур бәя бирмисеңме?

Пәри. Хәйләкәр син, хуҗам. Минем җавабымны көтәсең?

Баязит. Әйе, көтәм.

Пәри. Күчәм!

Баязит. Кая?

Пәри. Синең арттан килүчеләргә күчәм.

Баязит. Килерләрме?

Пәри. Алдыңда яңа китап.

Баязит *(кулына өстәлдән яңа китапны ала да, китапка карап)*. Димәк, мин ялгышмаганмын. Киләләр!

Пәри. Киләләр!

*Ишек катына Кәримә килеп баса. Пәри белән Фәрук карт юкка чыгалар.*

Баязит *(китапны куеныңа кы-*

*сып).* Димәк, киләләр. *(Китапны болгап.)* Киләләр, киләләр! *(Кулындагы китабын күккә чөеп.)* Киләләр! Ишетәсезме, киләләр! Сезгә әйтәм, алар киләләр! *(Кәримәне күреп, аның янына килә.)* Сенлем, Кәримә, ишетәсеңме, алар киләләр. Киләләр, киләләр! *(Китап киштәсенә төртеп.)* Димәк, алар минем... *(Китап киштәсе алдына барып тезләнә.)* Әсәрләремдәге образларның авазларын ишеткәннәр. Ишеткәннәр! Киләләр! Киләләр!

Кәримә *(сәерсенеп).* Киләләр, киләләр. Ишекне ачыйммы?

Баязит. Көләсең? Көлегез, көл! Ә мин көлмим. Менә, менә ул бездән соң килә торган Пәриле китап! Менә ул бездән соң килә торган Пәриле егет! Мин үз Пәриемә ышанам. Минем Пәрием алдамый. *(Тезләнеп, китапны кадерләп кенә идәнгә куя да, сак кына пышылдап.)* Рәхмәт сина, рәхмәт, Пәриле егет, рәхмәт! *(Күңеле тулып арткы планга китә.)* Бирешмә, бирешмә, егет! Безнен кебек заман җиленә буйсынып, үз Пәриенә хыянәт итмә, егет! Хәерле юл, хәерле юл сина, Пәриле егет!

*Салмак кына моңлы көй агыла. Ут сүнә.*

*Пәрдә.*

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

*Шул ук картина.*

*Пәрдә ачылганда Баязит, хыялына батып, өстәлдәге чынаякларга чәй агыза. Чәй чынаякларга акмыйча, өстәлгә ага.*

Баязит. Нишләвем бу?

Пәри. Дөньялыктан киткән улларың Ислам белән Хисамга чәй агызасың.

Баязит. Кәримә! Кәримә, кызым, кер әле!

Пәри. Ни булды инде?

Баязит. Өстәлгә чәй агыздым.

Пәри. Тагын мин Пәриенне гаепләрсең әле.

Баязит. Син, син гаепле! Хыялымда син Пәрием белән тарткалашып, кулыма кайнар чәй агыздым.

*Икенче бүлмәдән Кәримәнен «хәзер, хәзер» дигән тавышы ишетелә. Бүлмәгә Кәримә керә.*

Кәримә. Баязит Әсһәдуллович, нәрсә кирәк?

Баязит *(кулын селки-селки).* Теге мәлгунь өстәлгә чәй агызды.

Кәримә. Кем?

Баязит. Кем булсын инде, Пәри!

Кәримә *(аптырап, сәерсенеп).* Алай икән... Күзенә күренәдер инде, әйеме, Баязит Әсһәдуллович.

Баязит. Нәрсә?

Кәримә. Пәри.

Баязит. Сенлем, ничек Пәри күзгә күренсен? Башымда йөри, башымда йөри, сенлем. Пәри күзгә күренә димени?! Әллә саташасыңмы?

Кәримә. Өстәлгә кем чәй агызды соң?

Баязит. Җанымны яулап алган Пәрием.

Кәримә. Кая, күрсәт әле? Кулыңны пешермәденме?

Баязит. Ташласана. Узар әле. Миңа чәй керт әле. Нигәдер туңып киттем.

Кәримә. Әнә ич, ике чынаягыңа да чәй агызгансың, эч шуларны.

Баязит. Ярамый. Пәрием кушмый. Берсе — Исламымныкы, икенчесе — Хисамымныкы.

Кәримә. Алайса, Пәриенә әйт. Сиңа да ясасын.

Баязит. Үзенә үзен яса, дисең инде. Әй, кызым, кызым, Кәримә сенлем, минем Пәрием — минем жаным ул.

Кәримә. Пәри — жаның, ә мин жененме?

Баязит. Кызым, сине үпкәләтергә теләвем түгел. Синең кулың тәмле. Син ясаган чәйне эчсәм, үземне ялгыз итеп тоймыйм. Картайган көнемдә ялгызлыктан куркам. Өстәлдәге чынаякларга чәй агызам да ике улымны да янымa чакырам. Хыялымда шулар белән сөйләшеп, чәй эчәм. Читтән карап торган кешегә тиле булып тоеламдыр инде. Әле менә шуларга чәй ясыйм дип, хыялыма чумып, кулыма ялгыш кайнар чәй агызганмын.

Кәримә. Алар бит инде үлгәннәр.

Баязит. Үлсәләр соң?! Алар бит минем күңелемдә исәннәр.

Кәримә. Бүтән чакта үзем агызып куярмын.

Баязит. Кирәкми. Кирәкми, кызым. Бар үкенечем шул: исән чакларында мин аларга үзем ясап бер генә тапкыр да чәй эчертә алмадым. *(Кулына алтын беләзекле чынаякны алып.)* Менә монысы — өлкән улым Исламныкы. Алтын билбау белән. *(Икенче кулына көмеш билбаулы чынаякны алып.)* Ә монысы — төпчегем Хисамымныкы. Алар дөньяга килгәч, алтын-көмеш кебек булсыннар дип теләк теләп, беренче китабым акчасына алып кайткан идем.

Баязит *(чынаякларына карый да).*

Дөнья сукмагыннан атлаганда,
Уң кулымда иде алтын чынаяк,
Сул кулымда — көмеш чынаяк,
Чынаяклар төшеп челпәрәмә килсә,
Яшәү авыр, яшәү авыр икән, балалар.

*Салмак кына жыр суза.*

Идел бит ул – бик мул елга,
Ул бит диңгезгә китә.
Аккан сулар, искән жилләр
Йөрәгемне жилкетә.

*Куплетның азагында тузган киемсалым кигән бомж кыяфәтендә Ислам керә дә, ишек янагына сөялеп, жырның азагын тыңлап тора. Баязит аны сизми.*

Ислам.

Аккан сулар кире кайтмый,
Яшь гомерләр дә шулай...

Баязит. Кем син?

Ислам. Ислам. Синең алтын беләзекле чынаягың!

Баязит. Ә, алтын чынаягым? Энең Хисам, минем көмеш чынаягым кая? Килмәдемени? Мин сине бу кыяфәттә көтмәдем.

Ислам. Нинди кыяфәттә?

Баязит. Бомж кыяфәтендә. Бар, киенеп кил. Мин бит сине...

Ислам. Булмый. Мин кешеләр күңелендә шушылай сакланам.

Баязит. Нигә алай?

Ислам. Дөньялыктагы этләрен талады. Нигә чакырдың?

Баязит. Мин сине чакырмадым.

Ислам. Тынгы бирмисең. Тынычлап ятарга бирмисең.

Баязит. Мин сине чакырмадым. Мин синең тынычлыгыңны бозарга теләмәдем.

Ислам. Чынаягыма чәй агыздың.

*Пәри киштәдән башын чыгара.*

Пәри. Мин агыздым.

Баязит *(Пәригә).* Чакыргач, чык, әйдә. Нигә киштә ярыгыннан гына карап торасың? Актар ата йөрәген. Рәхәтлән!

Ислам. Тагын нәрсә кирәк сиңа миннән?

Баязит. Жаныма урын табалмыйм.

Ислам. Мине үз яныңа чакырып табармын дип уйлыйсыңмы?

Баязит. Тәрәзәдән дөньяга карыйм да уйларыма чумам. Пәриемә дәшәм.

Ислам. Бармы соң әле ул синең Пәриең? Саклый алдыңмы син аны?

Баязит. Шул сорауга җавап табалмаганга, синнән ярдәм сорыйм.

Ислам. Сатып алмадылармы синең ул Пәриеңне?

Баязит. Үземне дә шул сорау борчый.

Ислам. Очсыз хак сорамадыңмы? Күрәм, без киткәч, дөньясы бик үзгәрмәгән. Һаман да шул кабак, һаман да шул ук кешеләр. Кием үзгәргән, нәфес, намус үзгәргәнме?

Баязит. Бәлки күнел байлыгы белән китүчеләр күбәйгәндер.

Ислам. Күнел байлыгы белән килүчеләр кирәк.

Баязит. Нигә иртә киттең?

Пәри. Урынсыз сорау. Аңа китәргә мин, синең Пәриең ярдәм иттем.

Баязит *(Исламга.)* Нигә минем арттан атламадың?

Ислам. Синекеләр Пәриемне күсәк белән кыйнап үтерделәр. Мин бит халык дошманы Баязит баласы. Мин бит враг народаның баласы. Миңа яшәр өчен сынык икмәк табулары да ай-һай авыр иде. Миңа нәселебезне дәвам итәргә авыр иде. Миңа итәгемә утыртып балалар сөяргә, оныкларымны сөяргә ярамый иде, ярамый иде. Мин үземнең яшәешемнең чагылышын балаларымда, оныкларымда күрәсем килмәде. Җир өстендәге үз язмышымны бүтәннәр кабатлавын теләмәдем. Мин бу дөньяга сартир булып тудым.

Баязит. Нигә? Мин гаепleme?

Ислам. Син һәм синең Пәриең!

Баязит. Минем гаебем юк! Минем Пәрием гаепле түгел! Синең Пәриең минем Пәриемнән көчсез булганга, минем гаебем юк.

Ислам. Үз жаныңа тынычлык эзлисең. Барып чыкмас. Әгәр мин ул вакытта, син колхоз төзеп йөргән чагында, синең Пәриеңә каршы барсам, миңа ул вакытта яшәү юк иде. Әгәр мин ул вакытта синең Пәриеңә колак салып, хәер-догада булсам, бүген миңа яшәү юк иде. Син минем өчен дә, энем Хисам өчен дә, анабыз Хәтирә өчен дә яшәдең.

Баязит. Димәк, мин — карак? Димәк, мин сезнең гомерегезне урладым?

Ислам. Урламадың. Үзең бирдең, үзең алдың. Син безнең балачак хатирәбезне урладың!

Баязит. Димәк, мин сезне хатирәсез калдырдым?

Ислам. Әйе. Син безнең матур, яшь, кояштай балкып торган хатирәбезне урлап, безнең өскә кара болыт каплaдың. Без шул салкын кара болыт астыннан чыгалмыйча, туңып, шәбәреп, кагылып, сугылып, хатирәсез китеп бардык.

Пәри. Бирешмә, бирешмә, хуҗам. Син — әдип! Сиңа бирешергә ярамый.

Баязит. Бәлки ул хаклыдыр?

Пәри. Юк, юк, ул хаклы түгел! Әдипнең зурлыгы — бәхәстә. Әдипнең зурлыгы — фикерләр бәрелешендә.

Ислам. Билгеле, һәр кеше үз баласын матур итеп күрергә тели. Син мине хыялыңда матур итеп киендереп китерәсең килгәндер.

Пәри. Ә ул кеше түгел, ул — язучы! Мин Пәрие аңа аркылы төштем. Мин, мин сине бомж кыяфәтендә китерәсем килде.

Ислам. Нәрсә өчен?

Пәри. Бәхәс өчен.

Ислам. Шуннан кемгә файда?

Пәри. Укучыга.

Ислам. Ә миңа?

Пәри. Син — бирәү. Ул меннәр өчен туган. Ул — язучы. Ул дөньяны башкача күрә. Ул синең кебек кара болыт астында калганнарны яктылыкка, кояш астына чыгарыр өчен туган.

Ислам. Бәлки минем дә кояш астында яшисем килгәндер.

Пәри. Бар җиһан кояш астында яшәсә, әдипнең кирәге калмас иде.

Ислам. Ике улын, хатынын корбан итеп, Баязит нәрсә кырды? Пыскып янган чи усак утыны хәлендә калдымы?

Пәри. Бәлки Баязитның дәрләп

януы кирәкмидер? Анын пыскып озак януы хәерлерәктер.

Баязит. Дөрләп янганнар күптән янып бетеп онытылдылар. Бәлки мин гомерем буе укучы күзенә төтен генә җибәргәнмендер?

Ислам. Хак! Пыскып янган утынның җылысы булмый, төтене генә була.

Пәри. Ә безгә төтене кирәк, төтене. Кемнәрнеңдер күзенә кереп, безнең барлыкны белгертеп торырга төтене кирәк.

Ислам. Ә миңа җылы кирәк. Аңлыйсызмы, җылы кирәк.

Баязит. Ә син ашыкма, улым, ашыкма. Пыскыган учак кызып ята да, бер дөрләп янып китә ул.

*Бүлмәдә Хисам пәйда була.*

Хисам. Ә син шуның кызганын көтеп ятасыңмы? Син кабызган учакка су сиптеләр. Колхоз бетте, социализм бетте. Син сөргенгә куганнар кире дән кайтты, әткәй.

Баязит. Юк, юк, алар кайтмады, алар кайтмады. Син ялгышасың, алар кайтмады.

Хисам. Хәерче байдан аерылды.

Баязит. Минем ярлының өстәлендә икмәк күрәсем килде. Ул көн килде.

Ислам. Өстәлдә — икмәк, күңелдә — бушлык.

Баязит. Иман дисең инде...

Хисам. Иман? Нәрсә соң ул иман?!

Ислам. Иман ул, энекәш, менә синең үз подъездыңда атып үтерелүең.

Хисам. Ә син нәрсә кырдың? Нәрсә кырдың, алтын беләзекле Баязитның өлкән улы Ислам? Пивнушка төбендә хәер сорашып, каткан туның белән теге дөньяга киттеңме?

Ислам. Мин атамның хатасын аңладым.

Хисам. Ул атасының хатасын аңлаган!

Ислам. Мин тудырган атама хыянәт итмәдем.

Хисам. Ул атасына хыянәт итмәгән. Менә мин хыянәт иттем. Ә менә мин ул төзегән стройда үстем. Күрдем! Кыйналдым! Үлчәдем! Аның хатасын аңлап, шушы юлга бастым.

Ислам. Мин кеше өлешенә кермәдем.

Хисам. Ә мин кердем.

Ислам. Мин кеше алдамадым.

Хисам. Ә мин алдадым. Атам алданган кебек, минем дә алданасым килмәде.

Баязит. Дөрләп яндың да юкка чыктың.

Хисам. Минем пыскып янасым килмәде. Минем Пәрием шуны теләде. Әнә алтының пыскып, кисәү булып, дөньялыктан китеп барды.

Ислам. Мин үз үлемем белән киттем.

Хисам. Ә мине аттылар.

Ислам. Котырган эт хәлендә аттылар.

Хисам. Мылтыкка дарыны атам Баязит салды. Мылтыкка кургашны атам Баязит салды. *(Баязитка.)* Син, син житмеш ел буена халыкны хәерчелектә яшәттең. Син атаң Әсһәдуллага каршы барсаң, ә мин сиңа каршы бардым. Дөньяны мин үзгәртмәдем. Син корган колхозны мин туздырмадым. Син сөргенгә сөргәннәр, кайтып, синең колхозыңны туздырмадылар. Үзегез, үзегез туздырдыгыз.

Баязит. Кем инде ул — сез?

Хисам. Сез — коммунизм төзүчеләр! Туннарын кире ягы белән әйләндереп киючеләр!

Баязит. Ә мин беркайчан да тунымны әйләндереп кимәдем.

Хисам. Кимәсәң, кидерделәр. Житмеш ел буена туныңның тискәре ягын киеп йөргәнгә, үз җаныңа тынгы табалмыйсың. Пәриең безгә тынгы бирми. Хатаңны бездән эзлисең.

Баязит. Житте, булды! Күземнән югал! Күземнән югалыгыз!

Хисам. Алдады, алдады сине Пәриең, әткәй.

Пәри. Юк! Юк, мин аны алдамадым. Мин аны алдамадым! Ул мине күңеленең түренә яшерде.

Ислам. Әткәй, син инде безне үз янына бик чакырырга тырышма. Без синең жанына рәхәтлек бирә алмабыз.

Баязит. Нишлим? Пәрием чакыра.

Хисам. Пәриенә әйт. *(Китап киштәсенә төртеп күрсәтеп.)* Әнә бит алар синең күпме. Чакырсын шундагыларны.

Пәри. Хужам, басу каравылчысы Миңнулланны чакырыйммы? Хәзер үк мылтыгын асып, орденын ялтыратып килеп житә.

Баязит. Чакыр. Әгәр шул мылтыгы белән үземне атып үтерерлек булса, чакыр. Ә хәзер үземне генә калдырыгыз.

Ислам. Кинәш шул сиңа, әткәй. Күрәсең, ике улың да бер-берсенә капма-каршы, өстәлендәге ике чынаякны да бер-берсенә бәр дә челпәрәмә китер.

Пәри. Чынаяклар ватып кына узганны үзгәртеп булмый шул.

Хисам. Алайса, инсәнә шәленне сал.

Баязит. Явыз сез! Узган юлың, Хәтирән исенә төшсен дисезме? Югалыгыз! Күземнән югалыгыз! Минем күзләремне йомасым килә. Миңа ял кирәк ! Миңа бер генә секундка булса да күзләремне йомарга кирәк!

*Кабалана-кабалана машинка төймәләренә баса. Ислам белән Хисам, Пәри юкка чыгалар. Бүлмәгә Кәримә керә.*

Кәримә *(ашыгып килеп Баязитны тотып).* Баязит Әсһәдуллович, Баязит Әсһәдуллович, нишләвегез бу, нишләвегез? Тынычланыгыз, тынычланыгыз.

Баязит. Жибәрегез, мине жибәрегез! Миңа онытылырга кирәк. Миңа онытылырга кирәк.

Кәримә. Әйдә әле, әйдә, Баязит Әсһәдуллович, ятып торыйк.

Баязит. Кирәкми, кирәкми, сеңлем. Шушы машинка төймәләре генә миңа тынычлык бирә. Шуның төймәләренә бассам, яна әсәр баскан кебек, узгандагы уй-хыялларымнан качам.

Кәримә. Әйдә, әйдә әле, ятып торыйк, Баязит Әсһәдуллович. *(Баязитны ятагына яткыра.)* Хәзер мин сиңа кайнар чәй кертәм. Калтырыйсың, калтырыйсың, Баязит Әсһәдуллович. Әллә тундыңмы? Хәзер өстенә яраткан шәленне салам.

Баязит *(сикереп тора).* Кирәкми! Шәл кирәкми! *(Елап.)* Зинһар өчен шәл кирәкми. Кызганыгыз мине. Миңа шәл кирәкми.

Кәримә. Ярар. Одеял капLармын. Тынычланыгыз. Ник болай борчыласыз сез, Баязит Әсһәдуллович, ник борчыласыз?

Баязит. Пәрием тынгы бирми. Секунд саен, минут саен узганымны исемә төшереп тора.

Кәримә. Узганында күңелле мизгелләр булмадымыни соң синең? Әйт Пәриенә, шуларны исенә төшерсен.

Пәри *(киезләнгән чәчен тарап, киштәдән аякларын асылындырып утырган халәттә).* Нигә булмасын, булды. Ул бит аларны чакырырга кушмый.

Кәримә. Мин хәзер кайнар чәй кертәм. Ә син тынычлан.

*Чыгып китә.*

Баязит. Әй Баязит, Баязит, гомерең буе машинка шыкылдатуларың бушка булдымыни соң синең?

Пәри. Ник алай дисең?.. Ә Лилиян?! «Агыйдел» повестеңдагы Лилиян!

*Серле музыка янгырый. Сәхнәдә утлар гаммасы уйный. Аңа дулкыннар шавы кушыла. Ап-ак күлмәктән, сап-сары озын толымлы, күләч йөзле Лилия, шырык-шырык көлеп, сәхнәгә чыга да, дулкыннар шавына*

*кушылып, йөзеп бии башлый. Баязит торып утыра. Лилия бию азагында Баязитны кулыннан эләктереп ала, бөтерә һәм алгы планга алып килә. Яр буенда утырган халәт ясап, сәхнә алдында аякларын асылындырып утырта. Үзе аны яратып, артыннан кочаклап тезләнә.*

Лилия. Баязит, син мине сагындыңмы?

Баязит. Минем сагыну сиңа кирәкме?

Лилия. Син бит миңа җан өрүче.

Баязит. Мин — җан өрүче. Сине яшәтүчеләр сине сагынсын иде.

Лилия. Алары кем тагын?

Баязит. Укучы.

Лилия. Алар мине, синең сөйгәнең булганмын, имеш, су коенганда Агыйделгә батып үлгәнмен дә, син минем турыда хикәя язгансың, дип сөйлиләр. Бу дөресме? Мин синең сөйгәнеңме, Баязит?

Баязит. Син ничек уйлыйсың соң, Лилия?

Лилия. Белмим. Шул сорауга җавап эзлим.

Баязит. Мин бик күп яздым. Гарибен дә, горабасын да, аксагын да, туксагын да, чибәрен дә, ямьсезен дә. Шулар арасында иң гүзәле, иң чибәре, Агыйдел гүзәле — син!

Лилия. Димәк, син миңа гашыйк.

Баязит. Язучы үзе тудырган образга гашыйк булмаса, ул аны тудыра алмый, Лилия.

Лилия. Ә нигә миңа Лилия дип исем куштың?

Баязит. Син бит Агыйдел кызы. Ата-бабаларыбызның ишкәк ишкән, җәтмә салган Агыйдел елгасының төнбоегы, гүзәле.

Лилия. Син дә җәтмә салдыңмы?

Баязит. Салдым.

Лилия. Җәтмәңә мин эләктемме?

Баязит. Белмим. Анысын укучы гына әйтә ала. Сабый чактан хыялый булдым. Хыялымда үзем сайлыйсы ярның синдәй булуын теләдем.

Лилия. Таптыңмы соң, Баязит?

Баязит. Таптым да югалттым. Җәтмәм ныклы булмады. Тишелде, суга акты.

Лилия. Баязит, нигә син мине матур итеп яраткач, су кызы итеп яраттың?

Баязит. Син — матурлык алиһәсе. Җирдә яшәү аяусыз. Өзәрләр дип курыктым. Минем Лилиямне өзгән кебек, сине дә өзәрләр дип курыктым. Көндез ачылсын да төнлә йомылсын, төнен килеп бөрәр явызы өзмәсен дип курыктым.

Лилия. Ә ни өчен мин биюче?

Баязит. Матур биегәнгә биюче.

Лилия. Суда биеп буламы?

Баязит. Сабый чагымда Агыйделгә балык тотарга төшәм дә сәгатьләр буе төнбоекларга карап утырам. Су өстеннән йөзгечләр узганда, дулкыннар күтәрелә дә сезгә, төнбоекларга бәрелә. Камышлар көй суза, ә сез шул дулкыннар өстендә салмак кына халкым рухында бии идегез.

Лилия. Баязит, минем биюем кемгә кирәк?

Баязит. Сәфәр чыккан, ишкәк ишкән юлчыга. Ә син минем сабый чагымны хәтерлисеңме, Агыйдел кызы Лилия?

Лилия. Хәтерлим, ник хәтерләмим. Талдан үргән савытыңны күтәреп килә идең дә, кармагыңны салырга да онытып, чебиле аякларыңны ярдан суга асылындырып, сәгатьләр буе баржа бушаткан, баржа тарткан ач-ялангач бурлакларны карап, балыксыз кайтып китә идең.

Баязит. Мин ул чакларда дөньяның матурлыгын бары тик сездә генә күрә идем.

Лилия. Ул чакларда син бик матур итеп сагышлы җыр суза идең.

Баязит *(җырлый)*.

Бардым күлгә, салдым кармак,
Безгә балык эләкми шул.

Йөгереп китәрдәй булам да,
Кайтып җитәрдәй булам.
Көзге ачы җилләрдә лә,
Яшәү авыр илләрдә.
Көзге ачы җилләрдә лә,
Яшәү авыр илләрдә.

Лилия. Һаман да җырлыйсыңмы бу җырынны, Баязит?

Баязит. Кызганычка каршы, җырларга туры килә шул.

Лилия. Баязит, таң атып килә. Миңа китәргә вакыт.

Баязит. Китмә, китмә әле, су гүзәле. Тагын аз гына янымда бул.

Лилия. Миңа ачылырга вакыт. Юлчыларга биеп калырга кирәк. Үзең кил, үзең!

Баязит. Китеп барышым.

Лилия. Еракками, Баязит?

Баязит. Мәңгелеккә, төнбоек.

Лилия. Без дә синең белән китәрбезме, Баязит?

Баязит. Төнбоеклар калыр. Ә менә минем Лилиям... Белмим, әйтә алмыйм. Анысын киләчәк әйтер.

Лилия. Сине дә биеп озатырмынмы мин, Баязит?

Баязит. Белмим. Син биеп озатсаң, димәк, мин яшәгәнмен. Димәк, мин җир өстеннән атлаганмын.

Лилия. Сау бул, Баязит.

Баязит. Сау бул, туган җиремнең бердәнбер гүзәле, Лилиям! Сау бул, Агыйдел гүзәле! Сау бул...

*Бүлмәгә Кәримә керә.*

Кәримә. Кем белән хушлашасың, Баязит Әсһәдуллович?

Баязит. Үзем белән үзем.

Кәримә. Үзең белән үзең хушлашып буламыни ул?

Пәри. Була.

Баязит. Кызым, әнә киштәнең өченче бүлегеннән бишенче китапны алып бир әле.

Кәримә. Ул китап белән нишләмәкче буласың инде тагын?

Пәри. Алып бир диләр бит сиңа.

Кәримә. Шул китапларыңны актарасың да җенләнәсең, актарасың да җенләнәсең.

Пәри. Юк, ул җенле түгел, ул җенле түгел...

Баязит. Мин — Пәриле! Мин җенле түгел, мин — Пәриле.

Кәримә. Ачуым килмәгәе, кадалып кит шул Пәриең белән. Синеңчә булсын.

Пәри *(үкереп елап)*. Рәхмәт сиңа, рәхмәт, хуҗам!

*Пәри барып Баязитны кочаклап елый. Аңа Баязит та кушыла.*

Баязит *(елый-елый)*. Мине Пәрием беркайчан да ташламады. Рәхмәт сиңа, Пәрием, рәхмәт!

Кәримә *(тамашачыга)*. Вәт дивана карт, дивана карт... Идән уртасына утырып, мин дивана түгел, мин Пәриле дип елап утыра. Моны дивана дими, кем дисең инде?

Баязит. Их, сеңлем, сеңлем, әдип булу өчен Пәриең булу кирәк.

Пәри. Пәрисезләр — алар коллар.

Баязит. Әйт әле, сеңлем. Минем Пәрием булдымы?

Кәримә. Баязит Әсһәдуллович, синең Пәриең генә түгел, шайтаның да, җенең дә, убырлы карчыгың белән Кощей бессмертныең да булды. Бу ун ел эчендә үземә дә Пәри ояланы бугай инде.

Баязит. Әгәр минем Пәрием булмаса, мин сезнең өчен, халкым өчен ике улымны, хәләлемне югалтыр идемме?

Пәри *(Кәримәгә)*. Кимсетмәвегезне сорыйм. Синең Пәри исән. Пәриең исән булганга, син үз-үзеңә тынычлык табалмыйсың.

Баязит. Башкалар да минем газапны кичерәме?

Пәри. Юк! Күпләр күңелендә — шайтан! Мин — синең Пәриең шуларның шайтаны белән сугышам.

Баязит. Кызым, Кәримә, әнә китап киштәсенең өченче бүлегеннән

бишенче китапны алып бир, дидем бит!

Кәримә. Ярар. Укы да җенлән, укы да җенлән.

*Китап киштәсенә китә.*

Пәри. Әллә бу бала хаклымы? Әллә син хаталанасыңмы? Ун ел үз янында яшәтеп, язучының Пәриле булуын да төшендерәлмәгәч, син, Баязит Әсһәдуллович, кем буласың?

Кәримә *(киштәдән китап алып укый).* «БҮРЕ»! Роман. Ярый әле монысы Пәри түгел.

Баязит *(сикереп тора. Тотып ашардай булып Кәримә өстенә килә).* Син нәрсә, сеңлем? Мине тереләй кабергә кертәсең! Мин нәрсә, гомерем буе бу киштәгә чүп-чар язып тутырган дип уйлыйсыңмы әллә?

Кәримә *(куркып, китапны Баязитка ыргыта).* Бу тәмам ычкынды бугай, уктала ук башлады. Исән чагында чыгып качарга кирәк. *(Ишеккә омтыла, абынып егыла.)* Әстәгъфирулла, әстәгъфирулла... *(Сикереп тора да чыгып кача.)*

Баязит. Әллә бу бала, әллә мин саташам.

*Кулына китабын ала. Серле музыка. Сәхнәнең уң як алгы планында прожектор яктысында Мифтахетдин пәйда була.*

Мифтахетдин. Тәккә рәнҗеттең баланы, Баязит. Тәккә...

Баязит. Ә, син икәнсең әле, Бүре Мифтахетдин!

Мифтахетдин. Ул хаклы. Юк синең Пәриең.

Пәри. Бар!

Баязит. Бар минем Пәрием, бар!

Мифтахетдин. Юк, юк синең Пәриең!

Баязит. Ә мин бар димен!

Мифтахетдин. Сатылды синең Пәриең.

Пәри. Кемгә? Кайчан?

Мифтахетдин. Шәхес культы елларында Колымада үтереп кайттың син аны.

Баязит *(озак паузадан соң).* Мин курыктым. Мин генә түгел, күпләр куркытылды.

Мифтахетдин. Шуңа минем китап киштәсендә тузанга батып укылмыйча ятуыма җавап табалмыйсың да.

Баязит. Димәк, мина ясин чыгарга килдең? Миңа нишләргә иде?

Мифтахетдин. Минем хакта язмаска иде.

Баязит. Минем гадел тормыш төзисем килде.

Мифтахетдин. Төзедеңме соң?

Баязит. Атам мулла Әсһәдулла бәхиллеген алмыйча ялгыштым.

Мифтахетдин. Бер ат, ике сыер... Бер камыт та бер сарык! Барысын бергә җыйсаң, бер кулак. Ә нәтиҗә?

Пәри. Кулак дисең инде...

Мифтахетдин. Ә син кулакны аермакчы булдың. Кулакны аерып, бармакларны тигезләмәкче булдың.

Баязит. Син мичтән чыккан кабарып торган икмәкне каз маена манып ашаганда, синең күршең Галәвинең балалары алабута катыш арыш икмәгенә дә туймый иде.

Мифтахетдин. Минем анда ни эшем бар? Минем Галәви хатыны белән йоклаганым булмады. Балаларын туйдыралмагач, таптырмасын иде. Нәрсә, мине сөргенгә сөреп, минем балаларымның да алабута катыш арыш икмәге ашаганнарын теләдеңмени?! Бармакларны тигезли алдыңмы соң, Баязит?

Баязит. Һәр бармакның үз урыны.

Мифтахетдин. Чәнти бармак борын казыр өчен, Баязит. Алар чәнти бармак булып туганнар, чәнти бармак булып киттеләр дә.

Баязит. Ныклап тотар өчен барысы да кирәк.

Мифтахетдин. Ныклап тотты-

гызмы сон, Баязит? Дәшмисен? Баш бармак белән урта бармакны кисеп, ерак китеп булмый, Баязит. Борын казыйсы гына кала.

*Баязит хәлсезләнеп идәнгә тезләнә. Азаплана-азаплана күлмәгенең өске төймәсен ычкындыра.*

Баязит. Кәримә! Кәримә сеңлем, су... Су бир әле!

*Бүлмәгә кабаланып Кәримә керә.*

Кәримә. Нәрсә, нәрсә булды, Баязит Әсһәдуллович?

Баязит. Су... Бер йотым су.

Кәримә. Хәзер. Хәзер, Баязит Әсһәдуллович. *(Ашыгып чыгып китә.)*

Мифтахетдин. Бер йотым су...

Баязит. Сабыр, сабыр. Китәргә ашыкма, Мифтахетдин. Ашыкма. Бары тик бер йотым су...

Мифтахетдин. Бер йотым су... Бары тик бер йотым су!

*Сулы чынаяк тотып Кәримә керә дә Баязитка суза. Баязит, кабаланакабалана, суны эчә.*

Кәримә. Эч, Баязит Әсһәдуллович, эч! Шифасы тисен.

Мифтахетдин. Бер йотым су... Тәмлеме, Баязит?

Баязит *(суны эчә дә, кабаланакабалана).* Мин ялгышларымны уны белән түләдем. Мин үз ялгышларым өчен Ходай алдында да, сезнең алдыгызда да җавап тоттым. Сез йөргән җирләрдә мин дә йөрдем. Сез утырган зинданнарда мин дә утырдым. Мин ялгышларымны ике балам, хатыным Хәтирә гомере белән түләдем.

Мифтахетдин. Бер йотым су... Ә мин чит-ят җирләрдә туган яктан агылган болытларны көтеп ала идем дә җиргә төшкән янгыр тамчыларын, башымдагы бүрегемне салып, шуна җыя идем. Бүрегемне сыгып иреннәремә тидерә идем. Күпләр, туган җирләренен бер йотым суын эчәргә тилмереп, чит-ят җирләрдә туфрак булдылар. Соңгы минутларымда туган җиремнең бер тамчы суын кипкән иреннәремә тидерсеннәр иде дип, соңгы сулышымны алдым. Син бәхетледер инде, Баязит. Синең иреңнә су тидерүчеләрен күптер.

Баязит. Кызганычка каршы, мин ялгыз.

Мифтахетдин. Алдашма, Баязит. Чират торалар диген. Миңнуллаң үзе генә ни тора.

*Жырлый-жырлый Миңнулла керә.*

Миңнулла.

Көне буе карга кудым
Кукуруз басуыннан.
Әй, Миңнулла, һай, Миңнулла,
Ярап булмый, ярап булмый,
Бу дөньяның көенә.

Миңнуллага нәрсә булган? Эш кешесен эшеннән аерып йөртмәсәгез ярамыйдыр.

Мифтахетдин. Мин чакырмадым. Хуҗаң Баязит чакырды.

Миңнулла. Яратмаган сөяге булдым инде. Орден такты да хәзер күпсенә.

Мифтахетдин. Хуҗанны соңгы юлга озатырга да вакыт җитеп килә. Соңгы юлга озатканда, баш очында сез утырырсыз инде.

Миңнулла. Әйе. Минем аннан башка эшем беткән иде. Әнә, елданел каргалар арта. Күкне каргалар болыты каплый. Барысының да бушка ашыйсылары килә. Холостой мылтык шартлатып кына алардан котылып булмый. Дармоедлар күбәйде.

Баязит. Син нәрсә, Мифтахетдин, үлчәүнең бер ягына бастым, икенче ягына бастырырлык геройларың бармы, дисең инде.

Мифтахетдин. Юк. Соңгы сулышыңны алганда, бер йотым су тидерүчең бармы, дим.

Миннулла. Бәлки мин тидерер дип чакыргансыздыр? Гафу итегез. Мин — герой соц. труда! Мине вактөяк мәшәкатьләр белән борчымавыгызны сорыйм. Әнә, өстәлендә ике чынаяк. Салырлар! Мин киттем. Карга куарга. *(Жырлый-жырлый чыгып китмәкче була.)*

Көне буе карга кудым
Кукуруз басуыннан.
Хөршидә, әй, Мөршидә,
Ярап булмый бу кызларның,
Бу кызларның берсенә.

*Сәхнәдә Ислам белән Хисам пәйда булалар.*

Ислам. Ашыкма, ашыкма, Миннулла!

Хисам. Әйе. Кая ашыгасың, Миннулла?

Ислам. Ни өчен без?

Хисам. Әйе, ни өчен без?

Ислам. Ул сезнең өчен яшәде.

Хисам. Безгә нәрсә... Безгә төннәр буе машинка шыкылдавы.

Ислам. Төннәр буе күсәк белән башка суккан кебек машинка шыкылдавы.

Хисам. Сабый чак йокыларыбызны бүлгән машинка шыкылдавы.

Ислам. Баракның алты квадрат метрлы тынчу бүлмәсендәге төшләргә кереп саташтыра торган машинка шыкылдавы.

Хисам. Юк, юк, ул безгә кирәкми.

Ислам. Бутамагыз безне.

Мифтахетдин. Күрәм. Эшләрең жайдан түгел синең, Баязит.

Баязит. Китегез! Күз алдымнан югалыгыз! Кәримә, Кәримә кызым, ку, ку бу адәм актыкларын, ку!

Мифтахетдин. Нәрсә, Баязит, куркак Пәриенне тагы да куркыттыммыни? Янәдән ясин чыгарга кешең калдымы соң, Баязит?

Баязит. Калды. Диванам калды!

Мифтахетдин. Теге, син кызыллардан аттырган Сәләхетдин хәзрәтнең улы мәхдүм Галәветдин тилене әйтәсеңме?

*Киштәдән берничә китап ишелеп төшә, шул урында Галәветдиннең башы күренә.*

Галәветдин. Мин тиле түгел. Мин тиле түгел, мин — дивана!

*Мифтахетдин, Миннулла, Ислам, Хисам — барысы бергә шаркылдап көләләр.*

Барысы бергә: Ха... ха... ха... Ул бит тиле түгел, ул — дивана!

Баязит. Әйе, Галәветдинем дивана. Диванам — минем табышым. Дивананың Пәриен үтереп булмый. Ә сез акыллы. Акыллы башта Пәри яшәтүе ай-һай авыр. Мин диванамны сөргеннән кайткач тудырдым. Мина телем, динем турында сөйләргә ярамый иде. Мин, мулла баласы Баязит, диванамны Себердән кайтып төшкән көнне үк эшкә жиктем. Халкыма житкерәсе уй-фикерләремне диванам аша житкердем. Минем Пәриемне, диванам аша эшкә жиктем.

Барысы бергә. Ә без?

*Ижат иткән образлары Баязитның өстенә килә башлый. Баязит курыккан халдә почмакка поса. Шәл белән йөзен каплый.*

Баязит. Коткарыгыз, коткарыгыз мине!

*Сәхнәдә көлгән авазларга утлар гаммасы уйнавы кушыла. Бераздан сәхнә карангылана. Баязит утырган жирне прожектор яктырта. Шәл урынына Хәтирә пәйда була. Баязитның уң ягында Пәрие, сул ягында куркынган халдә Галәветдине утыра.*

Баязит. Хәтирәм, Хәтирәм, алар мина ясин чыгарга килгәннәр.

Мифтахетдин. Ясин чыгарга иманың бармы соң синең, Баязит?

Галәветдин. Бар, бар аның иманы! Кагылмагыз аңа.

Пәри. Мин, мин — Пәрие аның — иманы.

*Баязит иҗат иткән образлар төрле җирләрдән, шкаф араларыннан, идән ярыкларыннан чыгалар да сәхнәне тутыралар. Алар арасында гариб-горабасы да, аксак-туксагы да, доктор, академигы да, һәм башкалары да.*

Галәветдин. Мин, мин үзем ясин чыгачакмын хуҗама! *(Елап.)* Мин, мин, синең диванаң, сиңа ясин чыгачак.

Баязит *(куенына кысып)*. Рәхмәт, рәхмәт сиңа, минем диванам!

Мифтахетдин, Хисам, Ислам. Ә без, без?

Баязит. Кичерегез мине. Сез миңа Пәриемне яшәтер өчен кирәк идегез. Сез миңа диванамны сөйләштерер өчен кирәк идегез. Хушыгыз! Миңа китәргә вакыт.

Галәветдин *(Баязит янына килә дә, мәче кебек елышып)*. Ишетәсезме, ишетәсезме сез мине? Сез мине, мине, Баязитның диванасын яшәтер өчен кирәк идегез.

*Ап-ак киемнән Баязит арткы планга атлый. Аңа үзе иҗат иткән образлар ияр. Сәхнә караңгылана, сәхнә уртасында прожектор яктысында ялгызы гына ап-ак киемнән дивана ясин чыга.*

Галәветдин. Агыйдибииллилла...

Пәри. Хуш, Баязит!

*Кинәт көчле сихри көй. Ялыкйолык утлар балкышы. Сәхнәдәгеләр юкка чыга. Томан арасыннан ап-ак күлмәктән Лилия йөзеп барган халәттә сәхнә алдына килә дә кулындагы ап-ак яулыгын болгый.*

Лилия. Хуш, Баязит!!!

*Пароходлар гудогы ишетелә. Сәхнә караңгылана. Бераздан сәхнәдә ут яна. Китап киштәсендә бер генә китап калган. Киштәнең өстенә аягын асылындырып Пәри менеп утырган да балалайка чиртеп җырлый.*

Пәри.

Әй замана, замана,
Пәри шуңа таң кала.
Берәү китә, берәү килә,
Үзгәрми шул замана.
Пәри шуңа таң кала.

*Бүлмәгә Яшь язучы белән шәһәрнең зур гына Түрәсе керәләр.*

Түрә. Менә, яшь иптәш, рәхәтләнеп иҗат итегез. Сезгә бөтен мөмкинлекләре булган аерым фатир. Классик яшәгән бүлмә. Язучыга тагын ни кирәк? Яз да яз! Рәхәтләнеп иҗат ит. *(Чыгып китә.)*

*Яшь язучы китап киштәсенә бара да киштәдәге бердәнбер китапны кулына ала, укый.*

Яшь язучы. Дивана!

*Көй яңгырый.*

Пәрдә.



Әлфия
Ситдыйкова

# ҖЫРГА–МОҢГА ТУЛЫ ЕЛЛАРЫМ

## Җиңүгә бер адым

*Нур Баянга*

Җиңүгә калды тик бер адым...
Җилкетә йөрәкне кар суы.
Ашкынып үр арты үр яулый,
Батырлар тыялмый ярсуны.

Дөмегә илбасар фашистлар,
Тончыга-тончыга канына...
Җиңүгә калды тик бер адым...
Бер адым калды таң атуга.

Егерме өчесе апрельнең,
Җиңүгә калды тик бер адым.
Тор, шагыйрь! Егылма, түзем бул,
Чит җиргә башыңны ник салдың?!

Егерме өчесе апрельнең...
Батырның гомере — үлмәс җыр.
Нур Баян исеме хәтердә,
Җырларын яңарта һәрбер чор.

Батырлар, шагыйрьләр мәңгелек.
Гасырлар җуймаслык эзләр бар.
Йөрәкләр түренә үтәрлек
Кан белән язылган сүзләр бар.
Кан белән язылган сүзләр бар...

Әлфия СИТДЫЙКОВА — *шагыйрә; «Йөрәгемә яфрак сыена», «Җанда кабынган учак» һ.б. китаплар авторы. Чаллыда яши.*

* * *

Мин яшьлеккә йөгерә-йөгерә кердем
Балачагым калган үзәннән.
Яңа шыткан гөлгә тама бүген
Яшьлек хатирәсе күзләрдән.

Мин җәйләргә салмак атлап кердем,
Тышауланган иде хыялым.
Шау бакчага якты нурын сибә
Җырга-моңга тулы елларым.

Сары көзгә керәм ашыкмыйча.
Якыная кебек офыгым.
Сабый чакның бер ядкаре булып
Күзгә бага ике оныгым.

Кышларым да озакламас инде...

* * *

Заман шундый, заман кырыс.
Ә син яшәргә тырыш.
Алларга манылмаган шул,
Аклы-каралы тормыш.

Көн дә тетрәү, төн дә тетрәү,
Тетрәп тора дөньясы.
Җир түгел, ил тетрәгәндә,
Башны кая куясы?!

Тетрәүләргә чыдый-чыдый
Яши адәм баласы.
Җимерелсә дә, ишелсә дә,
Алга таба барасы.

Тәгәри ил арбасы...
Килми төшеп каласы...

## Кайту

Ак каен яфрагы саргаеп
Коелды бормалы юлларга.
Каендай саргайган чак булды
Ялгызым яшәгән елларда.

Бик озак кайттың син яныма,
Еракмы йөрәкләр арасы?!

Өрәнге яфрагы төсендә
Җанымның төзәлмәс ярасы.

Ничекләр түздең соң, димәдең,
Аңладың бугай син сүзсез дә.
Чаларган чәчләрем төсеннән
Чагылыр сукырның күзе дә.

* * *

Хатын-кыз итеп яраткан
Туганда мине Ходай!
Хак Тәгаләм, кичер мине!
Ир булып яшим бугай.

Табылмады тормыш йөген
Тартышыр якын кешем.
Хатын-кыз булып тусам да,
Башкарам ирләр эшен.

Сыенып минем җаныма
Яшәргә тели ир-ат.
Хатын-кыз булып яшәргә
Кайчан соң тияр чират?!

Инде кызым минем кебек
Ил йөген салып җанга,
Хатын-кыз булып туса да,
Ир булып атлый алга.

Хатын-кыз итеп яраткан
Туганда аны Ходай.
Хак Тәгаләм, кичерә күр!
Ир булып яши бугай.

Үзебез Ана булсак та,
Ата да булу кирәк.
Ир булып үтә гомерләр...
Шартлама, берүк, йөрәк!

* * *

Алу белән кушулардан тора гомер...
Алуы да, кушуы да — язмыш эше.
Алган чакта: «Тәкъдир», — диеп сабыр итсә,
Кушкан чакта: «Шөкер!» — әйтеп яши кеше.

Бүлгән чагын күргәнем бар ялгышларның,
Кыл икегә, тәкъдир язган язмышларны.
Бөлгән чакта хәтер барлый берәмтекләп,
Гомер буе эзләп тапкан табышларны.

Алу белән кушу гына түгел гомер...

## Ак күбәләк

Ак күбәләк очып йөри янда.
Әнкәемнең изге җаныдыр.
Ингә кунды. Меннәр арасыннан
Төпчек кызын күреп таныйдыр.

Туңган җаным җылыныплар китте
Сизүгә үк канат кагышын.
Ишеткәндәй булдым Әнкәемнең:
«Бәбекәем!» — дигән тавышын.

Мәңгелеккә күчеп киткәчтен дә
Галәм күзе аша багадыр.
Ак күбәләк очып йөри янда,
Изге җанлы газиз Анамдыр.

* * *

Без кайчандыр бер очрашкан идек.
Бер танышкан идек якыннан.
Язмышыбыз уртак булалмады,
Тәкъдирләр бит күктә язылган.

Син бер якта, мин икенче якта
Инләгәнбез тормыш кинлеген.
Кем аңлый соң яшьлек көннәрендә
Янда йөргән кемнең кемлеген?!

Уйлар таный җанга якыннарны,
Аермыйча холкын, милләтен.
Еллар үткәч, искә төшерә вакыт
Танышларның кадер-кыйммәтен.

Без кайчандыр бер очрашкан идек...



Нәҗип Әминов

# СЕБЕР КУНАГЫ

БӘЯН

*Бөек Җиңүгә өлеш керткән авылдашларыма багышлыйм.*

Бүгенге көн Гөлсем апа өчен иртәрәк тәмамланды. Сарык-кәҗәсен абзарга япты, кош-кортларын барлады, көн буе ачык торган бакча капкасын бикләп килде. Әле урамда якты булса да, ишек келәсен төшереп куйды. Ял итәргә кирәк, бетмәс бу дөнья мәшәкате, дип уйлады ул.

Бүген киче дә әйбәт югыйсә. Күрше Галимәләр, Шәмсенурлар капка төбенә чыкканнардыр. Берәрсенең эскәмиясенә тезелешеп гәпләшә торганнардыр. Көтү кайтып, көндәлек эшләрне тәмамлагач, авыл карчыклары капка төбендә сөйләшеп утырырга ярата. Кинога, кичке биләмгә баручы яшьләр дә шушыннан үтә. Бу вакытта кызыксынучан авыл әбиләре кемнең кем белән йөргәненә дә шаһит була. Элекке шикелле, бакча артларыннан яшеренеп кенә, күрешергә килүләр бетте хәзер. Бер кичне егет кызны озатса, икенче кичне инде алар житәкләшеп авыл урамыннан уза. Менә без нинди, янәсе. Элегрәк булса, гайбәт сату өчен иллә дә яхшы тема булыр иде бу, ләкин хәзер кул гына селти әбиләр.

— Заманасы башка инде анын, — дип сөйләп китә күрше Мәгърифәттәй. — Минем әни әтине йөрмичә-күрмичә, дип әйтимме инде, кияүгә чыккан. Әйбәт торганнар. Менә мин инде сезгә билгеле булган Хөсәен абзагызга шактый озак йөреп, ялындырып кына чыктым. Шулай да ачыктан-ачык кешегә күренеп йөрмәскә тырыштык. Ә минем кызым үзенең булачак ирен әллә ничә мәртәбә безгә алып кайтып күрсәтте. Ошыймы янәсе, күнегә торсын янәсе. Аллага шөкер, әйбәт торалар. Менә шундый заманалар инде хәзер.

Ә инде гәҗит-журналны күп укучы Гатифә карчык бу темага үзенең укып белгәннәрен өсти:

— Африка дигән җирдә егет кеше үзенең яраткан кызына өйләнгәнче әллә кайлардан тоткан арыслан тиресен алып кайтып күрсәтергә тиеш икән. Шул вакытта арыслан моны тотып ашаса... Кияүсез кала бит инде тегесе. Бар инде бу дөньяда сәер гадәтләр.

Әнисе сөйли торган иде, бу нигездә өч гаилә бергә тордык, дип. Ун-унбиш кеше була бит инде ул. Шул нигездә Гөлсем берүзе. Замана, замана шундый инде дип ике малае да чыгып китте. Әле ярый кече малае Казанда гына, ә олысы әллә кайда жир читендә. Күрше Сабир йорты салынган урында да өч гаилә яшәгән, ди. Хәзер Сабир берүзе шул нигезгә сыймый. Гөлсемнең тавыклары, киртә арасыннан башын тыгып, Сабир бакчасындагы берәр кортны ашаса да, башларына таш бәрергә әзер тора. Бөтен дөньяны кочаклап алыр иде. Мәңгегә килгән диярсең фани дөньяга. Тьфу!

...Әйдә, теләсә ни эшләсеннәр. Гөлсемнең дөнья артыннан куар вакыты үткән инде. Биргәненә шөкер. Хәзерге минутта электр самавырым яшәсен дип, ул чәй куеп жибәрде. Гәпләшеп эчәргә берәр кеше булса да ярап куяр иде. Хәер, сон инде.

Гөлсем апаның уйларын бүлеп, ишектә кыңгырау шалтырады. Бигрәк матур инде тавышы. Казандагы малае алып кайтып куйган иде. Электр фортепиано тавышы диме шунда.

Тәки түзмәгән, күрше Мәгъфиядер бу дип уйлап, хужабикә ишеккә юнәлде. Ишекне ачса, Түбән очтагы урамда торучы Гыйлемхан малае Газинур басып тора.

— Гафу итегез инде, Гөлсем апа, — диде ул, кабаланып. — Бер хәбәр алып кайттым. Шуның белән уртаклашмыйча булдыра алмадым.

— Малайлар белән бер-бер хәл бармы әллә?..

— Юк, юк, Гөлсем апа. Шатлыклы хәбәр булырга тиеш.

— Әйдә, өйгә кер алайса, сөйлә, — диде Гөлсем апа, ишекне кинрәк ачып. Газинур ялтырап торган жинелчә генә курткасын салып кулына тотты да, тузан сарган аяк киемнәрен тышта калдырып, өйгә үтте.

— Мин Себер ягында нефть чыгаруда эшлим, — дип башлады сүзен Газинур. — Минзәләдән очабыз, самолёт белән. Безнең промысел егетләре бервакыт концерт оештырдылар да Омск өлкәсенең Иртыш буендагы авылларына барырга тәкъдим иттеләр.

— Ә-ә, — дип сузды Гөлсем апа. — Әле хаман да жырлыйсынмы? Бигрәк матур, моңлы иде шул тавышың.

— Әй, анысы инде икенче мәсьәлә, — диде Газинур, уңайсызланып. — Елга буенда татар авыллары күп икән. Шуларның берничәсендә булдык. Исемнәре дә татарча: Сәет, Рәҗәп һәм башкалар. Менә шул Рәҗәп дигән авылда концерттан соң бер абзый үзенә кунакка чакырды. Бик яхшылап кунак иттеләр. Татарстан турында әй сораштырды инде. Әй, сораштырды. Безнең якларны да бик яхшы белә бугай. Мин инде элеккеге гадәт буенча анын тормышы белән кызыксына башладым. Гөлсем апа, беләсең бит инде, «кызыл эзтабарлар» түгәрәге оештырып мәш килеп йөри торган идек. Хәбир абыйны да эзләп карадык бит.

— Әйе, әйе, — Гөлсем апа авыр сулап куйды. — Кайда күмелгәнен дә белә алмадык бит. Хәбәрсез югалды, хәбәрсез.

— Гөлсем апа, сөйләп бетерим, бүлмәгез мине. Артыграк кызыксынып, безнең якларга кагылышлы сораулар бирә башлаган идем, сүзне икенчегә борды, берниндн дә ачык жавап ишетмәдек.

— Монда нәрсәдер бармы әллә, улым?

— Бар, Гөлсем апа, бар! Газинур сөйләп бетерергә ашыкты. — Чәйләр эчкәч, безгә икенче берәүләрдә йокларга тәкъдим иттеләр. Анда агач күп, зурзур йортлар үзләрендә. Менә шул йортта бер фоторәсемгә тап булдым. Солдат

рәсеме, фронтта төшерелгән. Рәсемнең икенче ягына «сугышчан дустым Сергей Иванчукка истәлек өчен» дип язылган.

— Ул кеше урысмыни соң? Рәҗәп авылын татар авылы дип әйттең ләбаса.

— Эх, Гөлсем апа... Ну-у, тыңлап та бетермисең инде. Анда бит тагын «дустың Хәбир Кәримовтан» дигән сүзләр дә бар.

— Хәбир, Хәбир... — Гөлсем апа бер мәлгә тынсыз калгандай булды. Әкрен генә урыныннан торып, стенадагы рәсем янына килде. — Шушындыймы? — диде ул, кулы белән ишарәләп.

Газинур да, урыныннан торып, рәсемгә якын килде һәм:

— Шушы, Гөлсем апа, шушы, — дип кычкырып җибәрде.

— Газинур балам, димәк, бу кеше Хәбир абыеңны белә. Рәсеме булгач, ул аны белергә тиеш.

— Гөлсем апа, мин сиңа иң мөһимен әйтәм. Бу кеше... Хәбир абый үзе булырга тиеш.

— Аһ! — Гөлсем апа өстәлгә сыгылып төште. — Балакаем, уйлап әйтәсеңме бу сүзләреңне? Кырык елдан артык, бер хәбәрсез.

— Мин озак уйладым, Гөлсем апа, юл буе уйладым. Дөрес, хәзер ул абзыйны менә бу рәсемдәге яшь солдат белән чагыштыруы кыен. Битенә снаряд кыйпылчыгы ярасы да өстәлгән. Ләкин мин нык ышанам: ул Хәбир абый булырга тиеш. Без вахтада унбишәр көн эшлибез. Вакытымны ничек үткәрергә белмәдем. Бу турыда сиңа кайтып сөйлисем килде. Нәрсәләр генә уйлап бетермәдем.

— Тукта әле, энем, иптәшенә дип язылган рәсем ничек инде ул анда кала.

— Бу бик гади генә чишелә, Гөлсем апа. Ул рәсемен тапшыра алмый. Сугыш бит ул. Сергей Иванчук бер сугышта һәлак була һәм рәсем Хәбир абыйның үзендә кала.

Бу минутта Газинур тынып калды, хуҗа хатынга күтәрелеп карады. Гөлсем апаның йөзе нык үзгәргән, күзләре бер ноктага төбәлгән. Озак елларга сузылган көтү газабының, авыр тормышның әйләнеп кайтуымы бу, әйтүе кыен иде.

## 2

Вакыт яраны дәвалый, диләр иде. Бәлки бу сүзләрдә дөреслек тә бардыр. Моннан кырык бер ел элек сугышка киткән Хәбир йөрәктә калдырган яра да төзәлгән кебек иде. Әнә ул үзе дә каядыр томан артында, шәүләсе сизелер-сизелмәс кенә күренеп киткән төсле. Ләкин зуп-зур күзләре, елмайганда күренеп киткән тешләре аның Хәбир икәнен әйтеп торалар шикелле.

Гөлсем апа, уйларыннан бүленеп, кече яктагы сандыгын ачты. Менә кыз чагындагы сафьян читеге, яшьлек истәлеге. Башка әйберләрен киеп бетерсә дә, читеген саклады Гөлсем. Сөлгеләр — Хәбирнең әнисе Шәрифелҗамал апа тукыган сөлгеләр. Нинди матур бизәкләре. Хәбир белән Гөлсем башка чыккач, бүләк итеп биргән иде ул бу сөлгеләрне. Ләкин Гөлсемнең максаты аларны алу түгел иде. Ике хатны — Хәбирнең соңгы хатын һәм аның иптәше язган хатны эзләде ул.

Менә еллар сарысы төшкән ике хат. Икесе дә кырык дүрттә Белоруссиядән җибәрелгән булган. Ничә тапкыр укыды инде ул аларны. Шулай да һәрвакыт әле генә почта тартмасыннан алгандай итеп укый бу хатларны.

«Мона кадәр дөнья күрмәгән авыл егете менә кайларга килеп чыкты бит,

— дип язган Хәбир әлеге хатында. — Ләкин җимерекләрдән башка бернәрсә дә юк. Бөтен җирдә янгын, корым исе. Алга барабыз, Гөлсем. Тиздән теге мөртәтләрне илдән куып чыгарачакбыз. Сезне сагынам. Төшләремә керәсез. Ильяс та ап-ачык булып төшемә керә. Ләкин Равилне генә чын итеп күз алдына китерә алмыйм. Аны күргәнем юк ич минем, шунадыр. Улларымны бик тә күрәсем килә. Үзем белән рәсемнәрегез дә юк ичмасам...»

Башкасын укый алмады Гөлсем, күзләрен яшь каплады. Күз яшьләре җыерчыклы битеннән төшеп, өчпочмаклы конвертка тамдылар. Бәлки шул күз яшьләре саргайткандыр хатларны. Алардагы сүзләр йөрәккә уелган кебек. Һәр җөмләсе, һәр сүзе исән.

Икенчесендә Хәбирнең иптәше Хәбирнең бик каты яраланганын, госпитальгә озатылганын хәбәр итә. Шушы ук хатның ахырында коточкыч сүзләр бар: «Әле генә килеп әйттеләр, Хәбир госпитальдә үлгән, диделәр. Эх, сезнең кайгыны аз булса да җиңеләйтә алсам иде».

«Туктале, Хәбир иптәшенең исеме онытылган лабаса.. Менә бит ул, Сергей И».

Һай бу хәтер дигәннәрне, ничек онытып җибәргән әле ул моны. Бу теге Газинур әйткән рәсемнең артында язылган исем-фамилия бит. Газинур чыгып киткәнче алган булсачы бу хатларны. Ул үз-үзен битәрләде. Болай булгач, Себердәге Рәҗәп авылында яшәүче Хәбир Кәримов белән аның Хәбире арасында бәйләнеш була түгелме соң инде? Йә Хода! Күрергә иде аны бер, кырык елдан артык гомер узса да, таныр иде ул Хәбирен.

Шулай да хисләренә артык ирек бирмәскә тырышты Гөлсем. Фамилия, исем туры килсә дә, ялгышлар була, диләр. Хәрби комиссариаттан килгән рәсми кәгазьдә «Хәбир Кәримов хәбәрсез югалды» дип язылган иде бит. Эзләтеп тә карадылар.

— Беләсезме, апа, — диде аңа Казандагы хәрби комиссариат кешесе, — миллионнар шулай һәлак булган. Күбесен таба алмыйбыз. Эзләтәбез, тапсак — хәбәр итәрбез. Сез аны бит күз алдына да китерә алмыйсыз. Мәхшәр көнендә югалган һәр кешене табып кара син.

— Менә шуннан соң, урыс әйткәндәй: «ни ответа, ни привета». Исәннәр турында кайгырталардыр, үлгәннәргә куллары җитми. Аларны да гаепләп булмый. Шундый мәхшәрдән кемне эзләп табасың?

Төне буе аның күзен йокы алмады. Уйланды да уйланды. Хәбирне сугышка озаткан көнне исенә төшерде.

### 3

Урман буендагы басуда атлы лобогрейка белән Хәбир арыш ура иде. Шул ук басуда башка хатыннар белән бергә Гөлсем көлтә бәйли. Вакыт-вакыт бәбәй арбасында яткан улы, ике яшьлек Ильяс янына йөгереп барып килә. Авызындагы имезлеген алыштыра. Исән генә була күрсен инде. Әнә Түбән урам Галиянең кызына шушы басуда салкын тиде бит. Үпкәсе ике яклап кабарган, диделәр, үлде дә китте. Гөлсем бу арада үзен тагын сәеррәк сизеп йөри әле. Тагын балага узмадыммы икән дип пошына. Шушындый вакытта, Хәбирне иртәме-соңмы сугышка алырлар дип торганда, ике бала белән ялгыз нишләрсең?

Ирләр, атларны туктатып, җиргә төштеләр, әбәт вакыты җиткән икән. Барысы да түгәрәкләнеп утырдылар. Нәниләре булганы тиз генә балаларын барып алып килделәр. Аз гына читкә борылып, күкрәкләре белән сабыйларын

туйдыра башладылар. Аналар да, бәбиләр дә бу минутларны зарыгып көтә, теләсәң кайсы вакытта туктап ял итәргә дә, тамак ялгарга да ярамый. Андыйларны бригадир Мәүләви абыйның тамак төбеннән чыккан, карлыккан тавышы көтә: «Нәрсә дип монда арт ягыгызны җәеп утырасыз, әллә Гитлер бәдбәхетнең безгә килеп җитүен телисезме?»

Электән кырыс холыклы булган аксак Мәүләви авылда ирләр кимегән саен әтәчләнә бара. Чөнки үзен сугышка алмаячакларын бик яхшы белә ул. Аның аягы аксавының да чын тарихы бар ди. Мәүләви каладагы бер хатын янына ияләшкән икән. Кала хатынының сөяркәсе ул гына булмаган күрәсең. Берсендә шундый хәлгә тап булган Мәүләви. Ишектә кыңгырау шалтырагач, теге хатын, бар кач, баҗаң килде, ул төрмәдә булган нәрсә, күрсә, сине исән калдырмас, дигән. Куркак Мәүләвигә шул җитә калган, ярым-йорты киенгән килеш икенче катның балконыннан беренче кат балконына сикермәкче иткән. Беренче кат фатирларының балконы булмаганын исеннән чыгарган бичара. Аягын имгәтеп, шуннан аксаклап йөри торган булып калган. Берничә көннән соң култык таягы белән кайтып кергәч, трамвай бәреп екты, дип алдаган ди. Ә аның хәбәре үзеннән алда кайтып җиткән иде инде.

Атау як урамда яшәүче Гыйльмулла сугышка киткәндә, Мәүләвигә бик каты янаган ди. Безнең хатыннарга бәйләнсәң, фронттан кайтып, төнлә агач мылтыктан атып үтерәчәкмен, дигән. Шуна үч итептер инде Мәүләви Гыйльмулланың хатыны Зөфәдиягә бәйләнепме-бәйләнде. Йә эшен килештерми, йә сонга калып чыгасың, иртә кайтасың, дип яшәргә ирек бирми. Бик көткәннәр иде дә Гыйльмулланы, фашисттан бер дә ким түгел бу Мәүләви, нәләт төшкере, кайтып атып та китми шуны, дип. Ләкин Гыйльмулла китте дә югалды. Фронтка килеп җиттек, дип бер хаты килгән иде, шуннан бирле хәбәре юк. Хатыны яшь коя, ай-яй авыр хатын-кызга ялгыз яшәве.

Хәбиргә сугышка китәргә дип язылган повестканы да шушы Мәүләви китереп бирде.

...Моңсу мәҗлес иде бу. Хәбирне озатырга авылда калган берничә ир-ат килде. Ерак туганнары Фатыйх абзый үзенең беренче герман сугышында күргәннәрен сөйләп алды. Бераз утырдылар да Хәбирнең исән-сау кайтуын теләп таралыштылар.

Ул вакытта нәрсәләр сөйләштеләр соң әле алар? Хәбир бер генә минутка да Ильясны үз яныннан җибәрмәде. Гөлсем, җаен туры китереп, икенче балага узуын әйтте.

— Миннән башка таяныр кешең — күршеләр инде, — диде Хәбир. — Туасы җан туарга тиеш. Кыз булса — Рәйханә, малай булса, Равил кушарсың.

Әйтергә генә ансат, кырык елдан артык вакыт үткән. Зиһеннәр томалана башлагандыр инде. Күпне күргән бит безнең башлар. Ләкин Хәбирне озаткан көн күз алдына ап-ачык булып килеп баса. Авылны чыккач башланган үргә кадәр озатып бардылар. Аерылганда, Хәбир Ильясны күтәрде дә күкрәгенә кочты.

— Туп-туры күзләремә кара, улым. Дөнья хәлен белеп булмый, әтиенне хәтереңә индереп кал. Ләкин кечкенәрәк шул әле син.

Гөлсем белән Ильяс үрдә бик озак басып тордылар. Әнә Хәбир утырган җигүле ат урманга кереп юк булды. Мәңгегә? Юк-юк, ышанмады ул: Хәбирнең һәлак булуына да, хәбәрсез югалуына да ышанмады.

## 4

Төш булдымы соң бу? Өндә булдымы? Гөлсем апа тиз генә анына килә алмады. Урамда сыер-сарык тавышлары ишетелә. Тиз генә караватыннан шуып төште. Адәм мәсхәрәсе, көтүем кала, дип хафаланды ул, гомер булмаганны...

Үзалдына сөйләнә-сөйләнә, ишегалдына чыкты. Абзардан малларын куып чыгарды. Иртә белән тәмләп су эчертә торган иде сарык-кәҗәләренә, менә бүген өлгерә алмады инде. Әле ярый көтүнең койрыгы үтеп киткәнче урамга куып чыгара алды малларын, Аллага шөкер.

Көтү куу мәшәкате Гөлсем апаны төнге уйларыннан бераз арындырып торды. Ләкин өйгә керүгә, ул уйларның йомгагы тагын чуалды. Хәбир! Әгәр дә бу хәбәр дөрес булса, моны ничек анларга соң? Шуның кадәр вакыт бер хәбәрсез, ике малаен ташлап. Юк, Газинур ялгыша булыр. Бик зур хыянәт бит бу. Хәбир алай эшли алмас.

Ә икенче уй: сугыш кешенең язмышын кырыкмаса-кырыкка төрләндерде, булмас димә, Гөлсем, дия иде. Көнне нәрсәдән башларга соң? Тукта, чәй эчеп алмыйча булмас, баш миендәге томанны таратырга кирәк.

Чынаякларын җыеп алгач, Гөлсем Газинурларга барып кайтырга булды. Барысын да сорашырга өлгермәгән ул кичә, сорауларның иге-чиге юк.

Газинурлар өе Түбән очта — инеш буенда. Инеш буена өянке, таллар утыртып, тагын да ямьләндереп җибәргәннәр. Читтәрәк яшәсән дә ярый хәзер, машина тузаны, ыгы-зыгысы юк, мал-туарга иркенлек.

Ишек шакуга, Газинурның әнисе Саниянең тавышы ишетелде:

— Керегез, кер, ишек бикле түгел бит.

— Исән генә торасызмы? — диде Гөлсем апа, өй эченә үтеп. — Газинур балакаем кирәк иде.

Анын тавышын ишетеп, бүлмәсеннән Газинур үзе килеп чыкты.

— Исәнмесез, Гөлсем апа, үзегез килгәнсез икән. Менә бүген китәргә җыенам, Минзәләдән телеграмма алдым. Димәк, икенче бригадага кеше житми, болай иртә чакырмаслар иде. Шулай да сезгә кермичә китми идем. Әгәр дә барасы булсагыз... — Әйтерсен, ул Гөлсемнең уйларын алдан белә иде.

— Әйе, әйе, — диде Гөлсем апа, аны бүлдереп. — Барасы булыр, ахры. Гомерем буе билгесезлектән интегеп яшәдем бит.

Ул яулык чите белән күзләрен сөртеп алды. Сания дә сүзгә кушылып китте:

— Гөлсем апакаем, бигрәкләр дә ерак бит, ничек итеп юлга чыгарсын икән?! Әллә берәр иптәш булса үзенә. Ул поездларда йөрүне бигрәк тә кыен диләр бит хәзер.

— Туктагыз әле, — Газинур ашыга-ашыга үзенекен тезеп китте. — Гөлсем апа, ике малаегыз бар лабаса. Алар белән киңәшергә кирәктер. Чакыртыгыз. Аларнын да әтиләр... — Ул бу урында туктап калды. Моны бит әле исбатларга кирәк дигән уй аның телен тешләтте.

— Тинтәк тә инде мин. — Гөлсем башын чайкап куйды. — Кызулык белән, янымда тормагач, аларнын барын да онытып җибәргәнмен бит. Бүген үк берәрсен чакыртырга кирәк.

— Гөлсем апа, мин сиңа хәзер ничек бару юлын өйрәтәм. — Газинур өстәл янына килеп утырды. — Безнең станциядән Омскига хәтле поезд белән барасың. Ә аннан соң Иртыш буйлап пароход, ягъни су юлы белән. Рәҗәп авылы елга ярында диярлек урнашкан. Билгеле, мин әйткәнчә, җиңел генә булмас, җәй көне бит, билет мәсьәләсе һәм башкалар. Йә, ярый, мин җыена башладым,

унышлар сиңа, Гөлсем апа! Мин сиңа бару юлларын язып та бирәм. — Ул тиз-тиз генә кәгазьгә сызгалады. Малайларына күрсәтерсең.

— Сиңа тагын шул авылга барырга туры килмәсме соң? — Гөлсем аннан ярдәм көтте. Ләкин Газинур, бик теләп ярдәм итәр идем дә бит, безне икенче промыселга күчерәләрдер, дигәч, Гөлсем инде бүтән аны борчымаска булды.

Үз өенә кергән кешене чәйсез чыгармаган Сания өстәл әзерләргә өлгергән иде инде. Китәргә дип кузгалган Гөлсем, хуҗа хатын бик каты кыстагач, ярар, берәрне булса да эчәрмен инде, дип зур бүлмәгә үтте.

— Кичәге хәбәрдән соң тамакка ризык бик бармый әле, — диде ул, чынаягындагы пар чыгарып торган чәйне кашыгы белән болгатып. — Аяз көнне яшен суккандай итте. Тормышта шундый хәлләр дә була микәнни? Ә без алар өчен монда яшь коябыз.

— Туктале, Гөлсем апа. Хәбир абый турында начар уйларга ашыкма. Менә минем китаптан укыганым бар. Анда берәү гомер буе үз йортыннан ерак булмаган урманда яши, ләкин гаиләсен күрергә, балаларын яратырга хакы булмый.

— Интеккән икән, мескенкәем.

— Фронттан качып кайткан була ул. Гаиләсенә күренер иде, сүз чыгудан, әләгүдән курка, гомере буе менә шулай куркак куян кебек яши.

— Соң ул сугыштан качкан бит. Хәбир нишләп андый булсын. — Гөлсем күтәргән чынаягын кире өстәлгә куйды.

— Хәбир абый сугыштан качкандыр дип уйламыйм, Гөлсем апакаем. Ләкин менә пленга эләккәннәрне безнекеләр азат иткәч, кайберләрен Себергә җибәргәннәр дип ишеткәнем бар. Шуннан куркып, пленнан теге якка да чыкканнары булган ди. Рәхим-шәфкать тимәгән аларга.

— И, Ходаем, ниләр генә күрми бу адәм баласы. Бер мизгел кебек кенә булган гомерен дә тыныч кына яшәргә бирмиләр. Рәхмәт, Сания, мин китим инде. Өйгә кайтып, малайларның адресын алыйм да күрше авылга почтага барыйм. Берәрсенә хәбәр бирергә кирәк.

Сания, бернәрсә дә ашамадың-эчмәдең, дип Гөлсем апаны бик кыстаган иде дә, ләкин тегесе кире утырмады, аның башын башка кайгы чорнап алган иде инде.

Саниялардән чыгып, кире үзләренә кайтканда, юлда берничә кеше очрады. Хәбир исән дигән хәбәр бөтен авылга таралып өлгергән иде ахрысы. Һәр очраган кеше Гөлсемне туктатып сүз алмашырга теләде. Ләкин Гөлсем туктап тормады. «Соңыннан, соңыннан, балакайларым, хәзергә төгәл бер сүз дә әйтә алмыйм әле», — дип үз юлын дәвам итте.

Өй ишеген дә бикләмичә киткән икән ләбаса. Картлык галәмәте. Хәер, авылда андый-мондый хәлнең булганы юк. Якын-тирәгә барганда, капка келәсенә күптәннән килгән гадәт буенча бау гына бәйлиләр.

Өйгә кергәч, иң беренче эше итеп стенадагы зур көзге артыннан адреслы иске конвертларны тартып чыгарды. Менә өлкәне Ильясның адресы. Анысы еракта, шахтада эшли. Аның өчен ут йотып яши Гөлсем. Гәзитләрдә гел шахталарда шартлау, ишелү турында язып кына торалар ди. Кайтыгыз бу якларга дип чакырып та карады, без инде монда ияләндек, пенсиягә хәтле шушында эшлибез, диләр. Ильясы бигрәк тә йомшак, яхшы күңелле, үзе әнисен чакыра. Кая инде ул анда чыгып китү, әзрәк ярдәмнәреннән өзмәсәләр, кыштыр-кыштыр йөрер әле шунда.

Бер әйтүгә чыгып китәр иде Ильяс әтисе янына. Кечкенә булса да, Хәбир

сугышка киткәндә, әтисенең кысып кочаклаганы, күзләремә туры кара, хәтерләп кал, дигән сүзләре анын күнеленә мәнгелеккә уелып калган шул.

Ә менә Равилендә бөтенләй башкача холык — кырыс, кискен. Казандагы эше дә бик җаваплы бугай инде. Әллә ул эшкә шундый кешеләр дә кирәктер. Якынлыгы да бар. Бары тик аңа гына хәбәр итәргә кирәк. Ләкин Гөлсемнең күнеленә шик төште, барырмы? Ни өчен шундый булып үсте икән ул? Ана берничек тә аңлатып бирә алмый. Бер ата, бер ана малайлары, югыйсә. Ә аерма... Э-эх! Гөлсем белеп тора, йә әни, әйт әле шуны, сиңа нәрсәгә кирәк инде ул, дияр. Йә элгрәк эзләргә кирәк иде, йә хатыны, балалары кирәк булса, сугыштан соң үз авылына кайтыр, әллә кая Себергә китмәс иде, дияр. Вакланып, төпченеп тормас ул — катырак бәгырьлерәк шул.

## 5

...Равил озак көттермәде. Үзенең кече улы Азат белән кайтып та җитте. Ишектән керүгә, әнисенең хәлен сорашты: Гөлсем аңа тиз генә барысын да аңлатып бирде.

— Барырга уйлыйсыңмы? — Әнисен тыңлап бетергәч, Равилнең беренче соравы шул булды.

— Барырга уйлыйм. — Ана бу сүзләрне ышаныч белән әйтте. — Сезнең икегезнең дә тормышыгыз әйбәт, ул яктан күңелем тыныч. Ләкин гомерем буе төзәлмәгән йөрәк ярам бар, әтиегезнең кайда икәнен белмим. Әгәр дә шул сорауны да ачыкласам, бу дөньядан тыныч күңел белән китәргә була.

— Йә инде, әни, шул кадәр ник үз-үзеңне бетерергә. — Равил әнисен тынычландырырга теләп, кулын анын җилкәсенә куйды. — Соң, хәбәрсез югалды, дигән хәбәре килгән иде бит.

— Эх, улым, улым. — Гөлсем улының кулын читкә этәрде. Тәрәзә янына барып басты, беразга тын калды. — Хәер, сине гаеплән тә булмый. Син әтиеннең йөрәк җылысын тоеп кала алмадың. Шуңа күрәдер синең күңелендә ана карата якынлык та, җылылык та юк. Ачуланма, улым, сине шәһәр шулай үзгәрттеме соң, катырак бәгырьле син.

Равилгә ничектер унайсыз, оят булып китте, Азат та ишетеп тора бит әнисенең бу сүзләрен.

— Әни, гафу ит, — диде ул, үз-үзен кая куярга белмичә. — Барырсың, мин риза. Ләкин мин синең белән йөри алмыйм, аңла, бездә зур төзелеш бара, аны ун-унбиш көнгә ташлап китә алмыйм. Менә синең белән Азат китәр. Әйеме, улым. — Ул мона кадәр тик кенә утырган улына эндәште.

— Ә сәяхәт кая, әти, пожалуйста, хоть җир читенә, — диде Азат, бераз мактаныбрак.

— Җир читенә түгел, бераз якынрак. Без сиңа барысын да аңлатырбыз.

Равил бераз икеләнебрәк торган әнисенә мөрәҗәгать итте:

— Әни, бер дә курыкма, Азат русчасын-татарчасын теттерә генә. Юлда йөргәне бар. Менә дигән иптәш, ана уналты яшь ләбаса. Бөтен юл расходын да үзем күтәрермен.

— Монысы кирәкми инде, улым, юлга житәрлек кенә запасым бар. Күрәсе кешеләргә күчтәнәчләр дә алырга кирәк. Кемнәр генә булса да, буш кул белән килеп керү матур булмас. Ягез, балалар, юлга хәзерләник.

Равил аптырашта калды.

— Әни, хәзер үкме?

— Әйе, нигә сузарга, якты җәй көнендә бармагач, тагын кайчан? Себер

ягына кыш көне чыгып китеп булмас. Ә Азат турында киленгә барысын да сөйләрсең, аңлатырсың.

Ләкин Гөлсем уйлаганча, барысы да тиз генә килеп чыкмады. Бүләкләр, күчтәнәчләр алып, станциягә барып билетлар юнәткәнче, ике көн вакыт узды.

Һәм Гөлсем белән Азат ерак юлга чыгып киттеләр.

**6**

Кайчандыр «Катыкчы» дип аталган өч-дүрт вагонлы поездда, аннан соң электричкада Казанга барырга күнеккән Гөлсем, ерак баручы поездга утыргач, бераз каушап калды. Вокзалда ук үзебезнең кешеләр очратсак ярар иде, дип хәсрәтләнде. Бәхеткә каршы купедагы калган ике урынга ирле-хатынлы татар кешеләре утырган иде. Поезд кузгалып, озак та үтмәде, бер-берсе белән якыннан танышып, кемнең кая, нинди максат белән йөрүләрен дә беләләр иде инде. Яңа танышлары Павлодарга бара икән. Казахстандагы дуслары чакырган. Турыдан-туры билет юнәтә алмасагыз, Омск аркылы килегез, дип өйрәтеп язганнар. Аннан Павлодарга поездлар йөреп тора ди.

Тегеләр сөйләгәндә, Гөлсем үз-үзен аклау юлларын эзләде. Сугышта югалган иремне эзләп йөрим әле, димәссең бит инде. Әбинең шөрепләре бушаган, дип әйтүләре бар. Аннан соң китәр сорашу, китәр сорашу. Берәүгә дә эч серен сөйлисе килми иде инде. Сөйләнәсе сөйләнгән.

Икенче малаемның улы белән олы малаем янына кунакка барабыз, дип котылды. Алдады инде Гөлсем, Ходай алдында да, бәндә алдында да үзен гаепле итеп сизде, ләкин нишлисең? Андый вакытларда күрше Галиәхмәт изге алдау дип котыла торган иде.

Әле ярый, тәрәзәгә карап барган Азат бер сүзгә дә катнашмады. Ул әллә бик кызыксынып тирә-юньне күзәтте, әллә әбисенең «изге алдавын» белдертергә теләми иде.

Әй, бу юл йөрүләре! Берәү дә кызык эзләп юлга чыкмыйдыр ул. Вагонда җәй көне эссе, кыш көннәрендә салкын була, диләр. Көне буе эш белән мәшгуль Гөлсемгә болай тик утырып кына баруы бигрәк тә сәер тоелды. Күршеләрен белән бераз сөйләшеп барасың да, вагон тәгәрмәчләренең тукылдавын тыңлап, изрәп йокыга китәсең. Аннан соң бергәләп ашарга утырасың. Гөлсем апа авылдан алган сый-нигъмәтләре белән юлдашларын да сыйлады. Проводник алып килгән чәй дә бик тәмле тоелды ана. Аннан соң оныгы Азат та, авыл кешеләре әйткәндәй, бик үткен булып чыкты. Теге вагон-ресторан дигән җиргә бара да килә.

Гел йоклап кына да бармады Гөлсем. Ятса да, күзен йокы алмаган минутлар күп булды. Ни дип барып керер инде ул Хәбирләр йортына. Ничек сүз башлар? Тукта әле, аның Хәбир икәненә чын-чынлап ышанып беткән түгелме соң? Әгәр дә Хәбир булмаса? Чит кешеләр ничек кабул итәрләр? Үз ире булган очракта да Хәбир өчен чит, яттыр инде Гөлсем.

Шулай уйланып ята торгач, төш күрде Гөлсем. Хат ташучы кыз бер төргәк акча китергән, имеш, кәгазь акчалар. Хәбир абый җибәрде, ди. Гөлсем эсселе-суыклы булып уянып китте. Картлык галәмәте комачаулады микәнни? Ничек бу вакыйга онытылып торган.

1950 елның җәе иде. Ул көнне хат ташучы Сәлимә аңа акча язуы китереп бирде. Гөлсем тегеләй дә, болай да әйләндереп карады, ләкин акчаның кемнән килгәнен генә аңлый алмады. Мөһеренә караганда Шәмәрдән станциясеннән

салынган. Ләкин кемнән ул? Гөлсемнең акча салырлык якыннары юк иде шикелле. Әгәр дә Себергә китешли бу акчаны Хәбир салган булса. Йә берәр кеше аркылы салдыргандыр? Сораулар, сораулар... Тәгәрмәчләр тавышы анын хәтер янчыгын селкетеп, менә шуларны искә төшерде. Андый акча тагын берничә тапкыр алды әле ул.

...Поезд Омск шәһәренә якынлашты. Пассажирлар дәррәү кузгалып төшәргә җыена башладылар. Купедашлары, Раиф белән Галия, барысының да исән-имин әйләнеп кайтуларын теләп, вагон ишегенә таба юнәлделәр. Поезд вокзал каршына килеп туктады. Гөлсем белән Азат ашыкмыйча гына вагоннан төштеләр, чөнки аларны вокзалда көтеп торучы юк иде.

Газинур, поездан төшүгә, су вокзалына барыгыз, дип әйткән иде. Сорашып, шунда юл тоттылар. Билет алулары чынлап та бик авыр булды. Монда да Азатның үткенлеге ярап куйды. Кассалардан сорашып чыккач, бүгенгә билетлар беткәнлеген белде дә, уйлап та тормыйча, вокзал начальнигы дип язылган ишекне шакыды.

Шактый озак торды Азат бу бүлмәдә. Менә ишек ачылды һәм аннан авызы ерылган малай күренде.

— Булды, әби, — диде ул, башкалар ишетмәсен дип пышылдап кына. Вокзал начальнигы шулай кушкан ди. Әби белән бергә бабайны эзләргә барабыз дип шактый сөйләгәч кенә билет табылган.

Су өстендә селкенгәләп торган «Ракета» дигәннәренә утыргач, Гөлсем пошаманга төште. Барып җитә алыр микән, күңелне болгата икән бит бу. Кузгалып киткәч тынычланды — әллә ияләнә төште, әллә селкетү азайды, тәрәзәдән карап бару мөмкинлеге туды. Менә нинди икән ул Иртыш елгасы. Бигрәк тә бормаланып-бормаланып ага икән. Гөлсем үзләренең авыллары янындагы кечкенә инешне күз алдына китерде. Ул да бит шулай бормаланып ага. Турыдан гына агасы да бит. Юк икән шул, су да турыга гына акмый, тормыш та борылышларсыз гына булмый икән. Барысы да әйбәт булса, Гөлсем дә Себергә барып йөрмәгән булыр иде. Димәк, аның тормышының бер борылышы шушында. Ул елганың бер яры — ялангач, ә икенчесен таллар каплаган булуга да игътибар итте. Юл йөрү сиздерә шул. Гөлсем тәрәзәдән озак карап бара алмады, изрәп йокыга талды.

...Күрше хатыны Гамилә белән арба тартып урманга барганнар, имеш... Курка-курка гына арбага чыбык-чабык төйиләр. Ни арада җыеп бетергәннәрдер, кайтыр юлга да чыктылар. Күңеле нидер сизенде, Гөлсем артына борылып карады. Ә анда, урман буенда яшел солдат киеменнән... Хәбир басып тора. Маңгаен ак марля белән бәйләгән, урта тирәсеннән алсуланып тора. Димәк, ул яралы. Гөлсем арбаны Гамиләгә калдырды да кире урманга йөгерде. «Хәбир, Хәбир», — дип кычкырмакчы булды. Ләкин тавышы чыкмады. Ә Хәбир аны абайламады ахры, акрын гына агачлар арасына кереп югалды. Гөлсем куып җитәргә ашыкты, тик сынган агачларга абынды, яшел ботаклар аның юлын бүлделәр. Гөлсем җиргә егылды, үксеп-үксеп елый башлады.

— Әби, әби, ыңгырашма инде, — Гөлсем Азатның бу сүзләреннән уянып китте, үзенең кайда икәнен аңламыйча, сәерсенеп, тәрәзәгә карады — анда елга, су.

— Уф Алла, — диде ул, Азатның башын сыйпап. — Төш күрдем, балам, бабаңны күрдем.

— Бабайны дисеңме, әби? Алайса исәндер ул.

— Белмим шул, балам. Очраша алмадым шул, күреп кенә калдым. Хәер, бик каты еладым. Төштә еласаң, шатлыкка, диләр бит.

«Ракета» тизлеген киметте. Берничә кеше, «Сәетово тукталышы», дип чыгу юлына юнәлде. Гөлсем дә Азатка тотынып алар артыннан иярде. Бу тирбәнүгә һич кенә дә ияләнә торган түгел икән, һаман башны әйләндерә. Әкрен генә басмадан яр кырыена чыктылар. «Ракета»га утырырга чират торучылар ризасызлык белдерсәләр дә, Гөлсем әллә ни игътибар итмәде, яшәп карасыннар әле безнең кадәр, аннан соң сөйләшербез, алар белән, йөгереп йөрерләрме, атлапмы?

Менә син, Себер авылы, нинди икән! Ярдан күтәрелүгә, урам башлана. Бераз баргач, ул икегә аерыла. Нәкъ әкияттәге кебек — унга барыргамы, сулгамы? Шушында туктап, авыл кешеләреннән сорашырга туры килде. Авыл кырыйларын урман чолгап алган, әмма урамнарда агачлар аз күренә. Бездәге шикелле шаулап торган җимеш бакчалары да юк икән биредә, дип уйлады Гөлсем. Бу уйларын Азатка да әйтте.

— Әйе, әйе, — диде малай, әбисенең сүзен җөпләп, — монда хәтта алмагачлар да күренми, ничек яшиләрдер.

Йортлар да үз авылларындагы мәхәббәтле күренмәде Гөлсемгә. Бездә халык көчен җәлләми шул. Өен салуга, такта белән тышлап ала, буйый, чистарта, ялап торгандай итә.

Иртышка суга төшүче бер хатын Хәбирләрнең өен күрсәтте. «Бара торгач, барып життем биек тау итәгенә» дигәндәй, Гөлсем алдына, бу йортка ничек керергә, сүзне нәрсәдән башларга, дигән сорау килеп басты. Азат та моны сизгәндәй:

— Әби, әйдә аз гына утырып тор, хәл ал, — дип капка төбендәге эскәмиягә таба ымлады.

Болай озак утырып булмасын Гөлсем дә, Азат та аңлыйлар иде. Тынлыкны беренче булып Азат бозды:

— Әйдә, әби, керик, тотып ашамаслар, монда кадәр килеп житкәч, кире кайтып китеп булмый.

Гөлсем авырлык белән генә урыныннан торды, эчтән генә белгән догаларын укыды, сумкасын әле бер, әле икенче кулына авыштырды, урамнан тыныч кына узып баручы авыл кешеләренә дә карап алды. Нинди кыен икән чит җирдә, ят кешеләр арасында. Әле ярый янында Азаты бар. Сулкылдаган йөрәген ничек тынычландырырга? Елар иде, күңелен бушатыр иде... Ярамый, ярамый, дип үз-үзенә кабатлады. Һәм шулай ук аптырап калган оныгына сүзсез генә ымлап, ишек кыңгыравына басты.

## 7

Татарстан егете Газинур килеп киткәннән соң, Хәбирнең тынычлыгы югалды. Хәер, алар күп иде, бер Газинур гына түгел. Күптән концерт-тамаша күрмәгән Хәбир, Татарстаннан килгән нефтьчеләрнең клубта чыгыш ясауларын ишеткәч, ашкынып шунда ашыкты. Билгеле инде, үзе генә түгел, Гарифә белән. Газаплар да, яралар да янарды бу кичтә.

...Китми күңелемнән минем һич
Ул сөекле илкәем.
Анда минем сөйгән халкым,
Анда газиз әнкәем.

Бу җыр Хәбирнең йөрәге аркылы җылы дулкын булып үтте. Ул аны әйтерсең лә күтәреп алды, башы җиңеләеп киткәндәй булды. Әйтерсең, алда торган томан пәрдәсе таралды.

— Гарифә, Гарифә, мин нишләп монда?

Ул хатынының кулын кысты, Гарифә аздан гына кычкырмый калды. Хәбир концертны карап бетерерлек хәлдә түгел иде, ул ишеккә таба юнәлде. Гарифә дә теләр-теләмәс кенә аның артыннан иярде.

Кичке салкын җил Хәбирнең башын сафландырып җибәрде, ул адымнарын кызулатты. Арттан Гарифәнең кычкырган тавышы ишетелгәч кенә, нидер исенә төшергәндәй туктап калды, урамдагы агачка сөялеп, Гөлсем, Гөлсем, дип пышылдады.

— Хәбир, җаным, нишлисең, бу мин Гарифә бит, әллә танымый да башладыңмы?

Гарифә Хәбирне култык астыннан тотып өйгә алып керергә азапланды.

— Беләм, беләм, син — Гарифә, сиңа бернинди дә үпкәм юк. Рәхмәт сиңа, мине тәрбияләдең, үз иттең. Минем Гөлсемем бар иде бит, Гөлсемем, малайларым. Ни өчен мин аларны шулай тиз оныттым соң әле?

Гарифә нәрсә эшләргә дә белмәде.

— Хәбир, әйдә, өйгә керик. Син аларны онытмадың бит. Көченнән килгәнчә ярдәм дә иттең, кайтып та килдең. Артыгын эшләргә мөмкин түгел иде бит.

...Җәйге төн кыска була. Ир белән хатын сөйләшеп таңны аттырдылар. Билгеле, күбрәк Хәбир сөйләде. Элеккеге тормышын сөйләде ул, чөнки хәзергесе икесенең дә күз алдында. Тормышлары әйбәт кенә бара иде кебек. Ләкин бүген араларына кемдер килеп керде. Әнә ул уртада тора. Аларга якынаерга ирек бирми. Ул — Гөлсем.

— Хәбир, азагы болай бетәсен белгән булсам, бәлки мондый адымны ясамаган да булыр идем, — диде Гарифә, өзгәләнеп. — Сизәм, мин хәзер сезнең арага кергән артык кеше.

— Өзгәләнмә, Гарифә, сине берәү дә гаепләргә җыенмый. Берәү дә артык түгел. Гаепле кеше ул мин. Мин алар турында онытырга тиеш түгел идем.

Ә Гарифә аны ничек итеп юатырга да, тынычландырырга да белмәде. Сызылып таң атты. Кояшның беренче нурлары урмандагы агач башларын яктыртты. Аннан соң алар тәрәзәләргә дә төште. Яңа көн башланды. Хәбир өчен дә, Гарифә өчен дә хәерле белән килмәде ул көн. Ул көн башваткычлар, җавап таба алмаслык сораулар алып килде.

## 8

Инде нишләргә? Хәбир бу сорауны әсирлектә үз-үзенә кат-кат бирә торган иде. Бөтенләй өметсезлеккә төшеп, фашист табаны астында яшәгәнче, үлүең артык, ичмасам туфрак булырмын, дип үз-үзенә кул салырга теләгән вакытлары аз булмады. Ләкин шул минутта күз алдына туган яклары, Гөлсем, ике улы килеп баса, меңә шулар ана яшәү көче бирә торган иде.

Ә инде үзебезгә кайткач... үзебезнең лагерьга эләккәч тә башына ул тиле уйлар аз килмәде. Монда инде аның фәрештәсе Гарифә коткарды. Әйе, әйе, Гарифә, моңа кадәр бөтенләй таныш булмаган Гарифә...

Лагерьда тик яткырмыйлар, күбрәк урман кисәргә җибәрә торганнар иде. Урманнан кайтканда, гел бер авыл аша үтәргә туры килә, урамында сирәк-мирәк кешеләр дә очрый. Ачыктан-ачык берәү дә үзенең хисләрен белдерми, ләкин күзләреннән сизелеп тора — берәүләр нәфрәтләнә, чөнки

Гитлер ягына чыккан «сатлыкҗаннар» үтеп бара. Ә икенчеләре күзендә кызгану хисләрен укырга мөмкин: болар да адәм балалары бит. Күпме сугышканнар фашистка каршы, күпме интеккәннәр. Менә тагын үзебездә газапланалар. Моннан да зур хурлыкның, түбәнсетүнең булуы мөмкин түгел. Шушындый кешеләр арасында укытучы булып килгән Сәет авылы кызы Гарифә дә бар иде.

Хәбир кичә кич авыл клубында концерт куйган нефтьче яшьләрне эзләп күрше авылга китте. Имеш, алар бүген шунда чыгыш ясаячаклар иде. Ә Гарифә ялгыз калды. Уйлары һәм берүзе.

Моңа кадәр үзалдына беркайчан да мондый сорауны куйганы юк иде — тормышы ничек үтте соң әле аның? Бу турыда уйлап та карамады, көн артыннан көн туа, гомер үтә. Инде балаларның балалары үсеп килә. Ләкин, барыбер бу сорауны бирә торган вакыт җитә икән. Яшисең, яшисең дә бер чиккә килеп төртеләсең. Анда туктап, артка борылып, үткәнеңне бер бизмәнгә салып карарга кирәк була икән.

...Сугыштан соң Кызыл Яр шәһәре янындагы авылда эшләмәсә, аның урамыннан үткәндә, арестантлар колоннасында Хәбирне күрмәгән булса, тормышы нинди булыр иде? Моны берәү дә әйтә алмый, тормыш юлын ике кат үтеп булмый шул.

Сугышта алган авыр яраларыннан интеккән, лагерьда кыйналган Хәбир кайсы ягы белән аңа ошады икән? Әллә кызгану хисләре өстенлек иттеме? Әллә язмыш шулай куштымы?

Гарифә башта ишегалдына, аннан соң бакчага чыкты. Тиздән бәрәңге казыр вакыт, көз җитәр. Хәзергә җылы әле, шулай да көз, әйтерсең, әнә теге урман артында гына, җаен, вакытын көтеп тора.

...Хәбирне лагерьдан чыгардылар, ләкин бернинди документ бирмәделәр. Хәер, бер кәгазе бар, анда үзәк районнарга кайту тыела дип язылган иде. Срогы да аталган — биш ел.

Кызыл Яр янындагы авыл кешеләренә, андагы эшкә тәмам ияләнеп бетсә дә, Гарифә аннан китүне яхшырак дип тапты. Хәбирне лагерьдан читкәрәк алып китү кирәк иде. Сәет авылына күчеп килделәр, урман якын, зур итеп йорт салдылар. Тормышлары кешенекеннән ким түгел. Халыкта шундый әйтем бар бит: «Үзем тапкан картам, тешли-тешли тартам». Гарифә дә гомере буе авырын да, җинелен дә тартты, ынгырашмады. Хәбирнең элеккеге тормышын сорамаска тырышты.

Тап-таза балалар үстерделәр. Үстерделәр үстерүен, ләкин алар замана җиленә ияреп чыгып та киттеләр. Хәзер инде оныклары белән кунакка кайталар.

Менә Хәбирнен күңеле тагын үзгәрде. Шатланырга да, кайгырырга да белмәде Гарифә. Хәер, башта шатланган иде, Хәбирнең Гөлсеме, ике малае булганын белә иде ич ул. Хәбир кайтып китмәсме? Татлы йокылар йокладым сабый чакларда гына, дип юкка гына җырламыйлар шул. Борчулы, йокысыз төннәр алда әле.

Төш җитәр-җитмәс Хәбир дә кайтып керде.

— Тоттым егетләрнең койрыкларыннан, — диде ул, урам капкасын ачып кергә. — Чынлап та бүген кич күрше авылда, Сөләйманда булалар икән. Концерттан соң безгә чәйгә килергә вәгъдә бирделәр. Газинур дигәне безнең яклардан булырга тиеш. Күп сөйләшергә вакытлары булмады.

Хәбир Гарифәнең дымлы күзләрен күреп туктап калды.

— Гафу ит, — диде ул, Гарифәнең җиңелчә генә калтыранган җилкәсенә

кулын куеп. — Мин бүтәнчә булдыра алмыйм. Ничә еллар, Гарифә. Син мине анларга тиеш.

Менә, менә елап җибәрергә торган Гарифә бары тик әйе, әйе, дип кенә әйтә алды.

Өйгә керделәр. Гарифә самаварын яңартып җибәрде. Сөйләшергә, анлашырга, алга таба ничек торырга икәнен анлашырга кирәклеген икесе дә сизә иде. Сүзне Хәбир башлады.

— Мин күрше авылга барганда да күп уйладым, Гарифә. Икегә бүленеп булмый. Син мине каядыр китәр дип уйлама. Гомеремнең күбрәк өлеше шушында, синең белән үтте бит минем. Ин авыр вакытларымда син таяныч булдың. Монда да балаларым, оныкларым бар. Ләкин, ачуланма, туган ягымны, әгәр дә исән булса, Гөлсемне, малайларымны күрәсем килә минем. Тик анда ничек кайтырга? Шушы еллардан соң алар күзенә ничек күренергә?

— Синең хәленне анлыйм, — диде Гарифә йомшак кына тавыш белән. Ул бераз тынычланган иде инде. — Бу килеш кайтсаң, алар сиңа нәфрәт белән генә караячаклар. Син сугышта һәлак булган әтидән иң начар кешегә әвереләчәксең.

— Әгәр дә авылга кайтып, теге вакыттагыча аларны читтән генә карап йөрсәм, ни булыр икән, ә? Бәлки, танымаслар да. Инде картаелган да, биттәге яралар да бик нык үзгәртте мине. Ләкин аларны күргәч, түзеп торып булыр микән? Исән генә булсыннар иде.

Ир белән хатын ул көнне күп сөйләштеләр, шулай да ныклы карарга килә алмадылар. Нишләргә, дигән сорау элеккечә алар алдында басып калды.

Ә кич җитүгә, кунакларны көтә башладылар. Хәбир мунча ягып җибәрде, Гарифә аш-су тирәсендә кайнады. Эш белән мавыгып, бераз борчуларыннан да арынып тордылар.

Менә өстәл дә әзер, мунча да җитешкән. Икесе дә чолан баскычына чыгып утырдылар, капка тавышын тизрәк ишетерләр, янәсе. Утырдылар да утырдылар, ә сүзләре һаман бер тирәдә әйләнде.

Ә капка төнге сәгать уникедә генә ачылды. Хәер, монда аптырарлык та түгел. Концерт тәмамланып, күрше авылдан килеп җиткәнче, шактый вакыт үтә. Капка ачылды, әмма анда бары бер Газинур гына күренде.

— Әйбәт булмаган, егетләр, — дип каршылады Хәбир Газинурны. — Ә без тырышкан булабыз, бөтен бер отделение каршыларга әзерләндек.

— Хәбир абый, Гарифә апа, егетләр сездән гафу үтенделәр. Безнең концертлар тукталып тора әле, эшкә чакырдылар. Барысын да анлатырга мине вәкил итеп җибәрделәр.

— Ярый алайса, — диде Хәбир, шаярып, — сиңа барысы өчен дә ашап-эчәргә, мунчада чабынырга туры килер.

— Менә монысына мин риза, — диде Газинур, кулларын угалап, өстәлдәге сый-хөрмәтне күргәч. — Ну үкенерләр дә инде егетләр, ләкин соң булыр.

Күбрәк Газинур сөйләде. Татарстандагы туган авылының исемен атаганда, Хәбирнең кулыннан чынаягы төшеп китте. Бер минутка каушап калдылар. Унайсызлыктан Гарифә коткарды:

— Хәбир абзаң фронтта контузия алган кеше. Кайвакыт шулай куллары хәлсезләнеп китә. Әйдә, Газинур энем, кыстатма әле, менә Себер нигъмәтләре белән чәй эч, — дип, ул сүзне икенчегә борырга маташты.

Газинурның: «Хәбир абый, сез үзегез кайсы яктан монда килеп эләктегез соң?» — дигән соравына да Гарифә җавап бирде:

— Сорама инде, балам, һаман да шул контузия шаукымы. Ул сугышка кадәр булган тормышын хәтерләми.

— Гомер буе шулаймы? — Газинур үзе дә сизмәстән урыныннан сикереп торды. — Шулаймы, Хәбир абый?!

Ә Хәбир җавап итеп җилкәсен генә сикертте һәм Газинурга ымлады:

— Сөйлә әле, егет, сөйлә. Матур җырлыйсың, матур сөйлисең дә син. Сүзләрең күңелгә сары май булып ята.

Газинур белән йорт хуҗалары таңга кадәр утырдылар. Капка төбендә машина кычкырткач кына әңгәмә туктап калды. Газинур киткәндә, Гарифәнең күңеле йомшарды.

— Җаең туры килсә, гел кереп йөр безгә, — диде ул, күзләрен сөртеп. — Әти-әниләренә бездән сәлам әйт, безнең белән таныш булмасалар да, Себердә менә шундый кешеләр яшәп ята, дип әйт.

Хәбир белән хушлашканда, Газинур аңа текәлеп карап торды. Нәрсәнедер хәтеренә сеңдереп калдырырга теләгәндәй булды ул.

## 9

Ишекле-түрле йөреп, Гарифәнең аяклары арыды. Нигәдер күңеле тыныч түгел. Хәбир дә озаклады. Көннәр салкынайтканчы Омскига балалар янына барып кайтам дип киткән иде ул. Гарифә вакыт-вакыт стенадагы сәгатькә дә карап ала. Мөгаен, соңгы «Ракета»га калгандыр. Исән генә йөри күрсен, организмы бик таушалган инде, урмандагы шыгыр-шыгыр килгән, менә авам, менә авам дип торган агачка охшаган. Бирсә дә бирә икән Ходай кешегә язмышны, башына төшкән газапларны кичергән йөрәгенә рәхмәт инде. Шулай булса да, күңеле күр анын, тагын бер тапкыр туган ягына кайтып килергә хыяллана.

Ишегалдында эт өргән тавыш ишетелде. Ул арада ишек тә шакыдылар. Кем икән бу?

— Керегез, керегез, мин өйдә, — дип кычкырды Гарифә. Ә үзе, тәрәзәдәге челтәрле пәрдәләрне күтәреп, урамга карады.

Кыяр-кыймас кына ишек ачылды. Ә ишектә... ишектә бөтенләй таныш булмаган яшь кенә егет һәм олы яшьтәге хатын күренделәр.

— Исәнмесез! — диде таныш булмаган хатын, аптырашта калган Гарифәгә карап. — Хәбирләр өе шушы, диделәр, менә... кердек инде, ачуланмассыз.

— Сез... сез кем буласыз соң? — Гарифә бер урында таптанды, җайсыз хәлдән котылу юлын эзләде. — Әйдә, түрдән үтегез, безнең як кешеләренә бер дә охшамагансыз.

Шулвакыт мона кадәр як-ягына гына каранып торган яшь егет телгә килде:

— Татарстаннан без, апа, — диде ул, ашыга-ашыга. — Әбием — Гөлсем, ә мин Азат булам, Кәримовлар.

— Татарстаннан? Кәримовлар, — дип кабатлады Гарифә, бер-ике адым артка да чигенеп куйды. Ләкин тиз генә үзен кулга алды. — Әйдәгез, үтегез. Ничектер, кисәк кенә... Хәер, Газинур килеп киткәннән бирле көттек без сезне. Татарстанга кайткач, сөйләр дә, кем дә булса килеп төшәр дип уйладык.

— Йорт хуҗасы күренми бугай, бәлки без урамда гына көтеп торырбыз. — Читенсенүеннән әлегә арынып бетмәгән Гөлсем ишек төбендә таптануын дәвам итте.

— Сез нәрсә, Себер дигәч тә, бирedә кыргыйлар яши дип уйлыйсызмы әллә?

— Гарифә бераз ачуланыбрак сүзен дәвам итте. — Без дә кунакны каршы ала беләбез. Ул кунакларны, кыстый-кыстый, өй эченә алып керде, стенага терәп урнаштырылган йомшак, чәчәкле япма япкан диванга утыртты.

— Бераз ял итегез. Чәем кайнаган, пирогларым пешкән. Хәбирне көтәм мин.

Хәбир сүзен ишеткәч, Гөлсемнең сискәнеп китүенә дә игътибар итте ул.

— Омскига балалар янына киткән иде. Теплоходтан төшүчеләр арасында сез аны күрмәдегезме?.. — Нәрсәдер исенә төшкәндәй, сүзе шул урында туктап алды. — Әй, юләр дә инде мин, сез аны танымыйсыз бит инде.

— Әгәр дә безнен Хәбир булса, танырмын шикелле. — Гөлсем урыныннан торып, тәрәзә янына килде, челтәрле пәрдә аркылы елга ярына күз салды.

— Бүген кайтыр микән?

— Кайтыр, кайтыр. Әле кичкә таба тагын бер теплоход була. Ә... килүләре бик кыен булмадымы соң?

— Юл газабы — гүр газабы, диләр бездә. — Гөлсем Гарифәгә таба борылды. — Ләкин алай ук булмады бугай. Менә Азат улым бик тырышты, — диде ул, оныгының аркасыннан сөеп. — Бөтенесенә ул йөгерде.

— Әби, мине бик мактама инде, — диде Азат, бераз унайсызланып. — Син үзең дә молодец, гомер буе авылда яткан димәссең.

Барысы да берьюлы тынып калдылар. Гарифәгә дә унайсыз, кыен иде бу минутта.

— Мин нәрсә дип сезне сүз белән генә сыйлап торам әле. Юл йөреп ачыккансыздыр. Әйдәгез, тиз генә кулларыгызны юыгыз да өстәл янына килегез.

Кунаклар өстәл янына утырган арада Гарифә үзенең тәм-томнарын чыгарып тезде.

— Менә шомырт, балан пироглары, пәрәмәчләр дә пешергән идем, — Гарифә бер-бер артлы бизәкле чынаякларга хуш исләре анкып торган чәй ясый башлады. — Без җиләк-җимешне күбрәк урманнан җыябыз инде, Ходай нәрсә бирсә... Монда алмалар да бик кечкенә булып өлгерә, бакчаны бизәп торыр өчен генә. Аннан соң, шунысы сәер, урманда чия үсмәсә дә, чиягә барабыз, диләр биредә.

— Әйе, әйе, һәр якның үз сөйләме инде, — диде Гөлсем, әле һаман да унайсызлануын яшерә алмыйча. Шуны сиздереп, кулындагы эссе чәйле чынаягы да калтырап ала.

— Тартынмагыз инде, кунаклар, — Гарифә ничек тә булса Гөлсемне тынычландырырга теләде.

— Ашагыз, эчегез, хәзинәдә барын. Азат энем, әйдә, әйдә, син әбиенә үрнәк күрсәт әле, яшьләрчә бул.

— Тырышам инде, апа, тырышам. Менә, — диде ул, бушаган чынаягын күрсәтеп. — Бик зур рәхмәт чәегезгә. Шомырт пирогы да бик тәмле була икән, беренче мәртәбә ашавым. Әби, әгәр дә мин урамга чыгып керсәм, елга буена төшсәм, ачуланмассыңмы? Иртышны беренче күрүем бит.

Гөлсем ни әйтергә дә белмәде. Гарифә белән бергә-бер калу аны куркыта да иде. Шулай да ул икеләнеп булса да ризалык бирергә мәҗбүр булды.

— Яр буйларында сак бул, зур су — куркыныч, — дип өстәде.

— Әби, бер дә борчылма. — Азат урыныннан сикереп торды. Беренчедән, мин суга кермим, чөнки көз житеп килә. Икенчедән, мин — Идел буенда үскән Казан егете. Ә Идел — Иртыш кына түгел ул!

Азатның сүзен Гарифә дә җөпләде:

— Яшьләр бөтен нәрсәне күреп, белергә тели. Каршы килмәгез, Гөлсем — Гарифәнен, киресенчә, Гөлсем белән генә каласы килә иде.

Азат тиз генә киемен әләктереп чыгып китте.

Бер дә мондый хәлләрдә калганы юк иде Гөлсемнең. Кем ул Гарифә аның өчен? Көндәшеме?.. Аның уйларын Гарифә бүлде.

— Тагын берне ясыйм, сусагансыздыр, — диде ул, Гөлсемгә таба кулып сузып.

— Рәхмәт, рәхмәт! — Гөлсем чынаягын өстәлгә куйды да, әкрен генә дога кылып, урыныннан тора башлады. — Гарифә, сез безнең ни өчен килгәнне чамалыйсыздыр инде, — диде ул, челтәрле пәрдә эленгән тәрәзә янына басып. Тәрәзә төбендәге гөлләргә дә күз салып өлгерде һәм хуҗа хатынга таба борылды. — Мин даулашырга да, әгәр дә Хәбир безнеке булса, бүлешергә дә, аны алып кайтырга да килмәдем. Гомерем буе үземне борчыган сорауларга җавап табарга дип кенә килдем.

Гарифә дә өстәл яныннан торып китте.

— Мин сезне аңлыйм, Гөлсем. Төп сорауга хәзер үк җавап таба аласыз. Фотографияләр бар бит. Менә альбом, карагыз. Тик менә монда утырыгыз. — Ул Гөлсемне янә диванга утыртты.

Гарифә өстәл җыештыра башлады. Ә Гөлсем күзлеген киеп актарды да актарды альбомны. Инде уртасына җитте бугай, ләкин бер генә таныш йөз дә юк. Һәм... балалар белән елга буенда басып торган бер ир-атны күргәч, диванга сыгылып төште, кулындагы альбомы идәнгә шуды. Бу аның Хәбире иде.

— Хәбир, син бит бу, ничек булдыра алдың, — диде ул, ыңгырашып. — Бу дөнья шулай ялганга корылганмы? Күпме күз яшьләре... Болар барысы да юккамы?

Ә Гарифә Гөлсем тирәсендә бөтерелде.

— Түзегез, Гөлсем, түзегез. — Ул каяндыр дару табып, Гөлсемгә эчерде. — Сезгә нык булырга кирәк.

— Хәзер ул кайтып керсә, мин нишләрмен, ничек аның күзенә күренермен. — Аңына килгән Гөлсем нәрсә эшләргә дә белмәде. — Юлга чыкканда, мин боларның берсе турында да уйламаган идем шул. Нинди зур хыянәт бит бу!

— Гөлсем, тынычланыгыз. Сезнең күзлектән караганда, Хәбир бәлки хыянәтчедер. Ләкин мин алай уйламыйм. — Гарифә, иелеп, идәндәге альбомны өстәлгә алып куйды. — Без икәү генә, Хәбир кайтканчы сөйләшеп бетерергә кирәк.

— Белмим шул, безнең сөйләшү барып чыгар микән. — Гөлсем урыныннан тормакчы булды. Ләкин булдыра алмады. — Бәлки безгә кайтып китәргәдер.

— Гөлсем, Гөлсем, — диде Гарифә, елмаеп. — Без сезне беркая да җибәрмибез. Кунак булырсыз. Хәзер инде китәм дисәгез дә, китә алмыйсыз, Омск ягына теплоход иртәгә генә була.

— Килеп каптык алайса. — Гөлсемнең тагын кәефе төште.

— Кабатлап әйтәм, Гөлсем, тынычланыгыз. Җайлап утырыгыз. Менә мин дә утырам. — Гарифә диванның икенче башына утырды да сөйли башлады.

— Мин Кызыл Яр шәһәрендә укытучы булып эшли идем. Сугыштан соң безнең шәһәр янында зур гына лагерь төзеделәр. Нинди лагерь икәнен чамалыйсыздыр инде. Һәм Көнбатыштан эшелон-эшелон тоткыннар алып кайта башладылар. Сез аларның нинди хәлдә икәнен күз алдыгызга китерә алырсыз микән? Үзләре тире белән шыр сөяк, кыйналганнар. Өсләрендә сәләмә

киемнәр. Шәһәрдә хәбәр таралды: алар немец әсирлегеннән азат ителгән безнең солдатлар икән. Сугыш вакытында плен төшкән совет солдаты сатлыкжанга тиңләнгән бит. Берникадәр вакыттан соң шәһәр эчендәге төзелешләрдә эшләтә башлаганнар үзләрен. Бервакыт безнең мәктәпкә ремонт эшенә дип биш әсирне җибәрделәр. Сак астында инде, билгеле. Әй, кызгандык үзләрен! Җай чыккан саен аларга ашарга әзерләп бирә идек. Татар икәнен белгәч, Хәбирне ничектер якын итә башладым. Сөйләшеп киттек. Мин ана ныклап аякка басарга булыштым. Алар күргән газапларны сөйләсәң...

Гарифә сөйләп арыды бугай, туктап су эчеп килде.

— Лагерьдан азат иткәч, аларга тагын биш ел туган якларына кайтырга рөхсәт юк, дигәннәр. Кая барсын инде ул? Зур гөнаһ эшләмим микән дип курка-курка гына аны үзебезгә алып кайттым. Гарифәнең сүзләре Гөлсемне тетрәндерде.

— Боларның барысы да дөрес булса, аңа безгә караганда да кыенга туры килгән, — диде ул калтыраган тавыш белән. — Безнең җанны кыйнасалар да, тәнебезгә тия алмадылар.

— Сөйләвемдә бер артык сүз дә юк, Гөлсем, Ходай шаһит. Шулай да гомерем буе үземне кем алдындадыр гаепле итеп тоеп яшәдем. Менә хәзер аңладым инде, ул Гөлсем — сез икән.

— Бу очракта кемне гаепләргә дә белмәссең. — Гөлсем тагын тәрәзә янына килде, чәчәкле гөлләргә күз салды. — Бәлки мина сезнең алда баш иеп, рәхмәт әйтергә кирәктер. Хәбир сезнең кайгырту нәтиҗәсендә бүген исән-сау, Хәбир исән!

— Сез аны чынлап та бик яраткансыз икән.

Урамда салмак кына эт өргән тавыш ишетелүгә, Гарифә ишеккә таба юнәлде.

— Хәбир кайтты ахры. Этебез аны шулай иркәләнеп каршы ала.

Ә Гөлсем, чәбәләнеп, бүлмә буйлап йөри башлады:

— Хәбир?! Гарифә, әйтегезче, мин нишлим? Ничек итеп аның күзенә күреним? Аңа ниләр әйтим?

— Үзегезне кулга алыгыз, Гөлсем, — диде Гарифә, ишек тоткасыннан кулын алып. Нык булыгыз, нык булыгыз! Аның да йөрәге бик таушалган. Зинһар...

## 10

— Кунаклар бар димме? Хәбир, ишекне ача-ача, үзалдына сөйләнде. — Ишек төбендә аяк киемнәре күбәйгән. Гарифә, кайтып та җиттем. Менә балаларның күчтәнәчләрен алып куй.

Кулындагы төргәкләрен Гарифәгә тапшыргач кына, тәрәзә янында ни эшләргә дә белми басып торган Гөлсемгә игътибар итте.

— Кайсы күрше безне үзенең визиты белән сөендерде? — диде Хәбир, шаярып. — Картаю җиткән ахры, күзләр дә урамда калган. Кем соң әле бу?

Гарифә Хәбир биргән күчтәнәчләрне тиз генә икенче бүлмәгә чыгарып керде дә ире янына йөгереп килде, егылып китә күрмәсен тагын дип аның җилкәләреннән тотты.

— Хәбир... бүген безнең кунак ... Гөлсем...

— Гөлсем? Кайсы? Безнең авылда ничә Гөлсем бар соң әле?

— Хәбир, аңына кил. Гарифә аның җилкәләрен селкетте. — Бу... бу синең Гөлсемең.

— Гөл... Гөлсем. — Хәбир бераз артка чигенде, күзләрен угалады, көч-хәл белән сүзләрен әйтә алды. — Көттем мин сезне, ләкин син үзең килерсең дип башыма да китермәдем... Килдеңмени? Исәнме, Гөлсем?!

Ул күрешергә дип кулларын сузды, ләкин аяклары аны тыңламады, урынында катып калды.

Гөлсем дә баскан җиреннән кубып китә алмады, әйтерсең, кемдер аны өй стенасына көчләп терәгән дә җибәрми.

— Хәбир, синме соң бу? Үзең кайтмагач килдек инде менә, — дип кенә әйтеп өлгерде.

— Әйе, Гөлсем, чыннан да мин бу. Язмыш тарафыннан кыйналган, Сталин боерыгы белән тибелгән мескен бер солдат. Авылга, сезнең янга әйләнеп кайта алмавым да миңа чиксез җан газабы китерде. Барыгыз алдында да фәкать мин генә гаепле.

Хәбир Гарифәдән су сорап, кесәсеннән дару алып эчте дә диванга килеп утырды.

— Гомер буе күрешүне көттем. Әмма син үзең эзләп килерсең, дип... — Ул сүзен бетерә алмады.

Гөлсем Хәбиргә күз салды. Шушы ак чәчле, битендә сугыш ярасы булган, басынкыланган, әкрен хәрәкәтле ир-ат аның Хәбиреме соң бу? Яшь чак булса, инде әллә кайчан бер-берсенең кочагына ташланган булырлар иде. Ләкин аяклары кузгалмый. Әгәр дә мондый уңайсыз хәлгә каласын белсә, Гөлсем юлга да чыкмаган булыр иде. Үткән гомернең билгесезлеге хисләрне шулкадәр үзгәрткән, аның нечкә кылларын тупасландырган күрәсең.

— Әле үзем дә өнемме, төшемме дип аптырап карап торам. — Гөлсем Хәбиргә таба бер-ике адым атлады. — Күзләремә күнел буйсынмый. Үлгән, диделәр, кара кайгыларга баттым. Ә йөрәгем синең каядыр еракта-еракта безне күзәтеп, сагынып яшәвеңне тоеп торды.

... Чынлап та, синме соң бу Хәбир? Күз нурларымны түгеп, басу капкасыннан озатып калганда, ике-өч тапкыр борылып кул болгадың, көчле гәүдәңне туры тотып, ышанычлы адымнар белән, яңадан бер тапкыр да әйләнеп карамыйча китеп бардың. Күпме еллар үткән. Син бик каты үзгәргәнсең, ләкин тавышың элеккечә, мин сине таныдым...

Гөлсем үз-үзен кулга алып, диванга Хәбир янынарак килеп утырды.

— Борчылма, Хәбир, борчылма. Кая, бер тотып карыйм әле үзеңне. — Гөлсем Хәбирнең җилкәләренә, кулларына кагылып алды. — Татар тотып карамыйча ышанмас, диләр бит. Чынлап та, син бит бу, Хәбир. Зинһар, тынычлан, тынычлан. — Гөлсем урыныннан кузгалды. — Без бирегә гаепләне эзләргә дә, аңа җәза бирергә дә килмәдек.

— Гөлсем, син һаман без дип сөйләшәсең. — Хәбир дә торып китмәкче булган иде, ләкин барып чыкмады. — Ә калганнарыгыз кайда соң?

— Мин оныгым Азат белән килдем, — диде Гөлсем, җавап итеп. — Ул елга буйларын карыйм дип чыгып китте.

Моңа кадәр сүзгә кушылыргамы, кушылмаскамы дип торган Гарифәгә чыгып китәр өчен җай килде.

— Хәбир, Гөлсем, Азат нигәдер озаклады. Ул-бу була күрмәсен. Мин карап кайтыйм әле. Ә сез сөйләшә торыгыз.

## 11

Өйдә тынлык урнашты. Беренче булып сүзне Хәбир башлады:

— Гөлсем, йә сөйлә, ничек яшәдегез?

— Хәтерлисеңме? — дип башлады сүзен Гөлсем. Ул бераз тынычланган иде инде. — Безнең бакча башында, яр буенда, ялгыз каен бар иде. Сугыш

елларында, утынсыз вакытта да мин аны кистермәдем. Ул әле дә исән. Яр буенда ялгыз каен, ул берүзе. Аны җил-янгыр, кар-буран да кыйный. Ләкин каен бирешми, үсә дә үсә, яши дә яши. Күпме генә кыенлыклар күрсәм дә, бирешмәдем. — Ул бу урында ике егетемне үстердем, дип әйтмәкче булган иде, Хәбирнең йөрәгенә бәрер дип тыелып калды. — Аллага шөкер, бүгенгә хәлемә риза булып яши бирәм. Бер мин генә түгел, бөтен авыл шулай яшәде бит.

— Ә мине язмыш менә монда китереп ташлады.

— Әйе, Гарифә миңа барысын да сөйләде — Гөлсем, күпме генә үзен тыярга теләсә дә, булдыра алмады. — Шулай да кайтырга мөмкинлек булгандыр бит, — диде ул, өзгәләнеп. — Ничекләр түздең?

— Булмады шул, — Хәбир бүлмә буйлап ишекле-түрле йөри башлады. — Биш елдан соң... сатлыкҗан мөһере сугылган килеш...

— Аңлаган булыр идек әле.

— Лагерьда күргән кимсетелүләр, газаплардан соң, мин бөтенләй икенче кешегә әйләндем. Гаскәр һөҗүм итеп барганда, әсир төшкәч, безне бигрәк тә мыскыл иттеләр. Гарифә булмаса, мин күптән гүр иясе идем инде. Биш ел эчендә балалар туды. Бәлки мин күргән мәхшәрләр онытылыр дип, Кызыл Яр шәһәреннән китеп, менә шушы авылга килеп урнаштык.

— Ә туган ягыңа, безнең янга кайтырга бер дә теләгең булмадымыни?

— Их, Гөлсем, кешене аңлар өчен үзең аның урынында булып карарга кирәк шул. Ә бу мөмкин түгел. Сезне, туган якны беркайчан да онытмадым мин, качып кына булса да бер мәртәбә кайтып килдем.

— Ничек? — Аптыравы йөзенә чыккан Гөлсемгә бу сүзләр аяз көнне күк күкрәгәндәй булды.

Хәбир Гөлсемне өстәл янындагы йомшак урындыкка утыртты. Үзе шкафтан бер альбом алып, Гөлсем алдына куйды.

— Минем кайтуымны сез сизмәдегез дә бугай. Менә бу рәсемнәрегезне альбомыңнан алдым мин. Сагынган саен рәсемнәрегезгә карап яшәдем, — диде ул, күзләрен сөртеп.

— Ничек түзә алдың? Безне күрмичә ничек кире киттең? — Гөлсем моны һич кенә дә аңлый алмый иде.

— Дөресен әйткәндә, мин сезне күреп аңлашырмын дип кайткан идем. — Хәбир өстәлнең икенче башындагы урындыкка утырды. — Көз житеп килә, көннәр кыска, — диде ул, сүзен дәвам итеп. — Кичтән өйдә ут булса да, шакып керергә йөрәгем житмәде, печәнлектә, хуш исле печән өстендә иске тун бөркәнеп йокладым.

Иртә таңнан ике баланы ияртеп ишегалдына чыктың, утын кисә башладыгыз. Сез пычкы тешләрен батырып каен агачын кискәндә, минем дә җан җәрәхәтләрем киселеп, ачылган кебек булды. Мин исән килеш балаларымның ятим үсүенә гарьләнүдән күз яшенә буылдым. Тагын бер кат үземне сатлыкҗан мөһере сугылган мескен кеше итеп тойдым. Шуңа күрә мондый мескен хәлдә сезгә күренергә батырчылык итмәдем. Авылдашлар алдында да җавап тотасы бар бит әле.

— Сугыш күргән солдат батыр буладыр дип торам. Ә син үз йортыңның бусагасын да үтә алмагансың.

— Бәхәсләшергә җыенмыйм. Әмма, сез бикләп чыгып киткәч, куркуымны җиңеп, өйгә кердем мин. Стенадан, альбомнан балалар белән төшкән рәсемнәреңне алдым. Угры шикелле балаларның иске киемнәрен әләктердем.

Өйне бикләп, ачкычны урынына куйдым да ызаннан су буена төштем. Чишмә суларын эчеп, Урта елга буйлап станциягә юнәлдем. Поездда, Себергә кайтканда, улларымның киемнәрен баш астына салып, күрешү хыялларымны төшемдә күреп яттым.

Гөлсем нәрсәнедер хәтеренә төшерергә теләгәндәй бер ноктага карап торды.

— Елы хәтеремә төшми шул, бервакыт Хәбир кайткан дигән хәбәр таралган иде, дөрес булган икән.

— Күпме генә тырышсам да, кемдер күреп калган. Гөлсем, сөйлә инде, улларым турында сөйлә, авылдашлар ничек яши?

— Әгәр дә арымаган булсаң, сөйлим. Ләкин аякларым оеп килә бугай, торыйм әле мин. Гөлсем үзенең иялəнгән урынына, тәрәзә янына килеп басты.

— Малайлар, Аллага шөкер, укыдылар, әйбәт кенә эшләргә урнаштылар. Ильяс еракта, шахтада эшли, ә Равил Казанда төзелештә зур җитәкче. Бүген синең янга анын улы Азатны алып килдем. Синең белән бергә сугышка киткән Гыйльмулла да кайта алмады. Исеңдәме, Гыйльмулла сугышка киткәндә, авылда бригадир булып калган аксак Мәүләвигә, әгәр дә безнең хатыннарга бәйләнсән, төнлә кайтып агач мылтыктан атып китәрмен дигән иде. Үзәккә үткән вакытларда Мәүләвине атарга Гыйльмулла да кайтмый ичмасам, дип уфтана идек. Якын күршеләребез Минзифа белән Шәмсенур әйбәт кенә яшәп яталар. Безне озатып, сәлам юллап калдылар.

Гөлсем, нәрсәнедер искә төшерергә теләгәндәй, тагын бераз туктап торды.

— Ачыклыйсы тагын бер соравым бар иде. Берничә ел миңа исемсез генә акча килгәләде. Мин аны башта тотарга да куркып тордым. Өйне зурайтканда, малайларны укытканда ярап торды үзе. Акча салучы син түгел идеңме?

— Әйе, мин, — диде Хәбир, башын селкеп. — Шулай гына булса да ярдәм итим дип, жай килгән саен салып тордым. Пенсиягә чыккач, туктарга туры килде.

— Ә Гарифә? Ул сүз әйтмәдеме? — Гөлсем, читенсенеп, як-ягына карап алды.

— Юк, юк. Без бик килешеп, тату яшәдек. Ул да нәкъ синең шикелле олы йөрәкле кеше. Анын янында курыкмыйча сөйләшә аласың.

— Рәхмәт, Хәбир, бу ярдәмегез өчен. — Гөлсемнең күнеле йомшап китте. — Ә... ә син берәребез килер дип көттеңме?

— Ничек кенә әле. — Хәбирнең дә тавышы калтыранып китте. — Безнең авылның Газинур исемле егете килеп чыккач, тагын йокысыз төннәр башланды. Менә-менә берәр кеше килеп чыгар шикелле. Еш кына Иртыш ярына басып сезне көттем. Ләкин син үзең килерсең дип башыма да китермәдем. Син мине беркайчан да гафу итмәссең дип уйладым. Мең рәхмәт сиңа, Гөлсем, бу бит нинди бәхет.

Хәбир Гөлсемне кочаклап алды. Икесенең дә күзеннән кайнар яшь тамды.

— Берәрегез килсә, ничек итеп җавап тотармын дип баш ваттым. Гарифә белән дә күп уйлаштык. Бер якын дустым, әллә Индия киносындагы шикелле хәтеренне югалтасыңмы, дип киңәш тә биреп карады, тик без дөресен сөйләп бирергә булдык.

## 12

Гөлсем белән Хәбирнең аңлашуларын өзеп, урамда эт өргән тавыш ишетелде. Озак та үтми өй ишеге ачылды, Гарифә белән Азат килеп керделәр. Гөлсем оныгын шелтәләгән булды:

— Улым, бик озак йөрдең, борчыла башлаган идем инде.

— Яр буенда балык тотучы агайлар белән дуслашып киткән ул, — диде Гарифә, Азатны яклап. — Менә күчтәнәч тә биреп җибәрделәр, елга балыгы.

— Әби, безнең Иделдә андый балыклар бөтенләй юк. — Азат яңалыклары белән уртаклашырга ашыкты. — Стерлядь, диделәр.

— Андыйларны бездә качып кына тоталар. Закон кушмый. — Гарифә балыкларны икенче бүлмәгә алып чыгып китте.

Гөлсемгә тагын бер сынау аркылы үтәргә кирәк иде. Азат ничек кабул итәр бит.

— Улым, таныш бул, бабаең, — диде ул, Азатны Хәбир янына алып килеп.

Ә Азат югалып калмаска тырышты.

— Ничә еллар югалып торган Хәбир бабам шушы буламыни? — дип, аны кочаклап алудан тартынмады.

Хәбирнең күзләрен тагын яшь томалады.

— Улым, оныгым! Йа, Хода, бу көннәрне дә күрәсем бар икән. — Ул бертуктаусыз Азатның башыннан сыйпады. — Рәхмәт... рәхмәт сиңа Гөлсем!

— Бабай, ә бабай! Үзең безнеке, ә үзең Себердә яшәп ятасың?

— Шулай килеп чыкты инде, улым. Тормыш дигәнең бик катлаулы. Хәбир Азатны иңнәреннән кочаклап, тәрәзә янына алып килде. Пәрдәне читкә этәреп, елгага таба күрсәтте. — Менә сез шәһәрдән елга буйлап теплоходта килдегез. Син берәр нәрсәгә игътибар иттең микән?

Азат бераз уйланып торды.

— Э-э-э. Елгагыз бик тә бормалы-сырмалы. Теплоход зур тизлек белән бара да алмый, гел борылыш та борылыш. Аннан соң ярның бер ягында куе булып агачлар үсә, ә икенче ягында бер куак та юк.

— Тормыш та менә шундый. Борма-борма бара инде ул, улым. Кайсы борылышы сине үзе белән алып китә — эш шунда гына.

— Бабай, ә син безгә кайчан кунакка кайтасың? — Азат үзенең такылдавын дәвам итте.

Читтән генә күзәтеп торган Гөлсем аларның сүзенә кушылырга булды:

— Йә инде, улым, бабаең болай да алҗыган бүген, бик интектермә. Кайтыр ул, кайтыр... Юлга чыккач, мин сиңа барысын да үзем аңлатырмын...

Ул арада икенче бүлмәдән Гарифә чыгып житте.

— Сезне тиз генә җибәрү юк әле, рәхәтләнеп кунак булырсыз. Хәзер өстәл әзерлим, әйдә, Азат балам, син миңа булышырсың.

Азат теләр-теләмәс кенә Гарифә артыннан иярде.

— Чынлап та, Гарифә дөрес әйтә, — Хәбир Гөлсемгә таба борылды. — Әле бөтен авылыбыз турында да сөйлисең бар.

— Хәбир, без озак тора алмабыз шул.

Гөлсем өстәл тирәсендәге йомшак урындыкка барып утырды.

— Авылда өй ялгыз, күршеләргә күз-колак булыгыз дип кенә юлга чыктык. Зинһар, әллә ниләр уйлама, сәбәбе шул гына.

Моны ишетеп, Хәбирнең күңелсезләнүе йөзенә чыкты:

— Мин тагын нәрсә өмет итәргә тиеш инде. Бер киселгән икмәк...

— Юк, юк, алай түгел. — Гөлсем Хәбирне тынычландырырга ашыкты.

— Мин ... дистә еллар буе борчыган сорауларыма җавап таптым. Сине күрдек, Аллага шөкер, исән-сау икәнсең. Аңлыйм — барысына да каһәр суккан сугыш гаепле. Сугыш аерды, сугыш безгә янадан бергә булырга ирек бирмәде. Әйдә, каршыма утыр, минем йөрәгемдә бер генә дә үпкә хисе калмады. Ышан.

— Ә малайлар? Алар ни әйтер? — Хәбир Гөлсем каршындагы урындыкка утырды.

— Малайлармы? — Гөлсем бераз уйга калды. — Ике тәүлек буе кире авылга кайтасы бар. Азат белән без уйлашырбыз. Ә сиңа, Хәбир, исән чакта бер кайтып килергә кирәк... Гарифә белән. Җир астыннан юллар юк, диләр бит. Улларыбыз да, авыл халкы да аңлар, җинаятьче түгел бит син!

Хәбир белән Гөлсемне өстәл янына чакырырга дип чыккан Гарифә соңгы сүзләрне ишетеп калды.

— Гөлсем дөрес әйтә, — диде ул, Хәбир янына килеп. — Туган ягыңа кайтып, бөтенесен сөйләргә, аңлатырга кирәк. Ничә еллар җаның тыныч түгел, гомер буе болай дәвам итә алмый бит. Мәңгелек яраң бер төзәлергә тиеш. Гөлсем, кайтырбыз, Алла боерса, кайтырбыз, — дип дәвам итте ул, Гөлсемгә таба борылып. — Ә хәзер барыгызны да табын артына чакырам. Рәхим итегез!

## 13

Бераз вакыт узды. Кайтты Хәбир үзенең туган авылына, Гарифә белән кайтты. Ләкин бераз соңга калынган шул. Гөлсем юк, өй ялгыз. Ә өйнең ачкычы нәкъ элеккеге урында. Ут яндырмыйча гына эчкә үттеләр. Хәбир Гарифәне урындыкка утыртты да өй буйлап йөрде.

Менә бит — аның кайчандыр үз куллары белән салган өе. Дөрес, Гөлсем янкормалар эшләтеп, бераз зурайткан. Менә монда балалар үскәндер. Стенадагы фотоларны күреп, аның тагын күзенә яшь килде, йөрәге кысылды. Әтиләреннән башка үскән ике улы. Шуңа күрә алар янына барырга да, аларны күрергә дә хакы юк бит аның. Ләкин ул үзен тынычландырырга тырышты. Кесәсеннән алып даруын эчте. Әгәр дә ул туган нигезенә соңгы мәртәбә кайткан булса?.. Юк, юк! Хәбир мондый күңелсез уйларны башыннан куарга тырышты. Гарифә аннан башка ни эшләр?

— Хәбир, куркам мин! Берәрсе килеп керсә. — Гарифәнең тавышы Хәбирне айнытып җибәрде.

— Керсә соң, — диде ул, үҗәтләнеп. — Ә мин курыкмыйм. Дистә еллардан соң мин үз нигеземә кайттым. Мин үз өемдә.

Гарифә көлеп җибәрде.

— Әле кайчан гына минем шикелле үк берәрсе килеп кермәсә ярар иде дип куркак куян кебек калтыранып утырган Хәбир батырайды да куйды.

— Беләсеңме? Безнең якта, эт оясында көчле, диләр. Мин дә үз оямда.

Хәбир сумкасыннан кечкенә пластик шешәләр тартып чыгарды.

Берсен Гарифә алдына куйды. Икенчесеннән ләззәтләнеп үзе эчә башлады.

— Безнең чишмә суы. Искиткеч, — диде ул, бераз эчкәч. Дөрес, суга сокланырга ярамый, диләр, ләкин сокланмый мөмкин түгел.

— Ә безнең авылда коелар гына шул. — Гарифә бер-ике йотым су эчкәч, шешәне Хәбиргә сузды. — Иртыш суын да сезнең чишмә сулары белән чагыштырып булмый. Бер ияләнгәч, яшәргә була инде, шулай бит.

— Шулай, — диде Хәбир, сузып кына. Кеше барысына да күнегә, барысына

да тузә. — Безнең чишмәләр күбесе инеш буенда. Кыш көне юлларны кар күмә. Ә без, үҗәтләнеп, тар гына юллар салып, барыбер чишмәгә төшәбез. Инеш буенда таллар, өянкеләр үсә. Шул таллар, өянкеләр астында без ялан кул белән тота торган ялтыравык чабаклар йөзә. Э-эх!

— Гафу ит, алар хәзер бармы икән соң?

— Кызганыч, бик кызганыч. Алар юктыр инде. Сугыш вакытында авылдашлар агачларны да кисеп, мичкә ягып бетергәннәр. Дөрес, бездән астарак, ике инеш бергә кушылган җирдә, урман шикелле таллар, өянкеләр үсеп килә. Аларын авылдашлар өр-яңадан утыртканнар. Авыл аякка басып килә.

Хәбир тагын бүлмәдән бүлмәгә, ишекле-түрле йөри башлады. Истәлеккә өйдән фотолар алырга кирәк. Аннан соң... югалмаган булса, сарайда тимерче сандалы булырга тиеш. Аны бабай әтигә калдырган, чөнки миңа кадәр безнең нәселнең ир-атлары тимерче, балта остасы булганнар. Шуны алам, дип уйлады ул. Сандал югала торган әйбер түгел, үзе тимер, үзе авыр.

Ул шкафны ачып тагын нәрсәдер карамакчы булган иде, аннан идәнгә бер конверт шуып төште. Хәбир үзе дә сизмәстән утны кабызып, конвертны үрелеп алды.

«Балаларым Равил белән Ильяска. Мин мәңгелек йортка киткәч укырсыз»

— Гарифә, Гөлсемнең соңгы хаты, укыйммы?

— Гөнаһ булмаса инде, балаларыма, дигән бит. — Гарифә иренә каршы килергә батырчылык итмәде, аны дулкынландырмаска тырышты.

Хәбир нигәдер ашыкты. Гарифә аны өстәл янына алып килергә, урындыкка утыртырга гына өлгерде.

«Исәнмесез, минем кадерлеләрем. — Хәбирнең тавышы калтырады. Укуыннан туктарга мәҗбүр булды. Күзлеген, күзләрен кулъяулыгы белән сөртеп алды һәм укуын дәвам итте. — Озак яшәдем, Ходай Тәгаләгә рәхмәт. Ләкин ул барыбер көннәрдән бер көнне үз янына, мәңгелек йортка чакырачак. Кайберәүләр миңа, син ирең Хәбир гомерен дә яшисең, дип әйтә башлаганнар иде. Мин үземә Ходай тарафыннан бирелгән гомерне яшәдем. Ә этиегез Хәбир үз гомерен үзе дәвам итә, чөнки ул исән. Әйе, ул исән! Әтиегез Себердә, бер авылда яңа гаиләсе белән яшәп ята. Ләкин аның бер гаебе дә юк. Кызып китеп, уйламыйча, аңа нахак сүзләр әйтә күрмәгез тагын. Әтиегез күргәнне Ходай беркемгә дә күрсәтмәсен».

Хәбир кинәт арыды. Хатны кычкырып укырга аның хәле калмаган иде. Шулай да ул сүзсез генә хатның ахырына барып җитә алды. Укып бетергәч, алтын йөрәкле кеше булгансың икән, Гөлсем, дип кенә әйтә алды.

Гарифә Хәбир тирәсендә бөтерелде. Аңа тагын дару салып эчерде. Гөлсемнең олы йөрәкле, алтыннарга алыштырмаслык кеше икәнен ул үз авылларында ук аңлаган иде. Ничек итеп түзде бит Гөлсем. Бөтенесен үз эченә алып, безгә авыр булмасын дип, шул йөкне иннәренә салып кире кайтып китте бит ул.

— Әйе, әйе. Нинди авырлыклар кичереп, япа-ялгызы, ике улын үстереп, иренә ачу-үпкә сакламасын әле. — Хәбир әйтерсең Гарифәнең уйларын белеп, пышылдап кына дәвам итте. — Моның өчен фәрештә булырга кирәк бит, фәрештә. Хәер, син дә минем өчен фәрештә булдың бит, Гарифә. Үлемнән алып калдың. Син булмасаң, мин бу көннәрне күрә алыр идеммени?

— Хәбир, бәлки кузгалырга вакыттыр. Юлыбыз озын бит.

— Син хаклы. — Икесе дә урыннарыннан кузгалды. — Әле ярый кайтканбыз.

Мин бераз тынычландым шикелле. Ходай кушса, бәлки улларым белән дә очрашырмын әле. Кайтырлар бит алар минем янга, безнең янга, Гарифә, син шуңа ышанасыңмы?

— Ышанам, Хәбир, ышанам. — Гарифә үзләренең зур булмаган сумкаларын кулына алды. — Әниләренең соңгы васыяте бит.

Ишек төбенә килеп җиткәч, Хәбир тагын өй эчен күздән кичерде.

— Хуш, туган нигез, хуш авылым! Хуш Гөлсем! Син исән чакта кайта алмадым, шунысы аяныч.

...Матур җәй ае иде. Авыл зираты янына чия төсендәге җиңел машина килеп туктады. Машинадан өлкән яшьтәге ир белән хатын төштеләр, кулларында чәчәк бәйләмнәре иде. Алар борылып шофёрга нидер әйттеләр дә зиратка таба юнәлделәр. Капкага җиткәч, хатын туктап калды, ир кеше юлын үзе генә дәвам итте. Ул зират эчендә шактый озак йөрде, әле бер, әле икенче чардуган янына туктап, кабер ташларындагы язуларны укыды. Никадәр таныш исемнәр. Шушы авылдашлары белән бергә гомер итәргә тиеш иде бит ул, ә язмыш, аны әнә кайларга алып барып ташлады. Таныш булмаган ир-ат бер чардуган янында бик озак туктап торды, инде чирәм капларга өлгергән кабер өстенә чәчәк бәйләмнәре куйды. Түзә алмады, тимер рәшәткәләргә тотынып елап җибәрде. Куллары, буялган рәшәткә буйлап, шуып төште. Ул тезләнде, чардуган янындагы җирне кочты һәм ишетелер-ишетелмәс кенә пышылдады:

— Кичер мине, Гөлсем!

---

***Редакциядән:***

*Хөрмәтле авторларыбыз! «Кыска бәяннар конкурсы»на 2015 елның 1 апреленнән әсәрләр кабул итү төгәлләнде. Конкурска килгән бәяннар белән укучыларыбызны таныштыру дәвам итә.*



Фәнил
Гыйләҗев

## «УЯН, МИЛЛӘТ!» ДИЕП КӨЙЛИ ТАТАР

### Тукай ятимнәре

Тукай һәйкәле янында сукбайлар йоклап ята.
Ә ул, әйтерсең, аларны шигырь укып юата.
Шигырь укый хәзер Тукай Мәскәүнең иң түрендә,
«Тотса мәскәүләр якаң», — дип, як-якка төкеренә...

«Тотса мәскәүләр якаң», — дип ачындың татар улы.
Якага түгел, телләргә үрелде Мәскәү кулы.
Үрмәләде үпкәләргә якадан урыс кышы,
Ничә гасыр ютәллибез кайтаралмый бурычны.

Авызлар тулы кара кан, кыйган юк төкерергә,
Арабызда үрчи бара телсезләр, бөкреләр...
Ничә буын үсте инде кисек тел — иман белән.
Кителде күңел кыллары, изелдек «Иван» белән...

«Ваня» исемен көтәрде күпме татар малае,
Кысалар кысылган саен, акыл барды тараеп...
Татарлыктан бу тарлыкка төштек әле без нигә?
Телләребез «тырмаланды», дәшмәс булды әниләр...

Дәшкәннәре саулык өчен сагаеп сакауланды,
«Тырмалы» Мәскәү сөя шул шамакай, сакауларны...
Дәшмәүчеләр эчтән көеп, саргая барды һаман,
Кипкән яфрак тәкъдирләре көзләрен була яман...

Син дә корыдың яфрактай, язларда корыдың шул,
Урыс кышыннан үпкәңне үптереп туңдырдың шул...
Мәскәү уртасында бүген шигырь укый синең сын,
Сәрхуш сукбайлар төш күрә, тоеп шигырь җылысын.

Син үзең дә сукбай булып йөргәнсең өйдән өйгә,
Инде Мәскәү ятимнәре аяк очыңа килә...

---

Фәнил ГЫЙЛӘҖЕВ (1987) — *шагыйрь; «Ризасызлык» исемле шигырь китабы авторы. Казанда яши.*

## Җан авазы

*I Бөтендөнья сугышы татар әсирләренең тасмага яздырылган тавышлары илгә кайткач*

Милләтемнең авазлары кайтты,
Тавышлары кайтты Ватанга.
«Гафил булма!» — дип җыр суза алар,
Дәгъва белдерәләр заманга.

«Уян, милләт!» — диеп көйли татар
Алман зинданнары эчендә.
«Фашист» дигән исем алган халык
Җыр җырлаткан безнең өчен дә.

Радиолар гөрләп эшләп торган,
Мәҗмугалар анам телендә:
Халкым үзен милләт итеп тойган,
Васыять язган дошман җирендә.

Үз Ватаным зиндан булган чорда
Зинданнарда хөрлек көн күргән.
Фашизмның асыл йөзен ачып,
Җыр агыла йөрәк түреннән.

Җыр яңгырый: «Гафил булма!» — диеп
Һәм киная ташлап заманга.
Милләтемнең җан авазы кайтты,
Чорлар кичеп безнең Ватанга!

## Кайтмадылар

*Гаяз Исхакыйны күздә тотып*

Төрекләрнең атасы бар. Безнең
Кайталмады шул ул халкыма.
Ата сатучылар аз булмады
Ватан таккан мәсләк хакына.

Мәсләкләре өчен аталарны
Диварларга терәп аттылар,
Гулагларга ябып череттеләр,
«Дошман» исемнәре тактылар...

«Ата» берәү иде һәм ул ата
Кызганмады һичбер баласын,
Милләт аталары себер китте,
Җәсәд итте сөрген даласын.

Үксез милләт балалары ул чор
Күп кимерде кыен күсәген.
Ятимләнгән саен милләтемнең
Түбәнәя торды түшәме...

Баш хакына милләт аталары
Котылдылар качып чит җиргә.
Өмет белән гомер сөрде алар,
«Бер кайтырбыз» диеп «хөр илгә».

«Хөр Ватанга кайтам!» — диеп алар
Җан аттылар, акыл куйдылар.
Максатларның хакы кыйммәт булды,
Туганнарын, нәселен җуйдылар.

Кайтмадылар... Кендек каны тамган
Туфрак җәсәдләрен күммәде.
Милләт кенә түгел, ятим калды
Милләт атасының теләге.

...Ата сүзе кайтты чорлар аша,
Бер әманәт булып Ватанга:
Милләт рухы өчен аталарны
Кайтарырга вакыт татарга!

***

Истанбулның үзәгендә йөрим,
Төркиянең гүзәл каласында.
Һәр тарафтан агыла гына азан,
Мәчет күрәм, кайда карасам да.

Ә Казанда карлар яуган, диләр,
Монда яңгыр күзгә бәрә генә...
«Ватаныңа кайттың, хуш килдең!» — дип,
Төрек халкы үтә үзәгемә.

«Ватанына кайттың», — диләр мина,
Нәүмизләнеп читтә йөрим шулай.
Ватанымда азан тавышларын
Карлар күптән күмеп киткән бугай...

## Нигезсезләр

Авылда көз. Урам-бакчаларда
Тәлгәш-тәлгәш балан.
Тиздән кыш киләсен онытыпмы,
Миләш яфрак ярган...

Акъәбине кәфенлеккә төреп,
Жиргә иңдергәчтен,
Төп нигезне бер маржага сатып,
Читкә киткән яшьләр.

Азан янгыраган урамнарда
Инде дуңгыз чиный.
Моржа тишегенә өрә-өрә,
Шомлы жилләр улый...

Ызаннарын жуйган нигезләргә
Күсе иялләшкән.
Ят чүп баскан бу тарафка кире
Кайтмас инде яшьләр...

Дуңгыз чиный, әбкәм догалары
Сеңгән нигезләрдә.
Төп йортына сатлык булган ул жан
Үзе үксез бәндә.

Ил буенча нигезсезләр үрчи.
Кимеп бара иман.
Авыл бүген гүя иң азаккы
Могиканын жуйган.

## Җеназа

Манаралар калкып дәшеп тора...
Янгыратып күкләр пәрдәсен,
Мәзин азан әйтә...
Шул мизгелдә
Тын калмыйча ничек түзәрсен?

Азан белән намаз арасымы —
Яшәү белән үлем арасы?
Мәрхүмнәрне искә алган чакта,
Нәкъ шулай ук тынып каласын...

Мизгел генә бары,
Берни түгел.
Бөтен гомер бары бер мизгел!
Күкне ярып азан ишетелә:
Соклана да, сыктый да күнел...

Соклана да күнел, тетрәнә дә:
Гавәм сонарттырды намазга...
Дөнья куып — дөнья куйды берәү,
Намазлары мәнге казада...

Сонгы намаз.
Сонгы тәкбир.
Тынлык...
Яшь тыгыла килеп бугазга.
Алда ләхет ята.
Ул — намазсыз.
Һәм укыла аңа җеназа.



Рөстәм
Зарипов

# ҮЗГӘ ЮЛДА

ХИКӘЯ

Яшерен-батырын түгел, үзгәртеп кору елларында милли азатлык даулаган митингларда мин дә канат ярып йөрдем һәм иҗтимагый үзәк оештырган шаулы корылтайларда да катнаштым. Мөнбәрләргә менеп, авызым белән «кош» тотулар насыйп булмады булуын, хәлбуки бәгъзе кыю, чынбарлыктан бәйсез карарлар кабул иткәндә, башкалар сыман рух киеренкелеге кичереп утыруым хак. Җөмһүриятебез биләмәсендәге барча милек аныкы гына булырга тиеш, дип теләктәшлек итүемне дә кире кагарга җыенмыйм. «Тели белсәң — теләк, тели белмәсәң — имгәк» һәм «Хыялларыгыздан сак булыгыз, алар тормышка ашучан», дигәннәре раска чыгар дип кем уйлаган?

Ул заман мин, шәһәрчегебездә урнашкан, җөмһүриятебезгә күрше, башлыча урыслар яшәгән өлкәдәге берләшмәгә караган, стратегик мал белән эш йөртүче бай оешмада җитәкче урынбасары вазифасында идем. Фәрештәнең «амин» дигән мәленә туры килде ахры, шартлы рәвештә әйткәндә, фәлән йөз ат көчле трактордай идарәбезне, «Кырмыска» мотороллерын хәтерләткән җирле берләшмә аламасына «тагып», мөһерсез калдырып, бүлекчә дәрәҗәсенә төшерделәр. Озак та үтми гайбәт таралды, имеш, май яккан ипиле эш урыныңнан колак кагасың килмәсә, айныкын айга, каядыр, кемгәдер, күпмедер сәмән кертү сорала, рәтен ничек чыгарасың — анысы синең эш, закон нигезендә «саңагыңнан» эләктерсәләр, җавапны үзеңә тотасы, саранланып киреңә катсаң, «әнә барыр юлың» дияргә мөмкиннәр. Ә инде карусыз, җаен чыгара белмәүче «эш атлары»ның хезмәт хакларыннан, ике, өч япьле бухгалтерияне эшкә җигеп, «тиешлесен» басып барачаклар... Рас модасы шундый, каян килеп, кая китмәгән, диеште күпчелек... «Тот итен ашасыннар», диючеләр дә табылды... Ә бер ир-атыбыз, танышырга килгән баш түрәнең ни үзеннән, ни шкаф хәтле тән сакчыларыннан өркеп тормыйча, уйлаганнарын батырып әйтте... Әйтте һәм гаризасын атып, эштән китте... Ул китте, без калдык... Күрәсең, батырлык сирәк йөрәкләрне ияртә, ә куркаклык массаларны дагалый...

Афәт бай техника паркыбызны сыпырып алып китүдән соң башланды. Инде кирәк саен кичә генә үзебезнеке булганны, ялынып, зарурлыгын исбатлап, гариза язып алу көненә калдык. Тора-бара, техника йөртүчеләребез артыннан, алтын куллы төзүче һәм ремонтчыларыбызны артыкка чыгардылар. Алар урынына җимеш сатудан арткан таҗик малайлары юлланды.... Алар юллады, ә эш сыйфаты

өчен җавапны безгә тотасы... Аппетит ашаганда килә, дияргәме, берәм-берәм башка хезмәтләргә дә житештеләр... Берәү үлми, берәү көн күрми, идарәбез кыерлануы хисабына яңа баш оешма көннән-көн котая барып, дүрт катлы конторасы ике канат үстерде, янәшәсендә катлы-катлы яңа корпуслар калкып, өстәл артындагылар бүлмәләргә сыймый башлап бүселде... Ихаталары чит ил маркалы, берсеннән-берсе кәттә җинел машиналар белән тулды, сыймаганнары урамга чыгып, як-яклап тезелде... Безне «алу» хисабына әллә ниткән идарәләр, бүлекләр, үзәкләр хасил ителеп, һәркайсы, чыдап кына тор, әмер арты әмер яудырырга, ягъни «бүрәнә аркылы бүре куарга» кереште... Аларга баш итеп кем балалары, кем хатыны туганнары, кемнең нинди этлектә «янган» әшнәләре утыртылуы хакында тел озайтсаң, баш бетмәле... Ә йомышың төшеп, хозурларына барып чыксаң, ишек төбендәге әзмәвер гәүдәле сакчылар, чакырыпмы, үз ихтыярың беләнме килүеңне тәфтишли. Мең бәла белән бусагадан уза алсаң да, эш пеште түгел, кабинетлы «кирәкле кишер яфракларын» урыннарында табам димә, ярты көн зарыккач, пәйда булсалар, кабул итмәскә мөмкиннәр. Тапшырасы эш кәгазьләреңә, алар теләгәнне искә алып, төзәтмәләр кертим дисәң, янә бәла, урын тәкъдим итүче юк, коридорда, тәрәзә тупсасы төбендә юансаң, шул ышыгыңны күпсенеп кырын караучылар табыла, җыештыручы яки сакта торучы тамак төбе белән кисәтү ясарга да күп алмый...

Бер тапкыр коридордан барам шулай, күземә күренә мәллә дип торам, каршыма атаклы киноактёр Ильминский тудырган образ, Эльдар Рязанов төшергән «Карнавал төне» фильмы каһарманы килеп чыкмасынмы! Һәм шул ук мәлдә махсус киемле ике әзмәвер әллә каян пәйда булып, җилкәләремнән эләктереп алдылар да иң якын бер бүлмәгә очыртып алып кереп, диварга сыртым белән сылап куйдылар, тыпырчыныр җай юк. Баксаң, коридордан баш түрә узганда, юлында аңа һичкем очрарга, күренергә тиеш түгел икән... Кайда сез, итагатьле әүвәлге җитәкчеләрем, яһүдләрем, урысларым, дип, бүре булып уларсың, валлаһи. Алары бит очраганда танып, исемемне, әтинекен дә кушып әйтеп, кул биреп күрешә, хәл сораша, чәй, кофе тәкъдим итә торганнар иде... Чуан өстенә кутыр дигәндәй, уңөченче эш хакыбызны, башка өстәмәләребезне кыерлау хисабына, им өчен араларында бер татар кешесе юк, тик килмешәкләрдән генә гыйбарәт спорт командаларын асрамага алдылар... Житмәсә, шулар уйнаганны эштән соң вахта автобусы белән калага барып тамаша кылу «бәхетенә» дучар ителдек... Әйттерерләр әллә ни, кайчан гына башларына күн бүрек, артларына гараж мөдиренең ямаулы кәнәфие төс яңа башлыкларыбызның фамилияләре Форбс китабына үрмәләде...

Онытып торам икән, Мәскәүдән килгән «олы абзыйлар» катышкан җыелышка чакырылу бәхетенә ирешкәнем булды... Кадрлар бүлеге мөдирен «дирижёр» иткәннәр, башкала кунагы сөйләгәндә, ишарәсенә буйсынып, җинелчә, уртача һәм көчле дәрт белән куллар чабып, узган гасырдагы утызынчы елларны «ял иттердек»...

Хуш, татарча сүз байлыклары өтек-төтек, русчалары әлле-хөлле, кардәшлек, кавемдәшлек, әшнәлек җепләре аша бер-бере кендегенә берегешкән, умыру инстинкты куәтле милләттәш түрәләргә, янә килеп шактый җинеләеп калган эш хакыма һәм янача аралашу тәртибенә ияләшә генә башлаган идем, чираттагы җәйге ялымны бүлеп чакыртып алдылар да, имза куйдыртып, кулыма кош теле хәтле язу тоттырдылар... Анда «кыскартылуым» хәбәр ителә һәм эшләп тору өчен тәгаенләнгән ике ай дәверендә хезмәт биржасына исәпкә басу мөмкинлеге искәртелә. «Нәрсәләрдән кемнәрне ясадылар бит», — дип сукранучы төркем янынннан сөрлегебрәк узып киткәнем булды, шуны берәрсе күреп житкердеме? Җылы якка ял итәргә юллама алгач, берләшмә карамагында янарак

булдырылган, әмма хезмәттәшләр күнеленә бер дә хуш килмәгән ял йортында, түрәкәйләребез кардәш ыруыннан, таныш-белешләреннән тупланган төксе персонал карамагында мәҗбүри дүрт көн түләүле иза чигү тәртибен ошатмыйча, сүгенеп төкергәнемне берәр юньсезе барып «саттымы», югыйсә?..

Шәһәрчегебез авыл советына карый һәм «кыскартылу»га дучар булучыларга гадәттә сыер саву операторы һөнәрен үзләштерү тәкъдим итәлә.... Авылда эш бар анысы, әмма бит анда гомер бакый түләү ягы такыр: «Эш тә бир, акча да түлә, кызык икән син», — дип, көлдерергә яраталар... Аптыраганнан, бөек шагыйребез Дәрдемәнднең «сөт калыр, ватан китәр», дигән юлларын тәкрарлый-тәкрарлый, җөмһүриятебез башкаласына сәфәр чыгам... Ичмасам анда эшкә дәшүче язулы маңгай төртер таш баганалар адым саен... Иясез маэмай сыман шуларга «бәйләнеп» йөри торгач, тәки берсе күнелдә тычкан утыдай өмет кабыза алды. Җаваплылыгы чикләнгән «Айга менәсем килә» атлы фирма җирле милләт вәкилләренә теләсә нинди ранг җитәкчесе булырга юл ача, дип язылган, адрес, сеанс башлану вакыты һәм шактый саллы билет бәясе күрсәтелгән иде белдерүдә. «Асылынсаң асылын агачның асылына», — дип, тәртәләрне шул тарафка турыладым.

Фирма, чорыбызга хас финанс пирамидаларының бүлекчәләре үрнәгендә, зарурлыгы чамалы булу сәбәпле, тышкы диварлары штукатуркасы чатнап коела башлаган нинди мәдәният йортын арендалаган булып чыкты. Фойеда буфет эшли, подвалына гардероб урнашып, бүрегеңне, исәнрәк булыр дип, үзеңдә калдыруга кодалыйлар. Рәхмәт яугырлары, өс киемемне алып калдылар тагы. Күрәм, минем сыман бәхет кошын койрыгыннан эләктерергә ниятлеләр байтак... Гамил Афзалчарак әйтсәк, «күтәреләм кабат вестибюльгә, башта бүрек, түштә галстук...» Аңлашылса кирәк, буфетны читләтеп узасы килми. Өлеш тәлинкәсеннән томаттагы килька кисәкләре капкалап, бер-бер артлы өч чәркәне авыштыргач, «бүре билеты» тоттыруларыннан күңелне изеп торган ачуташның эри башлавын, эчкә бераз җылы йөгерүен тоям... Ул да булмый, сеанска чакырып кыңгырау чылтырый. Фәкыйрегез, төркем агымы ихтыярына берсүзсез буйсынып, ярымкараңгы тамаша залына үтә һәм билетта күрсәтелгән урынны шырпы сыза-сыза, кулны пешерә-пешерә эзләп, тәгаенләп, «иярләүгә» ирешә.

Менә залга ут эленә. Тик озакка түгел, түшәмдәге люстрадан саркыган яктылык челемнәре әкрен-әкрен сүрелеп, шомлы, күгәрек музыка яңгырый башлый һәм сүсәрә төшкән каракучкыл яшел хәтфә пәрдә, чыкырдаган авазлар чыгарып, якякка ачыла. Сәхнә идәненнән урыны-урыны белән күтәрелә башлаган ак томанны ерып, кызыл пинжәк, ак күлмәк кигән, яшел галстук таккан, түбәтәйле, җыйнак сакаллы берәү кыйгачлап килеп чыга һәм ак, тигез тешләрен җемелдәтеп:

— Әфәнделәр! — ди... — Барыбызны да бире килеп отуыбыз белән котлый, киләчәктә һәммәбез өчен дә бар да «окей» булачак, — дип, кулларын киң җәеп, баш бармакларын тырпайтып, сөенче ала. Зал ару хәбәрне озакка сузылган көчле алкышлар белән каршылый...

Кыйссамдагы кайбер төгәлсезлекләр, төшереп калдырулар өчен алдан ук гафу үтенәм, чөнки буфетта тукталыш хәтергә сеңдерү сәләтемә төзәтмәләр кертте булса кирәк, әгәр дә биредә ишеткән-күргәннәрем, гомумән, төш кенә булып чыкмаса. Анысын да кире кагып булмый, чөнки хәмер ипле ятты, «бишенче нокта»мны тарткан кәнәфием тирән һәм йомшак булып чыкты, җитмәсә караңгыда да байтак утырылды, мәмрәп йокыга киткән булсам, мен гафу... Ни генә булмасын, исемдә калганнарны кыскача теземнәргә салырга рөхсәт итегез...

— Мөхтәрәм җәмәгать! — дип тә төчеләнә сәхнәдәге көяз хадим. — Без Русия куенында яшибез. Ә һәр дәүләтчелекнең, мәгълүм ки, үз юлы. Әйдәгез, шул юлны тәгаенләүче алтын баганаларны искә төшереп узыйк. Тәүге багана — «Русьта эчү

— күнеллелек ул», дип, Болгардан килгән ислам дәгъватчыларын нәүмиз итүе белән кавемдәшләре мәхәббәтен казанган бөек кенәз Владимир. Күнеллелек тарафдары, үзегез беләсез, православие динен хуп күреп, армый-талмый Русьне чукындыра, һәм шул изге ниятта Полоцк каласын яулагач, ул җирле кенәз кызын ати-әнисе, абый-энесе, ил күз алдында, сайлаган «үзгә юл» хакына микән, көчли һәм сонрак, үзеннән үч алырга ниятен сизеп, җәзалата...

Төптән юан чыккан карсак гәүдәсенә, пеләш башына һәм әмерчел, гөбедән чыккандай тавышына караганда, отставкадагы таз майор булса кирәк, сикереп торып, сәхнәбездәге нотыкчыны тәкәллефсез генә бүлдерергә җөрьәт итте:

— Ниткән милләтче саташуы бу?

— Гафу итегез, хөрмәтлем, моны, Шәһри Санкт-Петербург университеты директоры, тарихчы-галим Валерий Возгрин шулай яза...

— Әкият! — дип куя майор, әмма үз-үзенә ышанычы кими төшкәнлеген ахмак елмаюы фашлый башлый...

— Әби патша заманында анын әлеге гөнаһы өчен тирәнтен үкенүен, тәүбә итүен сурәтләгән рәссамнар бәйгесе дә узмаган дисез инде алайса?..

— Җыен чыкмаган Питердан чыгар инде, — дип сукранып куйды таз майор, карлыгып китеп.

— Питерга ризасызлык белдерергә кем дип белдегез үзегезне?

Зал, гуелдәп, кичәбезнен алып баручысы шелтәсен шунда ук куәтләүне урынлы дип тапты. Дәгъва белдерүче каушады, сыртына тир бәреп, күлмәге аркасына ябышкан булуы да бик ихтимал.

— Икенче алтын багана исә беренче православ патша — Дүртенче Иван, — дип дәвам итте сәхнә тотучыбыз, кулы белән майорга утырырга ишарәләп. — Улын җан тәслим кылуына тукталып тормыйм, чөнки залда ат дагалаганда, ботын кыстыручы бакалар булуы беленде...

Сәхнә утчысы прожекторын майорнын пеләшенә юнәлтеп алды. Чыгыш ясаучыбыз тәбәнәк көрсидәге графиннан кырлы стаканга салып су эчте һәм өзелгән сүзен дәвам итте:

— Һәм нәкъ менә шул мәшһүр патша хакимлеге чорында җәмгыятьтәге югары катлам урынын «опричнина» дигән аталыштагы түбән катлам яулый. Инҗилдәге «һәм соңгылар беренче булырлар» дигән күрәзә аерым бер илдә әнә шул гайрәтле патша тарафыннан, Күкләрдән күрсәтмә буларак кабул ителеп, монарчы күрелмәгән кинлектә һәм алымда гамәлгә ашырыла. Пётр Беренче — өченче багана, боярларынын сакалларын бүкәндә чаптырып, ил элитасын сарай хезмәтчеләре, ихата кешеләре — двор-жан — дворяннарга алыштыра... Дүртенче багана, үзегез беләсез, Ленин бабакай. Ул да иске эздән тайпылмый әлбәттә, азмы-күпме кадәре түл җыйган, бәгъзе затлылыкка ирешкән өске катламны пыр туздырып ташлап, чүплек аксөякләренә югарыга хут ача... Бишенче багана — Сталин, шул сортнын өскә калку үзлеген тойгач, бер-берсен әләкләп батыру форсаты белән тәэмин итә...

— Шуннан ни? — дип аваз салды таз майор янәшәсендәге фил гәүдәле ханым.

— «Үзгә юл» идеясе искермәде, мадам, — дип җавап күндерде кызыл пинҗәкле, тигез тешле авызын бетканче ерып. — Мин боларны кемнәрнедер гаеп итү, ирештерү өчен дип сөйләмим, таз майорларыгыз тыныч йокласын, ә бары тик теләге барларга кәнәфи табышу хакына, нәрсәне ак, нәрсәне кара дип кабул итү отышлы икәнен сендерергә мәтәләнәм. Сизеп торам, ничек итеп нинди дә булса фирманын, гәжит-журналнын, теле-радио, пароходчылык яки авиация компанияләренен районнын, каланын, милли республиканын төрле номерлы җитәкчеләре була алу темасына күчүемне көтәсез. Әйе, бар шундый

рәсми булмаган куәтле, барысын да хәл итүче, ахыргы сүзне әйтергә сәләтле инстанция. Безнең «Айга менәсем килә» фирмасы исә мәгълүм шартларда аның белән эшлекле мөнәсәбәтләр урнаштыруга иреште...

Күзгә төтен җибәрәме бу бәндә, чынын сөйлиме, аңламассың. Алай да тын алырга тукталыш ясавыннан файдаланып, урысның күнеле булсын, чукыныйк инде, дигәндәй, янә гөрләтеп кул чабасы иттек...

— Монда кергәндә алган керү билетын, кәгазь-каләм салынган пакетыгызны югалтырга өлгермәгән булсагыз, үзегез теләгән дәрәҗәле вазифаны һәм шуна ирешкән очракта ниләр майтарырга җыенуыгызны тәфсилләп, исем-фамилиягезне, адресыгызны күрсәтергә онытмагыз. Биредә кинокамералар да эшли, унайсызланмыйча гына әйтегез әйтәсегезне, видеоязмалар шулай ук кая кирәк, шунда барып ирешәчәк. Сезгә ун минут вакыт бирелә. Башладык.

Без пакетларны чаштыр-чоштыр ачып, кәгазь-каләмнәрне алып, ашык-пошык язарга керештек. Ун минут «ә» дигәнче уза икән, шул беленде. Язганнарыбызны һәм каләмне кире пакетка салып, рәтләр буйлап йөренгән, кыска итәкле униформа кигән, хат ташучыныкы сыман кыйгач каешлы сумка таккан сылу туташларга тапшырабыз.

Җилкәдән эш төште, дип җиңел суласак, ашыкканбыз, алып баручы зал уртасына үтә күренмәле, лотерея уйната торган җайланма чыгарып утыртты. Аның аңлатуына караганда, отучылар, сәхнәгә күтәрелеп, үз проектларын кыскача бәян итә, һәм андый бәхетлеләрнең гаризасы Мәскәүдә чиратсыз каралып, җәһәтрәк хәл ителәчәк... Калганнарга бераз сабыр итәргә туры килә, чөнки илдә безнең сыман һавадагы торнага өмет баглаучылар чутсыз, имеш... Музыка уйный башлады. Шуның ышыгында сәхнәгә хатларыбызны җыеп алган матур аяклы, нәзкәй билле сылукайлар чыкты. Башларына ак яулык япканнар, кызыл итәкләре кыска, шул ук төстәге түфлиләре биек үкчәле, ә иелгәндә-бөгелгәндә яшькелт бикиниләре чагылып китә. Берсе каядыр, ниндидер төймәгә баскан иде, үтә күренмәле барабан зырылдап әйләнергә кереште. Икенчесе, безгә артын куеп, музыка ритмына тирбәлгәләп, әйләнеш туктаганны көтә башлады. Туктагач, иелеп, барабан уемнан озаклап, йомры артын бора-бора, шар тартып чыгарды. Шарын учында әйләндерә-әйләндерә, залга күрсәтте. Сигезле санын абайладык.

— Димәк, сигезенче рәттә утыручы ота, — дип белдерде алып баручы.

Минем каршыдагы рәт бит бу! Эсселе-суыклы булып киттем.

Барабан янә хәрәкәткә килде. Һәм, ни гаҗәп, туташ тартып чыгарган яна шарда янә сигезле саны язылган иде.

— Димәк, сигезенче рәт, сигезенче урын! — дип белдерде алып баручы. — Рәттән ике сигез. Казахчасы секиз-секиз була. Sex-sex, дисәк дә гаеп итмәссездер. Сигезенче рәт, сигезенче урындагы бәхетле зат, бире чакырыла! Рәхим итегез, гүзәл ханым, әйдүк, котәбез! Кул чабыйк, дуслар, бүгенге кичәбезнең секс-символына! — дип гөрләде сәхнә хуҗасы.

Калку күкрәкләре күлмәген ярып тышка омтылган, эре сөякле таза ханым, ашкынып сәхнәгә чыгуга, кулына микрофон китереп тоттырдылар.

— Кем булырга телисез? — дип тапырыклады алып баручы.

— Миңа барыбер, — диде ханым, артык исе китми генә. — Булсын кабинеты, машинасы, яхшы эш хакы, башка унайлыклары, өстәмәләре. Нинди өлкәгә каравы мөһим түгел.

— Белмәгән эш белән ничек идарә итмәкче буласыз? Комсомол оешмаларында эшләмәгән идегезме, алай-болай?!

— Партия кая кушса, шунда бардык. Ә җитәкче булып эшләү, ике тиен — бер акча хәзер. Бу күп җирдә шулай. Белемле пенсионер урынбасарлар, кумасыннар

өчен, рәхмәт йөзеннән, артларын жыртып үлгәнче тырыша. Урынына астан казып карерләр дип тә хәвефләнәсе юк. Мин бер үтә мокыт эре түрәне беләм. Ничек күтәрелгәнен әйтеп тормыйм, бәласеннән баш-аяк. Кичләрен, ләх исерек хәлендә, тән сакчылары машинасына төяп өенә кайтаралар аны. Кабинет ишеге төбендә утыручысы, кем килсә дә, йомышы белән кызыксына һәм әшне хәл итәрдәй карт-коры урынбасарларга озата. Бетте-китте.

Алып баручы беркавым башын кашып уйланып торды.

— Сигезгә сигез... Сигезле ике балдакны гәүдәләндерә, бу бит — кавышу символы. ЗАГС башлыгы булуга ничек карыйсыз?

— Әйттем ич инде.

— Ә шунда аяктан егарлык нинди яңалык кертәчәксез инде, теләгегезгә ирешсәгез?

Ханым тамак кырды һәм гәүдәсен төз тотып, «ә без болай да булдырабыз», дигәндәй, мода күрсәтүче туташлар сыман «йөзеп» йөренә-йөренә сөйләп китте:

— Дөнья әдәбиятыннан укып беләбез, фәхешханәләрдә хезмәт күрсәтүче туташлар, христианча күркәм исемнәрен кырыйга куеп торып, үзләренә ялтыравыклы, яңгырашлы кыска исемнәр алалар. Төрек сериалларыннан белдек, солтан хәрәмсарайларында хезмәт итүче, гафу итегез, печтерелгән ирләр дә мөселманча исемнәрен кырый калдырып, чәчәк яки башка назлы кыска исемнәргә тиендерелгән икән. Корабны ничек атасаң, ул шулай йөзәчәк, дигән әйтем бар. Татар юрап китерер, дигәне тагын. Милләттәшләребезнең байтагы газизләренә шундыйракларны сайлый башлады бит...

— Жаны теләгән жылан ите ашый, — дип куя алып баручы, түземсезләнеп. — Нишләргә жыенасың, син шуны бәян ит?

— Исемнәренә туры килгән эш урыннары хакында алдан кайгырта торуын үтенгән хатны хакимияткә күндереп!..

— Авызыңа бал да май! Тагын?

— Туган теленнән ваз кичкән милләттәшләргә, аларның ана телен белмәүче балалары документына махсус тамга куюны гамәлкә кертәм.

— «Зомби» дип түгелдер ич?

— Юк, «зомби» да, «зобани» да дип түгел, ә «толерант» дип. Бездә бу хәзер шулай атала. Киләчәктә шундыйларга, аерылып торсын өчен, нииндидер өстенлек оештырасы иде...

— Андыйлар хәзер бик күп бит... Бюджетка авырлык китермәгәе.

— Трамвайда бушлай йөрү, мәсәлән?..

— Алар Казанда бетте түгелме соң инде?

— Калды, бер-ике маршрут. Менә шунда барып, бушлай жилләнеп кайтсалар, кемгә зыян?

— Мин каршы түгел.

— Бәрәкалла.

Залда көлешә башладылар, кемнәрдер кул чаба, хәлбуки урыны-урыны белән ризасызлык белдереп, сызгыручылар да табылды. Күрәсең, болары үзләре килделе-китте исем ияләре булды ахры. Яисә балаларына шундыйны ябыштырганнардыр? Нихәл итмәк кирәк, бездә бит ару гына саналган кешеләр туган теленнән ваз кичә, балалары арасында Тузик сымаграк исем йөрткәннәре дә юк түгел...

Янә барабан әйләндерелде. Инде башка бер бәхетле, күзенә ак-кара күренми, алга ыргылды... Сәхнәдән бәхетле елмаеп төшеп килүче гүзәлкәйне жилкәсе белән әздән генә бәреп очырмады.

...Алып баручы әйтүенчә, бу уен әле төн уртасына кадәр дәвам итәчәк, имеш...

Менә уртага ап-ап йөзле, сипкелле, сары чәчле, почык борынын сәхнә баскычына бәреп сыдыртырга өлгергән зат пәйда булды... Ул үзен аһәңнәр

шаһы дип таныштырды, исәбе — опера, оперетта театрларын, музыкага бәйле барча уку йортларын, уртачасын, югарысын бер түбә астына кертеп, шуларга баш һәм түш булу, академик исеме алу икән.

— Бүгенге сәхнә йолдызларына үзләрен җырчы дип санау гына җитми, композиторлыкка дәгъва итәләр, «Эт сөяккә бара», «Мәче багана башына бер менә, бер төшә» кебек аталышларга лаек корамаларын миңа ташыйлар, кайсы төректән «сөртә», кайсы һиндтән чута, урыс частушкасын йолкыштыручылар байтак, — дип башлады ул чыгышын, ашыга-кабалана. — Шуларның кәлҗемәләрен, оста ашчы ысулында, чит-ят тәмләткечләр дә өстәштереп, рухи азык сыйфатында сәхнәләргә, эфирга юлларлык хәлгә китерәм... Менә шундый татар моңыннан җәяүләп качкан хезмәт җимеше халык теленә «минусовка» дип кереп киткән... Шул «тискәре тамгалы» җирлеккә «йолдыз» җырлавын язу әле эшнең яртысы гына, фонограмма кулланышка әзер товар булсын өчен, аның тавышын төзәтергә, чистартырга, кытыршы җирләрен кыргычлап, җитмәгән төшләренә өстәштерергә кирәк...

«Аһәңнәр шаһы», сүзеннән бүленеп, үзен тынлыйлар, аңлыйлар микән дип, беркавым залга сөзеп карап торды һәм «кибәнен очларга» кереште.

— Бик күпләр минем аркада әллә кем чутында хәзер. Аларны беләләр, мине — юк. Ә минем үзенчәлекле иҗатымның өслүбен һәркем танырлык, теләсә кайсы җырның очлам өлешенә, кайта-кайта, кат-кат кабатлану тегәм, башлам шулай ук кайтарып-кайтарып уйналу сәбәпле, фонограммага ияреп ирен селкетүче, шактый ара сәер елмаеп, тез сыгылдыргалап торуга мәхкүм. Кайсы берсе, аптыраганнан, әле уңга, әле сулга кулын сузып куя. Эфир, сәхнә аша татар галәменә мин тутырганнардан чыгып бакканда, Сәйдәш, Яруллин, Яхиннар иҗаты ташка үлчим, хәтта кушылышта, әллә бар, әллә юк. Хәзер аларга ихтыяҗ да калмады, потлары бер тиен.

— Бәлки калдырылмагандыр? — дип кычкыра кайсыдыр, зал түреннән.

— Ә нишләп бар эшләнмәләрегез дә такмакчыл соң сезнең? — дип кызыксынасы итә алып баручы. — Аларны, кукиш сыман, тик өч нотадан гына корыштыруыгызның сере нәрсәдә?

— Соравына күрә тәкъдиме, имамына күрә тәкъбире, — дип кырт кисә җавап тотучы. — Сагыш-моң, авыр уйлар, кайгы-хәсрәт, язмыш катлаулылыгын җырга салу милләтебезне озак дәверләр йончытты лабаса, бәлки җитеп торыр? Татарга үз-үзеннән, үз рухыннан ял итәргә кирәк әзрәк... Ахмак — шат. Тиле — аннан да бәхетле, артына типсәләр, авыртмады дип куана... Табигатьтә аң юк, тик инстинктлар гына. Безгә яшәү хисен җуймау өчен гадиләшү лазем... Милләтне аңсызлык коткарачак.

— Җырчыларыгызның фонограммаларны артык каты акыртуларына аңлатма бирмәссез микән?

— Колакка катырак алар... Урысча әйтсәк, слухлары ташка үлчим...

Менә табак битле, әкәмәт дәү, бәрәңге борынлы, йомшак тавышлы сүз алды.

— Мин — танылган шагыйрь, — дип игълан итте ул — һәм, һәйкәл сыман катып, берара тын калып торды. — Исем-титулларымны, алган бүләкләрем исемлеген җепкә тезсәң, Самосыр тавына хәтле сузыла. Чыгарган китапларымны атка төяп карадым, тарта алмый. Һәм минеке сыман өслүб беркемдә юк! Ач-ялангач суфилар ысулындагы робагыйларның туклыкта иҗат ителгәннәре дисеңме, японнарныкы төсле өч-дүрт юллыкларны, самурайларның бусидоларын бар дип тә белми тәпәләгәннәре дисеңме, кыскасы, кайсын телисең, катыгын аша...

— Шуннан?

— Инде хаким партиягә кереп, депутат булып сайланып, парламентта гимнастика белән шөгыльләнәсем килә.

...Вакыт уза, сәхнә кыза. Ниндидер чалмалы, намаз вакытларын аерым бер төбәктә үзгәртеп, дини тормышны җанландырырга җыенуын сөйли башлагач, күк күкрәп, берара сәхнәдә ут сүнеп алды. Үзен сынчы дип таныштыручы, Тукайны, чорына карап, әле декабрист, әле большевик, әле хак мөселман итеп тасвирлауларга тукталып, аны шагыйрь буларак, пар атта җилдергән халәтен гәүдәләндерергә вакыт дип белдерде. Сәйдәш тә, сынчы фикеренчә, тәмәке төпчеге өелгән урнага сөялеп түгел, ә оркестр белән идарә иткән таякчыгына былбыл кунган гәүдәләнештә халык күңелендә яши...

Ниһаять, шарлардагы саннар мин утырган ноктада кисеште. Чыктым яктыртылган мәйданчыкка, карап торам өстән аска. Гоголь әйтмешли, йөзләр күрәсе килә, ә анда танаулар, танаулар... Әллә нәрсәсенә тез буыннарым калтырый башлады. Алып баручы сөйләргә тиешлегемне искәртеп ишарәләр ясый. Кемдер әйткән иде, сәхнәгә чыккач дулкынлансаң, үзеңне — көтүче, залдагыларны сарык көтүе санап хис ит, дип. Итәрсең, бар. Сарыклар бердәм күзгә бакмый бит ул. Янә бер танышым, кемнәрдер алдында каушасаң, ике кулыңны чалбар кесәнә тык та бармакларыңнан кукиш укмаштыр дигән иде... Тукта, монысы бераз булыша шикелле... Йөткереп куям һәм ни булса, шул булыр дип, автоочыш халәтендә нәрсәләрдер такылдарга керешәм...

Имеш, үзем хыялланган биек урынга менгереп утыртсалар, әүвәле түрәлек кәнәфиләрен тик конкурс аша яулауны җайга салам. Милли ясле, балалар бакчалары, мәктәпләр, милли университетлар ачыла, Сөембикә-ханбикәгә һәйкәл салына, һәм башка шуның ишеләр унай якка хәл ителә...

Залда утыручылар әйткән бер җөмләм саен пырх-пырх көлеп куялар, күрәсең, сөйләгәннәремне тапкырлау таблицасына иш санproblemsйлар... Исәп бирешмәскә, тешләрне кыса төшеп, үҗәтләнеп дәвам итәм:

— Төрле исем, бүләк, титул алучыларны, аларга шуны бирүчеләрне абруйлы жюри хозурына бастырам. Ничек алганнар, ник биргәннәр, эчтәлектән хәбәрләре бармы?

...Мишәр әйтмешли, «сүмәделәр бугай мине бирелә». ...Төшеп киттем сәхнәләреннән... Кая ди кул чабу, урыныма барып җиткәнче сызгырдылар, аяк дөбердәтteләр... Бәлки хуплауларын шулай аңлатканнардыр, шайтан белсен...

Менә тамаша мәйданына аркасы бераз гына бөкрерәк, чәче алдан коелып, тар мангае киң күренүче, калын йөнтәс кашлы, озын йонлач куллы, урта яшьләрдәге кемсә күтәрелде. Ул сәхнә уртасына чыгып, артка почмак ясап авыша төшеп, авырлыгы үзәген тәгаенләде һәм, түш кесәсеннән тарак чыгарып, барлы-юклы чәчен, аннары куе кашларын тарап куйды...

— Йә әфәндем, сезнең нәүбәт, сайрап җибәрегез! — диде алып баручы, авызын киң ачып иснәштереп. Кемнәрне, ничек итеп, нишләтергә җыенасыз?

...Монысы минем бакчага таш иде бугай, тарафыма бармак төртеп күрсәтеп хихылдаучылар табылды.

— Әссәламегаләйкем, мөхтәрәм ватандашлар! — дип сәламләде яна номинант чыңлап торган көмеш тавыш белән.

Тамашачыларны гүя алмаштырып куйдылар. Гүя катгый әмергә буйсынып, залдагылар урыннардан кубып, алкышлый башламасынмы?!. Агайның тугызынчы рәттәге тугызынчы урыннан булуы шулай тәэсир итте, ахры... Ул, кулын сузып, туктарга ишарәли. Буйсыналар, шайтан алгыры!.. Мин дә буйсынам, инәннең койрыгы!..

— Яшәсен икейөзлелек! Без бер күзәнәкле амёбалар түгел. Житәкче өчен икейөзлелек ул — минимум! Кул астындагылар өчен тешләгәнен өзә торган бульдог булу кулай, ә өстәгеләр катында пудель булып сырпалану хәерле, — дип тезеп китте әлеге иптәш. — Яшәү моделен эт үрнәгенә каулау — менә нәрсә бу буталчык дөньяны

тәртипкә кертәчәк. Иң әүвәле нишләргә дисезме? Иң әүвәле каравылчылар штатын арттырырга! Каравылчы, — гафу итегез, ул — эт вазифасы. Бездә алар һәр капка, һәр ишек төбендә, күбәүләп, өерелеп торырга тиеш. Җәмгыятьнең һәр күзәнәгенә эт рухы сеңсен! Эт ул, бик беләсегез килсә, тугрылык символы да. Шәп урынны эләктерү бер хәл, аны саклап калу өчен көн дә көрәшәсе. Тез астына бәрмәсеннәр дисәң, тугрылык уралышында калу хәерле. Кем әйтмешли, угры булсын, вәләкин, тугры булсын. Хакимият һәм интеллигенция. Аның да иҗади дигән төре шаукымлы. Халыкка безнеке түгел, алар сүзе кадерлерәк. Нишләргәме? Очсызларга аларны... Әйтик, житештерү даирәсендә дәрәҗәле, һәрнәрсәне гади хәл итү юлын табарга сәләтле белгечләр була. Әбит, беләсез, гади кеше тормышын артык гадиләштерсәң, бугазына үрелә башлавы ерак йөрми. Мәсьәләне катлауландыра, бутап бетерә торган эшем иясләре дә кирәк. Гавамны тулаем буйсынып кушканны гына үтәүчеләргә әйләндерү өчен, әйтик, укытучыларны һәр дәресен ничек укытуы, табибларны, һәр авыруны ничек дәвалавы, полиция хезмәткәрен кайсы җинаятьне адым-адым ничек эзәрләкләве турында көн дә бер калын дәфтәрлек хисап тоттырып аптырату аша хәл итеп була... Әдәбият-сәнгать өлкәсендә казганучыларны җимле тагаракка күнектерерү кулай...

Агай туктап тын ала, түш кесәсеннән почмагы күренеп торган аклы, яшелле, кызыллы кульяулыгын алып, тирләгән маңгаен корыта. Ә без, шушы ара, буш ара, дип тагын кул чабабыз. Ул таныш ишарәсе белән безне янә туктата һәм өзелгән сүзен ялгап дәвам итә.

— Мине беренче җаваплы вазифага эти урнаштырды. Хуҗам, эти дусты да булгач, киләчәктә көндәшлек ихтималын кисәтеп, канатларымны кыркуны кайгыртмады... Үзем дә, эти сүзен сүз итеп, һәр әйткәнен абына-сөртенә үтәргә, һәр җил чыгаруына «ярхәмикалла» дияргә ашыктым. Бермәл сизәм, агаем шәхсән үзенә «мичкә» тәгәрәтсәләр дә, әллә ни чәбәләнми, әмма мина берәрсе акаеп караса, бетте, җене чыга, ярсый, андыйны «ашап ташлавы» да ерак йөрми. Күрәсең, мин фәкыйрь койрык ролендә аның белән табигый ялганышка кергәнмен һәм миңа карата һәртөрле эләктерүләр, чеметүләр аның үзәк нерв системасына бәрә башлаган. Озын сүзнең кыскасы, теләгәнемә ирешсәм, үзем җитәкчелек иткән даирәдә әнә шул тәҗрибәм аша «койрык проекты»н һәр җәһәттә, тармакта хутка җибәрәчәкмен. Һәр шәхес койрык йөртүче һәм бер үк вакытта үзен койрык дип тә хис итсә, бу һәркайда тотрыклылык тәэмин итәчәк.

— Гелән арт сан күрү һәм иснәү ялыктырмас дисеңме? — дип кызыксынды алып баручы.

— Урыс шагыйре Андрей Вознесенский нәрсә ди? Бер координатлар системасында эт койрык болгый, икенчесендә — койрык этне, ди. Мин инде «эт»ләрне байтак селкештердем! Үземне дә йолкыштырганнары булды, шөкер...

Без түзмәдек, янә урыннардан кубып, көлешә-көлешә гөрләтеп, инде туктый алмый кул чаба башладык. Көтелмәгән тирбәлешләр давылыннан, кайчандыр ак булган, инде саргая төшкән түшәмебез әкрен генә диварлардан кубып күтәрелде һәм калае күгәреп ашала төшкән чатырлы түбәне дә эләктереп кузгалып китте...

Өйгә кайчан, ничек кайтып җиткәнне һич хәтерләмим. Алай да икенче көнне ике ай узганын көтми исәп-хисапны ясарга дип эш урыныма килсәм, сюрприз көтә, идарәбездә каравылчылар штатын арттырганнар икән, төркем башлыгы урынбасары урынын тәкъдим итәләр, эш хакым элеккесеннән бермәбер югары булачак. Үрря...

# НАСРЕТДИН ХУҖА БУЛГАН ИДДӘ

*Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында Н.Исәнбәтнең «Хуҗа Насретдин» спектакле куелу уңаеннан Татарстанның халык язучысы **Рабит Батулланың** спектакльне сәхнәгә куючы, театрның баш режиссёры **Фәрит Бикчәнтәев** белән әңгәмәсе.*

«Хуҗа Насретдин» — драматург Нәкый ага Исәнбәт тарафыннан 1940 елда языла һәм шул ук елда Камал театрында куела да. Икенче тапкыр ул пьеса 1952 елда янадан куела. Насретдин ролендә — Хәлил Әбҗәлил белән Касыйм Шамил. Бу тамаша 1956 елда Мәскәүдә уздырылган декадада катнаша һәм гаять зур уңыш казана. 1966 елда ул тагын куела, режиссёры — Хөсәен Уразиков, Хуҗа ролендә Фуат Халитов, Рәфкать Бикчәнтәев, Абдулла Шамуковлар була. 1989 елда исә бу пьесаны Марсель Сәлимҗанов куйды, Хуҗа ролен Равил Шәрәфи башкарган иде. Тинчурин театрында да «Хуҗа Насретдин» куелды, режиссёры — Рәшит Заһидуллин, Хуҗа ролен Алмаз Фәтхуллин уйнады.

Камал театрында иң күп уйналган пьесаларның «биш бармакка» кергәннәре арасында «Хуҗа Насретдин» иң алдагыларның берсе: Тинчуринның «Зәңгәр шәл»е, Исәнбәтнең «Хуҗа Насретдин»ы, Хөсәеневнең «Әни килде»се, Туфанның «Әлдермештән Әлмәндәр»е, «Диләфрүзгә дүрт кияү»е, Батулланың «Кичер мине, әнкәй»е... Еллар буе репертуардан төшми уйналган әсәрләр.

Һәм менә соңгы куелышында (чирек гасыр узганнан соң) үлемсез Феникс кошы кебек, «Хуҗа Насретдин» тагын сәхнәдә җанланды.

Әлбәттә, алдагы куелышлары һәрвакыт тамашачы каршында уңыш казана килде. Башкаручылар җанландырган һәр Хуҗа аерым, үзенчәлекле иде. Без, өлкән буын, Хәлил Әбҗәлиловның «Хуҗа»сын оныта алмыйбыз. Тамашачы бит ул консерватор. Хәлил аганың уйнавы безнең буын тамашачысы өчен канун иде. Башка «Хуҗа»ларны безнең буын кабул итә алмый. Әйтик, Шәүкәт ага Биктимеровның Әлмәндәрне уйнавы әле һаман да эталон, канун булып тора һәм Шәүкәт аганың Әлмәндәрен караган кеше, әгәр «Әлдермештән Әлмәндәр» янадан куела калса, бүтән актёр башкаруында Әлмәндәрне кабул итә алмаячак. Ләкин борынгы сәхнә осталары уйнаганны күрмәгәннәргә Хуҗаны Фәтхуллин уйнавы да эталон кебектер бәлки. Мәсәлән, башка Насретдиннарны күрмәгән тамашачы Равил Шәрәфине эталон буларак кабул итте. Һичшиксез, бүген Хуҗа роленә алынган актёр сәхнә классикларын оныттырырдай итеп уйнаса, бу — актёрның зур уңышы булыр иде.

Хәер, әйттем исә кайттым, һәр заманның үз Насретдины, һәр заманның үз Әлмәндәре булырга тиеш. Бу — табигый. Ләкин Хуҗаны уйнарга алынган актёр классик артистларны да өйрәнергә, аларның уңай якларын алырга, спектакльдән спектакльгә килгән кабатлауларын кире кагарга тиеш була. Юкса, яңа образ классикларны кабатлауга гына кайтып калыр иде. Бу гамәл режиссёрларга да кагыла. Ләкин классикларны кабатламыйм дип, мөгез чыгарулар да булгалады татар сәхнәсендә. Бер тарафтан икенчесенә ташлану да чын рәссам, чын актёр, чын режиссёрга хас гамәл булырга тиеш түгел.

«Галиябану» пьесасын уйнамаган театр, уйнамаган актёр, куймаган режиссёр юктыр. Театрның акча эшләре ташка килеп төртелгәч, янчык тутырыр өчен тиз-тиз «Галиябану»ны куя торганнар иде. Камал театрының Мәскәүдә булган олы гастролендә спектакльләргә халык йөрмәгәч, башка спектакльләрдәге җиһазларны яраклаштырып, тиз генә, гастроль репертуарында булмаган килеш, «Галиябану»ны уйный башладылар. Коткарды «Галиябану» театрны. Ә менә 70 еллар башында

ТДАТта куелган «Галиябану» спектакле бармады, аңа халык йөрмәде, чөнки ул спектакль искечә режиссура, искечә актёр уены, искечә сәхнә җиһазлары белән куелган иде. Пьеса искергән, дигән нәтиҗәгә килделәр. Шул ук елны Мәҗит Гафури исемендәге Башкорт драма театры Казандагы гастролендә «Галиябану» спектаклен уйнап, гадәттән тыш уңыш казанды. Пьеса искермәгән. Искергән иске алымнарны бер кырыйга куеп, «Галиябану»ны яңача яңгырата алды Уфа театры.

«Хуҗа Насретдин»нең яңа куелышын карап кайткач, мин Нәкый аганың кызы Йолдыз Исәнбәткә чылтыраттым. Кызганыч ки, Йолдыз ханым авыру сәбәпле театрга килә алмаган, ул бер ай инде авырып ята икән. Шулай да без кыскача гына сөйләшеп ала алдык.

— Мин кырыгынчы елдан бирле «Хуҗа Насретдин»ны һәр куелышында карый идем, — дип сүз башлады Йолдыз ханым, — күп мәртәбәләр карый идем. Артистларның сүзләрен яттан белә идем. Балаларга әкият сөйли ата-анасы, күп мәртәбәләр шул ук әкиятне сөйлиләр. Бала әкиятне яттан белә, ата-анасы берәр җирдә ялгышса, сүзләрен алмаштырса, бала, юк, алай түгел, дип атасын төзәтә. Ул әкиятнең эчтәлеген белә бит, кат-кат сөйләтә, ул кабатлаудан ләззәт ала һәм әкиятнең үзгәрүен теләми. Мин дә һәр спектакльне яттан белә идем һәм мин текстның үзгәрүен теләми идем. «Хуҗа» бит ул гел бертөрле куела иде. Әмма Хәлил абый бер төрле уйный, Фуат абый икенче төрле уйный Хуҗаны.

**— Әйе, Хәлил аганың Хуҗасы җиңел сөякле, көләч иде. Фуат абыйның Хуҗасы бераз авыррак, саллырак иде.**

— Шуңа күрә мин Фәритнең «Хуҗа»сын карарга да шүрлим. Минем элеккеге Хуҗаларымнан аерыласым килми. Кабул итә алырмынмы мин яңа куелышны, юкмы, әйтүе кыен. Шулай да сәламәтләнеп чыккач та театрга барам, Алла боерса!

Юбилей мөнәсәбәтләре илә халык өметләре акландымы соң?

Чыннан да, «Хуҗа Насретдин»нең беренче тапкыр куелышына 75 ел тулды бит. Яңа тамаша шушы бәйрәмгә аталгандыр кебек. Классика димичә, ни диярсең, валлаһи.

Без дә «Хуҗа Насретдин»нең яңа куелышындагы спектакльне зарыгып көттек. Һич шик юк ки, бу тамаша яшәргә хаклы!

Режиссёр да, рәссам да, композитор да, кием-салым тегүчеләр дә, актёрлар да, бу тамашаны дөньяга китерүдә күп көч түккәннәре, зур теләк белән гамәл кылганнары ачык күренә. Спектакль киң колачлы. Бер генә кеше дә беренче пәрдәсеннән соң залны ташлап китмәде. Соныннан тамашачы артистларны, режиссёрны, рәссамны, композиторны аягүрә торып алкышлый башлады. Бу алкышлар белән тамашачы үз сүзен, үз теләген ачык әйтте.

**— Мин, Фәрит туган, сезнең шәхесегездә фидакарь театр коллективын премьера белән чын күңелдән котлыйм!**

— Рәхмәт!

**— Ләкин үзара сөйләшүләр, фикер алышулардагы тәэсирләр төрле һәм бу табигый. Кайберләре, спектакль алга таба бармаячак, дип күрәзәлек кыла. Бәгъзеләре спектакль турында фикерен оештырып әйтә алмый. Күп тамашачыга спектакль ошаган, рәхәтләнеп карадык, диләр. Миңа калса, фикер төрлелегенә карамастан, бу тамашаның залы буш булмаячак. Без кем өчен иҗат итәбез соң? Халык өчен! Халык йөри икән, димәк, халык бу тамашадан нидер алып китә, ләззәтме, канәгатьләнүме, уен-көлкеме, әллә сәяси сорауларга җавап аламы?**

**Әйе, бу тамаша — гадәти тамаша түгел. Кайбер сәнгать белгечләре дә каушабрак калды шикелле, шул хисаптан мин дә. Спектакльдә серләр бар. Фәрит әфәнде, шул серләрне, астарлы сүзләрне, кинаяләрне бәлки без бергәләп ачыкларбыз? Исәнбәтнең пьесасын җентекле өйрәнмәгән кешегә, андагы үзгәрешләр, өстәмәләр мәгълүм түгел, ләкин урта тамашачы аны тулыкманы белән шулай, бер кул белән язылган, дип кабул итә.**

**Хәзер, диктофонны көйләп куябыз да... Ул сезне кыен хәлгә куймыймы, Фәрит туган?**

— Юк! Мине диктофон кыен хәлгә куймый, мине «Хуҗа Насретдин» кыен хәлгә куйды.

**— Ни өчен?**

— Премьерадан бирле йоклый алганым юк. Тамашачы анлармы минем бу эшемне, анламасмы, дип баш ватам. Хәтта «әлеге спектакльне бу килеш уйнарга ярамый, аны туктатырга кирәк» кебек шомлы сүзләр дә булды.

**— Фәрит туган, ни өчен игъланнарда «Хуҗа Насретдин» пьесасының икенче авторы пәйда булды? Программада Нәкый Исәнбәт белән рәттән Саадалла Ванус исеме дә бар.**



*Уңнан-сулга: Хуҗа Насретдин – Ф.Җиһанша, Ахун — И.Мөхәммәтгалиев.*

— Хәлил аганың уенын мин күрмәдем. Ул вакытта мин әле дөньяда да булмаган. Ләкин мин Марсель абый Сәлимҗановның спектаклен карадым, хәтта аның репетицияләрендә дә утырырга туры килде. «Хуҗа Насретдин»ны кую аңа бик авыр булды. Менә аның әйткән сүзләре: юк, Фәрит, диде ул беркөнне, мин Хәлил ага уйнаган спектакльдән котыла алмыйм. Әмма Марсель абый репетицияләрне өзми, ләкин эшеннән үзе канәгать түгел иде. Спектакль уңышлы гына чыкты. Әмма ул озын иде, Марсель абый Нәкый аганың сүзләрен кыскартырга базмады. Остаз күбрәк спектакльнең темпына дикъкать итте. Сәхнәдә хәрәкәт күп, анда чабалар, монда йөгерәләр, оркестр уйнап тора. Сәхнәдә шау-шу. Тик Нәкый абый әсәренә салган төп фикер тамашачыларга барып җитмәде шикелле. «Хуҗа Насретдин» әсәренә тотынгач, әлбәттә, авторның төп юнәлешен эзлисең, чөнки классик авторларда фикерләр күп. Исәнбәтнең бу әсәрендә дә эчкә яшерелгән мәгънә күп, аны тартып чыгарырга гына кирәк иде. Әсәр «фил» сүзе белән башланып китә һәм ул сүз күп кабатлана, әлбәттә, автор тарафыннан салынган саллы фикер бар, әлбәттә, ул яшерелгән, нык яшерелгән ул мәгънә. Нәкый абыйның бу әсәрендәге сюжетны эләктереп алып булмый. Андагы бөтен сюжетларны да уйный башласаң, төп фикерне югалтуың бар. Шуңа күрә мин, кайбер сюжетны бер кырда калдырып, фил темасын көчәйтергә булдым. Һәм Саадалла Ванус, мин аның әсәрләре белән күптән таныш, аның бик кыска гына драматик әсәре бар иде, әнә шул Саадалла әсәреннән кечкенә өлешләр керттем. Менә шул гына.

**— Әүвәлге куелышларында «Хуҗа Насретдин» оркестр белән музыкаль комедиягә тартым ысулда куела килә, бу куелышында ул притча шәкелендәге драмага тартым. Аеруча финалда. Килешәсеңме?**

— Килешәм! Һәм безнең максатыбыз да шул иде.

**— Фикер алышуларда: бу спектакльдә Фәрит Бикчәнтәев куелышында ярашмаганлык, ягъни эклектика бар, диләр. Чыннан да, сәхнә җиһазлары аерым, сүз аерым, киемнәр аерым, музыка, тавыш өлеше аерым яши кебек тәэсир калдыра. Әйтик, Баш вәзирнең киеме Урта Азия персонажларына хас түгел шикелле, хансарайга чакыртылган хатын-кыз хоры бүген дә еш җырланыла торган «Илкәем»не башкара. Җырның эчтәлеге спектакльнең сюжетына берни дә өстәми кебек. Диван вәзирләре, Баш вәзир бүгенге тантаналарда гына бәйрәмдарга тапшырыла торган букча тотып йөри. Әсәрне шушы заманга якынайту максаты белән эшләндеме бу? Әллә бер караудa ук аңлашылмый торган сер бармы монда?**

— Беренчедән, Җиһангир бит ул яулап алучы, читтән килгән баскынчы. Аксак Тимер күз алдында тотыла бит әсәрдә. Сюжет буенча Җиһангир хәзрәтләре әйтә: мин монда хан булып утырырга килмәдем, минем Һиндстанны, башка җирләрне яулыйсым бар, ди. Яуга чыгар алдыннан минем күңел ачасым килә, ди. Бөек яулап алучы Җиһангир хәзрәтләре бер урында утыра алмый, аңа яна җирләр кирәк, ул

һәр яулап алган илдә үзенең баскакларын калдыра да янә яу сәфәренә чыга. Вәзир хатын-кыз җырчыларны махсус чакырып, аларны җырлатып, Җиһангирга киная ясарга тели: менә син үз илеңдә түгел, чит-ят илдә утырасың, бу син басып алган халык, алар «Илкәем» дип өзелеп җырлый-җырлый, синең илең дә юк бит, дип әйтергә тели. Моны кемдер аңлагандыр, кемдер аңламагандыр... Ә Вәзирнең киеменә килгәндә, эш болайрак тора: Җиһангирның (Аксак Тимернең) янында Аурупа илләреннән килгән илчеләр, шымчылар еллар буе яшәп ята. Тарихта материал җитәрлек. Мәсәлән, Аксак Тимер янында Испаниянең илчесе Руи Гонсалес Клавихо белән католик монахы Алонсо Паэс байтак еллар Җиһангирның киңәшчесе булып утыра. Аларның өс киеме, әлбәттә, Ауропача булган.

**— Сүз иярә сүз чыккач әйтим әле. Илдус Габдрахманов уйный торган, чыраен кара бөркәвеч белән капланган шәхес кем ул? Кешеләрне таптап үтергән сугыш филен, иген кырларын харап иткән сугыш филен алдырыр өчен халыкны өндәүче (котыртучы) ул кем? Каратун монахмы? Әллә буза куптаручы бер бәндәме? Вакыт-вакыт ул кара каплавычын салгалап куя да, тамашачы аның башындагы бизәкле татар кәләпүшен күреп ала. Режиссёрның бу табышын «Азатлык! Азатлык!» дип кычкырып йөреп тә, соңыннан каршылыкка очрагач, авызларына су кабып, киресен кычкыручы «татар милләтчеләре вәкиле» дип тә шәрехләргә булыр иде. «Ни өчен ул христиан монахларына охшатып карага чорналган?» — дип сорыйлар.**

— Рәссам Сергей Скоморохов әйтә: Урта Азиядә карага бөркәнеп йөрүчеләр күп булган, хәтта вәзирләр дә кып-кызыл, кап-кара каплавыч бөркәнеп йөргән... Мөселман шигыйлар да кара кием киеп йөри, бәлки ул сәяхәтче шигыйдыр? Әлбәттә, ул кара киемле кеше котыртучы, аның максаты ни? Ул ил язмышы турында уйлап котырту, баш күтәрү юлын сайлаганмы? Әллә ул буш куык кынамы? Әйе, сез безнең кинаяне дөрес аңлагансыз. Гомумән, алдарлар, шарлатаннар, авантюристлар артыннан ияргән халык бәхетсезлеккә дучар була.

**— Пәрдә ачылгач та (баштан ук), тавыш көчәйткечләр аша кемдер без аңламаган телдә (бәлки ул «тарабар» теледер), ниндидер боерыклар бирә, нидер сөйли. Моның бер хикмәте бармы?**

— Бар! Ул Нәкый абыйда да шулай. Халык бер-берсен аңламый бит. Нәкый абый тарафыннан бер ишарә бар: халык бер-берсен ишетми дә, аңламый да. Баштан ук мин тамашачының игътибарын, колагын торгызыр өчен эшләдем бу эшне. Тамашачының дикъкате читкә китмәсен. Баштан ук баш ватсын, уйлансын тамашачы.

**— Музыка һәм тамашага ярдәм итәргә алынган тавышлар да вакыт-вакыт сүзләрне каплап китә, алар тамашаны кабул итәргә комачаулый. Артистларның болай да тавыш мөмкинлекләре куәтле түгел. Гомумән, музыка бу тамашагаятышмый кебек.**

— Форсаттан файдаланып әйтәсем килә, беренче күрсәтелешне карап кына бәя бирү дөрес түгел, минемчә. Каядыр бишенче-унынчы күрсәтелештә генә спектакль оеша ала. Марсель абый да шулай әйтә иде...

**— Без гаиләм белән ике тапкыр карадык.**

— Алайса, сизгәнсездер, мин спектакльдән спектакльгә үзгәрешләр кертәм, кыскартам, эш сөреше әле тәмамланмаган. Өченче көн спектакль унбиш минутка тизрәк барды. Үзгәрә спектакль, яхшы якка үзгәрә. Музыка өлешенең дә кайбер урыннарын үзгәртергә туры килде.

**— Халык кабул итә. Ләкин тамашачы, нәрсә әйтте ул, ни диде ул, дип аңламаган сүзләрне күршесеннән сорап утырган чаклары еш була.**

— Гомумән, бездә актёрларның сөйләм проблемасы бар. Кичә мин Мари театрын карадым, алар бар актёрларга да микрофон кигезгәннәр. Чөнки тавышлары ишетелмәячәк. Безнең зал — акустика ягыннан бик катлаулы зал. Кайсы урында тавыш яхшы ишетелә, кайсысының колагына тавыш барып җитми. Күп кенә Мәскәү театрлары да микрофон кулланырга мәҗбүр. Бүгенге яшь артистларның сөйләм-тел, тавыш мәсьәләсе кискен тора. Сәхнә теле укыту, театраль педагогика гомумән аксый.

Тавышы көчле булмаган яшь артистларны алырга мәҗбүрбез, ләкин аларның теле дә ташка үлчим, тавышлары да ташка үлчим, шуна күрә без театрыбызда тавыш, җыр, ачык сөйләм дәресләре уздыра башладык.

**— Тере ишәкнең зал аша үтеп китүе тамашачыларга ачык күренми, залга ут бирелми, ишәк белән Хуҗаны күп кеше караңгыда күрми дә кала. Шуннан соң ул ишәк сәхнә аша чыгып та китә. Ишәкне көлке өчен генә чыгаруны бу, ишәк тамашага ни өсти?**

— Курчак филгә капма-каршы тере, җанлы ишәк кертергә уйладык. Шул гына. Әмма халык та, котыртучы да Насретдиннан йөз чөергәч, Хуҗа бердәнбер тугры җан иясе — ишәген юлдаш итә.

**— Күктән төшкән филне (бәлки ул чит галәмнән килгән корабтыр) ничек аңларга? Күктән төшкән фил ул халык сыртына төшкән салымнармы, ул изү — халыкны сыту символымы? Шулай да булсын ди. Ләкин тамашачыны символга әзерләү күренмәде шикелле. Кешеләр җирдә (сәхнәдә) йөри, фил күктән төшә...**

— Бу очраклы гына шулай килеп чыкты шикелле. Рәссамның да, минем дә ул турыда уйлаганыбыз булмады... Фил ни өчен күктән төшә? Без бит һәрвакыт куркуны өстән көтәбез. Ә фил ул халык өчен куркыныч, фил таптап сыта, иген басуларын харап итә, йортларны җимерә... Күпкырлы символ бу. Әлбәттә, салымнарга да, эксплуататорларга да монда ишарә бар. Беренче көнне житәкчеләребез карады бит спектакльне. Мин шүрләп калдым. Беренче пәрдәдән соң мин алар күзенә күренмәскә тырыштым. Шәрәфле кунакларыбыз да аптырап калган иде. Алар, бәлки моны туктатырга кирәктер, бәлки кыскартыргадыр, дип фикер алышканнар. Икенче пәрдәдән соң фикерләре уңай якка үзгәрде. Монда төп персонаж Хуҗа түгел, төп персонаж халык бит. Сабыр итүче халык, түзем халык төп персонаж.

**— Хуҗаның салпы якка терәтелгән йортының диварында Болгарда сакланып калган манара тырпаеп тора, менә авам, дип торган өй диварындагы Болгар манарасы кемгәдер имәнеч булып күренәдер, кемгәдер ул астарлы киная, рәссам белән режиссёр, без куйган спектакльне ошатмасагыз, менә сезгә манарам! дип әйтәдер кебек.**

*(Моны ишеткәч, Фәрит әфәнде көлә башлады).*

— Башыма да килмәде! — диде Фәрит, көлүеннән туктагач. — Дөньяның асты өскә килгән бит. Манаралар — өстә, күк — аста.

**— Менә шушы мохиттә актёрлар авызыннан ишетелә торган сүзләр бар, ул сүзләренең күбесе Нәкый Исәнбәтнеке, калганы Саадалла Ванусныкы. Миңа калса, алагаем олы декорацияләр актёрларны бәләкәйләтеп күрсәтә. Монда да киная бармы? Кешеләр алар язмышлары астында чебеннәр, мескеннәр, дип әйтергә телиме режиссёр?**

— Андый фикер юк иде, Хуҗа бит дөньяны икенче төрле итеп, асты өскә килгән итеп күрә. Җиһазлар да ас-өс килеп бетә. Бу спектакльдә безнең идән күк гөмбәзе төсендә, ә йортлар күккә күтәртелгән. Бу Хуҗа Насретдиннең карашында шулай. Дөньяның асты өскә килгән. Халыкны мескен итеп, түбәнсетеп күрсәтергә тырышмадык, әмма халыкны кызгану бар.

**— «Актёрлар авызыннан ишетелгән сүзләр», дидем дә уйга калдым, шактый урыннарда актёрлар иҗекләрне, сүзләрне йота. Сүз тәмен белүче актёрлар сирәгәя бара. Ирләргә хас драматик баритон (басны әйтмим дә инде) тавышлы актёрлар юк, барысы да дип әйтерлек драматик тенор белән сөйләшәләр. Көр тавышлы актёрларның кимүе сезне борчыймы? Бәлки бу бөтен театрларның да уртак проблемасыдыр?**

— Бик борчый, әлбәттә, ләкин бу бөтен театрларга да кагыла торган проблема! Әйттем бит, тел осталарын чакырып, без тел, ачык сөйләм дәресләре уздырабыз.

**— Дәресханәдә бик кечкенә-уенчык парталар, вак урындыклар, Хуҗа шул тар дәресханәдә балаларны укыта. Мин монда бүгенге мәгариф системасына ишарә күрдем, татар мәктәпләре азая-тарая бара.**

*(Фәрит Бикчәнтәев көлемсерәп куйды).*



*Спектакльдән бер күренеш*

— Кызык, башыма да килгәне булмады, кем ничек аңлый инде, мин тамашачының һәр шәрехен контрольдә тота алмыйм. Катлаулы әйберне һәркем үзенчә юрый.

**— Инде актёрларның уены турында... Мәсәлән, бу уенда Зөлфирә Зарипованың авыз тутырып ачык сөйләве, бирелеп уйнавы күпләргә үрнәк булып тора... Мин Фәнис Җиһанша янына тагын бер-ике Насретдинне куяр идем. Юк, Фәнис Җиһаншаның уенын ошату-ошатмау турында сүз юк. Фәниснең тамак җепселләре кайвакыт карлыккалый. Аңа тавышын сакларга кирәк. Аны ял иттерү зарур... Әйтик, шул ук Искәндәр Хуҗа ролендә Миләүшә Шәйхетдинова (Гөлбану) белән бик туры килгән булыр иде. Искәндәр Баш вәзирнең «тиресенә кереп уйнады». Искәндәр Хуҗаны да югары кимәлдә уйнаган булыр иде.**

— Һәркемнең үз фикере. Әсәрне сәхнәгә куючы режиссёр бөтен фикерләр белән дә килешеп бетә алмый бит инде.

**— Әмма тамашачы шушы олы — авыр җиһазлар арасында кыймылдый торган кешеләрнең язмышын күзәтә, аларның сүзен йотлыгып тыңлый, ул авторларның, режиссёрның максатын, әйтергә теләгән фикерен тотарга тырыша. Һәм тамашачы шушы сүзләргә, шушы хәрәкәтләргә кул чабу яки дәррәү көлү белән җавап кайтара. Бигрәк тә хан янына кергән халык вәкилләренең үзен тотышы, кыю сүз әйтергә җыенып та, ханнан куркып, ләм-мим дәшми калулары, котыртучы Юлдашның чарасыз калуы, халык дәшмәгәч, теләгәненең киресен сөйләве вакытында зал тып-тын кала. Бу — тамашаның кульминацион ноктасы. Зал тынын кысып, нәтиҗә көтә. Димәк, тамашачы сәхнәдәге каһарманнар өчен җан ата! Ләкин сәхнәдәге халык-сарык ханга дөресен әйтәсе урында авызына су каба, котыртучы җитәкчеләре халык өстенә яңа налоглар өстәлүен, изелү шартларын хуплый. Хан урынындагы Хуҗа чарасыз кала, бу очракта ул фаҗигале шәхес булып күренә. Чыннан да, бу фаҗига бит. Халык үзе үз өстенә афәт китерә. Шулчак шаян-шамакай Хуҗа Насретдин чарасызлыктан тугры ишәгенең муенын кочаклап, сүзсез калса яки җыласа иде... Халык аны сатты. Халык бәхете өчен көрәшеп-көрәшеп тә, үз халкың үзенә дә, Хуҗасына да хыянәт итте. Чарасыз Хуҗа Юлаучыга өмет белән карый. Нигә мине саттың, дигән кебек ике кулын аңа суза, ләкин Юлаучы йөзен яшерә, Хуҗага арка белән борыла. Бичара Хуҗа өметләрен халык тарафына бора, ләкин бәндәләр аңа арка белән борылып, артларын туңкайтып, башка якка карап ята. Сәхнә уртасында Хуҗаның бердәнбер тугры җан иясе — аның ишәге калды. Бичара Хуҗа табылган ишәген тезгененнән тотып, өметсез рәвештә халыктан аерыла. Тәэсирле күренеш. Спектакльне драмага әверелдерә торган күренеш бу. Шушы күренеш өчен генә дә бу спектакльне куярга кирәк иде!**

— Элеккеге куелышларда финалда «Яшә, Хуҗа Насретдин» дип халык җырлый иде. Хуҗа Насретдин халыкны бәлаләрдән коткара иде. Бүгенге көндә халыкны бәлаләрдән хәтта Хуҗа да коткара алмый. Халык бары тик үзен-үзе генә коткара ала. Бары тик халык үзе генә! Ә халык котылышка омтыламы соң? Тамаша шул турыда!

**— Тагын бер мәртәбә сезне яңа спектаклегез белән тәбрик итәм! Әңгәмәгез өчен рәхмәт, Фәрит әфәнде!**

# ХУШ, ХУҖА НАСРЕТДИН!

«Гасырлар буе телдән телгә күчеп килгән һәм күп кенә көнчыгыш халыкларына уртак булган бу бөек халык әсәрендә, онытылмаслык Хуҗа Насретдин образы аша, халыкның үткенлеге, зирәк һәм тирән акылы, шаянлыгы һәм өметлелеге чагылган. ...Автор пьесада оста рәвештә бер билгеле, ачык идея үткәрә. Ул — халык акылының хан һәм түрәләр мәкереннән, алар урнаштырган тәртипләрдән өстен булуы, мораль яктан аларны җинеп чыгуы».

Муса Җәлилнең әлеге юллары алынган рецензия «Кызыл Татарстан» газетасында 1940 елның 29 апрелендә, спектакльнең премьерасыннан соң ике көн вакыт узгач басылып чыга. Режиссёрлар Е.Амантов, Х.Уразиков, К.Тумашева, художник П.Сперанский, композитор Җ.Фәйзи составындагы сәхнәгә куючылар бригадасы хезмәтенең тамашачыларга тәкъдим ителү вакытына игътибар итик.

Сугыш алды еллары. Европада инде бәрелеш сөреме өркелә. Бездә илдә хөкем сөргән киеренке, шомлы атмосферада хакимлек иткән даирәләр әдәбиятта һәм сәнгать өлкәсендә тоталитар басымны бераз йомшартырга мәҗбүр булалар. Шуны гына көткәндәй, татарның күренекле театр эшлекләре халкыбызның бөек шәхесләрен, шанлы тарихын, рухи байлыгын, акылын, зирәклеген чагылдырган «Тукай» (Ә.Фәйзи, 1939), «Хуҗа Насретдин» (1940), «Идегәй» (Н.Исәнбәт, 1941) әсәрләрен бер-бер артлы сәхнәгә чыгаралар. Шушы контекстта «Хуҗа Насретдин» әсәренең Җәлил язганча анлануы, шәрехләнүе табигый дә.

Инде менә ул еллардан соң 75 ел вакыт узган. Чор, ил, халык, илдәге вазгыять, дөньядагы хәлләр бөтенләй башка. Бүген инде мәйдан вакыйгалары, төсле революцияләр чоры, Украинадагы канлы бәрелешләр жанны тетрәтә. Хакимияттә утыручыларның үз амбицияләре өчен ил, дөнья халкын упкынга, һәлакәткә алып баруын, хәерчелеккә этәрүен, бөлгенлеккә төшерүен күреп торабыз. Сугыш филләре илләрне таптый, чәчкән игеннәрне изә, юкка чыгара, күнегелгән, җайга салынган тормышны җимерә. Менә шул шартларда «Хуҗа Насретдин» ничегрәк шәрехләнә, ничек яңгырый соң? Әйдәгез, шушы сорауга җавапны бергәләп эзләп карыйк.

Спектакльгә бер уйсыз, кайгы-хәсрәтсез ял итәргә дип килүчеләр ялгышырлар. «Хуҗа Насретдин» элеккеге кояшлы, элеккеге кебек чалт аяз күкле, якты тамаша түгел. Аның атмосферасы шактый гына болытлы, урыны-урыны белән кара дәһшәтле болытларга төренгән, менә-менә көчле давыл кубар, күзгалыр алдындагы дәһшәтле күк йөзен хәтерләтә. Шуна күрә дә сәхнә бизәлешендә көнчыгышның жанны иркәли торган ачык, якты төсләре, бай бизәкләре юк, соры, тонык төсләр өстенлек алган (бу артистлар кигән киемнәргә дә карый). Сәхнә төзелешенең, гомумән, тормыш дөреслеге белән чагыштырыр чамасы юк. Өч якта Хуҗа Насретдин, Сәхилә карчык, Бики бай — өйләрен бик шарты билгеләгән ниндидер яссылыклар. Хуҗа өенең алгы ягы вертикаль буенча тигезлеген әледән-әле үзгәртеп тора. Ул ныклы фундаментка утыртылмаган. Стеналар да гадәти тигез яссылык түгел, ниндидер корылмалар, төзелеш-торак элементлары күпертелеп ясалган. Әйтерсең лә дөнья үзенең күнегелгән формаларын, масштабын югалткан, үзенең күчәреннән ычкынган, туздырылган. Бәлки моңа Тимерче бистәсен туздырган Җиһангир явы гаеп̆ледер. Ә бәлки бу җимерек дөнья бүгенге вазгыятькә, ил, көн, халык яшәргә мәҗбүр булган җәмгыятьтәге бүгенге халәткә ишарәдер.

Соры, тонык төсләр персонажларның костюмнарында да өстенлек итә, хәтта Сәлви, Гөлбану кебек төп персонажлар да ачык төсләрдән мәхрүм. Гәрчә алар кеше сокланырлык, байлар күзе кызарлык булырга тиеш, мантыйк буенча.

Гомумән, яшьлек, мәхәббәт темасы спектакльдә тоныкландырылган, кыскартылган, ассызыкланмаган. Зөбәрҗәт һәм Алчын линиясе бөтенләй алып ташланган. Алар спектакльдә юк. Ә Хаммат — А.Шәйдуллин һәм Сәлви — Л.Әхмәрова герой һәм героиня буларак икесе дә күзгә артык ташланмыйлар. Бу — режиссёр установкасы — аларның сәхнәдә беренче күренүләреннән үк тормышка ашырыла. Әйтик, Хаммат

сугыш киемнәрен, кылычны күтәрә алмый интексә, Сәлви тамашачы алдына кача-поса, бөтенләй иелеп-бөгелеп, яны белән чыга. Гадәттә, мәхәббәт каһарманнарын тамашачыга беренче тәкъдим итү — һәр режиссёр алдында торган мөһим эш, житди бурыч. Бу очракта режиссёр аларның каһарманлык статусын махсус киметә, төшерә кебек. Шушы ук чишелеш Хужа хатыны Гөлбану — М.Шәйхетдиновага да кагыла. Ул үзеннән дә зур төенчек күтәргән хәлдә сәхнәдә күренә. Ни өчен? Хужаның өйдә берни эшләмәвен ассызыклау өченме? Яки башка максаттанмы? Ул кадәр төенне хатыннан ташытканчы, ишәк жилкәсенә бик жинел генә салып алып кайтырга да мөмкин булыр иде бит. Бәлки режиссёр Гөлбануга Хужа белән яшәүнең никадәр авыр икәнлеген аңлатырга теләгәндер? Чынлап та аның үз дөньясы, үз шөгыле. Тормыш вак-төяге аңа кагылмый. Дөнья көтүнең бөтен авырлыгы хатыны жилкәсендә. М.Шәйхетдинова-Гөлбануның әнә шул авыр, кыл өстендә яшәгәндәй язмышын баштарак сабырлык белән, алга-таба ачу-ярсу төсмерләрен дә кушып күрсәтә. Ә йолдызлы сәгатендә, бер көнлек ханбикә булгач, ул инде үзен күкнең жиденче катында тоя, үз кыланмышларының читтән караганда көлке күренүен дә аңлар дәрәжәдә түгел.

Фәнис Жиһаншин башкаруындагы Хужа Насретдин жүләр түгел, сәер дә түгел. Киресенчә, тирә-яктагыларга караганда, ул күпкә акыллы. Шуңа күрә дә ул дошманнары белән турыдан-туры көрәшми. Бар нәрсәне кызыкка әйләндереп, уенга алып көлкегә калдыра. Кунак килдеме — рәхим ит — менә сиңа баба шулпасы. Йорт тирәсендә койма корылмаганмы — менә бит йозаклы капка бар. Бүгенге термин белән әйткәндә, тормышта аның үз позициясе, һәр нәрсәне үзенчә аңлавы, максаты бар. Чыгымчы хатынын да тезгендә нык тота ул. Кызын да Бики байга түгел, Жиһангирга да түгел, үзе яраткан шәкерте Хамматка бирә. Димәк, алдына куйган бурычларын үти, максатына ирешә.

Жиһангирның тирә-якны корыткан сугыш филен тимерчеләр бистәсеннән алдыру өчен, халык сайлавын кабул итеп, хөкемдар сараена баруы да аның жүләрлек түгел. Башын юкка балта астына куя торган кеше түгел ул, үз акылына, зирәклегенә ышанганга бара һәм шулай ук үз дигәненә ирешә. Ул чын-чынлап халык лидеры, житәкчесе. Аның моның өчен бөтен мөмкинлекләре, барлык сыйфатлары бар.

Хужа — Жиһаншинның спектакльдәге иң төп дошманы —Болгар шәһәрен, Тимерчеләр бистәсен тар-мар иткән гаскәр башында торучы Жиһангир хан. Шуңа күрә дә Хужа һәм Жиһангир катнашкан «дипломатик сөйләшү» күренеше тамашаның иң жаваплы сәхнәләреннән. И.Хәйруллин Жиһангир хан образын чишүдә традицион юлдан китмәгән. Моңарчы аны гөрләп торган каты тавышлы, карашы белән кешене аяктан ега торган усал, куркыныч яугир буларак сурәтлиләр иде. Жиһангир — Хәйруллин исә артык экзальтациягә бирелми, тыныч, бераз гына арыган, шуна да карамастан бер нәрсәне дә күз уңыннан ычкындырмый торган хөкемдар булып гәүдәләнә. Бүген аның бар нәрсәне читкә куеп ял итәсе, көтелмәгән эшләр, жүләрлекләр эшлисе, кызыклы шәхесләр белән очрашасы, әңгәмә корасы килә. Үзе дә акыллы шәхес буларак Жиһангир — Хәйруллин үз алдында аңа тиң, акыл, зирәклек ягыннан аннан калышмаган, хәтта өстенрәк тә кеше торганны ул бик яхшы аңлый. Ләкин ачу килүен дә, явызлыгын да, мәкерен дә эчкә яшерә белә һәм башлаган уенын ахырга кадәр житкерә. Аның өчен уенның ничек бетәсе мәгълүм. Актёр үз героеның характерын, һәр күнел тирбәлешен, хәйләкәрлеген, мәкерлелеген тамашачыга ышандырырлык итеп житкерә.

Ф.Бикчәнтәевнең режиссура композициясендә үзәк урынны тоткан берничә персонаж бар. Алар — Бики бай — Р.Тажетдинов, Тархан — А.Хафизов, Ахун — И.Мөхәммәтгалиев. Халыкны тотып торган, хакимият, дин, байлыкны гәүдәләндергән бу персонажлар һәрвакыт бергә, бер уй, бер теләк, бер максат белән яшиләр: ничек кенә булса да Хужа — Жиһаншиннан котылырга! Ләкин вакыйгалар күрсәткәнчә, бу аларның кулыннан килә торган эш булып чыкмый. Өчлекнең үзегендә — И.Мөхәммәтгалиев тудырган Ахун образы. Бу дин әһеле дә үз дигәненә ирешү өчен берни алдында да туктапып калмый. Алдау, янау, куркыту, басым ясау — болар Ахун — Мөхәммәтгалиев куллана торган алымнар.

Тархан — А.Хафизов халык арасында дәрәжәле булып исәпләнсә дә, шактый түбән сыйфатларга ия кеше. Үз акылы белән нәрсә дә булса уйлап чыгарырга сәләте булмаса да, башкаларның этлегенә бик теләп кушыла. Мондый кешенең Хужа тарафыннан, артык көч куймыйча, көлкегә калдырылуы тамаша барышында аклана да.

Р.Тажетдинов башкаруындагы Бики байны ин элек Хуҗаның кызы кызыксындыра. Автор тасвирлавынча, Сәлвигә өйләнү өчен ул бар нәрсәгә дә әзер. Әмма Хуҗа бирешми, үз дигәнен эшли. Ләкин, безнең уебызча, Р.Тажетдинов — Бикигә спектакльдә активлык, үз дигәненә ирешү өчен ныклы омтылыш җитми кебек. Ул ничектер артык сүлпән, булса ярый, булмаса ярый дигән сыманрак хәрәкәт. Мәгълүм мәзәктәге тавык артыннан куган карт әтәч халәтенчә: куып тотсам үз эшемне башкарырмын, тота алмасам — җылынырмын.

Интернет сайтында чагылып киткән интервьюсында Ф.Бикчәнтәев, спектакль бу куелышта Хуҗа Насретдин турында түгел, дип белдерде. Әлбәттә, бераз эпатаж тудыру, кызыксындыру уяту өчен әйтелгән сүз булды бу. Хуҗа Насретдин дип аталган әсәрнең аның турында булмавы берничек тә мөмкин түгел кебек. Әмма тамашаны карагач, бу сүзләрнең өлешчә дөреслегенә ышанасын. Спектакль үзәгендә элеккечә үк Насретдин образы. Ул аның турында да. Әмма аның турында гына түгел. Спектакль халык язмышы, аның хакимият белән, лидерлар белән мөнәсәбәте, ахыр килеп, канга сеңгән коллык психологиясе, куркаклык, ихтыярсызлык турында да.

Н.Исәнбәт язган әсәрнең төп тексты, билгеле, бу фикерне тормышка ашыру өчен ныклы җирлек биреп бетерми. Шуңа күрә дә режиссёр спектакльне ике әсәр нигезендә эшли. Сирия драматургы Саадалла Ванусның сугыш филе турындагы притчасы тамашаның Насретдин линиясе белән бер үк хокуктагы икенче линиясен тәшкил итә. Шул мөстәкыйль линия спектакльгә бөтенләй яңа төсмер бирә, өр-яңа фикер өсти. Аңлашылганча, өстәмә линия сюжеты режиссёр өчен гаять мөһим. Хәтта ул аны Хуҗа темасыннан алгарак та этәрә сыман. Ни өчен дигәндә, искә төшерик, тамаша Насретдиннан түгел, ә менә нәкъ халык күренешеннән башланып китә. Ул ханның Тимерче бистәсенә куелган сугыш филен карап кайтып килә. Гаҗәпләнгән, бераз гына курыккан, шикләнгән дә төсле. Болай булса, бу кадәр ашаса, ул афәт бөтен бистәне корытачак, иген кырларын, ел уңышын изеп, таптап бетерәчәк.

Тамашачы белән икенче очрашуда халык арасында шик-шөбһә, канәгатьсезлек ноталары арта, бистәдән филне алдыру өчен, ханга вәкил җибәрү идеясе туа. Шунда ук лидер, җитәкче мәсьәләсе дә хәл ителә. Баштарак вакыйгаларны читтәнрәк күзәтеп торган Карт — И.Габдрахманов халыкка Җиһангир алдында үзләрен ничек тотарга, таләпләрен ничек итеп әйтергә кирәклеген өйрәтә башлый. Акрынлап канәгатьсезлек үсә, паника арта, ыгы-зыгы көчәя, ханга турыдан-туры мөрәҗәгать итү идеясе тагын да көчлерәк яңгырый. Һәм, ниһаять, финал сәхнәсе. Халык бер көнлек хан — Насретдин белән очраша...

Ассызыклап әйтик, бу соңгы күренеш режиссёр композициясендә ин төп, ин мөһим урынны тота. Хәтта бөтен спектакль фикер ягыннан шушы финал сәхнәсе өчен куелган дип тә әйтергә мөмкиндер.

Вакыйгалар үсешенең бу өлешенә җиткәч, янә спектакльнең сценографиясенә әйләнеп кайтырга кирәк. Чөнки ул тамашага яңа фикер бизәкләре өсти. Алдагы куелышларда Җиһангир ханның сарай күренеше традицион тормыш дөреслеге кануннары нигезендә хәл ителсә, бу юлы ул бик шартлы рәвештә чишелгән. Ачык төсләргә буялган орнаментлы диварлар, хәтфә келәмнәр, шәрык стилендәге мебель, өй җиһазлары, хәтта хан тәхете — болар берсе дә юк. Сәхнәнең диагонале буенча эреле-ваклы җил иссә дә селкенеп, очып китәргә торган куык-шарлар, өскә мәһабәт аркалар урынына шулай ук өреп кабартылган, энә очы тисә дә шартларга торган, әмма куркыныч кан төсенә буялган җанвар карачкысы эленгән. (Моны спектакльнең башыннан алып ахырынача телгә алынып, сөйләнеп килгән ханның сугыш филе, күчерелмә мәгънәдә халык куркуының символы дип аңларга кирәктер.) Ә сәхнә планшетына кем утырса, шунын формасын ала торган йомшак капчыксыман пуфлар ыргытылган. Алар барлык мебельне, хан тәхетен алыштыралар. Бөтен бу обстановка шартлы рәвештә ханның авыр сугышлардан соң хәл ала торган җәйге чатыры дип кабул ителергә дә мөмкиндер. Фикер ягыннан килгәндә, сәхнә бизәлеше халыкны куркытуга, изүгә, талауга, алдауга корылган хакимиятнең тотрыксызлыгына, нигезсезлегенә, аның менә-менә шартлап юкка чыгу мөмкинлегенә ишарә. Хәер, бәлки башкача да аңлап буладыр — адәм баласының фикерләү мөмкинлекләре чиксез.

## *100 нче бит: чор, милләт, вазгыять*

# ТУКАЙ–ТУКАЙ, ДИБЕЗ...

**2016 елда бөек шагыйребез Габдулла Тукайның тууына 130 ел тулачак.**

**Вакыт бик аз калды. Олуг юбилей борын төбендә генә. Яңа опера да, балет та язарга вакыт тар. Язучылар шушы олуг юбилей мөнәсәбәте илә роман-кыйссалар язамы, композиторлар Тукай сүзләренә яңа җырлар, кантаталар, ораторияләр, инструменталь әсәрләр иҗат итәме, шагыйрьләр Тукайга багышланган шигъри әсәрләр язамы, рәссамнар Тукай рухындагы эре полотнолы рәсемнәр ясыймы, кино-телевидение Тукайга аталган нәфис һәм документаль фильмнар төшерәме? Тукайның 125 еллык бәйрәменә «Тукай энциклопедиясе»н чыгарырга дип акча да бүленгән иде юкса, ләкин, ни сәбәпледер, чыкмый калды. Бу юлы — 130 еллык олуг бәйрәмгә — чыгармы икән ул?**

**Тукай турында түбәндәге әсәрләр басылды:**

**1. Классик әдибебез Әхмәт Фәйзинең «Тукай» романы (1956) һәм шагыйрьнең сабый чагы турындагы «Кечкенә Апуш» романы. Ул Татарстан китап нәшриятында (ТКН) 1957 һәм 1993 елларда чыкты. «Тукай» А.Садовский тәрҗемәсендә дүрт тапкыр русча да басылды, соңгысы 1977 елда чыкты («Советская Россия» нәшрияты).**

**2. Батулланың «Апуш – Тукай» кыйссасы «Казан утлары»нда чыкты (2011, №4-6).**

**3. Рөстәм Вәлиевнең «Заботы света» исемле романы Мәскәүдә 1977 елда басылган. Татарчага тәрҗемә ителмәгән. Олуг юбилей мөнәсәбәте илә ул романны русча да, татарча да аерым-аерым бастырырга иде.**

**4. Ибраһим Нуруллинның «Тукай» дигән фәнни-әдәби әсәре 1979 елда басылды (ТКН).**

**Тукаебыз вафатыннан соң 102 ел узган-киткән, Тукай турында нибарысы җиде пьеса язылган.**

**1. Әхмәт Фәйзи. «Тукай», тарихи драма (ТКН, 1943). Ул 1961 елда Камал театрында куелды.**

**2. Риза Ишморатның «Моңлы сазым» драмасы шул исемдәге китабына кергән (ТКН, 1983). Куелмаган.**

**3. Туфан Миңнуллинның «Без китәбез, сез каласыз» драмасы Камал театрында 1986 елда куелды.**

**4. Батулланың «Сират күпере» Тинчурин театрында 1986 елда куелды.**

**5. Ибраһим Нуруллинның «Тукай Петербургта» драмасы. Куелмаган.**

**6. Илдар Юзеевның «Очты дөнья читлегеннән» шигъри трагедиясе (1980). Куелмаган.**

**7. Әхәт Гаффарның Тукай турындагы «Соңгы сәгать» пьесасы (1986). Куелмаган.**

**Татар театрлары уннан артык. Алар шушы берәр пьесаны гына куйганда да Тукаебыз рухы рәнҗеп ятмас иде. Шулай итеп, Тукай атналыгы шаулап узар иде. Бу ярышта җиңгәннәрне бүләкләү турында да уйлыйсы бар.**

**Фәкыйрегез шушы тәкъдим белән Мәдәният министрлыгының әүвәлге җитәкчеләренә (Тукайның 120, 125 еллык бәйрәмнәре алдыннан) хатлар язып керткән иде, кызганыч ки, тәкъдимнәремне игътибарга алучы булмады.**

**Рабит БАТУЛЛА**

Хан белән «дипломатик сөйләшү»ләрдән соң бер көнгә хөкемдар хокукы алган Насретдин ин беренче эше итеп Тимерчеләр бистәсеннән сугыш филен алдырырга боера, ярлыларга кием-салым өләшергә, ачларны туйдырырга куша. Бары шуннан соң гына үтенеч белән килгәннәрне кабул итә башлый. Ф.Бикчәнтәев өчен халыкның хан сараена ничек керүе, анда үзен ничек тотуы соң дәрәҗәдә мөһим. Шуңа күрә ул бу күренешне режиссёрлар гадәттә тамашачыларны, залда утырганнарны вакыйгаларга тарту, алып керү өчен кулланыла торган алымнан башлап җибәрә. Залның сул як ишеге ачылып китә һәм халык әйтерсең лә хан сараена килеп керә. Зал үзәгендәге төп юл буйлап курка, каушый хан тәхетенә таба юнәлә. Әйтерсең лә алар белән тамашачылар да сәхнәгә күтәрелә. Аһ-ухлар, гаҗәпләнү, курку ымлыклары, сирәк-мирәк ычкынган репликалар, халыкның никадәр каушаганын, тәкатен, ихтыярын югалтуын ассызыклый. Ниһаять, керүчеләр аңнарын ярым җуйган халәттә, күзләренә ак-кара күренми торган бер аморф масса сыйфатында тәхет алдына килеп тезләнә, йөзтүбән каплана һәм сәҗдәгә китәләр. Томаланган аңга берни барып җитми, хәтта алларында үзләренең тимерчеләр бистәсе диванасы Хуҗа торганы да күзләренә күренми. Баштарак Карт — И.Габдрахманов алардан үзе өйрәткәннәрне кабатлатырга омтылыш ясап карый. Тик юкка, ихтыярын җуйган халыктан берни дә алып булмый. Аптыраган, бу хәлне күреп, аңлап торган Хуҗа үзе дә ярдәмгә килеп карый. Аларның ни әйтергә тиешлеген кабатлый һәм халыктан җавап булмагач, үзенең әле күптән түгел генә алар алдында сөйләгән «нотыгын» кабатлый:

— Җәмәгать! Мин сезгә бер сүз сөйләмәкче булам, нәрсә сөйләячәгемне беләсезме, юкмы?

Куркынган, калтыравык тавышлар:

— Юк, белмибез! Белмибез!

Хуҗа — Җиһаншин соравын янә кабатлый. Шул ук мескен тавышлар:

— Беләбез,беләбез!

Ниһаять, сорау Хуҗа тарафыннан өченче кат бирелә. Сирәк, өметсез тавышлар:

— Кайсыларыбыз белә, кайсыларыбыз белми, тәкъсир!

Һәм Хуҗаның катгый җавабы:

— Соң шулай булгач? Белгәннәрегез белмәгәннәрегезгә сөйләсен!

Спектакль тукымасында бу сөйләшү рефрен булып ике тапкыр кабатлана. Һәм аның мөһимлеген режиссёр үзенең сурәтләү чаралары ярдәмендә (бу очракта мизансцена, интонация) ассызыклый. Тимерчеләр бистәсендә яңгыраганда да, финалда да Ф.Бикчәнтәев Хуҗа Насретдин — Җиһаншинны сәхнәнең иң югары ноктасына — колгалардан берләштерелгән корылма түбәсенә үк күтәрә. Сүзләр дә шул ук. Әмма аларның яңгырашы, әйтелү интонациясе — җир белән күк арасы. Беренче очракта алар дәрт, шаяру, юмор белән, күтәренке рухта яңгырасалар, финалда өметсезлек, күңел кайту, төшенкелек өстенлек ала. «Белгәннәрегез белмәгәннәрегезгә сөйләсен!» Сүз асты мәгънәсе:

— Сезнең бу аңгы-миңге хәлгә житкерелгән, ихтыярсыз коллар халәтегездә минем сезгә кирәгем юк! Берегез белән берегез миннән башка да аралаша аласыз!

Курәмсең, коллык психологиясе белән котылгысыз агуланган халыкның да Хуҗа Насретдинга кирәге юк. Ул күтәрелгән биеклегеннән төшә, ышаган китерергә куша һәм берданбер таянырдай ышанычлы юлдашы белән халыкны ташлап китә. Хуш, Хуҗа Насретдин!

Менә шундый Хуҗа Насретдин! Менә шундый мәгънә! Ихтимал, әйтелгән кайбер фикерләр бәхәследер. Аны кабул итүчеләр дә, итмәүчеләр дә булыр... Ләкин шунысы кыйммәтле: тамаша залыннан беркем дә битараф чыкмый. Арада уйланып, гаҗиз калып чыгучылар күбрәк тә шикелле. Безнең карашка исә бу спектакле белән Ф.Бикчәнтәев иҗатының яңа төсмерләрен ачты, югарырак баскычына күтәрелде.

**Мөхәммәтгали АРСЛАНОВ,**
*сәнгать фәннәре докторы*



*Замандашлар. Сулдан уңга: Хәсән Туфан, Тимер Арслан, Сәгыйт Агиш. Уфа. 1958 ел.*



*Драматург Сәет Шәкүров (1917-1989).*



*Галимнәр-әдипләр. Сулдан уңга: Азат Әхмәдуллин, Мөхәммәт Мәһдиев, Вахит Хаков. 1983 ел.*



*«Казан утлары» журналында коллектив белән Татарстанның тарихи урыннарына сәяхәт-сәйранга чыгу традициясе бар. Бу фотода хезмәттәшләребез һәм язучы авторларыбызның Тукай-Кырлайда булган мизгел сурәтләнеп калган. Басып торалар (уңнан сулга): Фәйзи Галиев («Искра» колхозы рәисе), Марс Шабаев, Шәһидә Максудова, Гариф Ахунов, Равил Фәйзуллин, Гөлзадә Бәйрәмова, Тәслимә Сибгатуллина, Рәдиф Гаташ, Альбина Әхмәтова, Флёра Сабирова; алгы рәттә: Флүс Латыйфи, Алмаз Гыймадиев, Шаһинур Мостафин, Илгизәр Гатауллин (Яңа Кырлай урта мәктәбе директоры). 1998 ел.*



*Шагыйрь Хәсән Туфан җәмәгать һәм дәүләт эшлеклесе Камил Фәсиев белән. 1972 ел.*

# РЕЙХСТАГКА ҖИҢҮ БАЙРАГЫН БЕРЕНЧЕ БУЛЫП КЕМ КАДАГАН?

***Беркем дә, бернәрсә дә онытылмаган... Без бу сүзләрне, аларның тирән мәгънәсенә төшенеп тормыйча гына, шактый еш кабатлыйбыз. Кызганыч ки, чынлыкта да Бөек Ватан сугышының күп кенә каһарманнары, бөтенләй үк онытылып бетмәсә дә, хәзерге көнгә кадәр күләгәдә кала бирә. Шундый геройларның берсе — татар сугышчысы Газетдин Заһитов.***

XX гасырның 70нче елларына кадәрге барлык дәреслекләр, белешмәләр, энциклопедияләрдә «1945 елның 30 апрелендә фашист Рейхстагы хәрабәләре өстенә пулялар белән тишкәләнеп беткән, дары исе сеңгән Җиңү байрагын сержант М.А.Егоров һәм кече сержант М.В.Кантария кадады» дип язылган.

Рейхстагның үзәк гөмбәзе өстендә горур рәвештә җилфердәгән бу байракның «Правда» газетасында басылган, соңрак бөтендөнья мәгълүмат чараларын «әйләнеп чыккан» фоторәсеменә шик белдерергә кем җөрьәт итсен соң? Бу тарихи фотосурәтнең авторы, «Правда» газетасы фотохәбәрчесе В.Темин үзенең 2 майда немецлардан тулысынча азат ителгән Рейхстагка үтеп керүе, бинаның «Җиңү Алиһәсе» скульптурасында Җиңү Байрагы эленеп торуын күрүе хакында сөйли. Фоторәсемдә ачыграк күренеп торсын өчен, үзен озатып йөрүче сугышчыларга байракны үзәк гөмбәз өстенә күчертә ул. Шактый зур бинаның төрле урыннарында моннан тыш та берничә байрак һәм әләм җилферди. Бу аңлашыла да: Рейхстагка төрле яклап күпсанлы штурмлау төркемнәре һөҗүм итә, аларның һәркайсының үз байрагы була.

Хәзер, бу вакыйгаларда катнашучыларның хатирәләре, сугыш архивлары документлары һәм боерыклары басылып чыккач, ышанычлы рәвештә шуны расларга була: әйе, Егоров һәм Кантария чынлап та Рейхстаг түбәсенә байрак кадаганнар, ләкин алар — беренчеләр түгел. Рейхстагны штурмлауда катнашкан капитан С.Неустроев болай дип язып калдырган: «Мин, Берест белән түбәгә менәргә Егоров һәм Кантариягә кушып, ялгыш эшләдем. Чөнки алар атакага күтәрелмәде, Рейхстагны алмады, ә бөтен батальон белән яуланган данга үзләре генә коенды».

Моннан тыш, Егоров һәм Кантария 1975 елда дөнья күргән хатирәләрендә Рейхстагны штурмлауда беренче рәтләрдә булмаулары, өстендә байрак җилфердәгән бинага ул азат ителгәч кенә керүләре хакында язып чыктылар.

«Алар булмагач, кем соң?» — дигән урынлы сорау туа.

150нче укчы дивизия командиры В.Шатиловның 30 майда Рейхстагны басып алулары һәм 14.25 сәгатькә аның көньяк өлешенә кызыл байрак кадаулары хакындагы донесениесе аңлашылмаучылык китереп чыгара. Соңыннан бу хәбәрнең вакытыннан алда җибәрелүе мәгълүм була. Дөрестән дә, дивизия гаскәрләренең бер өлеше Рейхстагка бәреп керә, кемдер хәтта тәрәзәдән әләм җилфердәтә. Ләкин немецлар аларны тиз арада бинадан кысрыклап чыгаралар.

Шуна да карамастан, донесение инде югарыда утыручыларга барып җиткән була. Әлеге хәбәр нигезендә Беренче Белорусия фронты командующие Г.Жуков фронт буенча фәрман чыгара һәм аны И.Сталинга житкерә. Бу хәбәр Совинформбюроның сводкалары арасына да эләгә. 30 апрель кичендә күптән көтелгән әлеге хәбәр радио дулкыннары аша бөтен дөньяга тарала. Рейхстаг тирәсендә исә каты бәрелешләр дәвам итә, аның түбәсендә бернинди байрак та булмый әле. 30 апрель төнендә Рейхстагка берничә штурмлау төркеме бәреп керә. Сугышчыларның бер өлеше

түбәгә үрмәли, бары тик төнлә генә Рейхстаг өстендә кызыл әләмнәр һәм байраклар җилферди башлый...

## Кем беренче булган соң?

136нчы артиллерия бригадасының хәрби хәрәкәтләр журналына күз салыйк. Анда 1945 елның 1 маенда: «1945 елның 1 маена каршы төндә разведчиклар бригадасының өлкән сержант Г.Заһитов җитәкләгән төркеме иң беренчеләрдән булып Берлин өстенә кызыл байрак кадады», — дип язылган.



*Байрак элгән дүртлек: Г.Заһитов (сулдан икенче), М.Минин (сулдан беренче), А.Бобров һәм А.Лисименко.*

1945 елның 1 маенда ук инде Г.Заһитовны Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим итәләр. «Шәхси сугышчан батырлыклар яки казанышлар хакында кыскача анлатмалар» графасында түбәндәгеләр бәян ителгән:

«Безнең гаскәрләр Берлин үзәгенә якынлашып килгән чакта, иптәш Заһитов Рейхстагны штурмлауда катнашырга һәм анда беренчеләрдән булып Җиңү Байрагын кадарга шәхси теләген белдерде. 1945 елның 26 апрелендә Заһитов, сержант Минин, өлкән сержантлар Бобров һәм Лисименко белән бергә, сугышчан бурычны үтәргә кереште. Һөҗүм итүче пехота алдыннан үтеп, Заһитов Рейхстагка бару юлын ачыклады һәм шуның белән безнең сугышчыларның хәрәкәтенә булышлык итте.

28 апрельдә разведчиклар немецларның тылына үтеп, кыю һәм тәвәккәл эш иттеләр: сакчыны атып үтереп, подвалга бәреп керделәр, андагы 25 немец солдатын әсирлеккә төшерделәр.

29 апрельдә Заһитов һәм аның иптәшләре немецлар арасына үтеп керделәр, безнең артиллериянең Рейхстагны утка тотуына юнәлеш бирделәр. Алар урнашкан йорт немецлар тарафыннан камап алынса да, геройлар куркып калмадылар. Автоматлар һәм гранаталар ярдәмендә бу сугышта 40 немецны юк иттеләр һәм безнең җәяүле гаскәриләр килеп җиткәнче йортны дошманнан саклап тордылар.

30 апрельдә Заһитов иптәшләре белән бергә Рейхстагтан йөз метрлар читтәрәк үтүче монарчы билгесез каналга разведка ясады һәм әлеге канал аша үтүче кечү барлыгын белеп, кичекмәстән шул хакта рациядән 79нчы корпус командирына хәбәр җиткерде.

30 апрельдә штурм вакытында Заһитов Рейхстагка беренче булып бәреп керде, әмма шул чакта аның күкрәген пуля үтәли тишеп үтте (яраланганда партбилеты да тишелгән иде). Яраланган өлкән сержант Заһитов, сержант Минин белән бергә Рейхстаг башнясына күтәрелеп, беренче Җиңү Байрагын кададылар.

Рейхстагны штурмлауда күрсәткән тәвәккәллеге, батырлыгы һәм кыюлыгы өчен иптәш Заһитов Советлар Союзы Герое исеменә лаек.

136 АПАРКВның РАД командиры майор Максимов. 1945 елның 1 мае».

## «Байракны нинди дер шәрә хатынның таҗына беркеттек»

Биредә бер анлатма таләп ителә. Заһитовның күкрәген тишкән пуля йөрәктән нибары бер сантиметрга читтәрәк уза. Ләкин батыр Рейхстагка беренче булып бәреп кергәндә түгел, ә Җиңү Байрагын Рейхстаг түбәсенә беркеткәннән соң җәрәхәтләнә. Төн уртасында Заһитов кабаттан түбәгә менеп, байракның урынындамы-түгелме икәнлеген тикшерә. Шул чакта аны төн караңгылыгында «адашкан» пуля эзләп таба да инде. Бу хакта тулырак итеп әлеге төркемдәге Михаил Петрович Минин сөйли.



*Г.Заһитов.*

«Рейхстагны алуыгыз хакында сөйләгез әле», — дигән сорауга Михаил Петрович болай дип җавап бирә (аның сөйләгәннәрен берникадәр кыскартулар белән тәкъдим итәм):

«30 апрельдә җирле вакыт белән 21 сәгать 30 минутта артиллерия әзерлеге башланды. Аның тәмамлануына биш минут кала А. Бобров, Г. Заһитов, А. Лисименко һәм мин почмактагы тәрәзә уемыннан сикердек һәм каналга таба йөгердек.

Артиллерия һәм миномёт утлары Тиргартен (Рейхстагны әйләндереп алган парк.) эченә юнәлгәч, 22 сәгать 00 минутта, штурм башлануны белдереп, һавага күп санлы яшел төстәге ракеталар атылды. Бу вакытта без дүртебез дә каналның икенче ярында идек инде. Юан торба буйлап бер-бер артлы тезелеп элдерттек кенә.

Төп көчләр килүен көтеп тормастан, без шундук урам яктагы ишеккә таба ташландык. Заһитов бу маршрутны инде көндез үк өченче каттан бинокль аша җентекләп күзәткән иде. Без уктай атылдык. Уннан да, сулдан да дошманның «исән калган» ут нокталары телгә килде.

Безне әрдәнәләнгән төзелеш материаллары, кирпеч, балчык өемнәре бик яхшы саклаганга, дошман уты әлләни куркыныч түгел иде.

Рейхстагка якынлашкач, барган шәпкә алдагы ишеккә юнәлтеп автоматлардан ут ачтык һәм, бер мизгелгә дә тукталып тормастан, киң гранит баскычлар буйлап өскә күтәрелә башладык.

Ике якка ачылмалы бердәнбер галәмәт зур ишек бикле булып чыкты. Иңбашлар белән этсәк тә, аяклар белән типсәк тә, прикладлар белән бәрсәк тә, ишек бирешмәде. Керү урынында кечкенә генә тоткарлык килеп чыккан арада без Бобров белән полковник Писарев тапшырган Кызыл байракны диварга беркетеп куярга өлгердек. Бу 30 апрельдә 22 сәгать 10 минутта булды.

Берничә минут узгач, төп ишек янында бүтән частьлардан һәм подразделениеләрдән дә байрак йөртүчеләр килеп, байраклар һәм әләмнәр беркетә башладылар.

Ишекне тиз арада ватмасак, кинәт бәреп керү мөмкинлеген кулдан ычкындыруыбыз ихтимал иде. Гази баскычтан ерак түгел аунап яткан бүрәнәне күреп алды. Алар Лисименко белән икәүләп аска төштеләр һәм бүрәнәне күтәреп килделәр. Берничә мәртәбә бүрәнә белән бәргәннән соң, ишек ачылып китте. Бина эченә тоташ ташкын булып совет сугышчылары ябырылды. Гази Заһитов иң алда иде. Ишек ачылып киткәндә, ул бүрәнә белән бергә вестибюльгә «очып» керде...

Дошманның югалып калуыннан һәм һөҗүмнең беренче минутларында ирешкән уңыштан файдаланып, командирыбыз капитан В.Маков тагын да өскәрәк менәргә карар кылды.

Заһитов, Бобров, Лисименко һәм мин дүртәүләп баскыч буйлап югарыга ыргылдык. Иң алдан Гази чаба иде. Баскычка алып чыгучы барлык коридорларга гранаталар ташладык һәм автоматлардан ут сиптердек.

Чарлакны гитлерчылардан «чистартканнан» соң, Заһитов, фонаре белән яктыртып, очлары югарыга тоташкан, пластинкалы галәмәт дәү чылбырлы йөк чыгырына юлыкты. Аның буыннары кеше аягы сыярлык зурлыкта иде.

Чылбыр буенча бер-бер артлы өскә үрмәләдек. Һәрвакыттагыча, иң алдан Гази, аның артыннан байрак тотып мин үрмәлим. Дүрт метрлап менгәч, «тынлау» тәрәзәсе аша түбәгә чыктык. Шунда, төшеп ярылган снаряд яктылыгында Лисименко безнең ориентирыбызны — «Җиңү Алиһәсе»н ( без ул чакта скульптура төркеменә шундый исем биргән идек) күреп алды.

Артиллериянең ут яудыруына карамастан, байракны нәкъ менә скульптураның өстенә беркетергә карар кылдык. Мин әләм тукымасына 1945 елның 30 апрелендә 22 сәгать 30 минуттан алып 22 сәгать 40 минутка кадәр вакыт эчендә Рейхстаг түбәсенә беренче Җиңү Кызыл Байрагын кадаучыларның (үземнең, Бобровның, Заһитовның, Лисименконың) исемнәрен язып куйдым. Байракны бәйләп кую өчен

Заһитовка үзенең кульяулыгын тасмалап ерткаларга туры килде».

Әлеге сугышчан вакыйгада турыдан-туры катнашучының сөйләгәннәре чынбарлыкта да эшнең шулай булганлыгына шик тудырмый. Мининның бәян итүендә кызыклы бер деталь бар. Яугирләр сугышчан бурычның үтәлүе хакында капитан В. Маковка, ә ул рациядән шунда ук корпус командиры генерал-майор С.Н.Переверткинга хәбәр итә. Чиксез дулкынланудан капитан телефон трубкасына, сүзләрне сайлап тормыйча: «Иптәш генерал, минем егетләрем беренчеләрдән булып Җиңү Байрагын Рейхстаг өстендәге шәрә хатынның тажына беркеттеләр!» — дип кычкыра.

Нәкъ шул мизгелдә Газетдин Заһитов яңадан түбәгә менә һәм каты яралана. Пуля аның күкрәгендәге партия билетын һәм «Батырлык өчен» медале колодкасын тишеп чыга. Әмма Заһитов сугыш кырын ташлап китми, ахырга кадәр иптәшләре янында кала.



*М.Минин.*

## Ни сәбәпле аларга Герой исеме бирелмәгән?

Михаил Петровичның сөйләвенчә, берничә сәгатьтән (бу вакытта инде Рейхстаг алынган дияргә була, бары тик подвалда гына каршылык күрсәтүче дошман төркемнәре кала) алар саклаган баскычтан кыска күн куртка кигән лейтенант А.П.Берест, аның артыннан байрак йөртүчеләр М.Егоров һәм М.Кантария, аларның эзенә басып ике автоматчы күтәрелә. «Аларның алга таба ни эшләве мина билгесез, әмма шуны гына ышанып әйтә алам: 1945 елның 1 маенда Мәскәү вакыты белән иртәнге бишкә чаклы (ә җирле вакыт белән төнге өчкә кадәр) М.Егоров һәм М.Кантария түбәнең скульптур төркем торган җиренә менмәделәр һәм без саклаган баскычтан да үтмәделәр», — Минин сүзләре бу.

1945 елның 1 маенда 130нчы артиллерия бригадасы командованиесе штурмда катнашучыларның бишесен дә Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим итү хакындагы документларны әзерли. Г.Заһитов исеменә төзелгән документтан югарыда өземтә китерелде инде. Шуннан соң 2, 3 һәм 6 майда 79нчы корпус командиры, Өченче удар армиянең артиллерия командующие һәм алга таба югарырак дәрәҗәле башлыклары бу документны язма рәвештә раслыйлар.

Ләкин Г.Заһитов та, аның сугышчан иптәшләре дә Герой исемен ала алмады, аларның батырлыгы нибары Кызыл Байрак ордены белән генә билгеләп үтелде. Шулай булуга карамастан, аларны бүләкләү өчен әзерләгән документлар Оборона министрлыгының архивында сакланып калган (136нчы фонд, 212465нче тасвирлама).

Күрәсең, югары командование Рейхстагны штурмлаганчы ук, ана Җиңү Байрагын кадарга тиешле рус һәм грузин милләтеннән булган байрак йөртүчеләрне алдан ук билгеләп куйган. Моны шунсы да раслый: аларның кулында башка сугышчылардагы кебек зур кызыл киндер тукыма гына түгел, ә бәлки озын саплы, чехоллы чын байрак була. Өстәвенә, аларны резервта тотканнар һәм Рейхстагны алгач кына чыгарып җибәргәннәр. Алардан элек штурмлаучы төркемнәр тарафыннан эленгән кызыл байракларга беркем дә игътибар итмәгән. Бу инде сугышның җиңү ноктасы була, ул ноктаны махсус сайланган, җиде кат иләктән үткәрелгән һәм барлык таләпләргә туры килгән кешеләр генә куя алган. Әнә шул рәвешле идеологик фикерләүләр тормыш чынбарлыгыннан өстенрәк булып чыга.

Халык арасында аларны Иосиф Виссарионович үзе сайлаган дигән сүз дә йөри. Ә чынлыкта бу фикер маршал Г.Жуковның яки аның тирәсендәгеләрнең башына килергә дә мөмкин. Шул дәвер күзлегеннән караганда, аңларга да була: Рейхстаг өстендә кадалган байрак шартлы рәвештә Бөек Җиңүнең асылын гәүдәләндерә бит.



Министерство обороны Российской Федерации

Ордена Красной Звезды
ИНСТИТУТ
ВОЕННОЙ ИСТОРИИ
01 марта 1994 г.
N 199

117330 г. Москва, Университетский пр.
тел. 147-45-63

Исх. вх. № 149 от 29.12.1993 г.

ПРЕДСЕДАТЕЛЮ КОМИТЕТА ЛЕНИНГРАДСКОЙ ОРГАНИЗАЦИИ ВЕТЕРАНОВ-ОДНОПОЛЧАН
генерал-полковнику в отставке
Кубареву В.Н.

191187, г. Санкт-Петербург,
набережная Кутузова, 22

Входящий № 113 … 3 1994 г.

В результате исследования, проведенного Институтом военной истории Министерства обороны Российской Федерации на основе архивных документов, установлено, что первой на здание Рейхстага Красное Знамя водрузила группа капитана В.Н.Макова.

Исходя из этого Институт военной истории МО РФ поддерживает ходатайство Комитета ленинградской организации ветеранов-однополчан о присвоении звания Героя Российской Федерации капитану Макову В.Н., старшим сержантам Загитову Г.К., Боброву А.П., Лисименко А.Ф., сержанту Минину М.П.

НАЧАЛЬНИК ИНСТИТУТА
генерал-майор В.Золотарев

Фашистлар белән көрәштә һәлак булган күп миллионлы совет халкының канына манчылган. Әмма биредә Югары башкомандующийга яраклашырга тырышу теләген дә истән чыгарырга ярамый.

Идеологик һәм сәяси мотивлар арткы планга күчә барган саен, намусына тап төшермәгән тарихчылар, журналистлар, язучылар һ.б. һөнәр ияләре тарихи дөреслекне торгызырга кирәклеге хакында үз фикерләрен торган саен күбрәк белдерәләр.

Капитан В.Маков командалыгында Г.Заһитов, М.Минин, А.Бобров һәм А.Лисименкодан торган төркемнең батырлыгын бүгенге көндә барлык намуслы хәрби тарихчылар раслады инде. Бу хакта «1939-1945 еллардагы Икенче бөтендөнья сугышы тарихы»нан, (X том, Воениздат, 1979 ел), «Икенче бөтендөнья сугышында Совет Кораллы көчләре»ннән бай мәгълүмат табарга мөмкин.

Биредә «Хәрби энциклопедия»дән (III том, 1995 елгы басма, 292нче бит) өземтә китерү урынлы булыр:

«Беренче булып 1945 елның 30 апрелендә Мәскәү вакыты белән 22 сәгать 30 минутта 79нчы укчы корпусның капитан В.Н.Маков җитәкләгән штурмлау төркеме составындагы 136нчы армиянең туплы артиллерия бригадасы артиллерист-разведчиклары — өлкән сержантлар Г.К.Заһитов, А.П.Бобров, А.Ф.Лисименко һәм сержант М.П.Минин Рейхстаг түбәсендәге «Җинү Алиһәсе» скульптур төркеменә Байрак кададылар... 2-3 сәгать үткәч, Рейхстаг түбәсендәге атлы рыцарь кайзер Вильгельм сынына да 150нче укчы дивизиянең 756нчы укчы полк командиры Ф.М.Зинченко боерыгы белән, лейтенант А.П.Берест һәм өлкән сержант И.Я.Сьянов ротасы автоматчылары озатуында, разведчиклар — сержант М.А.Егоров һәм кече сержант М.В.Кантария 5нче Кызыл Байракны кададылар, 2 майда бу әләм Җинү Байрагы сыйфатында Рейхстаг гөмбәзенә кучерелде».



ВОЕННАЯ ЭНЦИКЛОПЕДИЯ
Том 3 изд.1995 г. стр.292
(Выписка)

ЗНАМЯ ПОБЕДЫ

Красное Знамя, водруженное советскими воинами в ночь на 01.05.1945 года над зданием поверженного рейхстага в Берлине является символом Победы Советского народа в Великой Отечественной войне 1941-1945 гг. Перед штурмом рейхстага Военный совет 3-й ударной армии вручил своим дивизиям девять красных знамен, специально изготовленных по типу Государственного флага СССР. Одно из них (известно под № 5) было передано 150 стрелковой дивизии. Подобные самодельные знамена, флаги и флажки имелись во всех других передовых соединениях, частях и подразделениях. Как правило, они вручались штурмовым группам, которые шли в бой с главной задачей – прорваться в рейхстаг и установить на нем Знамя Победы. Первыми в 22 часа 30 мин. (время московское) 30.04.1945 года водрузили Знамя на крыше рейхстага (на скульптурной группе "Богиня Победы") артиллеристы-разведчики 136 армейской пушечной артиллерийской бригады ст. сержанты Г.К.Загитов, А.П.Бобров, А.Ф.Лисименко и сержант М.П.Минин из состава штурмовой группы 79 стрелкового корпуса, возглавляемой капитаном В.Н.Маковым.

Шушы мәгълүматларга таянып, Татарстан һәм Башкортстан җәмәгатьчелеге (Г.Заһитов тумышы белән Башкортстанның Мишкә районыннан) 1994 елда Г.Заһитовка һәм аның иптәшләренә (үлгәннән соң) Россия Герое исеме бирү хакында үтенеч юллады. Әлеге үтенеч РФ Оборона Министрлыгының Хәрби тарих институтында



*Ягъсуф Шафиков (сулда) һәм Г.Заһитов музееның беренче директоры Галимҗан Бикбулатов данлы каһарманыбызның кабере янында. 2010 елгы фото.*

каралды һәм бертавыштан кабул ителде. Моны рәсми документлар да раслый. Әмма Оборона министрлыгында тарихка төзәтмәләр кертергә теләмиләр һәм барысын да искечә калдыруны мәгъкуль күрә.

Инде менә Бөек Җиңүнең 70 еллыгы якынлаша. РФ Президенты В.В.Путинның тәкъдиме белән, элек орден-медальгә тәкъдим ителеп тә, теге яки бу сәбәпләр аркасында аны вакытында алмаучыларның берсе дә бүген бүләксез калмаячак.

Нәкъ менә хәзер бу мәсьәләне күтәрү һәм тарихи дөреслекне торгызу өчен иң кулай вакыт дип уйлыйм. М.Егоров һәм М.Кантариянең батырлыгын таныган хәлдә чын геройларны да искә төшерергә кирәк.

Аларның күбесе инде арабызда юк, шуңа күрә бу барыннан да күбрәк геройларга түгел, безнең үзебезгә — бөтенебезгә дә кирәк.

## Каһарманның язмышы хакында

Татар сугышчысының язмышы турында берничә җөмлә өстисе калды. Газетдин (бүләкләү кәгазендә Гизий дип язылган) Казыйхан улы Заһитов 1921 елда Башкортстан АССРның Мишкә районы Янакош авылында туган. Милләте буенча — татар. Туган авылында 4нче сыйныфны тәмамлагач, күрше авылда җидееллык мәктәптә укый. Ике ел Бөре медицина техникумында белем ала. 1940 елда армия сафларына алынуы сәбәпле, аны тәмамларга өлгерми. Балтыйк буенда хезмәт итә. Бөек Ватан сугышында аның башланган көненнән үк катнаша. Командование боерыкларын намус белән үтәгән өчен берничә мәртәбә дәүләт бүләкләренә лаек була.

Сугыш беткәч, 1945 елда туган авылына ялга кайта. 1946 елның июнендә демобилизацияләнеп, Янакошка кайтып урнаша. Башта гади колхозчы була, соңрак аны авыл советы рәисе итеп сайлыйлар. Күрше авыл кызы Камилә белән гаилә корып җибәрә. Фрунзе исемендәге колхозда тракторчы һәм комбайнчы булып эшли. 1953 елның 23 августында Уфага запас частьлар алырга барганда, юл-транспорт фаҗигасенә юлыгып, якты дөнья белән хушлаша.

Аның бер улы, бер кызы этисез кала. Бүгенге көндә Нажиясенең җиде кызы һәм берничә оныгы, ә Мингалиенең ике улы бар.

Янакош авылында атаклы якташларының истәлеген кадерләп саклыйлар, мәктәп музеенда аңа багышланган махсус стендлар бар. Г.Заһитовның каберенә куелган гранит обелискта:

«Биредә Заһитов Газетдин Казыйхан улы күмелгән, 1921-1953. Ул штурмлауда катнашып, Рейхстагка беренчеләрдән булып Кызыл Байрак беркетә. Каһарманга мәңгелек дан», — дип язылган.

**Ягъсуф ШӘФЫЙКОВ**

# ТУКАЙ ТӨРЕК ТЕЛЕНДӘ ЯЗГАНМЫ?..

«Кояш» журналында «Клячкин шифаханәсе, 14 март, 1913 сәнә, Габдулла Тукаев» имзасы белән басылган «Уянгач беренче эшем» мәкаләсендә болай диелә: «Ярты төш мисалендә үтеп киткән 7 сәнәлек бер мөтдәт эчендә минем тарафтан шактый гына манзумат язылып ташланган. Ул манзумат, вак-вак диваннарга тәдвин ителеп, төрек-татар галәменең һәр ягына таралган. ...Шулай булган. Заман кичкән. Сулар аккан. ...Сабыр кирәк. ...Килер заман, һәр язучының үзен, сүзен вә шәхси тормышын инәсеннән җебенә кадәр тикшереп чыгарлар әле...»

Заманнар үтү белән, һәр язучының сүзен генә түгел, аның турында язылган кәлимәләрне дә тикшереп чыгу зарур. Бу юнәлештә Г.Тукайның башлангыч чор иҗаты турындагы мәгълүматларга аеруча игътибар итәргә кирәклек күренә.

Г.Тукайның Җаек чорында (1895-1907) язылган шигырьләренең теле турында, һәр әсәрне аерып алып та, авторның тулаем иҗаты яктылыгына куеп та, Ф.Әмирхан (1907, 1908), Г.Рәхим (1913), Җ.Вәлиди (1913, 1923), Г.Сәгъди (1923, 1926) мәкаләләреннән башлап, күп галимнәрнең, һәрберсенең үз максаты, үз чоры карашыннан чыгып, төрлечә фикер әйтүе мәгълүм *(Ганиева, 2002: 85-109)*.

Әлеге юнәлештә бер үк фикерләрнең кабатлануы да, яңаларының әйтелүе дә күренә. Фикерләр кабатлана дигәндә, Ф.Әмирханның «Габдулла Тукаев шигырьләре, 3 дәфтәр» җыентыгы басылып чыгу уңае белән язылган мәкаләсендә күтәрелгән мәсьәләләрне истә тотабыз. Бу мәкаләдә автор Г.Тукайның саф сөйләмә телендә язылган шигырьләрен югары күтәреп мактый: «Һәр милләтнең шөгарасы — шул милләтнең теленең сакчысы вә төзәтүчесе, шул халыкның кайгы вә шатлыкларын үзләренә вә башкаларга дөрест сурәттә аңлатучы вә халыкның коры сүзләрдә вә нәсерләрдә изһар итәлә алмаган халәте рухияләрен изһар итүчеседер. Шуңа күрә дә шигырь вә шөгарә халык әдәбиятында иң мөхтәрәм урынга куеладыр...»; «...Мәҗмугада «Шүрәле», «Пар ат», «Теләнче», «Кемне сөяргә», «Дөньяда торыйммы? дип кинәшләшкән дустыма», «Туган җиремә» дигән шикелле шигырьләр һәр җәһәтеннән тәкъдир ителергә шаяндыр (лаекдыр, хаклыдыр)».

«Иске төрек телендә» язылган дип уйланыла торган шигырьләрне автор өчен гөнаһ эш дип белдерә: «Бу мәҗмугада Габдулла әфәнденең халис татарча — һәр татар рәхәтләнеп укырлык язылган бик гүзәл шигырьләре вә халис татар мәгыйшәтеннән алынган тасвирлары янында, иске төрек теле белән язылып, гарәпчә, фарсыча, азәрбайҗанча, тагы әллә нәрсәчә телләреннән корылган шигырьләре дә күптер... Габдулла әфәнде кеби табигате шигъриятле кешеләрнең иске вә яңа төрек әдәбияты тәхте тәэсиренә төшеп тә, татар шагыйре урынына — үзләреннән мөтәкәллиф төрекләшкән шагыйрьләр ясаб чыгарулары татар теле вә әдәбияты ноктаи нәзарыннан гөнаһдыр. ...Гарәп сүзләреннән татарча төзелеп ясалган бәетләрнең татар шигырь мәҗмугасында торулары — бөтенләй урынсыздыр». Бу төрдәге шигырьләрнең дә «гүзәл чыгуы» искәртелеп үтелә: «Болардан башка төрек әдәбияты тәхте тәэсирендә язылган шигырьләрендә дә Габдулла әфәнде мөстәкыйль вә гүзәл тасвирлар дәреҗ итәдер», — дип, «Хур кызына» һ.б. берничә шигырьдән өзекләр китерелә, кайбер тәрҗемәләренең дә «телләрен истисна белән», ягъни телен искә алмаганда, бәхак (чыннан да) гүзәл чыкканнар, — дип бәяли *(Даменла, Әл-ислах, 1907, №9; Әмирхан, 1986: 11-14)*. Ф.Әмирханның икенче мәкаләсендә дә әлеге язмада чагылыш тапкан фикерләр дәвам иттерелә: «Моннан соң Габдулла әфәндедән халис татар телендә язылган озын-озын поэмалар көтәмез. Татар теленең (дикъкать итегез — төрек

түгел!) аз булса да алга атлавы өчен, мотлак куәи шигърияле затларымызның тәсаннигсыз (табигый) татар булып калулары лаземдер» *(Даменла, Әл-ислах, 1908, 2 февраль; Әмирхан, 1986: 22-23).* Шулай итеп, Г.Тукайның шигырьләре татар халкының саф сөйләмә телендә һәм иске төрек телендә язылган дип белдерелә. «Иске төрек теле» дигән төшенчә, гарәп, фарсы, азәрбайҗан телләре белән бергә бәйләп әйтелгәнгә, әлеге тәгъбирне гомумтөрки дигән мәгънәдә аңларга да була кебек. Г.Тукай үзе дә җыентыкларының «...Ул мәнзумат вак-вак диваннарга тәдвин ителеп, төрек-татар галәменең һәр ягына таралган...» — дип язганда, «төрек» сүзенең тулаем гаилә исеме булган «төрки» мәгънәсендә кулланылуы аңлашыла.

Берничә ел үткәч, Җ.Вәлиди М.Кашгариның «Диване лөгатет-төрек» хезмәтенә нигезләнеп (Безнең юл, 1927, №3) һәм «Йолдыз» белән «Вакыт» газеталарының телен тикшерү унаеннан *(Шунда ук: 1928, №1)*, «төрки-төрек-татар» төшенчәләренең үзләренә хас мәгънәләре булуына игътибар итә һәм болай дип белдерә: «...Төрекчә бар, төрки бар, болар — бер-берсенә башка нәрсәләр. «Төрекчә» дигәне — «госманлыча» дигән сүз. «Төркия» дигәне, гомумән, «төрек теленчә» дигән сүз. Димәк ки, татарча язылган китап төрекчә булмый, бәлки төрки була. «Төрки» ул — гарәпчә һәм фарсычага каршы куелып йөртелә торган классик бер тәгъбир...» (Шунда ук).

Әмма Г.Тукай иҗатына карата язылган мәкаләләреннән аңлашылганча, Җ.Вәлидинең әле «төрки-төрек» төшенчәләрен аерымламыйча куллануы күренә. Мәсәлән, «Габдулла Тукаев» (1913) дигән мәкаләсендә, асылда, Ф.Әмирханның «...халыкның кайгы вә шатлыкларын үзләренә вә башкаларга дөрест сурәттә аңлатучы вә халыкның коры сүзләрдә вә нәсерләрдә изһар ителә алмаган халәте рухияләрен изһар итүчеседер...» дигән фикерен кабатлап, шагыйрьнең сүзе гади генә сүз булмыйча, «...андагы хис вә мәгънә татар халкының мәңгелек җан азыгы булачакдыр...» дип инануын белдерә. Ләкин алга таба «шагыйрь сүзенең җан азыгы» булу фикере куәтләнми, «Тукайның шагыйрьлеге» хезмәтендә инде Җаек чорында язылган әсәрләренең телен «саф госманлыча яки бераз госманлыча» дип бәяли (Мәгариф, 1923), ягъни «иске төрек теле» дигән төшенчә аерым госманлы дәүләтендәге халыкның теле дигән мәгънәсендә тәгаенләнеп кулланыла.

Г.Ибраһимов та 1922 елда шушы ук фикерне кабатлый: «...Тукай кебек шагыйрьләр (башлангыч «Мөхәммәдия» дәвере) байтак вакытлар ярым «Тәрҗеман», ярым госманлы тәэсирендә бардылар. Ләкин тормышның төбендән табигый рәвештә күтәрелеп килгән халык хәрәкәте әдәбиятны, матбугатны үзенә корал иттерергә теле иде. Боның өчен җанлы халык теле лазем иде», — ди.

Аңлашылганча, шагыйрьнең гарәп вә фарсы алынмалары кулланылып языла торган әсәрләренең кыйммәте, аның теле кимәлендә, татар халкының сөйләмә теле яктылыгына куеп тискәре бәяләнә һәм озак еллар буена кабатланачак, «Г.Тукайның беренче шигырьләре госманлы-төрек телендә язылган» дигән фикер ныгытыла. Дөрес, Ф.Әмирхан мәкаләсендә, «телен исәпкә алмаганда, бу төрдәге шигырьләрнең дә «гүзәл чыгуы» фикере алга таба да дәвам иттерелә. Мәсәлән, әдәбиятчы галим И.Нуруллин әлеге шигырьләрнең сәнгати ягына игътибар итә: «...Тукайның бу чорда ара-тирә татарча язуын хупласак та, әлеге төркемгә кергән шигырьләрен сәнгатьлелек ягыннан бик үк мактый алмыйбыз. Шагыйрь үзе дә аларга ... «агитка» итеп караган», — дип, авторның иске татар телендә язылган мәхәббәт шигырьләрен һәм «Пушкинә» дигән одасын «...чын мәгънәсендә лирик шигырьләр булып, сәнгать ягыннан югары торалар. Әмма аларны аңлар өчен ...татарчага тәрҗемә итәргә кирәк», — дип белдерә *(Нуруллин, 1977: 82-83; 1979: 312-313).*

Шуның белән бергә, татар әдәби теле тарихын өйрәнеп, беренче мәкаләләрен яза башлаган Л.Җәләй «Тукай телендә фигыльләр» дигән күләмле мәкаләсендә: «...Тукай телен өйрәнү — татар әдәби теле тарихының мәгълүм бер баскычын өйрәнү дигән сүз ул», — дип, шигъри әсәрләрнең телен яңача тикшерергә кирәк булуны күтәрә *(Җәләй, 1938).*

Әмма бу фикер игътибар үзәгенә күтәрелә алмый. Татар әдәби теленең тарихы булган дип фикер йөртүче галимнәр кулга алына, юкка чыгарыла.

Г.Тукайның башлангыч чор иҗатын госманлы — төрек теле һәм әдәбиятына бәйләп карау дәвам итә. Ш.Рамазановның «Тукай һәм хәзерге татар әдәби теле» дигән

мәкаләсендә: «...Тукай иҗатына кадәр татар поэзиясе һәм татарча художестволы сүз культурасы турында шартлы рәвештә генә сөйләргә мөмкин». Тукайга кадәр булган татар әдәбияты «...поэтик идея, поэтик фикер ягыннан ярлы, сәнгатьчә эшләнеш ягыннан, күбесенчә, примитив, ...һәм тел ягы бөтенләй корама иде», — дип, үрнәк рәвешендә Г.Утыз Имәни, Ш.Зәки, Г.Чокрый әсәрләреннән мисаллар китерә. Г.Кандалыйның «саф татар телендә язган берничә шигыре генә өстенлек итеп килгән гомуми хәлне, әлбәттә, үзгәртә алмавын», «К.Насыйри «яна татар әдәби теле төзү юлында искиткеч зур эшчәнлек күрсәтүен» искәртә. «Лексик һәм грамматик нормалар карарлашмады, чуарлыклар артканнан-арта барды. Бер яктан, әле «төрки тел» дип аталган борынгы феодализм чорының корама «китап теле» дәвам итсә, икенче яктан, пантюркистлар Волга буе татарларына да әдәби тел итеп төрек телен көчләп тагарга маташтылар», — дип, үз чорының сәясәтенә туры китерелгән, әдәби тел өлкәсендәге теория аңлатыла *(Рамазанов, 1946, 1954: 58-61)*. Г.Тукай шигырьләренең теле дә әлеге нигезгә куеп тәгаенләнә: «Бу чорда Тукай ике телдә — татар һәм төрек телләрендә язды. 1905 елда басылган 7 шигыренең 4се татарча, 3се төрекчә, 1906 елда 39 шигырьдән 18е татарча, 14е төрекчә, 7се катнаш, 1907 елда 34 шигырьдән 29ы татарча, 3се төрекчә, 2се катнаш телдә язылганлар. ...Тукайның ул чакта әле татар әдәби теле мәсьәләсендә аерым концепциясе дә, нык позициясе дә булмаганлыкны күрсәтә...» (Шунда ук: 58-63).

Әлеге фикергә Г.Тукай иҗатына татар әдәби теле тарихының мәгълүм бер баскычын өйрәнү күзлегеннән җавап бирү көтелә. Бу юнәлештә, «төрек», «төрки», «татар», «катнаш» төшенчә-терминнарының мәгънәсен тәфсилләп, һәр шигырьдә кулланылган сүз һәм сүзформаларны, һичшиксез, «инәсеннән җебенә кадәр тикшереп чыгарга» кирәклек аңлашыла. Тикшерү барышында, асылда, өч сорауга җавап көтелә: 1) иске татар телендә язылган әдәбият тулаем рәвештә халыкка аңлаешсыз корама булганмы? 2) Г.Тукай төрек телендә шигырьләр язганмы? 3) Г.Тукайның татар әдәби теле мәсьәләсенә карата үз фикере булганмы?

Хәзерге татар филологиясендәге өйрәнүләргә нигезләнеп, әлеге сорауларга (мәкалә кысасында кыскача) түбәндәгечә җавап бирә алабыз.

1. Билгеле булганча, Г.Тукай иҗат итә башлаган XX йөз башына кадәр, һәр әсәрнең авторы үзе ассызыклап искәртә барганча, Болгар-Казан төркиендә язылып килә торган язма әдәбиятның 700 елга якын тарихы исәпләнә. Тукайлар чорына хәзерлек менә шушы тарихи нигездә бара. Г.Тукайга «Урта Азия һәм төрек шагыйрьләренә ияреп иҗат итүеннән» бигрәк, татар шагыйрьләренә ияреп язу өчен дә җирлек нык була.

700 елның соңгы ике йөз елына гына, ягъни XVIII гасыр башыннан XIX йөз ахырына кадәрге дәвердә язылa килгән поэзия әсәрләрендә авторларның үз вакытындагы әдәби телдән ничек файдалануына кыскача игътибар итик.

XVIII гасыр башында Габди (1679-1710 елдан соң) «...*Мескен Габди барчадин кәм, Шәһре — Казан, теле — төрки»*, — дип, һәр эшне Аллаһы исеме белән башларга кирәклеккә, намаз кылырга, рузә тотарга, дөнья эшен тәрек кылырга дигән нәсыйхәтен халыкның үз сөйләмә теле белән язып аңлата: *«...Барыр йиренез бер йирдәдер, / Йарлы, бай, хатын, ирeңез; / Биргәнегә шөкер кылып, / Һәр ни булса, бергә йигенез...» (Әхмәтҗанов, XVIII гасыр..., 2006: 13-30). «...Хәмде Аллаһ — кавыштырсын / Әкълим Казан шивәсен, / ...Казан йулы иленез, һай, / Сәйран икән йиренез...»* — дип иҗатын башлаган Габдессәлам (1700-1776) һ.б. авторлар: *«...Шәһре Болгар алдыңыйлар, / ...Гүзәл, мәкъбүл Болгар йулы, / ...үзем үлсәм, китап калыр йадкәр...»* — дип инанып шигъри юллар тезәләр *(Шунда ук: 121-124)*. Әсәрләрендә «мөселман ирәнләргә, бигрәк тә биле нечкә, үзе зифа гөлзар, агъзы шикәр, деле бал нигярым, сәвекле ярларга, карендәш, туганнарга» мөрәҗәгать итәләр. Бу «Иляһи бәет»ләр (мөнәҗәт, касыйдә, вассыйәтнамә, нәзым, мәдхия һ.б.) Болгар-Казан төрки шивәсендә язылa дип белдерелә, билгеле бер дәрәҗәдә гомумтөркилек сакланып һәм гарәп-фарсы алынмалары файдаланылса да, асылда, Болгар, Казан, Оренбург, Каргалы, Сарачин, Тубыл төбәгендәге кешеләр сөйләшә торган һәм аларның авыз иҗаты әсәрләренә якын булып язылганлыгы күренә *(Шунда ук)*.

Әмма XVIII гасыр ахыры — XIX йөзнең беренче яртысында шул ук Болгар-Казан төркие — иске татар теленең Г.Утыз-Имәни, Ә.Каргалый, Һ.Салихов, Ш.Зәки кебек шагыйрьләр иҗатында алтмыш-җитмеш процент гарәп һәм фарсы алынмалары белән туендырылган нигездә баруы мәгълүм. Бу авторларның барысы да диярлек Көнчыгышның бай мәдәниятен, әдәбиятын, гарәп вә фарсы теленең һәм традицион төркинең нечкәлекләрен үзләштергән шәхесләр. Алар үз чоры өчен актуаль булган катлаулы публицистик трактатлар иҗат итә. Әсәрләрнең күбесе урта гасырларда яшәгән дин һәм хокук буенча күренекле белгечләрнең дөньякүләм танылган хезмәтләренә нигезләнә. Аңлашылганча, бу әсәрләр укымышлы, белемле, гарәп вә фарсыны яхшы белүче укучыларны күздә тотып, гарәп-фарсы алынмаларын һәм традицион гомумтөрки сүз, сүзформаларны мул кулланып язылa. Димәк, адресат һәм тема үзгәреше язма телне үзенә җайлаштыра. Хәзерге телебездән аермалы буларак, иске татар телендә менә шундый мөмкинлек була.

Шуның белән бергә, XIX гасыр урталарына таба, XVIII йөзнең беренче яртысындагы «Иляһи бәетләр»дәге кебек, халыкның сөйләмә телендә, аның авыз иҗатында кулланыла торган сүзләрне файдаланып иҗат итү эше җанлана. XIX гасыр урталарында Баһави, үзенең кайгысын түгеп, моңлы адәмнәрнең күңеле ачылсын дигән изге теләк белән, фарсы телендәге чәчмә «Бүз йегет»не тезмә хәлгә китереп тәрҗемә иткәндә, шул моңлы адәмнәрнең үз сөйләмә телендә язарга кирәк булуын аңлап эшли. (Бу юнәлештә ул Болгар-Казан шивәсен үзе яшәгән төбәктәге казакъ телендәге сүзләр белән дә баетып җибәрә *(Гайнетдинов, 1977: 127-128)*.

Инде килеп, XIX гасыр ахырларына таба, Баһавиның «Бүз йегет», Г.Кандалыйның нәзымләрен файдаланып, Ә.Уразаев-Кормаши (1855-1883) үзенең «Кыйссаи Бүз йегет» (1874) һәм «Кыйссаи Таһир илә Зөһрә» әсәрләрен иҗат итә. Автор аларның ничек итеп язылуы хакында «Кыйссаи Таһир илә Зөһрә» әсәренең ахырында аңлата: «...Бу хикәяте гаҗибияне госманлы тәварихларындан күреб, җинелрәк телемез — нугай вә казакъ лөгатенчә чыгарыб, «Бүз йегет» нам нөсхәмез кеби, мин әүвәлиһи илә ахирихи, тасхих вә мокабәлә кыйлыб, иҗаз тарикынча, бу ике телгә тасниф кылдым». Автор кыйссаларының телен үзе яшәгән төбәктәге атамасы белән «нугай вә казакъ лөгатенчә» дип белдерә, госманлы тарихларын башыннан ахырына кадәр шушы телдә чагыштырып һәм төзәтеп чыгардым, ди. Кыйссаларында казакъ теленә хас булган сүз һәм сүзформаларны яратып куллана (Тукай әлеге әсәрләр кыргыз телендә язылган, ди), димәк, иске татар теленең аерым урынчылыкта файдаланыла торган тел берәмлекләре белән баетыла баруы тагын да киңәйтелә.

Алга таба әлеге юнәлеш М.Акмулла, Я.Емельянов һ.б. шагыйрьләрнең әсәрләрендә үзенчәлекле рәвештә дәвам иттерелә: татар халкының гомумсөйләмә формалары белән бергә, туган ыру-кабиләсе (Акмулла, үзе белдергәнчә — мишәр, Емельянов — керәшен) яисә яши торган урынчылыгына хас булган башкорт, казакъ һ.б. төрки тел берәмлекләре дә табигый бер җинеллек белән файдаланыла, тасвир чарасы итеп күтәрелә, сәнгатьле сөйләмдә тел берәмлекләренең кулланылышы аерым авторның шәхси үзенчәлеге белән баетыла, нәтиҗәдә, иске татар теленең колачы — мөмкинлеге арта, укучыларның даирәсе киңәйтелә.

Шулай итеп, гомумтөркидән килә торган традицион нигез саклаган хәлдә, билгеле бер төбәктә, ягъни Болгар-Казан төркие дип тәгаенләнгән иске татар телендә, XVIII-XIX гасырларда иҗат ителә килгән әдәбиятның, берсен-берсе алмаштырып кабатлаган ике нигездә баруы күренә. Шагыйрьләр, укучыны күздә тотып, темалары нинди булуга карап, иске татар теленең, беренчедән, халыкчан сөйләмә һәм авыз иҗаты әсәрләренә хас сурәтләү чараларын кулланып, икенчедән, гарәп-фарсы алынмаларын мул файдаланып яза алганнар. Хәзерге татар әдәби теленнән аермалы буларак, иске татар телендә иҗат итәргә менә шундый мөмкинлек туган.

Әлеге мөмкинлектән шагыйрьләр генә түгел, мәгърифәтче әдипләребезнең тагын да камилрәк рәвештә файдалануы күренә. Р.Фәхретдиннең биобиблиографик «Асар» хезмәте классик иске татар теленең гарәп-фарсы алынмалары белән баетылган төрендә, әти-әниләргә һәм балаларга дини-дидактик тәрбия бирү юнәлешендәге күпсанлы әсәрләре, автор үзе искәрткәнчә, «саф ана телемездә» язылa, тулаем төрки дөнья укып аңласын дигән максат белән иҗат ителгән хезмәтләрендә,

бигрәк тә «Шура» журналының һәр санында басыла килгән мәкаләләрендә гомумтөркинең угыз-төрек формалары эзлекле файдаланыла. Ф.Кәриминең «Салих бабайның өйләнүе», «Җиһангир мәхдүмнең авыл мәктәбендә укуы» кебек хикәяләре халкыбызның җанлы сөйләмә телендә, «Аурупага сәяхәт», «Кырымга сәяхәт» әсәрләре иске татар теленең үз вакытында «җәдиди госманлы» дип атала торган вариантында иҗат ителә. Алга таба иске татар теленең төрле тармаклы-вариантлы булып кулланыла алу үзенчәлеге, XIX гасыр ахыры — XX йөз башында беренче әсәрләрен яза башлаган Г.Исхакый, Г.Тукай, Дәрдемәнд, Г.Ибраһимов, Ф.Әмирхан, Ш.Камал, Г.Камал һ.б. классикларыбызның иҗатында, һәрберсенең үзенчә ысул-өслүбенә туры китерелеп, төрле дәрәҗәдә файдаланылуы мәгълүм. Димәк, гомумтөрки нигездә үскән иске татар теле халыкка аңлашылмый торган тоташ корама булган дип әйтергә һичнинди дә җирлек күренми.

*«Ник йоклыйсың, мужик? / Яз җитде һәм үсте / Чирәмнәр йортында, / Тор, уян, күтәрел! / Үз-үзеңә кара: / Кем идең, кем булдың? / Нәрсә бар милкеңдә? / Ындырда юк орлык, / Иген юк урырлык, / Атың бар бик начар, / Өч тәнкә торырлык...»* (Мужик йокысы) яки *«Кайда китде цензуралык, / Коллык, тарлык, ким-хурлык? / Артка карасак борлып, / Йырак анлар калдыя...»* (Хөррият хакында) кебек юллардан күренгәнчә, беренче шигырьләрен Г.Тукай, XVIII гасырлардагы «Иляһи бәетләр»дән, Баһави, Г.Кандалый, Ә.Уразаев-Кормаши, М.Акмулла әсәрләреннән килә торган традицияне дәвам итеп, «мужик»ка мөрәҗәгать рәвешендә, аның сөйләм теленә якын булган юнәлештә яза башлый. Г.Тукайның 1905 елга кадәр иҗат ителгән шигырьләренең теле дә халыкның сөйләмә лексикасына бәрабәр *(Курбатов, 1988: 54-59)*. «Яз галәмәтләре», «Кечкенә генә бер көйле хикәя», «Сорыкортларга», «Кемне сөяргә кирәк», «Татар кызларына», «Көз» һ.б. шигырьләре дә шул юнәлештә языла.

Г.Тукайның «Шәкерт, яхуд бер тәсадеф», «И каләм», «Ифтирак соңында», «Фикер» газетасына гына махсус түгел», «Гыйшык бу йа», «Пушкинә», «Газета мөрәттипләренә», «Дәрдемәнд дәгелмәйүм», «Хөррияткә», «Тәрбиятел-әтфальгә» һ.б. шигырьләренең күбесендә гыйлемгә-белемгә омтылу фикеренең бөеклеге тасвир ителә. Гыйлемгә-белемгә омтылу иске татар телендә «Кыйссаи Йосыф»тан башлап гасырлар буена тасвир ителә килеп, XVIII гасыр ахыры — XIX йөзнең беренче яртысында Г.Утыз-Имәни, Ә.Каргалый, Һ.Салихов, Ш.Зәки иҗатында бигрәк тә югары күтәрелә. Әлеге авторлар, традицион гомумтөрки нигезне саклаган хәлдә, гарәп-фарсы алынмаларын мул кулланып иҗат итәләр. Яшь Тукай да, Аллаһы Тәгалә сүзләре белән куәтләнеп, гыйлем-мәгърифәтлелекнең, затлы-зыялылыкның, халыкка хезмәт итүнең зарурлыгы тасвир ителә торган шигырьләрне нәкъ шул әсәрләрнең теле кебек булырга тиеш дип аңлый һәм шулай яза. Димәк, Г.Тукай башлангыч иҗатында гомумтөрки нигездәге Болгар-Казан иске татар теленең, беренчедән, халыкчан сөйләмә һәм авыз иҗаты әсәрләренә якын булган, икенчедән, гарәп-фарсы алынмалары һәм традицион язма формалары мул кулланыла торган мөмкинлеген дәвам итә.

Г.Тукайны беренче тәнкыйть итүчеләр тарафыннан әлеге мәсьәләгә үзенчәлекле мөнәсәбәт белдерелә, халыкчан телдә язылган шигырьләре санап күрсәтелә дә гарәп-фарсы алынмалары белән язылган шигырьләре төрек телендә язылган дип искәртелә. Татар әдәби теленең тарихы булуына игътибар ителми, игътибар итәргә тырышкан шәхесләр юк ителә.

XVIII-XIX гасырдагы ике йөз еллык язма әдәби телебезне эзлекле бер системада күзаллаганда, Г.Тукайның башлангыч чор иҗатына, үз вакытында Л.Җәләй ассызыклаганча: «Тукай телен өйрәнү — татар әдәби теле тарихының мәгълүм бер баскычын өйрәнү дигән сүз ул», — дип карарга тиеш булабыз (Җәләй, 1938). Шунысы куандыра: үз вакытында игътибар ителмәгән әлеге фикер безнең көннәрдә актуаль яңгыраш ала. Г.Тукай иҗатын тикшерү эше, идеология сәясәтенә бәйле булган революция, буржуазия, атеизм, яңа пролетариат әдәбияты кебек төшенчәләрдән арындырылып, «...Тукай әсәрләренең тел-стиле, нигездә, борынгы төрки истәлекләреннән, «Кыйссаи Йосыф»тан, XIV йөз ядкярләре, Мөхәммәдьяр поэмалары аша кулланылып, эшкәртелеп килүче тел-стиленең яңа тарихи шартларда дәвам ителеше ул...» — дип (Миңнегулов, 1997), объектив нигезгә утыртыла, һәм

башка авторларның (Абилов, Хисамов, Исмәгыйлов һ.б.) мәкаләләрендә дә шушы юнәлеш дәвам иттерелә.

Шуның белән бергә, «...бу елларда шагыйрьнең төрек әдәбияты тәэсирендә булуын да таныырга кирәк» *(Мөхәммәтшин, 2014: 49)*, башлангыч чор иҗатында «кайбер шигырьләре сиксән-туксан процентка төрек телендә язылган...» *(Галимуллин, 2014: 142)*, дигән фикерләр безнең көннәрдә дә кабатланып тора.

2. Ш.Рамазанов, телче галим буларак, иске татар теленең табигатен: «Бу тел үзенең лексик һәм грамматик төзелеше белән борынгы кыпчак-болгар, уйгур-чыгтай, гарәп-фарсы, госманлы-төрек һәм бераз татар телләренең катнашмасыннан гыйбарәт», — дип, дөрес аңлата. Әлеге телдә язылган «Йосыф китабы» һ.б. әсәрләрнең телен Г.Тукай «Алла белә, җен телендә» дип искәртә. Ул моны «...чын халык телен, чын халык рухын» саклый торган халык җырларының тел үзенчәлеге белән чагыштырып әйтә. Болай дип дәвам итә: «...Бу китапларны кем дәрес китабы итеп тоткан? Татарлар. Киләбез «Таһир-Зөһрәгә» ...Бу кем телендә? Кыргыз телендә. Бу кем китабы? Татар китабы. Бу — татарның бик искедән бирле укылып килгән әдәби китабы. Минем гуманымча, кечкенә чагында шушы китапны укып, йыламыйча үскән ирләребез вә хатыннарыбыз сирәкдер».

XX гасыр уртасына таба әлеге әсәрләр «искедән килгән, елап укыла торган әдәби китап» дигән фикергә, сәясәт таләбенә буйсындырыла, ягъни теле белән бергә тулаем инкарь ителә: «...Бер яктан, әле «төрки тел» дип аталган борынгы феодализм чорының корама «китап теле» дәвам итсә, икенче яктан, пантюркистлар Волга буе татарларына да әдәби тел итеп төрек телен көчләп тагарга маташтылар».

Төрки халыкларны берсен икенчесеннән аеру өчен уйлап чыгарылган нигезсез пантюркизм сәясәте хөкем сөргән һәм аңа карата каты көрәш барган вакытта, Ш.Рамазанов үзенең мәкаләсендә, Г.Тукай башлангыч чорында төрек телендә язса да, аннан котыла барды, «...аның иҗаты XIX йөзнең соңгы чирегендә Насыйри тарафыннан башлап җибәрелгән хәрәкәтнең җиңү маршы булып яңгырады, җиңү тантанасы булып гәүдәләнде», дигән фикерне укучыга җиткерергә тырыша (Рамазанов, 1954: 60-61). Алга таба башка авторлар да әлеге фикерне еш кабатлый: «...Әдәби тел мәсьәләсендә ул иҗатының башыннан ук пантюркистик политикага — капма-каршы позициягә басты. ...Пантюркистларның төрекчелеген кире каккан шикелле, пуристларның саф төркичелеккә кире кайтырга маташуларына да Тукай бик айнык карый алды. Шул теләк белән 1909-1910 елларда «Шура» журналы үткәргән «тел ярышы»н «тиле ярыш» дип атады... Бу урында да ул К.Насыйриның демократик принципларын югары күтәрде» *(Халит, 1962: 112, 140)*. Бу урында пантюркистларның «төрекчелек» һәм «саф төркичелек» дигән төшенчәләренә игътибар итик. Төрекчелек аерым бер халыкның теле дигән мәгънәдә аңлашыла, ә пуристларның саф төркичелеккә кайтуы нәрсәне аңлата? К.Насыйри исеме белән бәйле демократик принциплар дигән контекстта «саф төркичелек» татар теле дип аңлашыла кебек, ләкин «феодализм чорының корама «китап теле» булган «төрки тел» мәгънәсен дә алып килә.

Төрки белән төрек атамаларының, берсе икенчесенә мөнәсәбәтле рәвештә, төрле мәгънәләрдә кулланылуы М.Кашгариның мәшһүр «Диване лөгатет-төрек» хезмәтеннән башлап дәвам иттерелә, әлеге мәсьәләгә багышлап, Җ.Вәлиди рус һәм татар телләрендә махсус мәкалә яза *(Вәлиди, 1927, 2007: 236-243)*. XX гасыр башында, татар телендә газета басылырга мөмкинлек ачылгач, газетага дигән мәкаләне нинди телдә язарга кирәк соравына җавап эзләү барышында, төрле фикер-бәхәс кузгала. Язма тел дигән төшенчәне белдерү өчен, «түрки» — «төрек» — «татар» атамалары берсе икенчесен алмаштырып та, бергә дә файдаланыла: «Казан халкының үзара сөйләшенә торган телләре», «безнең Казан татарларымызның теле», «төрки лисанының Казан мөселманлар лөгате», «үз татар телемез», «ачык ана телемез», «урам теле», «Казан төркисе», «үз төрки телемез», «борынгы иске татар теле», «иске татар теле», «гавам теле», «лисане әдәби», «татар-төрек шивәсе», «Тәрҗеман шивәсе», «Казан халкы сөйләшә торган тел», «саф татар теле», «урта лисан», «китаби әдәбият лисаны» һ.б. *(Баязитов, 1905, Фәхретдин, 1910)*. Бу атамаларның күбесендә кулланыла торган «төрки-төрек», «татар-төрек» дигән төшенчә-атама төрки гаиләдәге халыкның лисаны-теле дип тә, иске татар теле (үз төрки телемез) дип тә аңлашыла.

Әлеге төшенчә Г.Тукай әсәрләрендә «үз ана телебез» *(Фикер, 1906, 24.09; 1956, 3: 93)*, «әдәбият ахшамындагы халыкның ана теле» *(Шунда ук: 22.11; 1956, 3: 108)*, «Тәрҗеман теле», «безнең телебез» *(Шунда ук: 26.11; 1956, 3: 116)*, «төрек лисани» (Яшен, 1909, 31.01; 1956, 4: 28), «ана телебез» *(Шунда ук: 1910, 13.11; 1956, 4: 73)*, «Туган тел» *(Шунда ук: 1910; 1955, 2: 104)*, «безнең татар әдәби теле» (Ялт-йолт, 1911, 18.01; 1956, 4: 85), «әдәбиятыбызның аслы, җәүһәре булган безнең Казан теле» *(Шунда ук: 1911, 18.01; 1956, 4: 116)*, «төрек-татар галәме» *(Кояш, 1913, 14.03; 1956, 4: 185)* буларак чагылыш таба. Г.Тукай «Уянгач беренче эшем» дигән мәкаләсендә: «Әй, җир йөзендәге төрек баласы, галимме син, хакимме син, падишаһмы син, теләнчеме син, инде мин сине өемә кертергә оялмыйм, инде син кем булсаң да, мин сиңа такмак китабымны мәгаль-ифтихар (мактана-мактана) һәдия итә алам», — дип һәм «...Ул мәнзумат (шигырь, поэма, дастан) вак-вак диваннарга тәдвин ителеп (җыентык булып төзелеп), төрек-татар галәменең һәр ягына таралган...» — дип язганда, төрек сүзенең тулаем гаилә исеме булган төрки мәгънәсендә кулланылуы аңлашыла.

XX гасыр урталарында менә шушы «төрки» төшенчәсенең тарихы, гомумтөрки телнең булуын белдерә торган фикер оныттырыла, дөресрәге, юкка чыгарыла. Язма төрки тел, халыкның җанлы сөйләмә теленә каршы куелып, буталчык, корама, халыкка аңлашылмый дип инкарь ителә, яңа әдәби тел булдырырга кирәк дигән фикер үсеш ала: «...Яңа татар әдәбияты тудыру һәм яңа татар әдәби теле төзү юлында беренче адымнар ясалды», — диелә *(Рамазанов, 1954: 60)*. Әлеге вазгыятьтә төрек теле пантюркизм дигән ясалма куркыныч мәгънә төсмере белән тарала, төрекләр үзләренең телен барлык халыкка әдәби тел дип танытырга телиләр, дип белдерелә. Гомуми эзлеклелектә караганда, «төрки» һәм «төрек» атамаларының татар филологиясендә төрле чорда төрле мәгънәләрдә кулланылуы күренә *(Вәлиди, 1928, 2007: 159-163; Бәширова, 2012)*.

Безнең көннәрдә «төрек теле» атамасы еш кабатлана һәм без аны аерым бер дәүләттә яши торган аерым халыкның теле дип аңлыйбыз, кулланабыз. Шулай да Г.Тукай төрек телендә шигырь язганмы, юкмы?

Әлеге сорауга объектив җавап алу өчен, төрек телендә язылган дип белдерелә торган шигырьләрдә кулланган сүзләрне «инәсеннән җебенә кадәр тикшереп чыгу» зарурлыгы күренә. Әмма башта сорауның теоретик нигезен күзалларга, ягъни темага бәйле рәвештә, татар һәм төрек телләре мөнәсәбәтен билгеләүнең зарурлыгы күренә. Бу телләр төрки гаиләгә берләшә торган ике төркемнең вәкилләре булып тора: татар теле — болгар-кыпчак, төрек теле угыз төркеменә карый, димәк, сөйләмә телләре ягыннан берсе икенчесеннән билгеле бер дәрәҗәдә аерыла.

XIX гасырның урталарына кадәр аларның икесенең дә язма әдәби телләре белән җанлы сөйләмә телләре арасында зур аерма күзәтелә. XIX гасырның урталарыннан һәр ике тел дә, милли әдәби тел буларак, ягъни халыкның сөйләмә теле җирлегендә формалашан яңа язма әдәби тел булып яшәеш ала. Әмма угыз-уйгур үзәгендә бара торган язма-тел традициясенең көче саклана, милли телләр белән бәйләнеше төрле телләрдә төрлечә дәвам ителә. Татар әдәбиятында угыз-уйгур нигезендә бара торган язма тел традициясенең көчле сакланышы XX гасыр башына кадәр дәвам итә. Г.Тукайның башлангыч чор иҗаты моның ачык мисалы булып тора. Димәк, Г.Тукайның 1905-1907 елларда Җаек чорында язылган шигырьләрендәге, ягъни классик иске татар теленә хас булган угызчылыкка караган сүз һәм сүзформаларын хәзерге төрек теленең берәмлекләре дип аңлату — тарихилыкны аңламау, аны юкка чыгару ул.

Милли телләр белән бәйләнештәге аермалыкны иҗтимагый тормышта бара торган үзгәрешләр барлыкка китерә. Төрекләр үз дәүләтендә яши, татарлар — дәүләтчелеген югалткан халык. 1928 елга кадәр һәр ике тел дә гарәп графикасын файдалана, аннан соң латин язуына күчә. Бу вакытта язма әдәбиятны уку һәм аңлауда һичнинди киртә куелмый. Г.Тукайны да, башка әдипләрнең иҗатын да, төрки дөнья, шул исәптән госманлы төрекләре дә, үз сөйләмә телләренә якынайтып тәрҗемәсез укый һәм аңлый ала. Г.Тукайның рус телендәге тәрҗемәләренең кардәш телләргә караганда күбрәк булуы шушы сәбәп белән аңлатыла.

1939 елдан татар язма теле кирилл-рус хәрефенә күчерелә, латинда калган төрекләр белән язма телдә аралашу туктала. Хәзерге вакытта Г.Тукайның иҗаты кирилл — рус

хәрефләренә кучерелеп укыла, иске татар теленең гарәп графикасындагы язуы белән бәйле үзенчәлекләрдән ераклашу барлыкка килә.

Шуна карамастан, гасырлар буена дәвам итеп килә торган язма төрки әдәби теленең бер буыны булган Г.Тукай иҗатында, дөресрәге, аның Җаек чорында язылган шигырьләренең һәркайсында, язма әдәби традициянең ничек дәвам иттерелүенә игътибарлы булу шарт.

«Голумең бакчасында...» шигыренә тукталыйк. Бу шигырьдә барлыгы 145 сүз кулланыла. Шуларның, кабатланып файдаланылуын исәпләгәндә, 43 е — хәзерге көндә дә актив кулланыла торган татар сүзе, «Төрекчә-татарча сүзлек»тә урын алган «дулашылым», «парлак» һәм «чук» дигән өч сүз — төрек теленеке. Димәк, сүзләрне лексема (сүзлектә теркәлгәнчә) халәтендә караганда, шигырь төрек телендә язылган дип әйтә алмыйбыз *(Хәмидуллин, 2014: 50-54)*. «Чук» сүзенең иске татар телендә язылган текстларда еш кабатлануы мәгълүм: ...чук зыяфәтләр, ...чук пөшәйманлар *(Г.Утыз Имәни)*; ...чук тәкәллеф, ...чук заман, ...чуклара фетнә пырагыб, ...чук догалар, ...чук тәмәннә әйләйүб *(Г.Каргалый)*; ...чук гөнаһ итдем *(Ш.Зәки)* h.б. Шуның белән бергә, бу шигырьдә төрки гаиләнең угыз төркеменә караган төрек теленә *(Кононов, 1977: 394)* хас орфографик һәм морфологик күрсәткечләр («ит» («ид») тамыры — 5 мәртәбә «идәлем» һәм «итмәлиез», «уйнат» сүзе — «уйнаталым», «бул» тамырының «ул» формасында — 2 мәртәбә «улалем», «бар» сүзенең — «вар», «вармы», «төрле» сүзенең — «дөрлү», «төшенү» сүзенең — «дөшенүбән», «болгар» сүзенең иялек килешендә «болгарың» формасында килүе) файдаланыла. Бу юнәлештә ул төрек теленә якынлаша кебек.

Әмма әлеге формаларның барысы да һәм тагын «йокы» сүзенең — «уйку», «күрсәтү» сүзенең — «күстәрү», «без» алмашлыгының «безем» һәм «безез» дип белдерелүе, таш язмаларыннан ук килә торган угыз-уйгур-кыпчак кабилә телләренең катнашмасы — гомумтөрки традицион күренешләр *(Тенишев, 1977: 35-40)* иске татар телендә теләсә кайсы жанр-стильдә язылган текстларда, төрле дәрәҗәдәге эзлеклелектә кулланылышта була. Ләкин бу, гәрчә аларда «угызчылык» өстенлек итсә дә, Ш.Рамазанов мисал итеп китергән Г.Утыз-Имәни, Ш.Зәки, Г.Чокрый кебек әдипләр төрек телендә иҗат иткән дигән сүз түгел. Бер үк авторның бер үк әсәрендә угыз формаларының еш кына кыпчак төркеменә караган чаралар белән чиратлаштырылуы — табигый күренеш.

Менә бу шигырьдә дә теләк модальлеге — 2 мәртәбә «улалем» (угызчылык), 2 мәртәбә — «улсын», «улсыннар» (кыпчак-татар телендә боерык фигыль формасында кирәклек-теләк мәгънәсе һәм тагын шундый ук «китсен», «итсен»), 1 мәртәбә «улдыгына» дип алмаштырыла. Шулай итеп, татар телендә, төрек телендә кулланыла һәм гомумтөркидән килә торган сүз һәм сүзформаларны бергә караганда, барысы 57 сүз була. Болардан башка тагын бу шигырьдә борынгы яһүди дине белән бәйле дип санала торган «Адәм» сүзе (2 мәртәбә), Европа-рус теле аркылы кергән «япун», «немсә», «француз», «журнал», «гәзитә» сүзләре файдаланыла, димәк, 64 сүз була. 145 тән 64 не алгач калган 81 сүзнең гарәп һәм фарсы алынмасы икәнлеге күренә. Әлеге алынмаларның 20 гә якыны («сәгадәт», «бәхет», «җен», «хәйран», «милләт», «дәфтәр», «каләм» h.б.) хәзерге вакытта да һәм язма, һәм сөйләмә телебездә актив кулланылуы мәгълүм, димәк, 60 лап сүз генә аңлашылмый була. Бу сүзләрнең күбесе «Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге»ндә тәрҗемә ителә.

Г.Тукайның «И Каләм!» шигырендә 149 сүз кулланылган. Шуларның 62 се төрки гаиләдәге башка телләрдә дә, шул исәптән төрек һәм татар әдәби язма телләрендә дә кулланылуы мәгълүм булганга, төрки-татар сүзе дип, ә «һәп» («һер») сүзен төрек теленеке дип аерып әйтергә мөмкин. 87сенең гарәп-фарсы алынмасы икәнлеге күренә. Г.Тукай иҗат итә башлаган вакытта классик иске татар телендә билгеле бер тотрыклы нигез булса да, сүзләрнең төрлечә язылышы да күзәтелә. Шуна күрә Г.Тукай шигырьләрендәге төрки-татар сүзләрен хәзерге әйтелешкә туры китереп һәм иске татар телендәге традицион язылыш дип бүлеп карарга мөмкин, әмма һәм сузык, һәм тартык авазларның бирелешендә транслитерация дәрәҗәсендәге төгәллек саклана алмый.

«И Каләм!» шигырендә түбәндәге сүзләр, **хәзерге татар** телендәгечә язылышта

бирелә дип әйтергә мөмкин: «китсен», «безне», «без дә», «тугры», «йул», «без», «ит», «калдырма», «итеп», «нә», «бези», «бу», «йаз», «ит», «йаз», «караны», «йаз», «кара», «дип», «ит», «акны», «ак», «бакма», «бак», «явыз», «асма», «колак», «дүрт», «күз», «кичмәсен», «карангылыкта», «без», «бер-бер итәрләр», «ни», «безгә», «бер», «безгә», «бер» (кабатлануларны санап, барысы — 40 сүз).

**Иске татар** телендәгечә, ягъни угыз төркеме телләренә хас булган үзенчәлекләр дә файдаланылган язылышта: «сән», «әйлә», «улалым» (булыйк), «кыйл», «сән», «бән», «ичүн», «дөшерден», «әйлә», «сән», «ушандак», «кәс» (кеше), «сәндән», «кәлер», «бәкләнер», «кәлде», «бөйлә» (бу илә), «әйлә», «кыйл», «улынсын» (булсын) (кабатлануларны санап, барысы — 20 сүз).

Бу сүзләрнең кайберләренең, мәсәлән, «ben» — «бән» *(Төрекчә-татарча сүзлек, 1998: 74)*, «dьюьг» — «төшер» (Шунда ук: 158), «ol» — «бул» (Шунда ук: 318), хәзерге төрек теленең әдәби нормасы булып саклануы гына аларны фәкать аерым төрек теленең сүзе дип санарга нигез була алмый, чөнки болар, төрки гаиләнең язма телендәге уртак байлык санала. Мәхмүт Кашгаринын «Диване лөгатет-төрек» хезмәтендә, әлеге сүзләрнең күбесе, аерым кабилә телләренә бүленмичә теркәлеп бирелгәнгә, гомумтөрки дип исәпләнә.

«Һер» — «һәп» сүзен төрек теленеке дип әйтә алабыз *(Шунда ук: 209)*, ул татар теленең сүзлекләрендә теркәлмәгән. Шулай итеп, 149 сүзнең 62 се төрки-татар сүзе икәнлеге күренә. Димәк, 87 се гарәп-фарсы алынмасы була, шуларның «каләм», «милләт», «китап», «гомер», «хәл», «заман», «бәхет», «җаһил» кебек 41енең татар телендә актив кулланылуы мәгълүм, 46 сын тәрҗемә итәргә кирәк була. Бу шигырьдә рус теле алынмасы — «Аурупа» сүзе дә файдаланыла.

«Ифтирак соңында» шигырендә исә 122 сүз кулланыла: 52 се — төрки-татар, шуларның 3 сен төрек теленеке дип әйтә алабыз, 70 сүз гарәп-фарсы алынмасы була. **Хәзерге татар** телендәгечә язылышта дип әйтергә мөмкиннәре: «сон», «ит», «итдем», «сөйләмәк», «йаздым», «күздән», «каным», «китден», «бер», «акланыр», «көн», «итәр», «йаздым», «йаздым», «улып», «көлдерден», «йандым», «бетде», «йыкдым», «итәм» (кабатланулар белән — 20 сүз).

**Иске татар** телендәгечә, ягъни угыз төркеме телләренә хас үзенчәлекләр дә файдаланылган язылышта: «чук», «илә», «бән» (10 мәртәбә кабатлана), «у» (ул), «кәндемә», «улды», «улды» (булды), «иштә» (менә), «акан» (аккан), «аглатыб» (йылатыб), «бези», «бәңа», «улыб» (булыб), «сән», «бези», «улдым» (булдым), «улды» (булды), «шимди», «йакан» (йаккан), «идәрсәм», «улыр» (булыр), «вирдем» (кабатланулар белән — 31 сүз). Димәк, бу шигырьдә автор 51 төрки-татар сүз файдалана. Шуларның «чук», «иштә» һәм «шимди» сүзләрен бик икеләнеп кенә төрек теленеке дип әйтә алабыз, чөнки «чук» сүзе иске татар телендә актив кулланылышта була, халык авыз иҗатында «күптин-күп, чуктин-чук сәламнәр җибәрелә»; «iюte» — «менә бу» *(Шунда ук: 231)* «Татарча-русча сүзлек»тә «устн.книж.» искәрмәсе белән теркәлгән; «юimdi» — «хәзер» *(Шунда ук: 411)* шулай ук иске татар телендә файдаланыла. 122 дән 51 сүзне алгач, калган 71 сүз гарәп-фарсы алынмасы була, шуларның 34 сүзе хәзерге татар телендә дә актив кулланыла, димәк, 37 алынманы тәрҗемә итәргә кирәк була.

«Гыйшык бу я!» шигырендә барлыгы 109 сүз кулланыла: 59 ы — төрки-татар, шуларның «парла» һәм «биңзәр» сүзләрен төрек теленеке дияргә мөмкин, 50 сүзнең гарәп-фарсы алынмасы икәнлеге күренә. Хәзерге татар телендәгечә язылышта дип әйтергә мөмкиннәре: «бу», «бер», «ит», «бу», «каршыма», «көл», «итеп», «аяк», «ач», «йөзеннән», «бер», «кансыз», «бер», «ит», «бу», «юк», «бер», «күз», «кашың», «Ходай» (кабатланулар белән — 20 сүз).

**Иске татар** телендәгечә, ягъни угыз төркеме телләренә хас булган үзенчәлекләр дә файдаланылган язылышта: «кәл», «йанайым», «кәл», «йанайым», «вир», «улмайым», «кызың» (кызның), «бән», «кәл», «кыйл», «бән дә», «сәнең», «әл», «баглы», «кортылмагым», «илә», «бән», «илә», «бәнем», «кыйл», «канланайым», «вир», «сәнең», «бундан», «ауланайым», «ауланайым», «салайур», «бәни», «салланайым», «салланайым», «сәнең», «айланайым», «айланайым», «шөйлә» (шу илә) (барысы — 35 сүз). Төрек теленең «parla» — «ялтырау, балку, нурлану» *(Шунда ук: 336)* сүзе

«парласын», «парланайым», «парланайым» сүзформа рәвешендә өч мәртәбә кабатлана, һәм «бинзәр» — «benzer» — «охшаш» *(Шунда ук: 75)* сүзе кулланылган. Шулай итеп, төрки-татар-төрек сүзләре (кабатланулары белән) — 59. 50 сүз гарәп-фарсы алынмасы була, шуларның 18 е хәзерге телдә дә кулланыла, 22 сен тәрҗемә итү сорала.

«Мөритләр каберстаныннан бер аваз» шигырендә — 103 сүз кулланыла. Шуларның 67 се — төрки-татар, икесе — төрек теле сүзе, 36 сы гарәп-фарсы алынмасы. **Хәзерге татар** телендәгечә язылышта дип әйтергә мөмкиннәре: «бер», «икәндер» (9 мәртәбә кабатлана), «белмәдем» (9 мәртәбә кабатлана), «ул», «шунлар», «имеш» (5 мәртәбә кабатлана), «юк», «итмәк», «өчен», «чын», «күнелдән», «каршы», «арыслан», «каршы», «коллык», «кул», «бу», «фәләннәр», «бер», «нигезе», «бу», «бу» (кабатланулар белән — 42).

**Иске татар** телендәгечә, ягъни угыз төркеме телләренә хас булган үзенчәлекләр дә файдаланылган язылышта: «идән» (9 мәртәбә кабатлана), «анлара», «тартаннар», «анларый», «таушан», «шунлара», «идәннәр», «вирән», «анларый», «санан», «безләри», «бунын», «бунлар», «йейән» (ашаган) (кабатланулар белән — 22). Төрек теленең 2 сүзе: «zalэю» — «эшләү, тырышу» *(Шунда ук: 111)* — «чалыйшан» сүзформасында ике мәртәбә файдаланыла, «зok» — «күп» *(Шунда ук: 131)* кулланыла. Шулай итеп, төрки-татар-төрек сүзләре 67 була.

36 гарәп-фарсы алынмасының 23 е хәзерге татар телендә файдаланыла, 13 алынманы анлату сорала.

«Пушкинә» шигырендә исә барлыгы 115 сүз кулланыла. Шуларның 41 е — төрки-татар, 2 се — төрек, 3 се — рус теле, 69 ы гарәп-фарсы алынмасы.

Шулай итеп, Г.Тукайның башка шигырьләрен дә тикшереп чыгарга мөмкин. Аларда сүзләр кулланылышы, классик иске татар телендә язылган башка күп кенә әдәби әсәрләрдәге кебек үк, гасырлар буена дәвам итеп килә торган угыз-уйгур-кыпчак нигезендәге язма тел традициясендә булуы анлашыла. Гомумтөрки язма телнең нигезен тәшкил иткән традицион угыз-уйгур сүз һәм сүзформаларын фәкать хәзерге төрек теленеке дип исәпләү тарихны белмәү яисә белеп тә махсус рәвештә бозып анлату булып янгырый. Иске татар телендә язылган әсәрләрне тикшергән вакытта, татар теле белән төрек теленең сүз һәм сүзформаларын берсеннән икенчесен аермыйча, киресенчә, аларны төрки-татар-төрек теле дип берләштереп, бик күп файдаланыла торган гарәп вә фарсы алынмаларына гына каршы куя алабыз. Әлеге алынмаларның күбесенең укучыга анлаешсыз булуы аркасында Г.Тукайның башлангыч чорда язылган шигырьләрен юлга-юл тәрҗемәдә бирергә мәҗбүрбез.

Ш.Рамазанов хаклы рәвештә болай дип яза: «Г.Тукайның теле, гомумән, шулай ук аның шигырь теле дә, лексик яктан бик катлаулы. Анда төрле телләрнең сүзләре һәм фразеологиясе, төрле стилистик катлаулар бар. Тукай татар теленнән башка тагын гарәп, фарсы, төрек һәм рус телләре белән яхшы таныш. Кирәк булганда, бу телләр белән үзе теләгәнчә файдаланган да. Тукай лексикасында төп материал — татар теленең сүзләре». Соңгы җөмләгә җыентыкны төзүчеләр түбәндәге анлатманы бирә: «1905-1907 елларда, әле әдәби тел мәсьәләсендә нык позициядә тормаган чагында, төрек телендә язылган әсәрләрендә, төп лексик материал — гарәп, фарсы сүзләре. Мәсәлән, «Голүмен бакчасында...» дип башланган шигырендә гарәп, фарсы сүзләре 56,3%, «Хәзерге хәлемезә даир» шигырендә — 56,3%, «Пушкинә» шигырендә — 55%, «Нур» газетасы турындагы шигырендә — 64,4%. Мондый шигырьләрендә кулланылган гарәп, фарсы сүзләренең күбесе, ... «китап теле»нең күпертелмә купшы һәм «югары стиль» дип аталган стиленә хас сүзләр булып, гарәп һәм фарсы телләре белән яхшы таныш булмаган кешеләр өчен бөтенләй анлаешсыз» *(Рамазанов, 1954)*. Димәк, Г.Тукайның башлангыч чор иҗатының халыкка анлашылу-анлашылмау мәсьәләсе турында фикер әйткәндә, аның татар-төрки-төреклегеннән бигрәк, иске татар телендә язылган барлык әдәбиятны өйрәнгәндәге кебек, төрки тел һәм гарәби тел яссылыгына игътибар итәргә тиеш булабыз. Бу хакта Ф.Әмирханның мәкаләсендә дә: «...гарәп сүзләреннән татарча төзелеп ясалган бәетләрнең татар шигырь мәҗмугасында торулары — бөтенләй урынсыздыр», — дип билгеләнүе мәгълүм.

Нәтиҗә ясап, болай дияргә мөмкин: Г.Тукайның даһилыгы аның 700 еллар буена дәвам итеп килә торган иске татар теленең табигатен анлауда һәм аның

тулаем мөмкинлеген файдалана белүдә чагыла. Иске татар теленең табигате дигәндә, авторларның, кайсы укучыны күздә тотып, нәрсә турында язуларына карап, гомумтөрки жирлек дәвам итеlә торган Болгар-Казан шивәсе — иске татар теленең, берсе икенчесен алмаштырып, беренчедән, халыкчан сөйләмә, авыз иҗаты тәэсире нигезендә һәм, икенчедән, гарәп-фарсы алынмалары һәм традицион язма формалар мул файдаланыла торган нигездә иҗат итәргә мөмкинлеге булуын истә тотабыз.

Г.Тукай, яза башлаганда, менә шушы мөмкинлекнең һәр икесен дә файдалана. Алга таба Г.Тукай халкыбызның сөйләмә теле байлыгын сәнгатьчә тасвирлау теле югарылыгына күтәрергә кирәк булуын аңлый: «...әдәбиятымызның асылы, җәүһәре булган безнең Казан теле...» икәнлегенә инануын белдерә *(Ялт-йолт, 1911, №29)*, традицион язма телне үзенчә яңартып һәм үстереп камилләштерә. Чыннан да, Г.Тукайның даһилыгы, аның Иляһи шигърияте, күп тапкырлар ассызыкланганча, нәкъ менә халкыбызның үз-милли сүзләре белән тасвир итү юнәлешендә ачыла, әлеге нигездә ул, поэзия жанрының, һәм тулаем төрки дөньяда, һәм башка халыкларның телләрендә яңгыраш ала торган гүзәл-нәфис үрнәкләрен иҗат итә дип кабатлый алабыз. ... Галимнәр белдергәнчә, җанлы-сөйләмә тел белән язма төркинең классик иске татар теленең ике формасы булып саналуы XIII-XIV гасырлардан ук билгеле булса да *(Фасеев, 1982: 29)*, аларның үзара бәйләнеш-мөнәсәбәте һәм гамәли кулланылышы төрле чорда төрле дәрәҗәдә икәнлеге күренә.

**Искәрмәләр**


Әмирхан Ф. (Даменла). Габдулла Тукаев шигырьләре // Әл-ислах, 1907, 3 декабрь.

Әмирхан Ф. (Даменла). Габдулла Тукаев шигырьләре // Әл-ислах, 1908, 2 февраль.

Әмирхан Ф. Әсәрләр. 4 томд. IV том: әдәбият-сәнгать тәнкыйте, биографик материаллар, хатлар. — Казан: Татар.кит.нәшр, 1986. — 390 б.

Әхмәтҗанов М. XVIII гасыр татар әдәбияты. Поэзия: төзүче, искәрмәләр һәм аңлатмаларны әзерләүче Марсель Әхмәтҗанов. — Казан: «Дом печати» нәшр., 2006. — 363 б.

Баязитов Г. Тел бәхәсе // Нур. — СПб., 1905-1914.

Бәширова И.Б. Татар әдәби теле тарихы. Гомумтеоретик мәсьәләләр: татар әдәби теленең билгешартлары һәм аларның өйрәнелеше. — Казан, 2012.

Вәлиди Ж. Тукайның шагыйрьлеге // Мәгариф. — 1923. — №3-4.

Вәлиди Ж. Сайланма хезмәтләр. — Казан: Мәгариф, 2007. — 271 б.

Гайнетдинов М.В. XIX йөз татар әдәбияты тарихына яңа материаллар. Баһави // Татар теле һәм әдәбияты. — Казан, 1977. — Б.127-128.

Галимуллин Ф.Г. XX гасырда татар-төрек әдәби бәйләнешләре мәсьәләсенә карата // Төрки халыклар әдәбияты һәм сәнгате Шәрык һәм Гареб мәдәнияте контекстында. — Казан, 2014. — Б.141-146.

Ганиева Р. Шагыйрьнең рухи дөньясы. — Казан, 2002. — 110 б.

Жәләй Л. Тукай телендә фигыльләр // Совет әдәбияты, 1938. — №3, 4, 5.

Кононов А.Н. Турецкий язык // Языки мира. Тюркские языки. — Бишкек, 1977. — С.394-411.

Курбатов Х.Р. Лексика и система первых произведений Тукая // Татарская лексика в семантико-грамматическом аспекте. — Казань, 1988. — С.54-59.

Миннегулов Х.Ю. Тукай һәм Урта гасыр татар әдәбияты // Тукай һәм XX гасыр мәдәнияте. Шагыйрьнең 110 еллыгына багышланган халыкара конференция материаллары. — Казан, 1997. — 323 б. — Б.54-63.

Мөхәммәтшин З.Г. Г.Ибраһимов һәм Ж.Вәлиди күрергә теләгән Тукай // Фәнни Татарстан, 2014. — №1. — Б.53.

Нуруллин И. Тукай. Жизнь замечательных людей. — М.: «Молодая гвардия», 1977. — 240 с.

Рамазанов Ш.А. Тукай һәм хәзерге татар әдәби теле // Татар теле буенча очерклар. — Казан: Таткнигоиздат, 1954. — Б. 58-93.

Тенишев Э.Р. Тюркоязычных письменных памятников языки // Языки мира. Тюркские языки. — Бишкек, 1977. — С.35-46.

Фасеев Ф.С. Старотатарская деловая письменность XVIII века. — Казань, 1982. — 171 с.

Фәхреддин Р. «Шура»ның тел ярышы. — Оренбург: «Вактъ», 1910. — 195 б.

Халит Г. Тукай үткән юл (Габдулла Тукайның тормышы һәм иҗаты турында очерк). Казан: Татар.кит.нәшр., 1962.

Хәмидуллин Р.Р. Г.Тукайның «Голүмең бакчасында...» шигырендә сүз кулланылышы // XXI гасыр фәне. Филология һәм сәнгать белеме мәсьәләләре. — Казан, 2014. — Б.50-54.



**Илида БӘШИРОВА,**
*филология фәннәре докторы*

# КЛАРА БУЛАТОВАНЫҢ «КӨЗГЕ ЧОР» ИҖАТЫНДА ФӘЛСӘФИ СЫЙФАТЛАР

Татар халкының фәлсәфи мирасы күп гасырлык тарихка ия. Аның башлангычы X-XII гасырларга – Болгар дәүләтенен «чәчәк аткан» чорларына барып тоташа. Татарның дөньякүләм танылган фәлсәфәчеләре булмаса да, һәр чорда төрки һәм мөселман дөньясында билгеле шәхесләре бар. Алар, әлбәттә, шагыйрьләр. Рәсәйдәге төрки халыкларга татар фәлсәфәсе, нигездә, шигърият аша таралган. Бу бүген дә шулай.

«Шигырьләрендә ниндидер сер бар анын. Гап-гади, барыбыз да күреп-белеп йөргән гадәти вакыйгаларны җырга сала ул, әмма шул гадилек, гадәтилек артында һәрчак тирән мәгънә, хис, әрнү ярылып ята. «Шушы яктан, шушы туфрактан без... Таллар җырлап, чишмәләре чыңлап, өянкеләр елап озата», «шатлыгымда хәсрәт орлыгы бар, хәсрәтемдә – бәхет орлыгы» – безнен җаннардан да сыкраган моң бит», – ди анын турында Роза Мулланурова. Клара Булатова чәчмә әсәрләр дә иҗат итә. Анын иҗаты заманга яраклы, кешелекле, әхлакый тәрбия бирүне күз уңында тота, күңелгә хуш килә, йөрәккә үтеп керә, укучыны уйланырга мәҗбүр итә торган тирән фәлсәфәгә ия.

## Фәлсәфи шигырьләрдәге хакыйкать

XX йөз – тормышнын бөтен өлкәләрендә дә кризислар гасыры буларак билгеле. Икътисади үзгәреп торулар яшәешебезнен аерылгысыз бер өлешенә әйләнде. Җәмгыять кичергән әлеге икътисади кризислар, ачыктан-ачык, кешелексезлек билгеләре булып торалар. К.Булатова шигырьләрендә Кеше яшәешнен үзәгендә тора, ягъни фәлсәфи җирлеге булган әлеге шигырьләр антропоцентрик сыйфатларга ия. Аларда шагыйрәнен дөньяны тануы, тормыш-чынбарлыкның җан әрнеткеч ачы хакыйкать белән күзгә-күз очрашуы, маңгайга-маңгай килеп чәкәләшүе, рухи һәм иҗади табышлары чагыла. *Чегән карчыгынын юрауларын / Күп тынладым, ярда тын утырып. / Һәм ышанмый анда кала алмадым, / Ялган икәнлеген белә торып. / Ул сөйләде: «Биек очасын, – дип, – / Куып житә алмас берәүләр дә, / Тик саграк бул: җирдә кара көчләр / Көндәш була биек менгәннәргә». / Ул алдады, биек менәсен, дип. / Биеклеккә, юк, мин үрләмәдем. / Җирдә кала бирдем. Җирдә йөрим, / Тиңе булып көндәш дигәннәрнен. («Җирдә кала бирдем»)*

Кеше гомере, анын бу тормышта мәгънәсе, бәясе бармы? Синен яшәвен шул гомеренә торырлыкмы? Шагыйрәне шул фәлсәфи сорау уйландыра. *Күнелемдә сорау, тик мин аны / Еллар буе дәшми эчтә йөртәм: / Аңлап, белеп, яклап бу дөньяны / Кем дә булса бездә яши микән? («Күңелемдә сорау, тик мин аны...»)*

Шагыйрә юкка гына шундый сорау бирми, чөнки бу – хакыйкать. Ул күп йөри, чынлыкны, дөреслекне күп күрә. Ә хакыйкать ул – кеше анынын тышкы дөнья белән туры килүе. Ул – процесс, барыш, хәрәкәт, ул һәрдаим үсә, камилләшә тора.

Клара Булатова моны бик яхшы аңлый, шуна да ул әлеге сорауны вакыты белән ачык калдыра. Башкаларны да уйланырга дәшә, аз гына булса да башларны эшләтергә чакыру ташлый, гафләт йокысыннан уятырга тырыша. *Түрдәгеләр түрге тирмәләрдә, / Кесә калын, буксә тезгә житкән. / Кемдер йортсыз-нисез инрәгәндә, / Түрдәгеләр рәхәт яши микән? / ...Мин бик озак йөрим шушы җирдә, / Балигълыгым*

*чоры эшләп үткән. / Безнең буын хәлен төшенердәй / Кем дә булса берәү яши микән? («Күңелемдә сорау, тик мин аны...»)*

Соңгы вакытларда «мәдәни кризис» төшенчәсе рухи дөньябызга көннән-көн ныграк үтеп керә башлады. Һәр буын үз чорының рухи кыйммәтләрен үзе билгели торган булса да, XX гасыр ахыры кешелек өчен мәңгелек саналган күп кенә кыйммәтләрнең бәясен үзгәртте, кешеләрнең ышанычын какшатты, өметен сүндерде.

Вакыт-вакыт чарасызлыктан өметсезлеккә бирелеп алса да, К.Булатова эзләнүдән туктамый, җирдәге хакыйкатьне төшенүен ассызыклый. *Мин тулаем беләм бу тормышны, / Мин тулаем таныйм һәрьягын. / Бүген көндә агы-карасы да, / Ала-коласы да бар аның. / Һәм берсе дә чалу ул төсләрнең / Мине читләп үтми дөньяда. / ...Бу тормышны мин тулаем беләм, / Һәм тулаем бәхил мин ана. («Мин тулаем беләм бу тормышны...»)*

К.Булатова кешенең чарасызлыгын, ялгызлыгын гына сурәтләп калмый, бәлки яшәештәге хакыйкатькә туры карап, тормышта үз юлыңны табарга өйрәтә. Шигърият сәясәттән шактый ерак торса да, күп кенә «көзге» шигырьләре фәлсәфи-сәяси эчтәлек ала. *Халык әйтә: «Сулар / Баштан болгана», — дип. / «Баштан чери балык» дигән сүзе дә бар. / «Бу — шул!» — дип әйтми дә, / Төртеп күрсәтми дә, / Башы булган кеше инде үзе аңлар. / ...Булды, тукта кулым! / Шуннан да артыгын / (Инде нокта куйдың) / Дәвам итмә инде. / Әнә күршең керде: «Тыкрыкка, — диде, — / Кара бөркәү белән бер машина килде...» (Нәрсә бу?)*

Соңгы вакытта иҗат иткән шигырьләрендә шагыйрә шактый кырыслана. Шигъри тәсбихының «Мәрьям ана»сын кан катыш әрнү тәшкил итә. *Хәтта үзем үлчәү югалттым ла, / Явыз, дисәгез дә баш тартмыйм. / Аш атканга әле таш атмыйм да, / Таш атканга инде аш атмыйм. («Әшәкелек көн дә баштан ашты...»)*

Автор 2003 елда Татарстан китап нәшриятында дөнья күргән шигырьләр җыентыгына да «Әрнү» дип исем биргән. Ә бит К.Булатованың моңа кадәр чыккан җыентыклары «Язлар алда», «Һәрвакыт янымда», «Җәйләр житсә», «Һәр язның үз җыры», «Гел кояшка карап», «Печән өсте», «Хәтер тәрәзәләре», «Миләш кагы», «Якты сагыш», «Шушы яктан, шушы туфрактан без», «Үзеннән-үзе туа җыр» кебек оптемистик рухтагы исемнәр белән дөнья күргән иде. Г.Афзал да: «Безнең Әлмәт якларында Клара Булатова шигырь укымаган бер авыл да, бер клуб та юктыр. Ул эшче яшьләр гомуми торагына берүзе барып әдәби кичә ясап кайта, больницага барып авырулар, сестралар, врачларга шигырьләрен укый. Бер сәгать тә укый, ике сәгать тә укый кәгазьсез-нисез», — дип язды. Чыннан да, ул шигырьләрдән яшьлек, сафлык, өмет, яшәү дәрте ташып тора. *Арыш кыры яшел-сары, / Серкәләре очкан чагы. / Ашыкма әле, утә әле, / Чуак чагым — июнь ае. («Июнь ае»)*

*Җәй айлары инде үтеп бара... / Саргылт ялкын булып, кыр тулып, / Көнбагышлар җилдә чайкалалар, / Күңелдәге якты җыр булып. («Җәй айлары инде үтеп бара...»)*

Тәнкыйтьче Р.Лотфуллин да 1970 елда: «Клара Булатова, ин беренче чиратта, дөньяның, галәмнең матурлыгын һәм иркенлеген, «тауларның биеклеген», «юлларның яктылыгын» күреп шатланучы, туган илебезне, «бәхет тулы» туган җиребезне, бөтен рәхәте-газаплары, шатлык-кайгылары белән тормышны яратучы, җир, кеше, ил язмышы, кешенең томыштагы урыны, яшәү мәгънәсе турында уйланучы һәм борчылучы лирик шагыйрә итеп танытты», — дип яза. Бүген дә ул әлеге сыйфатларын саклаган хәлдә иҗат итә, тик дөньяга башка яктан, башка күзлек аша карый.

Монда, әлбәттә, ун ел дәвамында Әлмәт шәһәренең «Луч» телекомпаниясендә «Җомга» тапшыруларын алып баруның да тәэсире булмый калмагандыр. Чөнки, тапшыру әзерләгәндә, авызы ачык, түбе тишек колхоз фермаларында гомерләрен уздырган Галимуллалар белән Саимәләрдән алып, алгы бүлмәләрендә без үкчәле, нечкә билле сәркатипләр утырган түрдәге түрәләргә кадәр бер тоткарлыксыз кереп йөргән журналист та бит әле ул. Кермәскә, түрдәге ике түрәнең берсе

аның укучысы. Ул инде керсә – күрә, күргәч сөйләтә яисә сөйләттерә. Әйе, әйе, сөйләттерә. Һәр фикерен шигъри калыпка салып сөйләшүче журналист-шагыйрәгә бу артык авырлык тудырмый. Әллә нинди бикле телләрне дә ачтыра ул. Һәм алар янынннан «пешкән, өлгергән» әзер шигырь белән кайта. Тик вакыт табып дәфтәргә генә теркәргә кирәк була. *Акка күчерәсе нәрсәләр күп, / Язылa бит әле дәфтәргә. / Язылa бит! Ходай шагыйрь итеп / Яраткан шул нәрсә әйтсән дә. («Акка күчерәсе нәрсәләр күп...»)*

К.Булатова терки дә, укучысына да житкерә. «Кеше жаны ни кичерә, нинди борчу йөри башларында», илдә ниләр бар – шагыйрә каләменнән калмый бар да теркәлә бара, чөнки поэзиянең асыл хасияте шагыйрьнең уй-хисләрен ачу белән бәйле. *Әгәр килсә бер зур түрә / Минем туган илемә. / Түбәтәй тотып торалар, / Тәрәт иткән жирендә,* – дигән әлеге юллар да шундый очрашуларның нәтижәсе.

*Уйдырма бер уен гөнаһымны, / И, чайкыйсыз инде телегездә. / Бер сүз әйтмәс идем, гөнаһ базы / Булмасагыз әгәр үзегез дә. / Актарынмас өчен сезнекендә / Сабырлыклар бирсен миңа Аллам, / Югыйсә бит телем таныш сезгә – / Үтсытырдай жавап кайтара алам! («Ә шулай да сезгә үпкәләмим...»)*

Мондый шәхси лирик ситуацияләр заман кешесенең тарихи-ижтимагый йөзен билгеләүдә әһәмиятле вазифа башкаралар. Күрәбез, шагыйрә үзенә кирәкле ситуацияләрне оста тотып ала белә. *Бүген әле (иллә «рәхәт»!) / Бәйрәм итә бар халык. / Шул бәйрәмнәр нәтижәсе – / Бара дөнья таркалып. («Ике мең дә өченченең...»)*

Шул ук вакытта шактый ачы һәм сәнгатьле итеп көләргә дә өйрәнгән. Тик, бу көлү артында никтер күз яшьләре күренә төсле. *Юк хәзер безләрдәй / Акылсыз кешеләр. / Акчасыз йөрмиләр – / Һәм дөрес эшлиләр. / Без генә ул менә / Мәгънәсез эт жиккән / Сәхнәдә йөрибез / Дермантин итектән. («Атнага бер генә...»)*

Шагыйрә билгеле бер тормыш шартларында гомер кичерә, шул тирәдәге хәл-вакыйгаларны, ситуация, конфликт, кичерешләрне күреп яши, үзенчәлекле характер ияләре белән аралаша, алар белән бәйләнеш-мөнәсәбәттә тора. Шунлыктан бу тирәлек аның күңеленә жуелмас тирән эз салып калдыра. *«...Цивилизация» дигән сүзне / Син нәрсә дип туглап йөртәсең? / Элек булган бүген тузган, дисен, – / Янарышны өмет итәсен? / Син, янарсын, әйдә, өр-яңадан / Туганны да читкә этмәсен. / Тик ул сиңа хезмәт итсен иде / Синен өстән хөкем итмәсен!.. («Иске-москы арасыннан...»)*

Илебезне «Кара алтын»ы белән шаулатып торган төбәкнең экологик торышына да битараф кала алмый ул, чөнки фән-техниканың алга китүе дә вакыты белән үзенең кире якларын күрсәтә. Әйләнә-тирә мохитнең табигыйлеге югалу, табигатьнең таушалуы кешеләрнең сәламәт яшәвенә, психологиясенә тәэсир итә, бүгенгесенә генә түгел, киләчәгенә дә куркыныч тудыра. *Чыгарабыз диеп жирнең маен, / Жир күкрәге күпме тишелде! / ...Зәңгәр газдан күкшелләнде каен, / Чахоткага тарган шикелле. / Керләнмичә кала алмаячагын / Бу якларда ачык бит инде. / Сафлык саклыйк дисен, сенлем, каен, / Берәр кая качып кит инде!.. («Чыгарабыз диеп жирнең маен...»)*

Ләкин вакыты белән башкачарак та жырларга туры килә шагыйрәгә. Тик «башкачарагында» да К.Булатова үзе булып кала. Үткен фикерләрен биктә торган теле артыннан да укучыларына ирештерү юлын таба. *«Кайда барсам – шунда ак бусага!» / Бу ышаныч хәзер кимеде... / Чичәнбикәлегем хак булса да, / Биктә тотам бүген телемне. («Хак иде лә чичәнбикәлегем...») Яки: Бездә дә ул тешләр бар, / Теш булмаса, телләр бар. / (Әмма телең теш артыннан / Чыкса, әллә ниләр бар...) («Көндәлектән «үтә дә генә акыллы» сафсата»)*

Беренче карашка Яшьлек, Мәхәббәт жырчысы – лирик шагыйрә буларак бәяләнсә дә, Клара Булатова ижатында тема төрлелеге, күтәрелгән мәсьәләләр шактый зурдан һәм аларның һәрберсе тулы канлы итеп, үзенчә ачылган.

Әдәбиятта зур урын алып торган Ватан, Туган ил, Туган жир, Туган як темасын ул үзенчә, берәүне дә кабатламыйча, яңа яктан ача. Туган ил, милләт өчен борчылуы

шигырьләрендә хәсрәт-ләгънәткә, ашкынулы экспрессив хисләргә төреп бирелә. Чарасызлыгы, сызлануы, яшәешнең камил булмавы һәм шул камиллекне аңлы рәвештә җимерүне күреп тору, рухи дөнья белән материаль дөнья арасындагы аерманы бөтен күзәнәге белән сизү – кеше аңының мәңгелек хакыйкатьне эзләвенә бер дәлил. «Хөррият!» дип...», «Иске-москы арасыннан...», «Район тулы укучылар», «Ике мең дә өченченең...», «2003 нең өченче көнендә...» шигырьләрендә илебез язмышы, кыйбласыз яшәвебез тулы чагылыш таба. *«Ирекле ил», «хөр дәүләт» дип, / Каш ясыйк дип күз чыгардык. / «Яла!» димә, «язма!» димә, / «Яла» түгел, бу – чынбарлык! («Каш ясыйм дип...»)*

Шагыйрә үзенең шигырьләрендә тормыш күренешләрен сурәтләү, мәсьәлә кую белән генә чикләнми. Ул шулар аша үзенең бәясен дә бирә. *Һай, ирекле булды, бәйсез булды / Мөстәкыйльлек алган татар халкы! / («Өлкән агай» ипләп кенә буды – / Тумас борын чукындырып атты.) («Һай, ирекле булды, бәйсез булды...»)*

Мондый шигырьләргә озак вакытлар «дөнья чырае» күрсәтелмәсә дә, узган гасырның 90 елларыннан моңарчы йокымсыраган аңыбыз күзәнәкләренә сәясәт ташкыны бәреп керде. Шигърияттә иҗтимагый фикер тирәнлеге күзәтелә башлады. З.Мансуров язганча «Коллонтай күк «кысан күлмәк»тән чәчрәп чыгарга омтылу моңарчы тыйнак булып күренгән К.Булатовада да тоемлана. ...Соңгырак әсәрләрендә «торгынлыкның үчен кайтару» сизелә.

В.Е.Хализев әйткәнчә, шагыйрә «Ярлары булмаган трагедия» концепциясен тудыра, чарасызлыкны, мәгънәсезлекне ачып бирә. Шул рәвешле, К.Булатова бүгенге тормышыбызда барган фаҗига-афәтләрнең шәүләсен шушы якты дөньяга чыгаруны, фаш итүне максат итеп куя кебек.

## «Тыелган темалар» яки сызлану фәлсәфәсе

Шигырьләрендә Татарстан, бәхет җырым син, дисә дә, шагыйрәнең тынычлыгын алган эш-гамәлләр шактый икән әле бу фани дөньяда. Туган телебезнең торышына, милләтебезнең яшәешенә дә, Кырым татарларының аяныч язмышына да битараф түгел К.Булатова. *Дөнья тар. Нигә миңа дөнья тар? / Юкса бит мин бик кечкенә бер татар, / Әллә татар булгангамы дөнья тар... / Бу дөньяның тар кысасын / Бәреп ватасы иде. / Өстебездәге албастысын / Алып атасы иде.*

Әдәбият галиме, тәнкыйтьче Т.Галиуллин 1991 елда «Шагыйрьләр элек «тыелган тема»ларга алынмыйлар, һаман да нәрсәдер көтәләр», – дип язса да, 1960 еллар башында ук инде, әлеге шигырьне укыгач, Ш.Маннур: «Мондый нәрсәләрне теләсә кайда кычкырып йөрмиләр», – дип кисәтеп куя. Ә сиксәненче елларда әлеге «тыелган тема»га язылган «куркыныч шигырь»не авторның үз тавышы белән «Голос Америки» дөньяга ишеттерә.

Инде 1972 елда чыккан «Җәйләр җитсә» дигән китабын «яңадан чистартып» эшләгәндә, аксакал әдипләребез Х.Туфан һәм Ш.Галиевлар кинәше белән кертми калдырылган бер шигырендә дә «әйтергә ярамый» торган шактый гына саллы, кыю фикерләр әйтелгән. *«Беренче төш хуҗаларга», диләр, / Халыктагы юрау-ырымның / Кем өстендә сыныйм дөреслеген? / Хуҗалары кем соң Кырымның? / ...Гомер кичкән туфрагыннан куккан / Кырымлылар ничек түзәдер? / Төшләренә дингез керәдер дә / Үзәкләрен кабат өзәдер...*

Ул елларда мондый юлларны язарга түгел, күпләр бу хакта уйларга да куркалар иде. *Шул халыкның аклануын көтеп, / Тыныч ята дингез, кымшанмый. / Тоташ халык хаин булуына / Дингез булып дингез ышанмый.*

Әйе, әлеге шигырь үз вакытында дөнья күргән булса, кемнең кем буласын һәм кайларда буласын әйтүе кыен. Мондый шигырьләре җыентыкка керми калса да, тәҗрибәле каләм ияләре К.Булатованың акыл куәсен, егәрен, чичәнлеген күрептоеп яшиләр. Татарстанның халык язучысы Нәкый ага Исәнбәт К.Булатованың каләм көчен бәяләп, 1968 елда ук: «Аның шигырьләре – чынлап та шигырь.

Анарда бай хиссиятләр теле, тоткарсыз тойгы, табигый агым бар. Укыйсын-укыйсын да ихтыярсыз: «Кулы тибеш йөри, каһәрнен!» – дип куясын», – дип яза.

Милләтебезнен рухи сагында торучы шагыйрә телебез язмышына бервакытта да битараф булмады. К.Булатованың «көзге» шигырьләре аны милләт, тел язмышын аналарга хас сыйфат белән кайгырта белүче олпат шагыйрә буларак күрсәтте. Бүген дә битараф түгел. *«Өфө һөйләй!» / Уфа көн-төн сөйли, / Башкортча да сөйли, татарча да. / ...Өфө һөйләй. Әйе, Уфа сөйли, / Үз теләндә сөйли, рухы көчле. / Ә мөстәкыйль Татарстан безнен / Үз теленнән үзе кача төсле. («Өфө һөйләй»)*

Бу – шагыйрәнең телебез торышына, телебез язмышына биргән бүгенге бәясе. Әлеге шигырьләрдә карасы кипкәнче үк тарихка кереп калырлык гыйбрәтләр чагыла.

К.Булатованың дөньяви фәлсәфәгә корылган «көзге» шигырьләрендә «яшәешнең шартлы моделе экзистенциональ яссылыкта сурәтләнә», дияргә тулы җирлек бар.

Экзистенциализм фәлсәфәсен профессор Д.Заһидуллина «сызлану фәлсәфәсе» дигән термин белән бирә. Әлеге фәлсәфә яшәешнең камил булмавыннан, кешенең үзен чиксезлек, галәм каршында артык кечкенә, Аллаһының бөеклеге янында бик түбән сизүеннән килеп чыкса да, К.Булатова шигырьләрендә сызлану фәләсәфәсе шәхеснең билгесез яки билгеле көчләр алдында кечкенәлеген сурәтләми, ә дөньяда рухи кыйммәтләр югала баруны проблема итеп күтәрә. *Бер нәрсәдән курка күңел / Бу имансыз заманда: / Явызлыкка кирәк түгел / Тәһарәт тә, намаз да. («Бер нәрсәдән курка күңел...»)*

Халкыбызның иманыннан мәхрүм калып, аккоштан күселеккә юлыгуына җаны бәргәләнә, сыкранып тыпырчына. Тик шагыйрәнең сызлануы аның гына бәласе, кайгысы, фаҗигасе булып анлашылмый, ә милләт фаҗигасе, бөтен кешелек дөньясыныкы буларак калкып чыга. *Калыкса да күтәрелә алмый / Югалалар башлык дигәннәр. / Дөньяларның кемгә мохтаж чагы? / Кайларда соң яна Пәйгамбәр? («Әвәләде дөнья кемне таштан...»)*

Шигырьләрдә лирик геройның кичерешләре шулкадәр көчле, хәтта тулысынча сурәтләп бетерелә алмый. Бу билгесезлек аша ачыклау таләп ителгән, ләкин аның аурасын сизү, шуны кичерү әһәмиятле булган тирән мәгънә белдерелә. *Ел гынамы? Гасыр үтте! / Безнен гасыр, / Ә бу гасыр ни күрсәтер? / Ни кыйратыр? / «Исә җилләр, бетә эзләр, күчә комнар»... / Кай дәвердә безнен җаннар кире кайтыр? («Яна елны көткәндә»)*

К.Булатованың әлеге шигырьләре укучыларны үзенең көчле дулкыны, эчке хәрәкәте, киеренкелеге, тормышның җитди мәсьәләләрен күтәрүләре белән җәлеп итә.

Шагыйрә һәм соңгы елларда прозаик буларак та танылып килүче Клара Булатованың «көзге чор» иҗатында урын алган фәлсәфи сыйфатлар һәм чынбарлык аның иҗат юнәлешен, кыйбласын, кемгә атап язуын билгели, чөнки фәлсәфә – табигать, кешелек җәмгыяте һәм фикерләү үсешенең иң гомуми законнары турындагы фән.

**Рәфкать ШАҺИЕВ,**
*филология фәннәре кандидаты*

# УКАЛЫ ИҖАТ

Узган гасырда ул миңа: «Остазым!» — дип эндәшә торган иде. Соңгы елларда бик ишеткәнем юк. Күреп-сизеп торам, үзе дә үсеп, остаз яшенә җитте, быел 65ен тутыра икән. Яше белән генә түгел, иҗаты белән дә җитлеккән прозаиклар сафына басты.

Камил Кәримовның «Ком сәгате», «Сакау күке», «Уен», «Игезәкләр йолдызлыгы» һәм 4 мең әбүнәчебезгә яңа гына барып ирешкән «Тургайлы болытлар» романын каршыма тезеп салдым да сызгыра белмәгән килеш, сызгырып куйдым — соңгы унбиш ел эчендә генә язылган әле болар. Соңгы егерме биш ел буе, тоташтан редакцияләрдә эшләгәнен дә исәпкә алсак, ирексездән сорау туа: «Кай арада язып өлгерә ул?» Гомеренә бер тапкыр гына булса да иҗат йортларына да бармаган килеш?!.

Социализмнан ерагайган саен, матур әдәбиятыбызның кайбер темалары, традицияләре, йолалары, хәтта кайбер шәхесләренең югалганын да сизәбез. Октябрь инкыйлабы, гражданнар сугышы, колхозлашу еллары, Бөек Ватан сугышы, Илне торгызу — ГЭСлар кору, Чирәм җирләр күтәрү, БАМ һәм КамАЗ кебек гигант төзелешләр... болар барысы да үткән гасыр әдәбиятында калды, дөресрәге шул вакыйгаларның шаһит-язучылары белән арабыздан китте. Шуңа күрәдерме, матур әдәбиятның «Матур» дигән укасы да коела башлаган кебек тоела иде инде миңа.

Яшерен-батырын түгел, үземнең иҗади активлыгым белән мавыгып, һәр яңа туган әсәрне күрмичә калуым да бик мөмкин. Бигрәк тә көн саен диярлек аралашып, көрешеп торган каләмдәшләремнең иҗатына игътибарым җитенкерәмәвен нык сизәм.

Г.Тукай исемендәге Олы бүләккә тәкъдим ителгән әсәрләр арасында Камил Кәримовның романнарын күргәч сагаеп калдым һәм аларны яңабаштан укып чыгарга мәҗбүр булдым.

Камилне мин беренче тапкыр 1975 елны, «Идел» Халыкара яшьләр лагеренда күргән идем. Бу «рабочий класс» ничек эләктеме безнең арага?..

Иҗат яшьләре өчен үткәрелгән семинарда аның «Тәнәфес» дигән хикәясен тикшергәннәр иде. И.Юзеев, А.Гыйләҗев, Ф.Шәфигуллин, Зөлфәт һәм мин, ул хикәя хакында җитди сөйләшү үткәргәнебезне хәтерлим. Күп тә үтми, ул хикәя «Казан утлары» журналында конкурста катнашып премия дә алды. Хикәянең нигезендә гап-гади вакыйга: зур авылда механизаторлар әзерләү өчен курслар ачыла. Төрле яшьтәге ат җигүчеләр, терлекчеләр һәм колхоз эшенә йөрүче агайлар бер төркемгә кереп, укырга җыела... Кыска гына хикәя гаилә низаглары, кеше күңелендәге ачышлар, хыяллар һәм җор телле диалоглар белән шыгрым тулган иде.

Тора-бара Камил Фаил Шәфигуллиннар белән ярышып «Ялкын» журналында премияләр ала башлады. Бер-бер артлы хикәяләр һәм повестьлар җыентыгы чыгара торды. Шәп хикәяче буларак, язучыларның һәр съездында, иҗади ел йомгакларында аның исеме мактап телгә алынганны да хәтерлим.

Ләкин илле яшьтән узгач, бер-бер артлы биш роман язар әле бу хикәяче егет, дип кем уйлаган?! Хәер, үземнән беләм, егерме алты яшендә көндезге бүлеккә укырга кергән егет өчен илле — иҗади гомернең яшьлеге генә лә ул!..

Ком сәгате... Камил Кәримовның сигез ел буе үзе кичкән тормыш тәҗрибәсе: михнәте-рәхәте, кавышу-аерылышулары, югалту-табышулары.

«Гомер юлының икенче яртысына житкәч, кешенең фәлсәфәсе үзгәрә», дип гади генә яздан башланып киткән роман фажигале яз белән тәмамлана.

Бераз акча эшләп, гаилә кору һәм өй салу хыялы белән янган 18 яшьлек Фазыл су бораулаучылар арасына килеп эләгә. Аның карлы-буранлы, зәмһәрир-чилләле, кыен, әмма романтикалы яшьлеге вагонда, кыр шартларында үтә. Һәм көннәрдән бер көнне эш урынындагы һәлакәт аны физик яктан сындырып ташлый. Фазылга өр-яңадан аякка басарга, яшәргә, базар шартларында чыныгып эшкә өйрәнергә туры килә. Бу урында «чыныгып» дип Н.А.Островскийга ияреп («Корыч ничек чыныкты») махсус яздым, чөнки Фазылның нәсел кушаматы Корыч икән.

«Ком сәгате»ндә ике пространстволы вакыт үлчәме: элек һәм хәзер. Бер жәмгыятьтән икенче жәмгыятькә күчкәндә, иң зур афәт, иң аяныч югалтулар гади эшче башына төште. Бу яктан караганда, язучының гражданлык позициясе аерымачык, ул — гадел хезмәт кешесе ягында. Онытылып барган эшчеләр язмышын, хезмәт темасын, мөмкин кадәр күпертеп, идеальләштереп, романтик рух өстәп, сурәтләү чараларын кызганмыйча бизәп, табигый күренешләргә төреп, афоризмнар белән көчәйтеп тасвирлый. Әлеге шигарьлек аның алга таба да ижатында тел вә стиль булып сакланып кала. Ул яңа романнарында да фикер тыгызлыгын югалтмый, киресенчә, көчәйтә генә. Әлеге жөмләләр комнан юылган алтын бөртекләре кебек, ялтырап килеп чыга.

Музыкаль спектакль карагач, бер жыр синең колагыңда калып, шул яңа көйне шыңшып кайтып китсәң, син бу киченне заяга уздырмагансың булыр. Яңа әсәр укыгач, күңелеңдә оригиналь бер жөмлә, зиһенеңдә үзгә бер фикер пәйда булса, әсәр буш түгел, ул сине рухи баеткан дигән сүз.

Язучыбыз Камил Кәримовның яңа әсәре саен хәтердә, күңелдә әнә шул сөенеч тамгасы кала. Әнә шундый канатлы тәгъбирләр, тора-бара халыкныкы булып китәрдәй астарлы сүзләр, ике мәгънәгә ия гыйбарәләр Камил ижатында тулып ята.

Алар Камилнең яңа чыккан «Игезәкләр йодызлыгы» (Казан утлары, 2010, № 9, 10) исемле роман-фарсында сәхифә саен кычкырып тора. Бу жөмләләр мөстәкыйль яши башлый, алар халыкныкы булып китә. Камил Кәримовның китапларындагы мәкальләшкән сүзләрне аерым китапка туплап, «Камил Кәрим мәкальләре» итеп чыгарырга кирәктер.

*Күз — ул табигатьнең бик сәяси чоры.*

*Ярлылар баш күтәрсә, байлар алтын күмә башлый.*

*Иван Иванычның сейфыннан кояш чыкты.*

*Халыкка ялган житкереп булмый: «Давай да давай! Тагын сөйлә дә тагын сөйлә!» — дип торалар.*

*Саңгырау кеше бәхетле бу дөньяда, чүп-чарны ишетми, йөрәген бозмый. Чукракның гомере озын.*

*Урман жимеше белән туенып яшәгән халык ерткыч була алмый.*

*Күзнең күзәннәре азынып чак.*

*Югалган көмеш алтыннан кадерлерәк.*

*Малай кеше Ир булып үскәнче, жүнле сыер кырык бозау үстерә.*

*Язмыш мәхәббәт артыннан йөри.*

*Рәхәт булган жирдә хәтәр бар.*

*Власть — властьны саклау өчен куела. Гади халык язмышы турында кайгырту — ул сайлаулар вакытында яңара торган уен гына.*

*Житәкчеләр сүзгә күчте — эшләре ун түгелдер.*

*Лжедемократларга дәреслекне көлгә очырыр өчен котельный моржасы кирәк.*

*Язуын язгансың да, акылдан язган димәсеннәр.*

*Яратмаган кешең белән яшәү — ялгызлыкның бер төре.*

*Тиздән бик хәтәр йогышлы чир — акча вирусы таралачак ди. Күп итеп акча жыйган саран байлар котыру авыруыннан кырылып бетәчәк.*

*Зур хужа килсә, кечерәк хужалар Хужа Насретдинга әверелә.*

*Күп сүз ул арзан бүләкне зурлап тапшырганда гына әйбәт.*

Камил Кәримовның әсәрләре әнә шулай буеннан-буена сурәтле тел, астарлы тел, кинаяле тел белән язылган, кактырып-суктырып әйтүләр әсәрне җинел укылышлы итә.

Соңгы ун еллыкларда әдәбиятка килергә тырышучыларның теле корама, җөмлә әйләнешләре урысча; язучының урысча уйлап, татарча язарга маташуы гадәти бер күренешкә әверелде инде. Шул нисбәттә Камил Кәримовның теле — саф, сурәтле тел, халыкчан тел, күпләргә үрнәк тел. Авторның очлы күзе, очлы колагы күпне күрә, күпне ишетә. Ул — күзәтүчән кеше һәм өлгергән әдип, чөнки, Камил остател буларак та, психологик сурәтләүләр иясе буларак та иҗатын баетты. Аның күптән түгел генә китап булып чыккан «Уен» әсәре дә нәкъ Камилчә, остател, астарлы, кинаяле әсәр буларак иҗат ителгән. Җыр куәсенә ия Сөмбелә исемле артистканың катлаулы, четерекле язмышы, хәтәр егетләрнең аңа мөнәсәбәте романны укылышлы итә, укучы әсәрдәге каһарманнарны таный башлый, чөнки андагы образлар тормыштан алынган, артык бай кешеләрнең уртак психологиясе аларны охшаш итә, һәркем унай яки тискәре образларда үз танышларын күрә башлый. Шуңа күрә дә «Уен» әсәре журнал нөсхәсендә чыккач ук шау-шу кузгатты.

Камил Кәримовның язу алаңы киң, ул хикәяләр дә, сатирик повестьлар да, мәкаләләр дә яза, көн кадагына суга торган темаларны калкытырга җөрьәт итә. Башка язучылар сирәк кагыла торган темалар — Камилнең иҗат мәйданы. Әдәбият, сәнгать, журналистикада эшләүчеләр — аның төп каһарманнары. Камил бу мохитне бик яхшы белә, үзе дә артист, үзе дә сәхнә остасы, мәшһүрләр белән озын юллар йөргән кеше. «Уен» белән «Игезәкләр йолдызлыгы» нәкъ үзенең каләмдәшләре, сәхнәдәшләре турында.

Ләкин, шагыйрь әйтмешли, «сүз башым бит шүрәле»... «Ком сәгате» дилогиясе автор кайчандыр үзе бораулаган чишмәләр кеби кәүсәр роман булса, «Игезәкләр йолдызлыгы» — роман-фарс, ә инде «Тургайлы болытлар», роман-элегия буларак, әдәби мирасыбызга яна сәхифә дип кереп калачак. Моны авторның новаторлыгы дисәк тә ялгышмабыз... Бу әсәр «Яңа татар әдәбияты» хрестоматиясендә һичшиксез үзенә урын табар дип ышанам. Исемнәре энциклопедиябезгә кергән язучыларыбызга аеруча игътибар итәр чак житте. Бәлки, кайберәүләрнең әсәрләрен дәреслекләрдән алып, бүгенгеләрне күбрәк өстәргә кирәктер.

«Ком сәгате» роман-дилогиясе, «Уен» һәм «Игезәкләр йолдызлыгы» романнары Республикабызның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә чын-чынлап лаек. Әгәр кем дә булса Камил Кәримовка тиешле ошбу бүләкне тартып алырга җөрьәт итә икән, йә әйтегез, иҗатыгыз белән кайсыгыз камилрәк?!.

**БАТУЛЛА,**

*Татарстанның Халык язучысы,*
*Г.Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреаты.*

# НӘНИЛӘРНЕҢ ҮЗ ШАГЫЙРЕ

Рафис Корбанның әдәби иҗат казанышлары барыннан да бигрәк нәниләр шигърияте белән бәйле. Дөрес, әдәбият сөючеләргә ул үзенең лирик һәм публицистик шигырьләре, шигъри тәрҗемәләре, үзгәртеп кору елларында И.Шакиров башкаруында милли гимн булып яңгыраган «Уян, татар!» садәсе (халык көе), «Кайларда йөрисең, сөйгән яр?» (И.Закиров көе), «Әни теләкләре» (Ф.Әхмәтшина көе) һ.б. лирик җырлары аша да яхшы таныш.

Шулай ук балалар драматургы буларак, курчак театры репертуарын баету юнәлешендәге иҗат эшчәнлеге дә аерым игътибарга лаек. Казан курчак театры аның «Куркуын җиңгән Куян» (1994), «Бардым күлгә, салдым кармак» (1996) исемле пьесаларын сәхнәләштерде. «Керпе малае дуслар эзли» (1995) пьесасы Татар дәүләт яшьләр театры сәхнәсендә куелды. Чаллы курчак театрында «Куркуын җиңгән Куян» (1998), Уфадагы «Нур» татар театры һәм Чаллы татар драма театры сәхнәләрендә «Патша кызы һәм җырчы» (2001) исемле пьесалары уңыш казанды. Авторның күп кенә лирик шигырьләренә профессиональ һәм үзешчән композиторлар тарафыннан көйләр язылган. Нәниләргә багышлап автор ике дистәдән артык китабын бастырды. Ул — 1990 елдан СССР һәм Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

Шагыйрь «Яра» китабына кергән «Әһ, дусларым...» шигырендә, узган гомере турында уйланып: «Бер көн картлык килер агач таягына таянып», — дип көрсенеп куя һәм шунда ук, үз табигатенә туры китереп, күрәсең, моңа шигъри җавабын да бирә: *Тик мин, дуслар, ул таякка әле / Башкача бер гамәл табармын; / Малай чакның агач аты итеп, / Атланырмын да бер чабармын,* — ди һәм, ашыкмасын, «һич тынгылык күрмәс миндә...» дип картлыгын кисәтергә дә онытмый.

Чынлап та, Рафис Корбан иҗатта һәм иҗтимагый-әдәби эшчәнлегендә, нинди генә яшькә җитүенә, нинди генә хезмәтләр башкаруына да карамастан, табигате белән һәрчак актив һәм алга омтылучан, эчкерсез-ихлас, балалар шигъриятенә, нәниләр дөньясына да гомер буена үз һәм тугрылыклы булып калды.

Нәниләр әдәбияты — гаять катлаулы, нечкә һәм гаҗәеп үзенчәлекле бер өлкә. Монда чын-чынлап уңыш казану өчен, көчле теләк, тырышлык, балалар теленә яраклаштырып яза белү генә аз, моның өчен, В.Г.Белинский сүзләре белән әйтсәк, табигатьтән нәниләр әдибе булып туарга кирәк. Ул — шулай ук гаять сирәк очрый торган талантларның берсе. Г.Тукай, А.Алишларыбыз янына янәшә куярлык нәниләр язучысын ни өчендер гасырлар да тудырырга бик ашыкмый. Әйтик, «Безнең гаилә», «Гали белән Кәҗә» кебек шигырьләрне хәтта Дәрдемәнд, Ш.Бабич, Һ.Такташ, М.Җәлил, Х.Туфан, Ф.Кәрим кебек классикларыбызда яки, бу өлкәгә махсус игътибар итеп, профессиональ иҗат эшчәнлеге алып барган яшьрәк буын шагыйрьләребездә дә күпләп табармын димә. Нәниләр шигърияте ул — берәмтекләп табыла торган тауар. Шуңа монда шигъри табышларның үзкыйммәте бермә-бер кадерлерәк. Алардагы һәр уңышлы психологик яки эстетик җәүһәрнең милли нәниләр шигърияте хәзинәсен баетуда аерым бер әһәмияте бар.

Рафис Корбан — үз иҗатында дистә еллар дәвамында әнә шушы четерекле өлкәгә тугрылыклы хезмәт итүчеләрнең берсе. Ул Г.Тукай, Ә.Фәйзи, Б.Рәхмәт, Ш.Галиев, Р.Миңнуллин иҗатларында урнашкан уңай традицияләрне кыю дәвам итә. Без бирер дә аның, димәк, татар телле нәниләр шигъриятенең дә уңышы саналырлык егермеләп әсәренә тукталып үтәрбез.

***

Үзенең нәни укучысы, дөресрәге бәләкәй тыңлаучылары белән үзара аңлашырга ниндирәк уртак тел таба соң әдип?

Барыннан да элек, шагыйрь буларак, нәни дусларына ул үзенең сәнгатьле-

сурәтле шигъри фикерләвен тәкъдим итә: *Искитмәле бу төн, / Әкият күк серле! / Күктә йолдызлары / Алма кебек эре! / Урман, болын, кырлар / Ай нурында йөзә. / Офыкта ажаган / Күктән алма өзә. / Керми күзгә йокы, / Тынлап ятам тынып: / Бакчада төн буе / Алма коела тып-тып. («Алмалы төн»). Күбәләкләр оча уйнап, / Ә һавада бал исе. / Чәчәкләр дә канатланып / Очып китәрләр төсле. / Чикерткә концертын тынлап, / Кояш та киткән оеп; / Җилләр дә талган йокыга, / Үләнгә башын куеп. («Җәйге көндә»)*

Авторның шигъри фикерләве еш кына баланың берәр шөгыленә яки уенына килеп үрелә: *Ә бакчада мине бер кош / Уздыра — / Ничә көннәр сыздырыпмы- / Сыздыра! / Ул чынлап та курайчыдыр, / Мөгаен... / Томшыгыдыр — анын моңлы / Курае. («Курай»). Инде белдек: буран нигә / Туктаган — / Ул бит безнең өйгә кереп / Йоклаган. («Буран нигә туктаган?»)*

Шигырьдән-шигырьгә баланың яшәеше, аның танып белүенә бәйле төстә уй-фикерләве, тойгылары тирәнәя, киңәя, тармаклана бара.

Әнә ул дус-ишләрен үзе белгән күп төрле бакчалар белән таныштыра һәм гөлләр-чәчәкләр бакчасы, яшелчә бакчасы, җиләк-җимеш бакчасы... дип саный торгач, азакта үзләренә аеруча якын булган тагын бер бакчага туктала: *Нинди бакча дип тормагыз, / Бу бакчаны күрсәгез; / Бу бакчада ни үсәме? / Бусында — без үсәбез! («Бакчалар»)* — дип, аның белән горурлану җаен таба.

«Җиләктә» шигырендә бала — ямьле табигать кочагында. Биредә дә автор үз героеның психологик үзенчәлеген бик төгәл тотып алуга ирешә: *Җиләклектә / Җиләк күп; / Җиләклектә / Чиләк күп. / Һәр малайда / Бер чиләк, / Каян җыярга / Кирәк / Моның кадәрле / Җиләк? / Барыбер булмас / Тутырып... / Ашыйм гына / Утырып.*

Шагыйрь нәни геройларын җанлы табигать эчендә сурәтләргә ярата. Монда алар кызыграк та, мавыктыргычрак та булган чын тормыш каршылыклары белән очрашалар: *Йөгерә сукмак, чаба, / Элдерә болын буйлап. / Үләннәр белән уйнап, / Чәчәкләр белән уйнап.*

Озын-озын юллар үткәч, балалар алдында сукмак кинәт юкка чыга. Әмма табигать, баланың үзе кебек үк, һәрчак серле, шигъриятле. Анда балага өлкәннәргә лаеклы булып үсү өчен файдалы хикмәтләрнең әледән-әле чыгып торуы да һич гаҗәп түгел: *Сукмакны бит кайчандыр / Кешеләр салып үткән. / Димәк, сукмак салырга / Безгә дә чират җиткән. («Сукмак»)*

Баланың яшәеше турыдан-туры өлкәннәр тормышы белән тыгыз бәйле. Алар белән бергә ул борчылырга, бергә сөенергә — кыскасы, чын-чынлап яшәргә өйрәнә. Тик аерма шунда: эчке халәт кебек шактый гына абстракт төшенчәләрне дә бала үз күнел дөньясына якын булган рәвештә сиземле итеп күреп-танып ала: *Авызларны ера шатлык, / Көлү булып йөзгә чыга. / Шатлык керсә бүлмәләргә, / Тәрәзәләр шыр ачыла. / Урамнарга чыга шатлык, / Калмый торып өйдә генә... («Шатлык»)*

Өлкәннәр күнелендә йөргән абстракт идеяләр дә анын нәкъ үз телендә — тоемлы рәвештә килеп ирешә: *Шатлыклардан шатлык туа, / Әверелә матур җырга. / Бары тик бер шатлык кирәк / Җир төренсен өчен нурга.*

«Мин бәйрәмнәр яратам» шигырендә, бәлки шуңадыр, бәйрәмнәрнең көн саен булып торуына да бала һич каршы түгел. Чөнки күмәк сөенеч алып килгән ул бәйрәмнәрдә анын теләк-фантазиясе, уены-чыны могҗиза булып бергә кушыла. «Минем туган көнемдә» тәрҗемә шигыре дә моның бер ачык мисалы: *Мин торт состым, өлкәннәр / Эчтеләр шампанский. / Ә тәмле тамак песи / Каймак ашагански.*

Авторның гади генә тормыш күренешләреннән дә шигъри мәгънә, хикмәт-могҗиза таба белү осталыгы «Үзем башлыйм» шигыренә дә үтеп кергән: *Батыр калу өчен әле / Мина бераз иртәрәк. / Тик шулай да Сабан туен / Үзем башлап җибәрәм.*

Халкыбыз, димәк, Сабан туенда да нәниләргә чын бәйрәм тантанасын — тормыш белән хыялның бергә кушылу шартын тудыра алган булып чыга.

Баланың табигый халәте, холкы, барыннан да бигрәк аның уенчыклары белән уйнавында, аларга булган мөнәсәбәтендә ачык чагылыш таба. Авторның дистәләгән

шигырьләре әнә шундыйлардан: *Әти миңа туган көнгә / Бүләк итте автомат. / — Син хәзер чын солдат, — диде, — / Автоматтан ат та ат! / Әйбәт атты автоматым. / Ике көн буе аттым. / Курыкмагыз атар бу дип... / Мин инде аны ваттым. («Автомат»)*

«Сөйләшергә өйрәтәм» шигырендә баланың мәхәббәте аның курчагына төбәлгән. Бөтен шартын туры китереп — чын әниләрчә итеп, ул аның белән аралашу, ана карата үзенең ярату тойгыларын аңлату җаен таба: *Булсам да бик / Нәни мин, / Курчагыма / Әни мин. / Ашатам да / Йоклатам, / Елаганда / Юатам. / Аннан юам / Керләрен: / Оек белән / Күлмәген.*

Әмма тәрбия хәтта уенда да каршылыксыз гына бара алмый. Ул әнә, әнисе кебек, кызының бөтен сораганнарын да үтәр иде дә, курчагы сөйләшә белми икән: *Сөйләр иде, — / Шуны да / Белми торам, / Карале, / Курчагымны / Сөйләшергә / Өйрәтәсем / Бар әле.*

Әле аның бер тыңлаусыз шәкерте дә бар. Ул — Муйнагы: *Мөмкин түгел өйрәтергә / Һичбер ничек! / Уенчык эт түгел шул ул, / Ул — чын көчек! («Уенда уен гына»)*

Автор баланы укырга өйрәтү, аны мәктәпкә әзерләү һәм, гомумән, нәниләрнең фикерләү сәләтен үстерү мәсьәләләренә дә якыннан торып катнаша. Аның шигъри табышмаклары — шуның бер мисалы: *Беркем аны югалтмаган, / Ләкин һаман табалар... / Сез дә табышыгыз әле, / Нәрсә соң ул, балалар?*

Шагыйрь нәниләргә сатирадан да өлеш чыгармый калмый. «Каюмның дуслары» шигырендә без нәниләрнең үз алыш-бирешенә тап булабыз: — Каюм, Каюм, / Дустың кем? / — Әлбәттә инде, / Гөлсем! / Ишетәсеңме, / Гөлсем? / Бир алмаңның / Берсен!

Берсеннән икенчесенә, өченчесенә күчеп... дуслык тойгысын шулай раслата торгач, дуслыкны ныгыту чираты Әюпкә җитә: — *Бүген дустың / Кем, Каюм? / — Әйдә, син дус / Бул, Әюп! / — Ләкин минем / Кесәмдә / Юк шул һичбер / Нәрсә дә!..*

Көлке дә кызганыч та... әмма нишләмәк кирәк, монысы инде безнең бүгенге үз тормышыбыз.

Авторның «Капкорсак» шигыре дә бик күпләрне чеметә торган итеп язылган. Ул кулинария һәм берочтан ана телен югалту, әхлак-тәрбия өлкәсенә дә тигез кагыла: *Капкорсак, капкорсак, / Ашаган күп бавырсак. / Ашаган күп тәбикмәк, / Коймак, бәлеш һәм икмәк. / Чәкчәк, сумса, кош теле / Һәм ике табак белен. / Ашаган чакта белен, / Йотып җибәргән телен. / Аңа соң тел ник кирәк? / Ашарга бир тизрәк!*

Шагыйрьнең рус әдәбияты классикларыннан файдаланып иҗат ителгән тәрҗемәләренең дә әнә шушы милли хәзинәбезне баетуда зур әһәмияткә ия булуын әйтеп үтәргә кирәк.

Аларның «Минем туган көнемдә» дигәне белән алда танышып үткән идек инде. Биредә мисал итеп тагын берсен атап үтик. Ул — «Санамыш»: *Бер, ике, өч, дүрт, биш. / Бакчага кергән куян. / Кәбестәне кимергән, / Китергән бик зур зыян. / Сунарчы аңа аткан, / Куян һушын югалткан. / Өйгә алып кайткачтын, / Куян чыккан да качкан.*

Санамыш булгач, уен башлана... димәк, шау-шулы, шигърияте балачак дөньясы дәвам итә.

Шулай итеп, без шагыйрьнең нәниләр шигърияте казанышларына кечкенә бер күзәтү ясадык. Иң нәни укучы-тыңлаучыларыбызны шундый мавыктыргыч һәм хикмәтле шигъри телдә сөйләштерә белгәне өчен без аларның барысы исеменнән шагыйрь абыйларына олы рәхмәтебезне җиткерик.

**Равил РАХМАНИ,**
*филология фәннәре кандидаты*

# ШИГЪРИЯТ ДӨНЬЯСЫ: 2014 ЕЛ

Гомуми планда караганда, XX-XXI йөз чикләрендә татар поэзиясенең, үткән гасыр шигъри традицияләрне үстереп, дәвам итеп баруы белән янәшәдә, хискичереш бирелеше, образлы сурәтлелек, сәнгати алымнар җәһәтеннән яна эзләнүләр, тәҗрибәләр юлына керүе күренә. Традиция һәм яңачалыкның үзара бәйләнеп баруы, керешеп китүе — әдәби барышның гадәти үсеш үзенчәлеге.

Соңгы еллар шигъриятендә, бер яктан, кешелекнең үзенә, яшәеш кануннарына бәянең, фәлсәфи гомумиләштерүләрнең, яшәү мәгънәсенә, яшәү кыйммәтенә мөнәсәбәтле уйлануларның алга чыгуы, шуңа бәйле күңел һәм фәлсәфи лириканың активлашуы күзәтелә. Икенче яктан, яшерен эчтәлек алымы аша ачылган субъектив катлам җәмгыяткә, милләт тормышына хас проблемаларны, иҗтимагый барыш, аның шәхескә, кеше тормышына йогынтысын ачып бирүгә юнәлтелә, тәнкыйди бәя фәлсәфи фикер-карашлар белән кушыла яки фәлсәфә үзе бер катлам-башлангыч төсендә алга чыга. Өченчедән, поэзиянең тематик яктан баю-төрләнүе, проблематик яссылыкта әхлакый мәсьәләләрдән гомумкешелек кыйммәтләрен яктыртуга таба хәрәкәт итүе дә ачык күренә. Дүртенчедән, шигърияттәге сыйфат үзгәрешләре иҗат юнәлеше, агымнарының, стиль тенденцияләренең төрлелегенә тоташа: сүз сәнгатенең бу төрендә романтизм, реализм юнәлешләре төрле стиль тенденцияләре белән байый, алар белән янәшәдә модернистик, постмодернистик алымнар бергә берегеп үсә-үзгәрә.

Чор шигъриятендә формалашкан мондый сыйфат үзгәрешләре 2014 ел дәвамында «Казан утлары» журналында дөнья күргән лирик һәм лиро-эпик әсәрләрдә дә үстерелеп, камилләштереп барыла. Бербөтен шигъри бәйләм итеп караган вакытта аларның татар поэзиясендә калыплашкан төп стиль тенденцияләрен дәвам итеп, әдәби мәйданга чыгуы күзгә ташлана: иң беренче нәүбәттә милләт тормышына, аның бүгенге халәтенә, җәмгыятьтәге тәртипләргә, вазгыятькә бәя бирүгә йөз тоткан тәнкыйди башлангычның үстерелүе; җәмгыятьнең актуаль мәсьәләләрен әдәби текстка нигезләнеп чишәргә омтылган интеллектуаль тенденциянең дәвам иттерелүе; лирик герой халәтенең хыялый-идеалистик омтылышларын, хис-кичерешләрен сурәтләү объекты итеп алган романтик юнәлешнең үстерелүе.

Бу елда дөнья күргән шигъри әсәрләрнең күпчелеге реалистик алымнарга таянып иҗат ителгән; алар, нигездә, гражданлык лирикасы жанрын үстереп бара. Бу яктан А.Хәлим шигырьләре үзенчәлекле, чыгарылма кебек кабул ителә, анын «Мөрәҗәгать», «Эмпайр-Бильдинг, 106 кат» кебек шигырьләре хәзерге татар поэзиясендә сәяси лириканың, үтә аз санда гына булса да, яшәвен раслый.

Шушы юнәлештәге шигъри әсәрләрнең бер төркеме җәмгыятьтәге вазгыять, көнкүреш, иҗтимагый барышка бәя бирүгә йөз тотып язылган. Аларда, кагыйдә буларак, иҗтимагый детерминация саклана, лирик герой белән җәмгыятьтәге тәртипләрнең каршылыгы алгы планга чыга, иҗтимагый барышны тәнкыйтьләгән тәнкыйди башлангыч көчле бирелә, шигъри әсәрләр тукымасында милли, иҗтимагый проблемалар калкытып куела. Бу яктан Р.Харис, Г.Рәхим, Ф.Дәүләтбаев, М.Кәримов, Г.Морат, Л.Фәтхетдинованың тәкъдим ителгән шигырьләре үзенчәлекле.

Мәсәлән, Р.Харисның «Беренче хәбәр», «Елатмаска иде бәбиләрне», «Учым», «Курыкмыйча яшик» кебек шигъри үрнәкләре шагыйрь иҗатындагы дөнья сурәтендә үзгәрешләр барганлыгы хакында хәбәр итә. Әлеге үрнәкләрдә Р.Харис

фәлсәфилектән читләшә төшеп, реалистик алымнар ярдәмендә үз ватаныннан читкә омтылу («Байбәтчә»), курку («Курыкмыйча яшик») проблемаларын калкытып куя. Бу бәйләмдәге шигырьләре аша ул үз җирендә яшәүнең кеше тормышындагы иң зур бәхет булуын ассызыклый.

Ф.Дәүләтбаевның «Тормышта да шахматтагы кебек», «Бутамагыз мине», «Караңгылыкта» кебек шигырьләрендә дә охшаш мотивлар алга чыга, иҗтимагый тормышка, җәмгыятьтәге яшәү тәртипләренә бәя калкытып куела. Мәсәлән, «Караңгылыкта» шигырендә караңгылык ил тормышын, җәмгыятьтәге вазгыятьне бәяләүгә юнәлтелә. Кеше кадере булмау, хөсетлек, байлыкка омтылыш, гаделсезлек караңгылыкны тудыручы һәм лирик герой күңелендә сагыш хисен уятучы сәбәпләр төсен ала. Г.Рәхимнең «Безнең чор кешесе», «Кемгә ышанырга» шигырьләрендә дә кешелексезлекнең безнең чор кешесе холкындагы төп сыйфат булуы идея төсендә формалаша: *Аюдан курыкмый кеше, / Бүредән курыкмый кеше, / Таулардан курыкмый кеше — / Кешедән курка кеше.*

Л.Фәтхетдинованың «Мәгънә», «Мин иҗатка кайтам», «Буын арты буын алмашына» кебек шигырьләрендә дә охшаш мотивларның алга чыгуын күрәбез. Әлеге шигырьләр бәйләмен туплаган «Сүз кыйммәте бүген — ихлас фикер» гыйбарәсе әсәрләр тукымасыннан чыгарылган идея кебек кабул ителә. Шагыйрә, алдагы шагыйрьләрдән аермалы буларак, бүгенге җәмгыятьтә кешенең генә түгел, сүзнең дә, иҗатның да, ихлас фикернең дә булмавын ассызыклый.

М.Кәримовның «Булабыз», «Искә алу» кебек шигырьләре әйләнә-тирә тормышка сатирик бәя булып укыла. «Булабыз» шигырендә иҗтимагый-сәяси вазгыять лирик герой күңелендә әрнү хисен тудыра, «без, без», «булабыз» гыйбарәләрен уйнату аша шагыйрь бүгенге яшәешнең гаделсезлеген, сәяси барышның кешене монафикъка әйләндерүе проблемаларын калкытып куя.

Бу юнәлештәге шигырьләрне бербөтенгә туплап караганда, аларның, җәмгыятьтәге проблемалар кебек үк бертөрле, охшаш мотивларга йөз тотуы ачыклана. Әлеге матур үрнәкләр янәшәсендә катлаулы шигъри сурәтлелек белән баетылган, яшерен эчтәлекне эзләп укырга мәҗбүр итәрдәй реалистик үрнәкләрне дә күрәсе килә.

Мәсәлән, бу юнәлештәге шигырьләр бәйләмендә Г.Моратның «Әкиятне башлыйк яңабаштан» шигыре үзенчәлекле укыла. Шигырь структурасында әкият бүгенге яшәешне бәяләү барышында кулланылган метафора вазифасын үти, халык язмышын, бүгенге һәм киләчәк турындагы шагыйрь уйлануларын җиткерүче булып тәгълләшә. Әкияттәге бармагын кыскан Шүрәлене ирекле итеп күрү теләге, әфсенгә тарыган Ак бүренең әфсенен кире кайтару омтылышы, Аркадашлары чокыр казыган Турай батырны коткару, Сак белән Сокны кавыштыру хыялы һ.б. аркылы әдип Яңа яшәеш моделен төзи; шартлы алым — әкиятне һәм чынбарлыкны кушу аша мифологик үткәнне һәм бүгенгене бер ноктага җыя, фәлсәфи күзаллау аша яшәешкә, җәмгыятьтәге тәртипләргә бәя-мөнәсәбәт белдерергә омтыла. Әкияткә хас аерым сыйфатларны автор кеше тормышына үрнәк итеп күтәрә: *Әкиятне башлыйк яңабаштан, / Җен кайтарсын ана каргышын, / Пәри ярлыкасын үксезләрне, / Сак белән Сок кабат кавышсын. / Әкиятне башлыйк яңабаштан...*

Р.Корбанның «Тукран» шигыре дә җәмгыятьтәге проблемаларны ачу барышында метафорик сурәтлелеккә мөрәҗәгать итеп язылган: *Уйлыйм аннан: безнең дә, дим, / Җәмгыять бара череп. / Эчтән анны җиз башлы корт / Кимерә — ришвәтчелек. / Ничек безне тазартырга? / Башымда янгрый оран. / Агачларны түгел, гүя, / Миемне чукый тукран.*

Шуның белән янәшәдә аерым бер шигырьләрдә милли проблемалар калкытып куела, милли хәл-халәткә мөнәсәбәт метафора-символлар, эзоп теле ярдәмендә укучыга ирештерелә. «Казан утлары» журналының 2014 елгы саннарындагы реалистик шигырьләр арасында алар күпчелекне тәшкил итә. Мондый шигъри үрнәкләрдә, кагыйдә буларак, татар милләтенең киләчәге, татар теленең киләчәк язмышы, аның тормыштагы урыны, роле, милли битарафлык, ваемсызлык проблемалары әйдәп бара. Мәсәлән, Г.Рәхимнең «Каян килә», «Ватаның бармы», Ф.Дәүләтбаевның «Ат

өстендә — татар урыны», Р.Сәлахиевнын «Тел язмышын уйлап», Т.Шәмсуаровның «Бергә булыйк, бердәм булыйк», «Татар чәе», Х.Бәдигыйнын «Безнең сүзләр», Н.Әхмәдиевнын «Ыру башы — Ак бүре», З.Мансуровнын «Явыз Иван кинәше» һ.б. шигырьләр шул хакта сөйли.

Мәсәлән, Н.Әхмәдиевнын «Ыру башы — Ак бүре» шигырендә Г.Тукайның «Безнең милләт үлгәнме, әллә йоклаган гынамы?» гыйбарәсе эпиграф итеп алынып, шигырь шул сорауга җавап төсендә язылган. Ак бүре метафорасы шигырь структурасында милләткә бәя бирү функциясен беркетә. Анын батырлыгы, ыру саклау сәләте татар менталитетын, ак бүре / капкындагы соры бүре оппозициясе татарнын холкын һәм бүгенге хәл-халәтен бәяләүгә юнәлтелә. Татарда ак бүре сыйфатларынын җинеп чыгачагына ышаныч идея булып укыла.

Охшаш мотив М.Галиевнын «Чыдам тау да, үзән дә без» шигырендә дә тәкъдим ителә. Татарнын үткәне / бүгенгесе оппозициясенә корылып иҗат ителгән шигырьдә балбал, бөркет, дала, тау, үзән, каганат кебек метафорик-символик образ-детальләр татарнын шанлы тарихын сурәтләү юлында файдаланыла. Бүгенге халәтне тасвирлау барышында кулланылган әрнеп үскән әрем образы авторнын матур табышы буларак кабул ителә һәм татар халкы язмышынын ачылыгын да, хокуксызлыгын да, лирик геройнын әрнүен дә үзенә сыйдыра. Шигырьнең соңгы юллары автор позициясе булып укыла: *Кайтавазлар инри юашланып: / Бүгеннән без, бәлки, бөгелмәбез.*

Шагыйрьнең «Дүрт төс — дөньянын дүрт ягы», «Тарихка караш» кебек шигъри үрнәкләре дә шушы дулкында кабул ителә.

Ф.Гыйззәтуллинанын «Ачыла хәтер», «Чиксезлек» шигырьләре дә авторның милләтнең бүгенге халәтенә, битарафлыгына сызлануы булып кабул ителә.

Р.Бәшәрнең «Мираж» шигыре эзоп теле бирелеше ягыннан үткенлеге белән аерылып тора. Метафорик сурәтлелек ярдәмендә милләт язмышына бәя бирү ягыннан да, шигъри үлчәме җәһәтеннән дә ул XX йөз башында иҗат ителеп, онытылган, бүген аз катлам укучыга гына таныш поэмалар кебек укыла. Бер караганда шигырьдә идеологик яки идеологик эчтәлеккә ишарә ясаган образлар юк кебек. Әмма яшерен эчтәлек алымы әсәрдән яна мәгънәләрне табарга мөмкинлек бирә. Мираж / төш каршылыгы шигырь структурасында чынбарлык / хыял кебек тәгалләшә, миражга хас сусыз, эссе чүл, шомлы ил, шәүлә, әләмсез, адәмсез ил метафора, эпитетлары татар милләтенең бүгенге халәтен ачуга буйсындырыла. Татар укчысына Дәрдемәнд иҗатыннан яхшы таныш булган искән җил, тузгытылган комнар һәм ком таулары күмгән юллар кебек символик образлар шигырь структурасында кылган гамәлләрнең, үткән елларның мәгънәсезлеге, эзсез үтүе мотивын янарта һәм лирик герой күнелендә әрнү тудыра. Оппозицион вариантта бирелгән төштәге азан моңы, бәхетле кешеләр, җәннәт тормышы кебек образ-детальләр исә лирик геройның милләт киләчәге хакындагы хыялы булып тәгалләшә. Шигырь тукымасыннан милләтне шушы хыял яшәтә дигән фикер саркып чыга. Шагыйрьнең «Авылда» шигырендә дә охшаш мотивлар урын ала, ләкин сәнгатьчә эшләнеше, образлылыкнын байлыгы җәһәтеннән ул элгәресеннән калыша.

Н.Сафинанын журналның 2014 елгы саннарында басылган шигырьләре милли мотивларга байлыгы, яшерен эчтәлекнең тирәнлеге белән аерылып тора. Бу яктан «Өмет тирәге» шигыре үзенчәлекле. Әсәр структурасында ул аерым кеше гомереннән башлап милләт тарихына кадәр гомумиләштерелгән катлаулы метафора төсен ала. Кыш, көз, яз кебек табигать фасыллары да шундый ук гомумиләштерү юлын үтә: кеше гомерендәге аерым этаплардан башлап, милләт яшәешендәге аерым дәверләрне бәяләү максатында кулланыла, шигырь тукымасында кабатлана килгән өмет тирәге лирик герой күнеле кебек укыла. Тирәкнең төрле халәтләрен сурәтләү аша идея тәгалләшә: яфраклары коелган өмет тирәгенең дә бөреләнер, яфрак ярыр мизгеле киләчәк. Бу юллар яшерен эчтәлек аша автор позициясен тәгалләштерә: милләт тормышында да якты киләчәк булыр! Шагыйрәнең «Хәтере кайтканнарга» шигыре дә шушы дулкында интерпретацияләнә, шәрехләнә ала.

Р.Фәйзуллиннын «Китә казлар...» шигыре башка идея белән өртелә.

Хронотопка бәйле төстә шартлы өч өлешкә бүленгән шигырь татар халкы язмышының төрле борылышларын ачарга мөмкинлек бирә. Милли поэзиядә авыр язмышны, аерылу сагышын гәүдәләндереп килгән традицион каз образын автор яна мәгънә белән баета һәм сәяси, идеологик эчтәлектә укучыга тәкъдим итә. Шигырьнең беренче өлешендәге Донбасска киткән казлар шигырь тукымасында төрле кыйтгаларга таралган, сибелгән һәм үз нигез тамырларыннан аерылган татар язмышына ишарә булып кабул ителә. Лирик геройның әрнүе дә аларның бүгенге тормыш-көнитешенә бәйләп куела һәм шигырьне сәяси мотивларга баета. Әсәрнең икенче өлешендә гәүдәләнгән Иделгә китеп баручы казлар үз төбәгендә гомер үткәреп тә, аяныч яшәешкә дучар ителгән татар язмышын танырга мөмкинлек бирә. Шигырьнең өченче өлешендә кайтып баручы казлар автор позициясен житкерү функциясен ала. Лирик геройның әрнүе татар авылларының бетүе, буыннар өзелү белән бәйләп куела. Соңгы өлештә бирелгән рәшә образы, традицион символик эчтәлек белән өртелеп, автор өметләренең булмавын ассызыклый: *Беткән авыллар өстендә / Тик рәшә балкышлары. / Инеш буйларында калган / Тирәк ябалдашлары.*

Р.Мөхәммәтшинның «Ак бүре» либреттосы да милли проблематикага йөз тотып ижат ителә. Бер яктан, ул, татар халык әкиятләренә нигезләнеп язылган либретто буларак, хәзерге татар поэзиясендә бу жанрның актуальлеген тагын бер кат раслый. Әсәрнең уйланмасында, сәнгати эшләнешендә М.Җәлилнең «Алтынчәч» либреттосы белән охшашлыкларны да күрми мөмкин түгел. Татар язмышы Хан һәм Ханбикә ыруының фажигасе аша ачылып, татар әкиятләренә хас, начарлык кылуның нәтижәсе үзенә начарлык булып кайту, гафу ителү, сихер кайтару, югалту — табу мифологик мотивлары татар язмышын чагылдыру һәм бәяләү юлында отышлы файдаланыла. Милли проблематиканы мифологик материал аша тәкъдим итү уңышлы кабул ителә. Р.Мөхәммәтшин ижатының гына түгел, гомумән хәзерге татар поэзиясенең үзгенә хас булмаган бу әсәр аерым образларның символик югарылыкка күтәрелүе, үтә гомумиләштерелеп тасвирлануы белән үзенчәлекле. Хан һәм Дию каршылыгы әсәр структурасында милли мәсьәләләрне калкытса, Ханбикә, аның язмышы аркылы автор татар халкының яшәешен, хәл-халәтен чагылдыра. Әсәр тукымасында көчле рухлы, язмышның сындырып сынауларына да бирешмәгән, бетүгә хөкем ителгәннән соң да югалмаган Ханбикә татар халкының символик гәүдәләнеше, башбирмәс образы булып аңлашыла. Тәгин — аның лаеклы дәвамы да — шул мәгънәви яссылыкта кабул ителә. Кам ана азатлык символы булып тәгәлләшә. Әсәр тукымасында Ак Бүре милләтне саклап калырга, азатлыкка алып барырга тиешле сыйфатларны гомумиләштереп туплый. Татар халкының азатлык, бәйсезлек өчен көрәшен гәүдәләндерү аша автор татар халкын Ханбикә, Кам ана кебек батыр, максатчан булырга чакыра.

Х.Камаловның «Кырлар көрсенүе», «Тылсымлы кыр», Ч.Мусинның «Нигезен тартадыр ул», Р.Корбанның «Урыс капка», Р.Шәриповның «Биш алма» әсәрләрендә, С.Рәхмәтулланың «Утырып уйланыр чак» шигырьләр бәйләмендә көнүзәк мәсьәләләрдән татар авылларының язмышы проблемасы калкытып куела. Мәсәлән, Р.Шәриповның «Биш алма» әсәрендә лирик геройның әрнү хисенә кайчандыр шаулап-гөрләп торган, тулы канлы тормыш белән яшәгән авылның югалуы фажигале төсмер бирә, аның бетүе нәтижәсендә илаһи матурлыкның югалуы сызлану тойгысы тудыра: *Ни эшләдек? Нәрсә карадык без? / Нинди олы байлык югала... / Ничек кенә жимермәделәр бит, / Тыгып алып утка, суга да... / Жимерелгән нигез, әнкәм монда кала, / Куршеләрем кала, йөрәгем, / Каберем дә шунда калсын иде... / Бу васыять — соңгы теләгем.*

Татар авылларының бетүе белән үткәннәрнең жуелуы, рухи жепләрнең өзелүе хисснең дәрәжәсен көчәйтә, шигырь кешелек дәвамлылыкны, көчешне сакларга тиеш дигән фикер белән тәмамлана.

Күренгәнчә, милли тематикага йөз тоткан шигырьләр сәнгати алымнарга, яшерен эчтәлеккә байлыгы белән аерылып тора, образларга яңа мәгънәләр өстәп, поэтик янарыш, жанр төрлелеге хакында да хәбәр итә, милли шигъриятнең

үз традицияләренә тугрылыгын да ассызыклый. Шулай да, журналның еллык саннары белән тулаем танышып чыкканнан соң, авраздаш мотивларга язылган шигырьләр күбрәк түгелме икән, дигән сорау туа. Әлбәттә, милләтнең бүгенге халәте шартларында бу күренеш, бәлки, үзен аклыйдыр да, әмма журнал битләрендә милли эчтәлекле шигырьләрнең дә мотивлар, аларны җиткерү юллары җәһәтеннән төрле булуын күрәсе килә (мәсәлән, Р.Мөхәммәтшинның либреттосы бу яктан төрлелекне дәлилләп тора).

Традицион төстә аерым бер шигырьләрдә милли мотивлар билгеле шәхесләргә мөнәсәбәтле формалаша. Тукай турындагы поэзиядә XX йөз башында ук әйләнешкә кергән бу алым әле бүген дә актуальлеген югалтмый.

Мәсәлән, С.Әхмәтҗанованың «Арча поезды» шигырьләр бәйләмендә үзгә күренеш — тукталышлар аша милли шәхесләргә бәя бирү сыйфаты алга чыга. Билгеле, бәйләмдә «Арча капкасы» шигырьләр циклы белән аваздашлыклар да шактый. Әлеге бәйләмнең башында ук бирелгән «Арча поезды» шигыре гомуми планда кереш кебек кабул ителә, укучыны әзерләү юнәлешендә урын ала. Әлеге образ аша әдәбият тарихына күзәтү ясау — татар поэзиясендә үзенчәлекле күренеш. Арча төбәгендә туып-үскән яки буыннар чылбыры шушы төбәккә тоташкан Г.Курсави, Ш.Мәрҗани, Г.Тукай, Г.Камал, Г.Бәширов, С.Хәким, Г.Ахунов, М.Мәһдиев кебек шәхесләргә тукталып, шагыйрә аларның милли барышта, әдәби аренадагы урынын барлый, аларга мөнәсәбәт аша милләткә бәя бирергә омтыла (шулай ук Тукай турындагы поэзиядән үк үстерелә килгән алым), Арча төбәгенең татар халкы язмышындагы урынын да тәгаенләштереп куя.

Ф.Фәсхинең «Җанны пакьли торган яктылык» шигырьләр бәйләме татар поэзиясендә форма яңарышы барганлыгын тәгаенләштереп куя. Татар әдәбияты, мәдәниятенең төрле өлкәләрендә хезмәт куеп, дөньядан үткән шәхесләргә багышлап язылган шигырьләрне үзәк идея бербөтенгә туплый: алардан соң калган мирас, якты гамәлләр милли яшәешкә нур өстәп, яктыртып тору мөмкинлегенә ия! Һәр багышлауга бирелгән барельеф-портретлар шигырьгә өстәмә эчтәлек биреп, форма эзләнүләре хакында хәбәр итә. Бу — багышлауларда сирәк кулланыла торган алымнардан.

Ф.Жамалетдинованың «Балта» шигырендә Җәлил шәхесенә мөнәсәбәт проблемасы алга чыга һәм шушы юлда автор балта метафорасына мөрәҗәгать итә. Алман балтасы / татар балтасы янәшәлеге Җәлилне физик үтерү / шагыйрьнең рухын «үтерү» янәшәлеген ачуга юнәлтелә. Әлеге фонда Җәлилгә булган мөнәсәбәт милләтнең үзен бәяләү чарасы буларак яңгырый.

Р.Ахунҗанованың «И Габдулла — Апуш» шигыре исә традицион алымнарга таянып иҗат ителә. Шул рәвешле, журналның 2014 елгы саннарында дөнья күргән багышлаулар, нигездә, таныш, билгеле мотивларга корылса да, яңа алымнарга да мөрәҗәгать итә, форма ягыннан төрле булуларын да билгеләп үтми мөмкин түгел.

Романтик юнәлешкә мөнәсәбәтле шигъри әсәрләр, нигездә, яшәеш кануннарын аерып чыгарып, яшәеш кыйммәтләрен аңлау-анализлауга йөз тота, фәлсәфи гомумиләштерүләр ясау омтылышы көчле. Кагыйдә буларак, романтик әсәрләрдә мәхәббәт темасы әйдәп бара, журналның быелгы саннарында басылган шигъри әсәрләр дә моннан чыгарылма түгел. Бу юнәлештәге шигырьләр жанр хасиятләре ягыннан күңел лирикасын үз итә.

Р.Низаминың «Күперләр», «Төнге яңгыр», Х.Камаловның «Парча», Г.Рәхимнең «Менә шундый хәл», «Боз сөңге», Р.Фәйзуллинның «Баскыч төбендә утырам...», Н.Сафинаның «Шундый халәт», Ф.Жамалетдинованың «Хыялда», «Кульяулыгым йөртәм», Р.Корбанның «Сөю киткәч», «Нидер кала» кебек шигырьләрендә, Л.Вәлиеванын «Яшәү — мәйдан...» шигырьләр бәйләмендә, «Казан утлары» журналының 3 нче санында дөнья күргән Г.Тукай, Р.Мингалим, Р.Гаташ, М.Әгъләмов, А.Хәлим, Р.Вәлиев, Р.Миңнуллин, М.Мирза, Г.Морат, Л.Шәех шигырьләрендә мәхәббәт кеше җанын җылытырлык көч буларак бәяләнә.

Аерым шигырьләр образлы сурәтлелек ягыннан үзенчәлекле кабул ителә,

традицион образларны өстәмә мәгънәләр белән баету яки яна образ-детальләр кертеп җибәрү романтик шигърияттәге поэтик эзләнүләрне раслый. Мәсәлән, Р.Фәйзуллинның «Күчмә утраулар» шигыре бу яктан кызыклы. Күчмә утрау / утрак җир каршылыгына корылган әсәрдә Аккошта, Кабанда булган утраулар образы метафора төсен ала. Шушы фонда тормыш, яшәү елгасында очраган күчмә утраулар мәхәббәт тарихлары булып тәгәлләшә. Гомер юлында кичерелгән мәхәббәт кеше күңелендә онытылмый, гомер буе саклана дигән фикер автор идеясе кебек яңгырый: *Бар ул андый утраулар / Аккошта, Кабанда да... / Әйтмибез генә, бар алар / Һәрберебезнең җанда.*

Э.Байназаровның «Без» шигырендә дә охшаш образлылык һәм мотив чагылыш таба. Гомумән, бу яшь шагыйрьнең иҗатында образлы сурәтнең көчле булуы күзгә ташлана, ул катлаулы, көтелмәгән янәшәлекләр ярата (мәсәлән, «Кечкенә мәгънәсезлек»), композицион алымнардан сирәк мөрәҗәгать итеп торган монтаж алымын отышлы куллана. Мәсәлән, «Мүкләнгән диварлар җылысын кызганды» шигырендә укучы тыгыз сурәтлелек белән очраша, мүкләнгән дивар, бәсләнгән ирен кебек эпитет-метафоралар мәхәббәтнең салкынлыгын җиткерү юлында файдаланыла: *...Мүкләнгән диварлар җылысын кызганды, / бәсләнгән иреннәр дәшмәде артыгын; / бер язга сыймады атасы таңнары, / бер таңы җитмәде әйтергә актыгын.*

Н.Сафинаның «Көзге уй» шигыре дә шундый эзләнүләр ягыннан кызыклы. Традицион көз / сагыш янәшәлеге белән беррәттән кулланылган яфрак / йөрәк, яфрак / көймә янәшәлекләре шул хакта сөйли. Мәхәббәттән аерылу лирик герой күңелендә сагыш хисен уятып, бер-берсен баетып килгән образ-детальләр, сары эпитетын кабатлау, сары яфрак кебек йөрәк, сары көймә кебек йөрәк, сары канатлы кош канатлары метафора-чагыштырулары шушы сагышны көчәйтү функциясен ала. Алар аша автор үз фикерен җиткерә: мәхәббәттән аерылу, алдану кешене мәңгелек сагышка сала һәм бу халәт кеше җанында даими хискә әверелә.

И.Иксанованың «Акъдингез көндәлеге» шигыре шагыйрә иҗатын тагын бер кат экзистенциаль мотивлар белән баета. Биредә ак дулкыннар, күчкән комнар, югалган эзләр, диңгез кебек экзистенциаль эчтәлекле традицион романтик образ-детальләрнең мәгънә көчеше кичерүен күрәбез. Гомер агышында кеше яшәешенең мәгънәсезлеген, эзсез югалуын җиткерүче образлар шигырь тукымасында мәхәббәтнең сафлыгын, аны җуюга бәйле сызлануны ачуга юнәлтелә. Шагыйрә мәхәббәтне ике кеше арасындагы хис-халәт баскычыннан кеше яшәешенең Мәңгелек мәгънәсе, кыйбласы югарылыгына күтәрә.

Г.Рәхимнең «Боз сөнге» шигырендә ут / боз сөнге янәшәлегенең мәхәббәт / нәфрәт көчешен җиткерүгә юнәлтелүе матур шигъри табыш булып тора. К.Булатованың «Һәр Мәҗнүннең үз Ләйләсе була» шигырендә традицион мәхәббәт символларына әверелгән Ләйлә—Мәҗнүн образларына мөрәҗәгать белән очрашабыз. М.Галиевның «Төштән — төшкә» шигырендә дә мәхәббәт темасын ачу барышында Сөю Таҗы, Илаһи наз кебек шәркый, суфичыл эчтәлекле романтик образларның янарышы уңышлы кабул ителә, тагын бер кат шагыйрьнең сүз остасы булуын дәлилли.

Аерым шигырьләр романтик материалда кешенең яшәеш кануннарын бәяләргә, яшәеш закончалыкларын аерып куярга омтыла. Мәсәлән, Ф.Мөслимованың «Мизгелләр елларга биргесез» шигырьләр бәйләмендә илаһи мәхәббәт кеше гомеренең төп кыйммәте, яшәү мәгънәсе, яшәештәге иң төп таяну ноктасы югарылыгында тәкъдим ителә: *Атама-анама таяндым, / Дусларга, балама, ярыма... / Аккан су шикелле барысы — / Соң барып җитте шул аңыма. / Ниһаять, мәңгелек Сөюгә / Күзләрем ачылды: яраттым! / Аһ, озак сынадың Син мине, / Ташлама, ярлыка, йа Раббым!*

Шундый ук мотив Г.Корбанованың «Тарихында нинди серләр бардыр...», «Май аеның садәлеге белән...», Р.Идиятуллинның «Таулар хакында ике шигырь», «Рәсүлуллаһ, алтын сүзгә төреп...» кебек шигырьләрендә дә урын ала.

И.Иксанованың узган елда басылган шигъри әсәрләре шагыйрә иҗатында фәлсәфилекнең көчәюе хакында хәбәр итә. «Арчада бер кичә», «Җай белән

хушлашу», «Минем җәем» кебек шигырьләре кеше гомеренең төрле мизгелләрен, халәтләрен ачуга юнәлтелә. Җәй / яшьлек янәшәлеге, әти-әниле балачакның, мәхәббәтле яшьлекнең үтүе мотивлары шигырьләрне бербөтенгә туплый һәм сагыш хисен уятучы сәбәпләр тәсен ала, буыннар алмашы, югалту һәм табышлар автор тарафыннан яшәешнең мәңгелек кануннары буларак билгеләп куела: *Күңеленә күчсен минем илем — / Мүкле күлем, урман, болыннар... / Күбәләкле җәйдә / Миннән соң да / Чакрып торсын аны бу юллар! / ...Хатирәләр тулы җәйдә йөрим / Кызым белән. / Хисләр ташыган... / Хисләремә төреп мин кызыма / Яшел җәйләремне тапшырам.*

К.Булатованың «Гомер аты шундый тиз чапты...» шигырьләр бәйләменә тупланып бирелгән шигырьләрендә дә охшаш мотивлар белән очрашабыз.

Х.Мөдәррисованың «Хәтер тибә даш диварга» шигырьләр бәйләме шигъри материалда кеше фәлсәфәсен тәкъдим итә. Мәсәлән, «Вакыт һәм хәтер» шигырендә шушы юлда татар поэзиясе өчен традицион Вакыт образына мөрәҗәгать итеп, аны төрле мәгънә калыпларында уйнату алымы кулланыла. Аның аша автор Вакыт чикләрендә кеше гомеренең чикләнгәнлеген, мизгел булуын раслый. «Су белән күк», «Уй-каурыйны очлап алып...» шигырьләрендә исә циклик Вакыт образы әйләнешкә кертелеп, кеше гомеренең «мәхәббәтле» һәм «мәхәббәтсез» этапларын аерырга мөмкинлек бирә. Традицион төстә шигырьләр структурасында кеше гомеренең Вакыт кысаларында чикләнгәнлек мотивы янартыла. Р.Корбанның «Өч җыр» шигырендә дә җыр образы, бишек җыры, тормыш җыры, үлем җырына әверелеп, кеше гомеренең төрле этапларын аерып куя.

Поэзиядә фәлсәфилеккә омтылыш тенденциясе фәлсәфи эчтәлекле жанр формаларының яңарышына да тәэсир ясый. Мәсәлән, Р.Идиятуллинның «Тормыш» һәм Д.Гарифуллинның дүртьюллыклар бәйләме хикмәт һәм робагый жанрларына стилизация буларак кабул ителә.

Бу чор шигъриятенә хас сыйфатларның берсе буларак интеллектуаль тенденциягә хас алымнарның да кулланыла килүен әйтә алабыз. Мәсәлән, Р.Харисның күпкатламлы, күпмәгънәле метафорик-символик сурәтлелеккә корылган, укучының үзенә чишәргә калдырылган шигъри табышмакларны хәтерләткән, әзерлекле укучыга юнәлтелгән «Кара түгәрәк» шигыре бу яктан үзгә, интеллектуаль алымнар белән баетылып, укучыга тәкъдим ителә. Сәнгати чаралардан көтелмәгән борылышлар, катлаулы чагыштырулар, сынландыру, янәшә кую, бер күренешнең мәгънәсен икенчесеннән табу, өченчесе ярдәмендә ачу — Р.Харисның лирик фикерләү үзенчәлеге — бу шигырьдә дә актуаль булып кала.

«Кара түгәрәк» шигырендә Малевичның «Кара квадрат»ындагы сурәтлелек шигъри метафора ролен башкарып, кара, яшел, сары һәм ал сызыклар яшәешне, кеше тормышындагы аерым мизгелләрне бәяләү югарылыгына күтәрелә. Кара / чиксезлек янәшәлеге аша автор мәңгелекне тәгълләштерә, мәңгелек / фани каршылыгының чиген акыл билгели: *...һәм янадан каралыкка бата... / Аргы ягы аның — Чиксезлек!.. / Чиксезлекнең бу ягында тота / Акыл билгеләгән чик безне...*

Шагыйрь фикеренчә, кеше яшәеш дәвамында мәңгелектән килеп, өзлексез төстә акыл белән танып-белеп булмый торган мәңгелеккә омтыла, шушы омтылыш кеше тормышында түгәрәкне хасил итә. Традицион поэтик эзләнүләр белән янәшәдә журнал битләрендә әзерлекле укучыга юнәлтелгән, катлаулы метафорага корылган мондый шигырьләрне ешрак күрәсе килә.

«Казан утлары» журналының 20104 елгы саннарында поэмаларның үтә аз санда булуы сагайта. Бу күренеш татар поэзиясендә поэма жанрының кризис кичерүе хакында хәбәр итмиме?! Әллә алар журнал битләренә тәкъдим ителмиме? Әбит поэма жанры һәм, гомумән, күләмле жанрлар үсеше поэзия күтәрелешен дәлилләүче күренешләрнең берсе буларак билгеләнә. Еш әйтелгән фикерне тагын ассызыклап кабатлыйсы килә: татар поэмасы XX гасырның икенче яртысындагы күтәрелешен, поэзия мәйданына С.Хәким, И.Юзеев, Р.Әхмәтҗанов, М.Әгъләмов һ.б. кебек поэма осталары килүен көтә.

Әлбәттә, күләме ягыннан чикләнгән бер мәкалә кысаларында гына бер ел

дәвамында басылган барлык шигъри әсәрләргә җентекле бәя бирү, һәрберсенең шагыйрь иҗатындагы һәм, гомумән, татар поэзиясендәге урынын билгеләп, тәгаенләп кую мөмкин түгел. Йомгаклап әйткәндә, «Казан утлары» журналының 2014 елгы саннарында басылган шигъри әсәрләр хәзерге шигъриятгәге, әдәби барыштагы күп кенә тенденцияләрне чагылдыра. Традицион образлылык, мона кадәр даими мөрәҗәгать ителгән мотивларның, алымнарның, сәнгати чараларның кулланылышы шигърияттә традиционлыкның көчле булуын ассызыклый. Бер үк вакытта әдәбиятта эзләнүләр барганлыгы да сизелеп тора. Традицион образларны яңа мәгънә калыплары белән баету, XX йөз башы татар поэзиясендә кулланылып, даими барыштан читтәрәк калган алымнарны, образларны яңартып җибәрү, форма эзләнүләре шул хакта сөйли. Журнал битләрендә төрле буын шагыйрь-шагыйрәләрнең иҗат җимешләре белән таныштырып бару да матур күренеш буларак бәяләнүгә лаек. Быел сан ягыннан күбрәк авторларның иҗаты урнаштырылу да күзгә ташлана. Хатын-кыз шагыйрәләр иҗатына да шактый урын бирелгәнлеген билгеләп үтәргә кирәк.

Шуның белән янәшәдә шигъри әсәрләр татар поэзиясендә аерым күренешләрне, «минусларны» аермачык күрергә, тоярга да мөмкинлек бирә. Бер яктан, яңа алым, яңа агымнарга йөз тотып язылган, үзгә әдәби концепциягә таянган әсәрләр аз, дөнья әдәбияты югарылыгында эзләнү җитми. Дөнья әдәбияты постмодернистик үсеш юлына кергән мәлдә безнең поэзиядә андый экспериментлар булса, уңышлы булыр иде. Мин һич кенә дә татар поэзиясенең традицион үсешенә каршы килмим, мең еллар буена калыплашкан сыйфатлардан йөз чөерүне максат итеп куймыйм, әмма әдәбиятта төрлелек булу соралып тора.

Икенчедән, татар поэзиясенә «поэтик ыргылыш», «шартлау» җитми кебек тоела. 1960 елларда Р.Фәйзуллин, Р.Харис, Г.Рәхим, Р.Гаташ һ.б. шагыйрьләр поэтик борылыш, «шартлау» ясый, татар поэзиясен форма һәм эчтәлек ягыннан баету, яңарту омтылышы белән яна бит. Бүген поэзиягә килгән яшь буында ниндидер әдәби сүлпәнлек, иҗади кризис сизелә, аларның журнал битләрендә басылган әсәрләреннән чыгып караганда да, иҗади эзләнүләр, поэтик экспериментлар ясап карау хасиятенең җитеп бетмәве күренә. Яшь буын шагыйрьләрнең күбесе традиционлыкка йөз тота, ә яңалык, иң беренче чиратта, поэзиядә үз сүзен әйтеп, калыплашкан шагыйрьләрдән бигрәк, яшь буыннан көтелә. Ә бит андый эзләнүләр дә юк түгел! Әмма журнал битләрендә никтер алар чагылыш тапмый кала. «Казан утлары»нда бәлки яңа алымнар, агымнарга таянып язылган әсәрләрне бастыру мәйданын булдыру кирәктер, шушы юнәлештә берәр рубрика эшләнгәндә дә зыян итмәс иде кебек. Иң яхшы үрнәкләрне генә тәкъдим итеп барганда, бу һич кенә дә «Идел»не кабатлау булмас иде.

Өченчедән, «Шигъри хәтер» рубрикасында күбрәк шигъри үрнәкләр күрәсе килә. Мәсәлән, быелгы саннарда Н.Акмал, Д.Сирай шигырьләре уңышлы кабул ителә. Һәр санда бер авторның ике-өч шигыре генә басылып барса да, уңышлы булыр иде, алар бит татар поэзиясенең тутыкмас җәүһәрләре!

**Нурфия ЮСУПОВА,**
*филология фәннәре кандидаты,*
*КФУ доценты*

# КАЛӘМ ҖИЛЕ

## Роберт Әхмәтҗановның туууна 80 ел



Шигырь язучылар, шөкер, күп. Шагыйрьләр санаулы гына. Шуларның берсе — Роберт Әхмәтҗанов. Кызганыч, аның иҗаты үзе исән чагында ук беркадәр үгисетелгән. Сәбәбе — яраклаша белмәгән холкы гына түгелдер, түрә булып тормаган һәм беркайчан да узгынчы дәрәҗәләргә кызыкмаган яисә үзеннән мескенрәк хәлдәге бәндәләргә тәлинкә тотмаганга күрәдер. «Төркем-төркем булып йөрүчеләр бер-берсен күтәрделәр, ә мин аз аралашучан идем. Мондый сыйфатым белән бер яктан оттым, икенче яктан оттырдым. Ләкин мин үзем булып калуым белән бәхетлемен», — ди иде шагыйрь.

«Казан утлары» журналы редакциясеннән шушы мәкаләне язарга тәкъдим иткәч, мин, Роберт Әхмәтҗанов иҗатын яхшы ук беләм дип йөрүче берәү, аның китапларын, иҗаты турында язылганнарны кабат күздән кичереп, «Америка ача» алмавымны тәмам аңлагач кына, кулыма каләм алдым. Уртак якларны эзләргә тырыштым. Әтисез калган балачак (кемдер шуның өчен безне битәрләмәкче), иҗатка иртә тартылу, холыкта — алда әйтелгән «көтүгә ияреп» йөрмәү яки, урыс әйтмешли, «ак карга»лык, өстәвенә икебез бер яшьтә (30да) Язучылар союзына кабул ителгәнбез икән. «Атказанган» исемен ул миннән 5-6 ел соңрак алган... Боларны санаган булып, мин һич тә үземне аның янәшәсенә куярга уйламыйм. Роберт абыйның «бераз» соңга калып алган (минем дә бу эшкә өлеш кертүемне искә алып сөенәм) Тукай бүләге бар! «Барысының да Тукай буласы килә, тик берәү дә 27 яшьтә үләргә риза түгел», — диләр бит...

Тик шуны гына искә төшерим: дәүләтебезнең Г.Тукай исемендәге мәртәбәле бүләгенә дә — «Тургай тәрәзәсе» *(Татар. кит. нәшр., 1995)* һәм «Кечкә кошлар» *(«Мәгариф» нәшр., 1999)* китаплары өчен — 2001 елда гына, чордашларыннан, энекәшләреннән бик күпкә соңга калып иреште ул. Турысын әйтик: хәтта шәкертләре, терсәкләре белән этә-төртә, аннан алдарак лауреат булырга тырышып карадылар...

Һәм ни күрәбез? Чын талантны мөтәшагыйрьләрдән аера белгән, әдәби тәнкыйтьтә ат уйнаткан затлардан Нил Юзиев, Дания Заһидуллина, Равил Рахмани, Рифә Рахман яисә Сибгат Хәким, Айдар Хәлим, Рәмис Аймәт кебек өлкән һәм яшь каләмдәшләре генә, Рәис Даутов, Миргазиян Юныстай башка жанрларда иҗат итеп тә, күңелендә «шигырь уты сау» булган әдипләр генә аның чын бәһасен беләләр, аңлыйлар. «Роберт ялгыз йөри, әмма үз бәясен белеп йөри», — дип әйтә иде Сибгат ага. Ә менә 6 томлы «Татар әдәбияты тарихы»нда да XX гасыр ахыры шигъриятенә багышланган 40 биттән артык текстта *(6 нчы том, 2001)* бу гаҗәеп иҗат әһеленең исеме «һ.б.»лар арасында (кайбер исемнәр, мәсәлән, миңа таныш та түгел) дүртме, бишме тапкыр атап кына узыла. Шаять, ул зур хезмәтнең 8 том булып әзерләнә торган яңа басмасында мондый тар күңеллелек тамыр җәя алмас дигән өметтәбез. Бу иҗат турында әтрафлы, үзенә лаеклы тирән гыйльми хезмәтләр дә язылыр, килер әле ул көн, килер!

*Яңгырларда кечкә кошлар кайта,*
*кечкә кошлар –*
*бу тормышка сабый чактан*
*җыелган сорауларым...*

Шагыйрьнең генә түгел, чорның йөрәк тибеше язылган «кардиограмма» түгелмени бу?!

Дулкын өстенә дулкын булып килүче «кечке кошлар»да — чор сулышы, чор тавышы, кул сузымыдай озын сызык белән ул күзгә төшеп торган энгерне сөртеп ала сыман. Шагыйрь гади күренешнең катлаулы табигатен тоя, катмарлы чынбарлыкның гади хакыйкатен ача. (Бу юллар унаеннан мин моннан 32 ел элек фикеремне белдереп язганмын икән. Сүз унаенда әйтеп китим: студент чактан ук таныш булсак та, ул кадәр аралашып яшәгән кешем түгел иде Роберт абый. Шулай да, Татарстан китап нәшриятында баш редактор вазифасын үтәгән чагымда аның «Җәяүле күбәләк», ә инде «Мәгариф» нәшриятын җитәкләгәндә — алда телгә алынган, йөрәк кадәрле генә шигырь китабын һәм «Каләм җиле» дип исемләнгән, әдәби портретлар, тәнкыйди-публицистик язмалар, истәлек-хатирәләр тупланган берләнбер җыентыгын чыгару мөмкинлегем булды. Шулчак егерме ел элек язылган һәм «Казан утлары»нда дөнья күргән кайсыдыр мәкаләмнең «Хәтер җиле» дигән исеме искә төшкән иде...) «Каләм җиле» китабы аның, өлкән һәм яшь каләмдәшләренең уңышларына куану белән бергә, «китапларны хәзер талантлар түгел, байлар бастыра, шигырь базарын ак чырайлы үргән бәрәнге кебек китаплар басып китте» дип ачынуын да сыйдырган иде.

Инде, юбилей мөнәсәбәте белән, Роберт Габделвәли (китапларда — Вәли) улы Әхмәтҗановның тормыш һәм иҗат юлын да кыскача искә төшереп үтик. Татар әдәбиятына байтак күренекле әдипләр биргән Балык Бистәсе төбәгенең Күгәрчен авылында (гаҗәеп, ул аның бер тәрҗемәи хәлендә дә телгә алынмый) 1935 елның 1 апрелендә дөньяга аваз салган (райком секретаре малае!), ә гомер елгасының башы, балачак башкаласы — әнисенең (ул аның Гомәр Бәшировның «Намус» романындагы Нәфисә прототибы булуына ышана, шуңа анык дәлилләре бар кебек иде) туган авылы Иске Арыш. Сабыйлык, яшүсмерлек еллары узган әлеге авыл «...Арышым, Син минем Парижым!» дип күп еллар үткәч тә искә алырлык хәтер җөйләре калдырган... Беренче шигырен алты яшендә үк Алим таулары, Мирәт басулары, Тәрбели буйлары «әйтеп торып» яздыруын сөйли иде. Педагогия институтының 2 нче курсында укыганда, «Беренче яз» исемле тәүге мәҗмугасын кулына алган. Бу инде урыс шигъри дөньясында Евгений Евтушенко, Андрей Вознесенскийлар мәйданны шаулата башлаган чор. Шуннан соң җәмгысе егермеләп китабы дөнья күргән. Ярты гасырлык иҗат гомере өчен күп тә түгел шикелле. Тик аларның һәркайсы таза чикләвек төшедәй нык, ару һәм кабатланмас тәмгә ия. (Әлбәттә, ана, алда әйтелгән сәбәп һәм сылтаулар аркасында, күптомлыклар бастыру форсаты чыкмый. Ышанам, якын киләчәктә буыннар алышынып, затлы шигъриятне «кибәк»тән аера белүчеләр килер һәм бу гаделлек тә торгызылыр.)

Роберт Әхмәтҗановның иҗат йөзе турында сөйләгәндә, аның поэмалары турында («Таш аргамак» һ.б.), шулай ук балладалар остасы («Гармун турында баллада», «Таш елады» һ.б.), халык күңеленә кергән мәгънәле, моңлы җырлар авторы («Якты елга», «Солдатлар», «Саумы, Кояш!», «Синең эзләр», «Кояшларын белән кил син мина»...) икәнлеген әйтми калмыйлар. «Таш аргамак» белән яшьләр газетасы оештырган әдәби ярышта беренче урынны алгач, агайлар ул әсәрне татар шигърияте кануннарына туры килмәүдә гаепләп, өлкә комитетына ук барып җиткәннәр. Газетада игълан ителсә дә, премиясе бирелми калган. «Шушы вакыйгадан соң мин остазларымның йөзендә кояш тотылганын күрдем», — дигән иде шагыйрь «Шәһри Казан» (2001) газетасында Рәмис Аймәт оештырган әңгәмәдә.

Заманында без чыгарган «Балачак әдипләре» китабында *(«Мәгариф» нәшрияты, 2000)* әлеге басма өчен махсус язып, сабый чакларын искә төшереп, «Кайда соң сез, балачак торналары? Кайтыгыз...» дип өзгәләнгән иде ул. Гомумән, Роберт Әхмәтҗанов иҗатында «шуышып йөрүчеләр»не таба алмассыз. Анда барысы да канатлы — кошлар, күбәләкләр (хәтта «җәяүле» булганнары да) һәм болытлар гына түгел... Үземә фикердәш итеп, Миргазиян ага Юнысны чакырам, аңардан узып сүз әйтмәс өчен, «Альбатрос язмышы» дигән мәкаләсеннән (1999) шактый зур өзек китерергә рөхсәт сорыйм: «Роберт Әхмәтҗанның кошлар дөньясына мөрәҗәгать итүе, минемчә, очраклы хәл түгел, — дип язган иде ул. — Чын-чыннан күзәтүчәнлекнең иң югары ноктасына ирешкән шагыйрь генә аңлый булса кирәк кошларның безгә, бигрәк тә татарларга, үрнәк, акыл бирерлек җан ияләре икәнлеген... Кошларның көзен җылы якка, язын кире туган якларына

кайтып йөрүләре татарның гасырлар буе бәхет эзләп йөрүен хәтерләтмимени?.. «Кичке кошлар»ның һәм, гомумән, шагыйрь иҗатының кошлар дөньясы белән даими элемтәдә хәрәкәт итүе татарда ирекккә омтылу хисләренең уяна башлавы белән бәйле». (Бу инде синә, абзый, 40 биттә дүрт юл урын таба алмавыңның да серен ачып бирә! Якташы, каләмдәше Равил ага Фәйзуллин әйткәнчә, бездә шигырь — «башлар себер китәрлек», бары тик фәһемләп укый белергә генә кирәк.) Шагыйрьнең образ-метафоралар яңалыгы, форма-калып үзенчәлеге, иҗатындагы публицистик егәр... — болар хакында яздылар һәм язарлар әле. Әлегә Дания ханым Заһидуллинаның Татарстан Фәннәр академиясенең «Фәнни Татарстан» журналында басылган «Роберт Әхмәтҗанов иҗаты: абстракт образлылык» дигән өр-яңа хезмәтен укырга тәкъдим итәм.

Кыскасы, Роберт Әхмәтҗанов иҗатының тамырлары тирән, офыклары киң, күкләре биек «...иде» дип әйтәсем килми, чөнки ул шигырьләр, поэмалар, балладалар һәм җырлар әле дә булса яңа буын укучыларын әсәрләндерә, күңелләрне биләп яшәвен дәвам итә. Мондый бәхет теләсә кемгә тәтеми!

**Мөдәррис ВӘЛИЕВ**

# Роберт Әхмәтҗанов

## Шигырь иле

Сүзеңне сал вакыт арасына, —
иркен итеп алсын ул тынын...
Аккан су да сиңа: «бер!» дигәндә,
ике тапкыр какмый дулкынын!

Каләмең дә канатланган сыман,
шигырендә һәр сүз суласа!..
Сүзләр елый, алар тончыгалар,
вакыт аралыгы булмаса...

Тезелеп калсын иҗат түтәлләрең,
Чәчәкләнсен Шигырь илендә!
Затлы орлык сыман сикереп төшәр
тере сүзләр булсын телендә!

Ак кәгазьгә төшеп, йөгереп китсен,
Зур иҗатка илтсен эзләре.
Бер җөмләдә килеп очрашсыннар
«Сөям!» белән «сине» сүзләре...

Һава калдыр, сулыш калдыр сүзгә, —
тылсым уты янсын шигырьдә!
Мәхәббәтең сал да шул юлларга,
һич чыкмаслык итеп сихерлә!..

Вакыт-вакыт рухың килеп чыкса,
галәмнәрдән килгән авазга,
ал син аны, шагыйрь, йөрәк тавышың
язылып калсын
ап-ак кәгазьгә!..

## Илгә кайту

...Кайту уңаена, сагынудан
Йөзне куеп янгыр жиленә,
Егылырмын әрекмәннәр төбенә,
кырмыскалар, бөҗәк иленә...

Һәм... тормам да шуннан. Жирне кочып,
Ябынып өскә үлән юрганын,
тынлап ятармын мин
безнең якта
«тропик янгыр» шаулап койганын!..

Танавынны ера әрем исе:
«Күзенне ач, абый, тормышка!..»
Берни булмагандай, кулым буйлап,
йөк күтәреп кайта
Кырмыска!..

Тоныкланган күкрәү авазларын
ишетермен әле беравык...
һәм...
Сикерермен чиксез галәмгә мин,
десант кебек,
йолдыз нурларына
уралып....

Төнге күктә
Сүнгән үз йолдызым
Күренеп торыр бераз,
моңланып...

## Яңа елда

***(китүләр турында)***

Искә алдым барча дус-ишләрне,
киткән шагыйрьләрне — берочтан...
Һәркайсына бер жыр адарынсам,
чыгармынмы изге бурычтан?..

Аларны мин инде күз алдымнан
берәм-берәм тезеп үткәрәм.
Алар ядкаренә, дога итеп,
Моңлы шигырем, сине күтәрәм!..

Алар инде үтте... Дөнья иркен, —
киләселәр әле килерләр.
Тик... киткәннәр кайтмый. Алар белән
китте минем асыл шигырьләр!

Китеп барды гүзәл тойгыларым, —
аларны мин шактый озаткан...
Тик аларсыз ялгыз бер атауда
торып калдым кебек азактан...

Мөлдерәмә күнелем бушатырга,
елатырлык хискә сусадым...
Шигъри чакмам китте кайсыгызда, —
дөрләп янмый шигъри учагым?

Иске ел да китә үз юлына, —
ярамый да бит ул китмичә:
кемнәр китсә, кемнен киләсе бар,
игелек иктенме син, буш сүзләрме, —
беркем әйтмәс, үзең китмичә...

Бусагадан аяк сөртеп кердек, —
иске елны, имеш, калдырып...
Янасында кемне ниләр көтә,
ни көтәбез күзләр талдырып?
Баш очында
өмет йолдызларын яндырып...

## Төклетура

Әйдә, дускай, оч син, Төклетура,
җәй аркылы,
август болыннары буйлап оч,
солы кырларының зеңләгәнен,
әремнәрнең шавын тыңлап оч!

Сиңа ияреп,
үткәннәргә кайтам,
күкрәк куеп тыгыз җилләргә.
Синең белән бергә уйнап оча
безнең аваз — туган җирләрдә!

Безнең кырларны да читләп үтми
табигатьнең изге догасы...
Хәл белергә кергән Күбәләкнең
тәрәзәмдә яна укасы!..

Төклетурам,
бөҗәкләрнең басы, —
Сыйдыргансың — йөрәк алкышлый, —
туар заманнарның авазларын
узганнарга,
ерак ызаннарга
җырлый-җырлый
очып барышлый!

Болыныма җиткәч, ял итеп ал, —
ак чәчәккә кунып
тибрән бер!
Таң гөленә миннән сәлам җиткер,
тымык болыннарны җилләндер.

Минем өчен дә бер син оч шунда,
үләннәрем тагын билдәндер...
Озак көттек җәйне, ә кем белә, —
бу җәй безгә атап килгәндер?..
Яшьлек кырларыма кайт син, анда
Кояш алтын такыя кигәндер!

***Редакциядән:*** *шагыйрь үзе исән вакытта тапшырылып, басылмыйча калган шигырьләр.*



Рамил
Вәлиев

# ҖАННЫ АЙКЫЙ САГЫШ БУРАНЫ

## Язмыш

Бу дөньяга аваз салганчы ук,
Язмыш кара күлмәк кидергән.
Һәм әйткәндер: киләчәктә әле,
Аһ, мин моның башын идерәм.

Тәүге тапкыр тавыш бирү белән,
Кара җәймә җәйгән алдыма.
Изүемнән кысып тоткан да ул,
Алып килгән кыя янына.

Шул чагында кояш сүнәр иде,
Булсам мин бер адым атлаган.
Сабый күнеле бит ул керсез, диләр,
Гөнаһсызны Ходай саклаган.

Язмыш, башка мине сынама син,
(Күпме кыенлыклар күтәрдем).
Кайгылардан һич иелмәс башым,
Мин аларны гөлләр итәрмен.

## Сабыйга

Кардан да ак биләү әзерләгән,
Сабый, әнкәң сине төрергә.
Гомер буйларыңа җитәр булып,
Шушы аклык күчсен күңеленә.
Бүгеннән үк нурга тулсын жанын,
Явызлыкка урын калмасын.
Син бит, бары игелек кылып кына,
Яшәү өчен хокук алгансың.

Рамил ВӘЛИЕВ — *яшь шагыйрь; шигырьләре көндәлек матбугатта даими басылып килә. Актаныш районында яши.*

## Кол

Мәхәббәттән гел чыңгылдый
Күңел кылы.
Гомер буе кеше шушы
Көйнең колы.

## Ялвару

Кызганмачы, Ходай, бәхетләрдән
Өлеш чыгарырга миңа да.
Тузан кадәр генә булса да ул,
Елмаюым житәр дөньяга.

## Нигә?

Язмыш, язмыш, алларыма минем
Элдең дә бер буй житмәслек алма...
Ачы итеп көлә-көлә үзең:
— Мә, ал, — дидең, — син өлешсез калма.

Бигрәкләр дә ачы шаярасың,
Кеше өлешенә ымсытып.
Нигә соң, гөнаһлы бәхеттән
Мин дучар яшәргә ут йотып?!

## Аңладым

Тәкъдиремә язган: гомеремдә
Бер яр сөеп карый алмадым.
Андыйларга, яшәү — тәмугъ икән,
Үлем — оҗмах, —
Шуны аңладым.

## Үкенеч

Ана белән бала. Ерак ара,
Жылы хатлар гына йөриләр.
Тик күңел янәшә, бер-берсенә
Әзер алар жанын бирергә.

Үзәк өзде беркөн шомлы хәбәр:
Тизрәк кайт, ашык, бәбкәем.
Кояш сүнә, балам, безнең өчен, —
Соң сәгатен яши әнкәең.

Соңгы мизгел. Ана күңеленнән
Балаларын сөеп ятадыр.
Көчкә сулыш алып, сорау бирә:
Газиз улым кая, кайтамы?

Әйтерсең лә бүген дөнья бетә,
Жанны айкый сагыш бураны.
Бөтен туган, бер баланы көтеп,
Тәрәз аша күзли урамны.

Гүр ишеген ачкан килеш ана
Иң якынын көтә ерактан.
Сөен, әнкәй, әнә, ашыга-ашыга
Жанкисәгең атлый сукмактан.

Килеп життем, әни, яннарыңа,
Тик берничә адым арасы.
...Күралмады ана бәгырькәен,
Кулсузымда калды баласы.

Әй, гомеркәй, канатлы кош кебек,
Бер мизгелдә үттең син очып.
Әнкәемне соңгы тапкыр хәтта
Үбәлмичә калдым мин, кочып.

# СЕЗНЕҢ ЯЗМЫШ СУГЫШ УТЫ БЕЛӘН ҮРЕЛГӘН

**Абдулла Әхмәт**
*(Әхмәтов Абдулла Сафиулла улы)*
*(1905–1976)*



Язучы-прозаик һәм драматург. 1905 елның 25 мартында Курган өлкәсенең Притобольный районы Звериноголовск авылында урта хәлле крестьян гаиләсендә туа. 1922-1923 елларда — Чиләбе өлкәсенең Олы Солтан авылындагы ятим балалар йортында тәрбияче, 1925 елда совет-партия мәктәбен тәмамлаганнан соң, Свердловск шәһәрендәге «Сабан һәм чүкеч» газетасында әдәби хезмәткәр булып эшли.

1932 елда Казанга килә һәм Казан дәүләт педагогия институтына укырга керә. Институтны тәмамлагач, «Совет әдәбияты» журналы редакциясендә әдәби хезмәткәр, аннары Казан химия-технология техникумында һәм музыка мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты укытучысы булып эшли.

Бөек Ватан сугышы башлангач, фронтка китә, ике ел буе алгы сызыкта гади солдат булып хезмәт итә. Яраланып, госпитальдән дәваланып чыккач, янадан алгы сызыкка кайта. 1943 елның 15 мартыннан сугышның ахырына кадәр «Алга, дошман өстенә!» исемле башта — Калинин, соңыннан Беренче Балтыйк буе фронт газетасында хәрби корреспондент буларак, Польша, Германия туфракларын таптый. Фашистлар Германиясе тар-мар ителгәч, редакция белән Кытай — Маньчжурия җирләренә барып чыга, анда «Суворовча кысрыклау» исемле Байкал арты фронт газетасында хәрби корреспондент булып хезмәт итә. Фронттагы сугышчан хезмәтләре өчен А.Әхмәт Кызыл Йолдыз ордены һәм медальләр белән бүләкләнә.

1946 елда армиядән кайткач, ул башта Татарстан китап нәшриятында яшьләр-балалар әдәбияты редакциясе мөдире, аннары 1952-1955 елларда «Пионер» журналының җаваплы мөхәррире булып эшли.

Абдулла Әхмәт 1976 елның 28 октябрендә Казанда вафат була.

**Язучыларга**

*Каләмдәшләр!*

*Сезгә канлы фронтларда сугышып чыккан А.Әхмәттән сәлам. Ржев өчен барган бәрелештә катнашып, җиңел яралы булып чыктым һәм хәзер Калинин шәһәре янындагы госпитальдә ятам. Күп ятарга туры килмәс, янадан кулга винтовка алырга туры килер. Фронт миндә бик нык тәэсир калдырды һәм бик күп кыйммәтле материаллар бирде. Алла, исән калсам, рәткә салыр идем, дип торам.*

*Сәламләп, А.Әхмәт.*
*17 август, 1942 ел*

Кире кайту адресы: Калининская обл., п/о Черногубово, ящик 5.

**Тажи Гыйззәткә**

*Тажи абзый!*

*Сезгә һәм каләмдәшләргә кайнар сәлам. Үзем җәрәхәт төзәлгәч, янадан фронтка килдем. Госпитальдә ятканда, вакыт барында, «Безнең танк» (аны радиодан берничә тапкыр биргәннәр икән) һәм «Күзәтче Мостафа» исемле ике хикәя һәм «Көтү минутлары» исемле 2 пәрдәлек пьеса җибәргән идем. Хәзер темалар күп, тик вакыт юк. Алай да кыска хикәяләр язып җибәрергә дип җиң сызганып торам. Хатыгызны алдым, ул бик өметләндерде, онытмагыз инде.*

*Мина партиягә керү өчен характеристика җибәрсәгез иде.*

*Көндәлек өчен блокнот, конверт җибәрә алмассызмы?*

Хат кыр почтасы штемпеле буенча 26.11.1942 елда язылган. Кире кайту адресы: Полевая почта 341, часть 502. Ахметов А.С.

***

*Тажи абзый!*

*Сугышчан сәлам! Ниһаять, карт капитанны кайтарабыз, аннан соң, бәлки, бәндәнез-карт солдатка да кайту эләкмәсме? Зур әсәрләр өстендә утыруыгызны ишетеп, мәмнүн булдым. Үзем «Ил балалары» исемле 3 пәрдә, 5 күренештә балалар өчен пьеса язып бетердем. Шомартып бетергәч, җибәрермен. Академия балалар пьесасын куймас микән? Семьяма иткән ярдәмнәрегез өчен рәхмәт.*

*Кулыгызны кысып, А.Әхмәт.*
*27 сентябрь, 1943 ел*

**Хәмит Ярмигә**

*Ярми, дус!*

*Хатынны алдым, ул бик шатлык китерде, югыйсә, мин инде Ярми онытты мы дип уйлый башлаган идем...*

*Сезнең исән-сау булып, гөрләтеп яшәп, эшләвегезне белгәч, чын йөрәктән шатландым. Ил нинди генә авырлыклар кичермәсен, безнең гыйльми эшләргә дошман зарар китерә, аны туктата алмас!*

*Агишка, Хәйригә, Халитка һәм башка мине сораган иптәшләргә сәламемне белдер. Мине кайгыртып йөрүең өчен рәхмәт. Маннурның, Хатыйпның адресын җибәрә алсаң, шәп булыр инде. Билгеле, газиттә эшләсәм, мин илгә зуррак, күбрәк файда китерер идем. Язучы өчен кирәк булган илһам да, материал да күбрәк булыр иде анда. Хәзер мине, сәламәтлегемнең шәп булмавы (нестроевой) аркасында, икенче тапкыр фронтка барганда, фронттан ерак булмаган бер җирдә, бер санбатта эшкә алып калдылар...*

*Хәмит! Мин, ниһаять, үземнең партиялелегемне оформить итәргә булдым. Сугышта, һөҗүм алдыннан партиягә бер алынган булсам да, анда, һөҗүмнән соң мин җәрәхәтләнеп, частемнән аерылдым. Ярми, бу хатны алу белән тизрәк рекомендация (тиешле тапсаң) җибәрсәң иде. Газиздән дә сорадым. Институтның кайбер эшләре турында да язсаң иде. «Фольклор» чыкмадымы? Хатын белән балаларына сәлам.*

*Дустың Абдулла Әхмәт.*
*29 декабрь, 1942 ел*

***

*Ярми дус!*

*Синең хатынны һәм рекомендацияңне күптән алган булсам да, хат язмый торуымның сәбәбе – хатыңда Минзәләгә китәм дигән иде. Инде кайткансыңдыр дип уйлап, хат язырга булдым.*

*Без[1] исән-саулар. Газета чыгарабыз. Мин корректор штатында, шуннан башка штат юк. Ә эш бар, житәрлек. Тәржемә дә итәм, секретарьлык эшен дә алып барам, ижат та итәм. Хуҗаның хәрби вакыт мәзәкләрен дә биргәлим. Казандагы радиодан биргәннәр икән, журналга керә дип язганнар. «Ил балалары» исемле балалар сәхнәсе өчен 3 пәрдә, 5 күренештә бер пьеса яздым, биредә укыдым, төзәтеп, эшләп бетердем. Тиздән җибәрермен.*

*Их Ярмуш, без Маннур белән еш кына сине искә алабыз, сагынабыз... Син скрипкәңне ияк астына кыстырып, смычокны аркылыга сузып җибәрүгә, мин ун бармакны берьюлы рояль клавишаларына басып «Баламишкин»ны уйнап җибәргән чаклар хәтергә килә, колак төбендә шул вакыттагы музыка яңгырый...*

*Ләкин ни өчендер, мин сине хәзер элеккеге шат, шаян, уенчак түгелдер дип күз алдыма китерәм дә, үзем дә әллә нишләп китәм... Ни өчендер сине мин хәзер, дус кеше, зур, эре, бик житди кеше дип күз алдыма китерәм... Билгеле, минем сине элекке шат, уенчак жырчы да, музыкант та, дус та итеп күрәсем килә.*

*Юк, ни генә булмасын, без элеккеге дуслар булып калырбыз дип сөйләшеп алабыз хажи (капитан Шәйхелислам Маннур) белән.*

*Мин дә беркадәр үзгәрдем, дус. Мин хәзер азрак сөйлим, сирәгрәк көләм, сирәгрәк шаярам. Ә музыканы, жырны мин хәзер, шашып, үлеп яратам...*

*Ай, Сәйдәш концертында буласы иде!.. Ах, симфоник оркестрны тыңлыйсы иде!*

*Алишка, Хәйригә, Халитка, Жәләйгә һәм башка галимнәребезгә сугышчан сәлам. Өй эченә дуслык сәламе!*

*Хат көтеп, сине сагынган, бик-бик сөйләшәсе килгән дустын.*

*А.Әхмәт.*
*10 октябрь, 1943 ел*

***

*Кадерле дустым Хәмит!*

*Синең редакциядә чыккан зур «Тукай» минем янга исән-сау гына килеп житте. Үзем бик зур хөрмәт белән, буш вакытларда укый башладым. Татар теле, малай, сагындырган. Әгәр мөмкинлекләр булса, шундый яңалыкларны жибәреп торсагыз, мин, фәкыйрегез, бик мәсаллләм булыр идем. Син, егет, хат язмый башладың әле. Вакыт булганда язгала. Үземнең тормышта үзгәрешләр юк, искечә яшәп киләм әле. Хәзер 4нче часть начальнигы булып эшлим. Баламшин белән хәбәрләшеп торам. Якын арада үзенең наступлениегә китүе турында язган иде. Исән-сау гына башкарып чыгарга язсын инде. Ул Ленинград фронтында. Бала-чагаларыгызга миннән күптин-күп сәлам.*

*Жибәргән китабың өчен күп рәхмәтләр жибәрәм.*

*Сораган агай-энеләргә һәм дустларга күп сәлам.*

*Сәлам белән сагынып, Абдуллагыз.*
*27 февраль, 1944 ел*

***

*Хәмит яки Халит!*

*Менә Сезгә «Хужа Насретдин — фронтта» дигән кечкенә жыентык жибәрәм. Әгәр дә карт Хужаның бу йөрүләре тарихи әһәмияткә ия була торган булса, аларны бастырып чыгару чарасын күрерсез әле. Кереш сүзем ошамаса, яисә үзегез язуны тиешле тапсагыз (бу минем өчен яхшырак), үзегез язарсыз.*

*Инде бастырмау хәерлерәк булса, мин кайтканчы, институтта торсын иде... Ә без: «Исән булсак, бер кайтырбыз...»*

*Үзегездә ниләр бар?*

*25 еллыкка Институт нәрсәләр хәзерли? Язсагыз, без бик мәмнүн булыр идек һәм газетабызга да бирер идек.*

*Хуш иттек. Галимнәргә фронт сәламе.*

*Чуктин-чук сәлам белән, Әхмәт солдат — Хужа Насретдиннең урынбасары.*

*14 ноябрь, 1944 ел.*
*Литва — Леплявка*

***

*Хәмит дускай!*

*Хатыңны алдым, рәхмәт. Казан сагындыра, үзеңне күрәсем, туйганчы әңгәмә корасым килә, рәхәтләнеп нәкъ элеккечә якшәмбене үткәрәсе килә. Хатыңны укыганда, син бөтенләй күз алдында торасың, хәтта мин синең тавышыңны да ишеткән кебек.*

*Да, теге мәсьәләдә синнән ярдәм кирәк булачак. Бигрәк тә син, Ярмуш, институттан аны бетерүем турындагы язуны алып тизрәк жибәрсәң, шәп булыр иде. Ә техникумнан анда укытуым турында карчык алыр, ана язырмын мин. Институтны мин 1936 елда бетердем. Бирсәләр ярый инде... Хәтерендәдер, мин кичкене бетердем. Завуч Иван Иванович Назаров иде. Ул кайтмадымы? Ул безнең фронтта, МСТдә эшли иде.*

*Да, «Идегәй»[3] турында без, тулы булмаса да, ишеткән идек. Хәерле булсын инде. Тик шуны гына әйтәсем килә: әсәрләр язганчы һәм аның турыда шау-шу кузгатканчы, ЧК белән хәл кылып куясы калган икән. Алай дисәң, син ул мәсьәләдә Москвага баргаладың да бугай инде. Ярый, бу турыда кайткач аңлашырбыз. Нәкый[4] күтәреп чыккан нәрсә бит, ә???*

*Ярми, шушы көннәрдә генә мин институтка, синең һәм Хәмитнең исеменә «Хужа Насретдин — фронтта» дигән мәзәкләр жыентыгын жибәргән идем. Анда аның хаты да бар иде. Алдыгызмы икән? Андагы кайбер уңышлыларын теге сүз мастеры Фәйзигә биргәндә дә шәп булыр иде. Эстрадага куплетлары да бар аның.*

*Әй, егетләр, үтә дә соң гомерләр! Розаң[5] синең мед. институтта укый диген, ә!*

*Фимага[5] һәм ана, институт әһелләренә сәламемне тапшыр. Әйе, Ярми, хәзер сине чын мәгънәсе белән «Ярмуш карт» яисә «Габделхәмит хажи» дияргә була бит, ә?*

*Тормышында булган яналыкларыңны хәбәр итеп торырсың әле. Кемне куярлар икән институтка? Тагын нинди үзгәрешләр булыр?*

*Безнекеләргә булган ярдәмегез өчен чын күңелемнән рәхмәт.*

*Хуш, дус, тиздән каушыйк! Әхмәт солдат.*
*20 ноябрь, 1944 ел*

***

*Ярми дус!*

*Синең хатларны алу белән, дәрт өстенә дәрт ялгана, көч арта. Синең кебек ахирәт дустым булуына куанып бетә алмыйм. Ә бит бу соңгы елларда бик күп кешеләр дә, дуслар да, башкалар да бик нык сыналдылар. Минемчә, безнең дуслык сугыш елларында көчәйде генә.*

*Минем семьяны кайгыртуың өчен аерым рәхмәт сиңа. Бигрәк тә фатир мәсьәләсе хәл кылынса, шәп булыр иде. Югыйсә ул өйдә шундый матур, акыллы балаларның харап булулары бар. Юеш, салкын бит анда! Әйе, бу өлкәдәге эшенә дә зур уңышлар телим. Инде булмаса, үзем (исән-сау кайтырга туры килсә) кайткач, мин сөйләшә белермен алар белән...*

*Мәзәкләрне үзең ничек тиешле тапсаң, шулай чыгар. Бу хат белән тагын да берничәне җибәрәм. Булган берсен җибәрә торырмын. Билгеле, мин аларның кечкенә генә бер җыентык булып (рәсемләп) чыгуын артыграк күрер идем дә бит. Ярый инде.*

*Эшең матур баруына куандым. Фольклор сиңа инде ул 5 бармагың кебек таныш. Син ул мәсьәләдә судагы балык кебексең. Аның шулай булуы бик яхшы. Син бу өлкәдә үсәргә тиеш кеше. Ныклы, тирән хәзерләнеп татар фольклорының бер кызыклы, әһәмиятле темасы буенча диссертация язарсың әле. Минемчә, бу кирәк нәрсә һәм син аңа хәзерлән. Барып чыгачак ул.*

*Әйе, кайтып булса, синең белән бер фольклорлап алыр идек. Мин — рояльгә, син каз муеның сузар идең. Ә рояль өстендә теге нечкә билле, нәфис рюмкалар...*

*Маннурдан хат алмыйм мин. Әллә адресы башка, әллә башка сәбәп. Минем хатым җавапсыз калгач, башка язганым юк әле. Адресын җибәр әле миңа. Без хәзер алар ягына — Көнчыгыш Пруссиягә китеп барабыз. Юл озын. Яна җиргә барып җиткәч, тагын язармын әле. Дошманның өенә керәбез, тагын да ераграк китәбез. Хәер-фатыйхада тор.*

*Пьесалар конкурсына бер пьеса җибәргән идем. Аның буласын, булмасын белмим. Гадәттәгечә булса, башланыр да ташланыр инде ул. Шул турыда да яз әле, зинһар.*

*Халитка, Агишка һәм башка яшь галимнәргә сәлам.*

*Хуш, дускай, хуш! Дустың Әхмәт солдат.*

Бу хат датасыз булса да, аның 1945 елның апрелендә язылуы мәгълүм.

***

*Ярми дус!*

*Сине бөек Җиңү белән, дөньяда мисал булмаган шатлык белән котлыйм.*

*Әйе, ниһаять, Гитлер дигән аждаһа үзенең коточкыч оясы белән асты-өскә килде, чәнчелде. Европага азатлык кояшы нурын сибә башлады.*

*Мондый тантаналы көннәрне бергә булып булмады.*

*Хуш, дус.*

*Әхмәт солдат.*
*15 май, 1945 ел*

**Хәсән Хәйригә**

*Хәйри иптәш!*

*Күп сәлам. Каләмдәшләрнең башкаларына да сәлам. Мин хәзер Маннур, Шамовлар белән эшлим. Моннан соң язарга да мөмкинлек булачак. Күптән түгел командировкадан йөреп кайттым, күп кенә материал алып кайттым. «Өч дус» исемле очеркны Казанга да җибәрәм.*

*Минем бер үтенеч сезгә: миңа Маннур артыннан иҗат һәм гомумән характеристика җибәрсәгез икән. Аттестация алу өчен кирәк. Аннан Союз членлыгына справкам да*

*юк минем. Өченче мәсьәлә — фронтовик-язучыларга дип әзерләнгән әйберләрегез, әгәр миңа да тиешле булса, Маннур артыннан җибәрсәгез, шәп булыр иде. Менә бер үтенеч башлаганнан өч үтенечкә дә житте. Тажи абзыйга, Кашшафка, А.Гомәргә сәламемне житкерсәң иде.*

*Гаиләгә иткән ярдәмнәрегез өчен рәхмәт.*

*Сәламләп, А.Әхмәт.*
*29 май, 1943 ел.*
*К. авылы, Смоленск өлкәсе*

***

*Хәсән иптәш Хәйри!*

*Хатың һәм матур теләкләрең өчен рәхмәт. Үтенечемне башкаруың өчен тагын бер рәхмәт. Эш, билгеле, күп. Тәржемә дә, корректорлык та, секретарьлек тә һ.б., һ.б. да бар. Үзебезнең газетада да катнашмый ярамый. Монда мин дошманга каршы көрәшкә «мәрхүм» Хуҗа Насретдинне дә терелтеп худка җибәрдем. Балалар тормышыннан «Ана һәм бала» исемле пьеса өстендә утырам, бетерү белән җибәрермен. Әсәрдә, немецларга каршы көрәштә, безнең балаларның героик эше чагыла. «Солдат балалары» дигән хикәяне язып бетердем. Монда тыл һәм фронт бердәмлеге чагыла. Зур пьеса язу өчен дә материал җыюны дәвам иттерәм.*

*Агай-эне исән-сау. Алардан да сәлам. Күптән түгел Шәрәф Мөдәррис кереп чыкты, командировкага китеп бара икән. Газетабызны Союзга җибәреп торам, аласызмы? Караштырасызмы?*

*Сездә ниләр бар? Сирәк булса да, Шамов белән икебезгә бер генә булса да, хат җибәргәләсәгез, шәп булыр иде. Союзның эшен белеп торасыбыз килә.*

*Ярый, хәзергә хуш иттек, барлык язучыларга һәм Сүнчәләй кызына сәлам белән,*

*Абдулла Әхмәт.*
*21 июль, 1943 ел. Н. авылы*

*Хәсән! Шушы мәзәкне «Совет әдәбияты»на бирсәнче. Мин аларга җибәргән идем, шуларга өстәмә булыр.*

**Гази Кашшафка**

*Кәшшаф иптәш! Сәлам. Без исән һәм газеталар аркылы Сезнең дә исәнлегегезне ишетеп шатбыз. Моннан элек «Бер авылга кергәч...» исемле бер язма һәм Хуҗа Насретдин мәзәкләре җибәргән идем, шаять, алгансыздыр.*

*Бу хат белән «Солдат балалары»н җибәрәм һәм журналда балаларга урын бирерсез дип ышанам.*

*Тиздән фронтка китүемә 2 ел тула, сезгә берәр әсәр җибәргән саен хат язам. Әйберләремнең күбесе басылып киләләр, ансына рәхмәт. Ләкин Хуҗа Насретдин мәзәкләренең язмышын белмим. Билгеле, мин алар турында нинди дә булса берәр сүз ишетәсем килә. Бу турыда һәм башка кайбер мәсьәләләр турында бик күп хатлар язсам да, бер-ике авыз гына булса да сүз-җавап алу бәхетенә ирешә алмадым.*

*Әнәс тә җавап төргән кәгазьгә: тиздән хат язам, дигән иде. Хәер, аның бу сүзенә ай ярым гына тулды бугай...*

*Фатихка, Әнәскә дусларча сәлам. Журналны җибәреп торуыгыз бик матур гадәт. Бу гадәтне ташламасагыз иде.*

*Дуслык сәламе белән, А.Әхмәт.*
*20 ноябрь, 1943 ел.*
*Г. авылы*

***

*Хөрмәтле Газый! Өйдән хат алган саен, Союзның матур эшләре турында ишеткән саен, Сиңа рәхмәт укыйм. Минем «14» баланы онытмавың өчен дә, татар әдәбиятында шактый гына борылыш тудыруың өчен дә рәхмәт, солдат рәхмәте!*

*Мин язгалыйм, җибәргәлим. Балалар сәхнәсе өчен пьеса җибәргән идем. Язмышын белмим әле. Конкурс турында газета хроникасыннан гына беләдек. Шартларын тулы беләсе килә. Язачакмын. «Безнең танк»ның 2 ел буе чыкмавына эч поша, ачу килә. Татиздат планына нәрсә керү, нәрсә кермәвен дә белмим. [...] язып җибәргән идем.*

*Күптән түгел «партия члены» дип язылган билет алдым һәм йөрәгем янына салып куйдым.*

*Бик кайтасы килә дә, ни, ә рәте килми тора әле.*

*Хуш.*

*А.Әхмәт.*

Хат датасыз. Кыр почтасының штемпеле: 17.05.44.

**Мирсәй Әмиргә**

*Мирсәй!*

*Стандарт хатыгызны алдым. Шуңа җавап: 3 ел сугышта йөрү аркасында, билгеле, үзгәрешләр һәрьяктан да бар. Сез язучыларга яңа билетлар бирү уңае белән шундый үзгәрешләрне сорыйсыз. Аларның анкета өчен кирәкле булганнары күп түгел.*

*Менә алар: мин инде шушы елның башыннан партия члены. Кандидатлыкка 43 елның башында Великие Луки өчен көрәштә алынган идем. Елдан артык инде фронт газетасында эшлим. Элек корректор идем, хәзер — корреспондент-организатор (Шамов белән бер үк должностьта), үзем офицер званиесендә түгел. Должностем — офицер должносте, хезмәт хакым, паёк — барысын алар белән тигез алам, званиене үзгәртү артыннан йөрергә вакыт та юк, һаман алгы кырыйда йөреләә, аннан соң, «хикмәт анда түгел», дип тә саныйм мин. Димәк, звание анда да кирәк булса — өлкән сержант.*

*Инде иҗат мәсьәләсе болай: очерклар язам, журналда күрәсез, билгеле. Җибәргән әйберләрем, «Ана һәм бала» исемле пьесадан башкасы, бар да басылдылар. Бу пьесаны фронттагы «агай-эне» барыр дигәннәр иде, билгеле, аның турында тулы җавап алганым юк. Язып яткан әйберләр бар.*

*Булды. Хуш, Мирсәй!*

*Әхмәт солдат.*

*5 октябрь, 1944 ел.*

*Литва.*

*Кайткан булса, Кашшафка, Разинга, Г.Бәширгә, К.Нәҗмигә, Таҗи абзыйга, А.Гомәргә, Хәйригә, Әминәгә һ.б., һ.б.ларга сәлам!*

**Әхмәт Ерикәйгә**

*Иптәш Ерикәй!*

*Каләмдәшләргә сәлам. Берничә тапкыр Союзда булсам да, Сезне туры китерә алмадым.*

*Җылы каршылавыгыз өчен зур рәхмәт. Казанда 10 көн торылды, ләкин 4 ел өчен бу бик аз вакыт булган икән. Бернәрсә эшләп тә, күрәсе кешеләрне күреп тә бетеп булмады.*

*Без Читага килеп җиттек һәм тирле-тирле комлы урамын таптарга тотындык. Хәзергә эш башлаганыбыз юк.*

*Йә бу безнең илнең байлыгы, киңлеге, матурлыгы! Себерне, бигрәк тә Байкал күлен күрмичә, бу матурлыкны тулы килеш һич күз алдына китереп булмаячак икән! Әйе, Байкал күле буе әкияттәге кебек сихри матурлыкка ия икән! Без аны да күрдек.*

*Безгә дә Союз билетлары алсагыз икән. Мин, сораулары буенча, анкета тутырып калдырган идем.*

*Бәйрәм күңелле узгандыр инде. Сезне нәрсә белән котларгадыр инде.*

*Хушыгыз, дусларча кулыңны кысып,*

*Әхмәт солдат.*

*Безнең адрес: Чита 2ая, ул. 9го января, 22 а. Ахметову.*

Бу хат датасыз булса да, ул 1945 елның июлендә язылган.

**Искәрмәләр**

[1] Язучылар Афзал Шамов һәм Абдулла Әхмәт.
[2] «Идегәй» — татар халкының тарихи-эпик шигъри дастаны.
[3] Нәкый Исәнбәт (1899-1992), язучы.
[4] Роза — Хәмит Ярминең кызы.
[5] Фима — Хәмит Ярминең тормыш иптәше.

*Хатларны һәм искәрмәләрне* **Әлфия ШАМОВА** *әзерләде.*

# БЕЗНЕҢ ЯЗМЫШ

ИСТӘЛЕКЛӘР

*Бу истәлекләремне мәрхүм әтиемә һәм мәрхүмә әниемә багышлыйм.*

*Кәгазьдәй ап-ак кар, ап-ак кар,*
*Күзләрең күреме җиткәнче.*
*Үтелгән гомерне язып бар,*
*Күңелнең карасы беткәнче,*
*Күзләрнең яшьләре кипкәнче...*

Гамил Афзал

## «Аерылабызмыни, Мәрзия?»

...Әлегә җиңнәребезне сызганып, укуга һәм клиникаларда эшләргә җигелдек. Субординатор вазифасын тырышып үтибез. Көндәлекләр язып барабыз һәм аларны җитәкчеләребез даими тикшереп торалар. Шыксыз үрдәк бәбкәләре аккошларга әверелеп баргандай, без тиз арада хәрби табиблар буласы затлар. Әмма ышанып ук бетмим әле.

Көтә торгач, Мәрзия дә килде. Аны Мәскәү вокзалында куанып каршы алдым. Трамвайга утырып фатирга киттек. Такси ялларлык хәлем юк иде. Туйдан һәм «сәяхәтемнән» соң кесәм такыраеп калды. Дөнья гөрләп торганда, тормышның шул ягы аптыратмасын иде! Украинадан Мәрзиягә кучтәнәчкә йодрык-йодрык хуш исле «Антоновка» алмаларын алып кайткан идем. Кечкенә түгәрәк голланка мичле, тимер сәке белән нәни өстәлле, сандык хәтле кысан бүлмәгә икебез көчкә сыйдык.

Табын әзерләп, очрашу хөрмәтенә маржаны да утырттык. Ләкин сөяркәсе белән ызгышып йөргән хуҗабикәгә минем яшь татар кәләшем, гаебе булмаса да, кай ягы беләндер ошамады. Әллә балага узуыннан курыкты инде. Фатирга кертүчеләрнең балалы гаиләләрне җеннәре сөйми. Әллә җепшек Питер һавасы килешмәүдән тамагын кыргалап йөрүеннән шикләндеме? Башта үзе тәкъдим итсә дә, савыт-сабаларына орындырмый башлады. Үз савытларыбызны юнәтеп өлгермәгән идек шул, юнәтерлек чамабыз да юк иде әле.

Аннары, уйлавымча, минем белән үзе дә шаярырга өметләнгән, болай тиз өйләнермен дип уйламаган бугай ул. Һәрхәлдә, миңа шулайрак тоелды. Гади генә татар кызына офицерны күпсенүе дә ихтимал.

Кыскасы, көннәрнең берсендә ул безгә яңа урын эзләргә кушты. Әйтергә генә ансат. Ике миллион ярымлы шәһәрнең өчтән бер өлеше диярлек хәрбиләр, укучылар. Бик сирәкләренең генә фатирлары бар. Казармаларда, тулай торакларда вә кеше фатирларында бүлмә-почмаклар яллап яшиләр. Бигрәк тә академияләргә, югары курсларга килеп тулганнары. Ә алардан гайре башка югары вә урта уку йорты шәкертләре һәм завод-фабрика килмешәкләре бар бит әле!

Димәк, тагын ничәнче тапкыр вакытыңны вә өстәмә акчаңны сарыф итәргә кирәк. Үзәкләргә үтте инде бу фатир мәсьәләсе! Балалы Чурин кебекләр моны тулысынча татымый калдылар, чөнки икенче сыйныфтан соң аларны гаиләле тулай торакка урнаштырдылар. Хәмбәлгә дә, Васфыйга да шунда бүлмәләр бирделәр. Тулай тораклары Литейный күпер янында гына, элекке патша казармаларында. Анда ни дүрт йөз сум түлисе түгел, ни һәр адымыңны күзәтеп торучы хуҗа юк!

Әнәс ХӘСӘНОВ (1929) *Лаеш районы Атабай авылында туган. Кырымдагы Феодосия шәһәрендә яши. Отставкадагы медицина полковнигы. Россия Язучылар берлеге әгъзасы.*

Бу юлы, байтак эзли торгач, мәшһүр Малков базарында, Тамбов урамыннан аена 400 сумга коммуналь фатирның бер бүлмәсен көчкә ялладым. Анысы Мәскәү вокзалын ураган Обводный канал артында, шәһәрнең икенче ягында. Ераграк шул. Трамвайның дыңгылдавы башка тиеп бетә. Анысына чыдар идең дә әле, тик бүлмә кандалалы булып чыкты. Ленинградның шул каһәр төшкән нәселле канэчкечләре юньләп йокы күрсәтмиләр. Төне буе хәләл тәннән хәрәм табып, усал этләр урынына талыйлар! Шундый кечкенә хәерсез сасы нәмәстәләрнең кеше тиресенә ничек тешләре үтә диген! Дуст сибеп кырып бетердем дигәндә генә тагын әллә кайлардан кереп тулалар. Бөтен кат-кат ябыштырылган обой аслары аларныкы!.. Десантчылар сыман түшәмнән үк яткан урынына сибеләләр!

Йорт урыны болай ярыйсы үзе. Завод-мазарлар юк, тыныч. Йорт каршында тимерьюлчыларның мәһабәт Мәдәният сарайлары — графиня Панинаның шактый төсен югалткан ике катлы (ярым подвалын исәпкә алмаганда) йорты. Киң баскычтан менүгә, икенче каттагы холлында узган заманның берничә гүзәл мәрмәр сыннары тора. Иң кызыгы — Гамлет сыны. Ул шамакай Йорикның баш сөяген тотып, гаҗәпсенеп карап тора. Бөек В.Шекспирның атаклы әдәби каһарманын менә кайда очраттым! Шекспирны мин Габдулла Тукайны вә Александр Пушкинны яраткан кебек яратам. Без кичләрен шул сарайга кино карарга кергәләдек. Эрмитажга, Рус вә Суворов һәм медицина музейларына да барып кайттык.

Хуҗа — житкән кызлы тол хатын. Ит комбинатында эшли. Итсез тормый. Урлауның җай-әмәлләрен таба инде. Үзләре икенче бүлмәдә. Бүлмәбез җылы, батарейлары кызу. Тормышыбыз мактанырлык түгел. Өйгә җибәргәч һәм фатирга түләгәч, акчабыз очын очка ялгарга көчкә житә. Мохтаҗлык кәефне кыра. Мәрзиянең бертуктаусыз күңеле болгана тагын. Юньләп ашый алмый, йончыгып бетте. Сәбәбен беләм. Куаныр урынына көенергә туры килә. Саулыкка тук булмагач, балага узуы авырга төшә... Кичен, академиядән кайтышлый, анарга әчкелтем-төчкелтем тундырылган җиләк-җимеш юнәтергә тырышам. Тик файдасы аз шул. Аннары, алар белән генә туклана алмыйсың бит! Балага узган хатыннарның токсикоз һәм эклампсия чирләре булгалый. Ходай күрсәтмәсен! Мәрзияне кызганам, кайчакларда исә арып-талып кайткан җаныма житә кала — ачуым чыга. Акча җитмәү сәбәпле, саулыгы чамалы гына булуына карамастан, ирексездән, бераз декрет акчасы да булыр дип, тукымалар эшкәртүче фабрикага эшкә керә. Бу бик авыр, цехлары эссе, шау-шулы һәм тузанлы. Тукыма станоклары вә зыр-зыр әйләнгән орчыклар артыннан өлгерергә кирәк бит. Төнге сменага да чыгарга туры килә. Кем уйлап тапкандыр бу төнге сменаны? Йокысы килгәндә, кеше ничек юньләп эшли алсын ди?

Илебездә байтак кына авыр эшләр хатын-кызлар җилкәсендә. Хәлем булса, эшләтмәс идем кана! Житешмәүлек эшләтә.

Тузан өермәсендә тирләп эшләгәнгәдер, култык астына эт терсәге чыкты. Аның белән байтак интекте. Үзем дәваладым. Ни әйтсәң дә, яман, зарарлы производство инде. Декрет ялына чыкканчы түзә алса ярар иде! Стажы да, акчасы да бераз булыр иде... Кала акча сөя. Ләкин кайда нечкә, шунда өзелә бит ул. Авырлы, әкрен хәрәкәтчән Мәрзия сменачы кызу марҗага ошамаган. Ачуы кабарып, тегесе бар көченә хатыным өстенә авыр кул арбасын этәреп бәрдерткән! Һаман да шул этлек галәмәте... Хәерле булсын, нидә хикмәттер, татар булгангамы, хатынымны кайда да өнәмиләр! Әлбәттә, мондый хәл мине куандырмый. Шуның белән генә эш тәмамланса икән! Теге арбаның әчкә орынуы зарарсыз узмый. Таң алдыннан эченнән кан саркый башлый! Бер килсә, килә бит ул. Кара кайгыга батып, Академиянең гинекология клиникасына киттек. Анда исә, өметебезне өзеп, баласын төшерәләр! Бер бәхетсезгә гел бәхет юк. Олы каза, ахыры ни булыр... Безнең, гаепсез-гаеплеләрнең, арабыз киеренкеләнә. Таягының чукмарлы башын язмыш иң әүвәл Мәрзиягә орса,

икенче очы мина да тими калмый. «Бер унмасаң, гел унмассың!» — дигән мәкаль исемә төште. «Бусыннан да унмадым, ахры!» — дип эчемнән сызам инде.

Күңел сүрелеп, Мәрзиядән дә әкренләп күңел кайта башлый. Кинәт кабынып киткән мәхәббәт шуның белән сүнәр микәнни? Бер уйласаң, эчкерсез Мәрзиянең монда ни гаебе бар инде? Ләкин үземне дә гаепли алмыйм. Хискә бирелүчән шул мин. Адәм психикасы бигрәк нечкә һәм үтә катлаулы нәрсә ич. Бигрәк кызганыч, саулык ягыннан хатынымнан унмадым. Ятим үскән баланың нинди саулыгы булсын ди? Мин аны да, үземне дә жәллим. Үземне бәхетсез дип саныйм. Аһ, барча кешеләр бәхетле булсалар икән! Гонаһ шомлыгы сыман, берсеннән-берсе килеп чыга бит! Мәрзиядән күңелем кайта башлагач, кайбер гадәтләре дә ошамый башлады. Атасыз-анасыз, тиешле тәрбия алмый үскән кызның, билгеле, кимчелекләрен табарга мөмкин. Бердәнбер кояш хәтле кояшта да таплар бар ич. Аннары кешегә яраклашу да ансат түгел. Мин моны үзем кичереп беләм. Ә Мәрзия исә минем зәвыкларымны да белеп бетермәгән, күнегеп тә өлгермәгән, тәҗрибәсе дә юк. Шулай булгач, арабызның бозылуы табигый инде. Очкыннан янгын кабына. Моның өчен нәни генә сәбәп тә җитә кала. Ә сәбәпләр бар инде. Мина, максималистка, алар саллы һәм бик җитди булып күренәләр. Килешмәгән гадәтләре гомер азагынача төзәтелмәслек булып тоелалар. Тормыш күрмәгән япь-яшь кызны үзем белән чагыштырып, үз аршыным белән үземә тинләштереп маташам... Һәрхәлдә, тырышса да, Мәрзия минем кебек була алмый инде. Әлегә мин менә шуны аңламыйм һәм аңларга да теләмим. Без, ирләр, эгоистлар инде. Мәрзиянең тере җан буларак ни кичерүен исәпкә дә алмыйм!.. «Сукыр булдым микәнни, ничек боларның берсен дә күрмәгәнмен?» — дип, үземне үзем битәрлим. Ихласың кайтып, бизә башласаң, чебен хәтле кимчелек-җитешсезлек тә филгә хәтле күперергә мөмкин ул!..

Югыйсә, мина белергә кирәк иде: бер адәм дә фәрештә түгел. Берәү дә бөтен яктан камил адәм була алмый, булмый да. Шулай да тырышып карыйсы иде... Ләкин холык дигән үҗәт нәрсә гел үзенекен итә. Анарга, «тыел», дип артык боерып булмый. Печтик кенә сәбәп тә ачуымны чыгара, ә Мәрзия исә арабызны җайлый белми, җайлашырга өйрәнмәгән. Яшь шул әле. Сүрәнәеп, йомылып йөри бирә. Шулай чүмәлә өстенә чүмәлә өелә торгач, бөтенләй сөйләшми башладык диярлек. Җитмәсә, әнием каты гына чирләп киткән. Теш казнасы һәм өч тармаклы нервысы (тройничный нерв) үтереп сызлый икән. Бернинди дәва ярдәм итми, ди. Көтмәгәндә бу чире каян килеп чыккан тагы? Әни өчен дә борчылам инде. Беләм: әгәр дә ул нерв һәм Гассеров төене сызлап китсәләр, дәвалавы бик кыен. Бөтенесе дә берьюлы бергә төелделәр: бик җитди, үтә җаваплы алтынчы курсым (гомеремнең төп максаты), Мәрзиянең сафтан чыгып баруы, әнинең авыруы һәм акча мохтаҗлыгы... Түземлегем төкәнә, тәкатемне тота алмыйм. Өстәвенә, иске кәгазь акчаларның бәяләрен ун мәртәбә киметеп, яңаларына алмаштырдылар. Яман гадәтләренә кергәнчә, чукынган «юлбашчыларыбыз» бу юлы да халыкны алдадылар, чөнки кибет һәм базар әйберләренең бәяләре ун тапкыр кимемәде бит! Бераздан яңа акчаның да дәрәҗәсе тиз төшә башлады. Шуларның барысын да исәпкә алганда, төшенке халәтемне аңлау кыен түгелдер. Мина җитә калды. Ашыгып өйләнеп тагы ялгыштым, ахры. Ашыгып эшләнгән эш яхшыга китерми шул. Шулай гомер буе мина ялгышырга язылган микәнни? Гомумән, бер дә ялгышмый яшәргә була микән ул? Тагын җавапсыз сораулар... Тормыш җитди мәсьәләләрен һәм җан көйдергеч сорауларын куеп кына тора. Уйлан, кыймылда, эзлән генә, бәндә!

Кайчакларда Валяны исемә төшерәм. Мәрзияне аның белән чагыштырып карыйм. Анысы ягымлырак, елмаючан, низагны уен-көлкегә әйләндерә belә иде. Мәрзиянең шул яклары җитми. Аннары, ул татарча укымаган, ана теле уртаклыгыбыз чамалы гына... Валяны исемә алам да сагынам. Хәтта татар телен дә өйрәнә башлаган иде бит... Урамнарда очратам да, йөрәгем сулкылдап куя. Әллә юкка аерылдым инде?

Аерылдым да бетте-китте генә түгел икән шул! Аз булса да бергә гомер ителгән, күнегелгән, тирән эзе калган. Бала чагында ук рәнҗетелгән әчле ятимә түгел иде.

Ә бусы белән бик аз тоз ашалган әле. Бер-беребезгә ияләшеп-күнегеп тә өлгермәдек. Ашыккан ашка пешкән дип белеп әйткәннәр шул!.. Мәхәббәтебезнең гомере шундый кыска микәнни? Беренче сынауга да түзмәде... Тагын шул Сабир абыйның әтигә сөйләгәне искә төшә. Бик акыллы, тәҗрибәле зат булган. Ул бездә, әти белән эче бал эчеп һәм җиз кураенда елатырлык көйләр уйнап алганнан соң, дулкынланып болай дип әйткән иде: «Габдрахман дускай, кайчакларда Гарифә белән без бер урында дүртәүләшеп кунабыз!» Әти гаҗәпсенеп: «Ничек алай?» — дип сорады. «Үпкәләшкән чакта Гарифәм: «И, минем беренче ирем исән булса!» — дип уфтанып, әйләнеп ята. Ә мин эчемнән генә: «И, минем беренче хатыным исән булган булса!» — дип көям. Менә шулай бер ятакта дүртәү булып куябыз!» — диде. Билгеле, мин бу сүзләргә читтәнрәк, сиздермичәрәк колак салып утырам. Зурлар арасына кысылу юк! Менә хәзер үзем дә Сабир абый хәлатенә төштем. Инде бер урында «өчәү» ятабыз. Ә бәлки, Мәрзия дә тормышка чыгуына үкенәдер...

Үзен сагына башлагангамы, бер көнне «Гостиный двор» ягына барганда кинәт Валяны очраттым. Яна тәнкә кебек ялтырап елмая. «Менә үземә нутрий якалы яңа бишмәт сатып алдым әле!» — ди. Аннары әкрен, үзгәргән тавыш белән болай диде: «Өйләнгәненне ишеткәч, башым әйләнеп, егыла яздым. Ни булды дип сорыйлар, әйтә алмыйм. Нишләдең син, тилергәнем?» Соңгы сүзләрен әйткәндә еламсырап ук җибәрде. Өстемә кайнар су сиптемени! Аерылсак та, миннән өметен өзмәгән икән ләбаса. Булыр икән елга тиң мизгелләр! Өнебезгә соңга калыбрак, эш узгач кына киләбез шул.

Үкенү һәм кызгану хисләре укмашып, берьюлы җаныма ябыштылар. Әйе, мин тиле шул һәм бүтәнчә була да алмыйм бугай. Менә шулай тормышымның бик авыр чагында якын кешең очрап, җәрәхәтле йөрәгеңә тоз салсын әле!

Андый шомлы чакларда якыннарың төшкә дә керәләр. Шундый төшләрне ничек һәм кай якка юрарга да аптырыйсың. Зираттан кайтучы кеше кебек, моңаеп барам. Мине гаепләргә, зинһар, ашыкмагыз. Валя белән биш ел чамасы гомер ителгән, ә Мәрзия белән беренче ел гына. Ул әле мина ияләшеп тә бетмәгән һәм җан җылысын кирәгенчә бирә алмый...

Мәетләр һәм узган гомер тереләрнең аякларын богаулап тотып торалар, ә яңа буыннар искеләрнең иңбашларына менеп югарыга (алга) таба омтылалар, дип борынгы юнаннар тикмәгә генә әйтмәгәндер инде. Бу — гомер фәлсәфәсе. Узган гомернең, истәлекләрнең тәэсиреннән тиз генә арынып булмый икән. Ә бәлки, бөтенләй арынырга кирәк тә түгелдер... Хәтерсез кеше тулы акыллы түгел иң ул!

Менә шул шомлы очрашудан соң тагын үзгәрә төштем. Тамчы тама-тама ташны тишә... Сөмсерем тәмам коела башлады. Мәрзиядән күнелем һаман сүрелә бирә. Беләм, аның монда гаебе бик аз. Ихтыярсыз, үзем шундый җан корыткыч бәндәгә әверелдем. Болай үзеңне һәм башкаларны изалавыңның бернинди мәгънәсе юк. Ләкин эчендәге әллә нинди аңлаешсыз куәтле көч киреләнеп үзенекен кыла бирә! Бу кадәр куәтле хисне җен-шайтан коткысы диләр инде әллә? Әйе, киреләнеп, кеше үзенә-үзе дошманга әверелә ала икән. Ни һәм кем кирәк соң миңа? Үземне-үзем аңлый алмыйм. Ник болай өзгәләнәм? Нихәтле чәбәләнсән дә, барыбер идеалыңа ирешә алмассың. Шуңа күрә ул бәллүр идеал да. Әлбәттә, җан тынычлыгы кирәк. Тик ул үзеннән-үзе тумый лабаса. Сәбәбе һәм шартлары булырга тиеш. Нәкъ менә шулар җитми дә инде. Хикмәтле бoҗра яки лабиринт эчендә адашып әйләнәм түгелме? Үземне-үзем аңлый, үземә дәва таба алмагач, кешеләрне ничек дәваларммын соң? Әйткәннәр бит: «Табиб, башта үзеңне савык!» — дип. Ничә мең еллар буена нинди генә фәлсәфәчеләр һәм галимнәр төпченеп өйрәнгәннәр, әмма «кеше» атлы җан иясенең серләрен ачып бетерә алмаганнар шул. Әнә Ленинградта, Бехтеров исемендәге махсус ми институтында илле елдан

артык ми һәм психика серләрен кумәкләшеп өйрәнсәләр дә, нәтижәләре ташка үлчим генә. Ирексездән, Джонатан Свифтның сатирик Лапу «галимнәре» искә төшә. Без теләгәнчә ми серләре ачылмаса да, кешедәй акыллы роботлар уйлап чыгарылсалар да, кешене алар беркайчан да бөтенләй алмаштыра алмаслар. Аларда барыбер адәм хисләре булмаячак. Ә хиссез акыл — жансыз нәрсә ул.

Кеше — Галәмнең иң катлаулы жан иясе. Эволюциянең асыл тажы. Йә, Кеше бул инде, дим, була алырмынмы? — дип, үз-үземә сорау бирәм. Тырышып карармын, көчем житсә. «Көчем житсә», дигәч, үз-үземә бөтенләй ышанып бетмим, ахры...

Мәрзия савыгып, янә эшли башлады. Бу юлы яна урында, данлы «Светлана» фирмасында. Ә минем тагын да кызурак көннәрем килеп житте — диплом алды, дәүләт имтиханнарына жиң сызганып әзерләнер вакытым... Бик авыр, алты ел укуымның очланып баруы дигән сүз бу.

Арабыздан хәерсез кара мәче узды мәллә? Бер кәлимә сүз катмыйбыз. Мәрзия турсаеп йөри. Мондый очракта якынлашып булмый ул. Бер-беренә баш бирмәгәндә нинди якынлашу булсын ди? Нинди генә хәл килеп чыкмасын, ни генә булмасын, һаман беренче хатын белән чагыштырасын һәм икенчесенең житешмәгән якларын ачыграк күрәсең.

Бер ятакта «өчәү» ята бирәбез. Бу үзенә бер бәлагә әверелде. Өйдән дә куандырырлык хәбәр юк. Әни һаман терелә алмый. Аның зарларын истә тотып, язга таба стоматология кафедрасының белгечләренә күрсәтмәкче булдым. Чакыргач, ул март азагында килде. Алдан аны патшалар сараен, Эрмитажны күрсәтергә алып бардым. Гомерендә күрмәгәннәрне гажәпләнеп һәм сокланып карады. Аннары икенче көнне метрога киттек. Заман могжизасы ич. Анда эскалатор баскычына басуга, мин: «Әни, менә хәзер жир астына төшеп китәбез!» — дигәч, ул, бахыр, кинәт чүгәләде. Коега чиләк төшергән кебек төшәбез дип уйлаган! Метро тукталышларын бик кызыксынып карады. Метро да анарга бик ошады. Фин вокзалы тукталышында өскә чыгып (80 метр тирәнлектән), стоматология белгечләренә күренергә киттек. «Тикшереп карарбыз, калдырыгыз!» — диделәр.

Әни шикләнүчән иде. Аны байтак үгетләп, тынычландырырга туры килде. Ахырда, клиникада ятып калды. Яңагын рентген сурәтенә төшерделәр. Тикшерделәр. «Янак сөягенә шеш чыга башлаган!» — дигәч, куркып киттем. Алай булса, хәле яхшыдан түгел икән. Аны-моны әйтмәдем инде. Әни рак чиреннән курка иде. Операция ясаячаклар дип кенә аңлаттым. Әни янында буласым килеп, үзем дә ЛОР клиникасына кереп ятарга булдым, чөнки бу ике клиника бер үк бинада һәм уртак коридор белән тоташканнар. Бер-берсенә эчтән кереп йөрергә була. Ятуымның икенче сәбәбе дә бар — тамагымның бадәм чикләвеге сымак бизләрен алдырту. Тамак бакасы белән чирләп еш интегә идем. Ләкин әнкәм анда ятмаган булса, әле дә ул бизләрне алдыртмаган булыр идем! Минем авырулар киеменнән килеп керүемне күргәч, әни бик гажәпләнде. Операция ясатырга кергәнемне белгәч, үзенең хәлен дә онытып хафаланды. «Зыяны тимәс микән?» — дип берничә тапкыр сорады. Әнине операция залына хәтле үзем озаттым һәм операциясе тәмамланганчы ишек төбендә көтеп тордым. Операция унышлы узды. Әнине мөмкин хәтле тынычландырырга тырыштым. Соңрак үземә дә операция ясадылар. Анысы авыр узды, чөнки бизләр жөйләнеп беткәннәр. Тамагымнан төне буе кан саркыды.

Кан агуы туктамагач, янымдагы тумбочкага бөерсыман стериль тазчыкка эскәк һәм тампон китереп куюларын күргәч, котым очты. Жәрәхәткә тампон салып, эскәк кыстырып куймакчылар икән бит. Авырткан жәрәхәткә! Шүрләвемнән кан тамырлары спазмланып, кан саркуы үзеннән-үзе туктады тагы! Элек тә яралардан каным озаграк агучан иде. Атна буе ризык ашый алмадым. Сыекчаларын гына көчкә-көчкә йота идем. Ярый әле ул-бу булмады. Тамак бигрәк четерекле жир. Юан кан тамырлары вә үтә мөһим нервлар янәшәдә генә!..

Көтмәгәндә тавык шулпасы китереп, Мәрзия бераз күңелне күтәрде тагын. Шул көннән бирле күп кенә вакыйгалар онытылган, ә бусы һаман хәтеремдә әле!

Изгелек онытылмый ул!

ЛОР клиникасында ятканда, акылга сыймаслык зур вакыйга булып алды. Бөтен дөньяны гаҗәпләндереп, дәүләтебез Галәмгә кешене — Ю.Гагаринны очырган! Бу хакта шапырынып бертуктаусыз радио сөйләп тора. Телевидение ду куптарып шатлыклы җыеннарны күрсәтә. Палатада шуның турында гына кызу гәп бара. Халык масаеп дулкынлана. Әйтерсең, үзебезне күк гөмбәзенә очырганнар! Бар икән, диләр, илебезнең куәте һәм маһирлыгы! «Болай булгач, АКШы торып торсын әле!» — диешәләр. Безгә әллә ни булды. Менә шушы мәлдән соң өзлексез Космос шаукымы башланды да инде. Бөтен кычкырып торган проблемалар кинәт... юкка чыкты! Бары тик Космос белән генә башларны әйләндерергә тотындылар. Миллиардлаган сумнарны берөзлексез җилгә очыра тордылар!

Күкрәкләренә Алтын Йолдызлар тагучыларның саны хәттин ашты. Космонавтларны әзерләүче үзәкне «каһарманнар мәктәбе» дия башладылар. Тора-бара Космос белән мавыгып уйнашулар халыкның бәласенә әверелде. Ә без — мәнсез алданучылар моңарга башта белештерми куана идек... Юктан Космос белән шөгыльләнеп һәм бөтен җирнең булдыксыз әрәмтамакларына, хакимият вә дан-шөһрәт сөючеләргә халкыбызның мал-мөлкәтен сарыф итеп, «тәмгысыз-риясыз» ярдәм итә-итә, коры сөяккә калдык та инде. Бу да совпартократларның җинаяте. Әлегә алар сафсаталаналар, тик без аларның кем икәннәрен инде беләбез. Мохит һәм авыл хуҗалыгы җимерелеп бара, халык бөлгәннән бөлә, ә болар, Космос дигән булып һаман да корал туплап, бөтен дөньяны өркетеп, якасыннан тотып тормакчы булалар!

Үзем, ә сонрак әнием дә операцияләрдән соң бераз савыгып чыктык. Әмма аның да, минем дә кәеф юк. Тамак һаман авыртып йотарга комачаулый. Әни: «Минем өчен генә кереп, операцияне юкка эшләттен!» — диде. Үзенең дә сызланулары бетмәгән иде әле. Аның да Мәрзиядән ихласы кайта башлаган. Үзенең өендә дә, монда да сынап өлгергән инде. «Бәхетең булмады, улым, үзенә тиңне таба алмадың!» — диде ул, мине кызганып. Ул хаклы иде. «Әнә Хәдия үзебезнең як кешесе, синең кебек врачлыкка укый!» — дип тә өстәде әле.

Әни кайтып китте, әмма киеренкелек калды. Мәрзия әлегә өйрәнчек дәрәҗәсендә эшли, эш хакы да ташка үлчим генә. Арабыз шулай тәмсезләнгәндә, Кунашактан үзе дә юньләп белмәгән аналы-уллы кешеләр кунып чыкты. Аннары агаеның балдызы да килеп китте. Күземә кеше күренерлек идеме? Үзем дә «чыпчык хокуклы» буларак, хуҗа бүлмәсендә ничек яшәргә белмәгәндә, андый чакырылмаган «кунаклар» комачаулап йөрмәсеннәр иде! Ичмасам, чыбык очы хәтле туганнар булсалар иде!..

Башыма тай типкән, ахры, әллә ничек үҗәтләнеп киттем, хәтта авыз ачып сөйләшәсем дә килми. Йөкле булса, бәлки, андый булмас идем. Мәрзия үзе дә тәкәбберләнеп инәлми. Хатын башы белән, бичара, уртак тел табарга тырышмый. Нишләргә? Үзеннән дә биегрәк сикереп булмый. Әлегә сабыр итебрәк торырга кирәктер. Аннары, бәлки, берәр җае чыгар. Балабыз булмавы хәерлерәктер дә әле... Хәзер дәүләт имтиханнарына бирелебрәк хәстәрләнергә кирәк. Адәм хуры булып каласы килми...

Сыйныфташларым төркем-төркем партиягә керә башладылар. Хәтта «рядовойларыбыз» да калышмыйлар. Югарырак үрләргә исәплиләр. Төшемлерәк һәм дәрәҗәлерәк эш урыннарын партия әгъзаларына бирәләр бит. Партиягә керү бөтен гамәлләрдән дә мөһимрәк һәм өстенрәк санала иде. Аның таныклыгын оҗмах пропускысына тиңлиләр! Лейтенант Поварницын белән дуслашып йөргән капитан Стародумов та шунда керергә гариза язган. «Моңарчы керми, кырыкка җитеп барганда нигә кердең?» — дип сорагач, — «Җыен булдыксызлар һәм хәйлә-мәкерле икейөзлеләр шунда оялап, сиңа акыл сатып идарә итсеннәр әле!

Алар сина җыеннарында юк-барлар өчен тел-теш тидереп, тәнкыйтьләсеннәр ди, ә син араларына кереп, үзенне яклап каршы сүз дә әйтә алма! Ичмасам, шулар өерендә утырып, теләсә кайсын үзем каезлап тәнкыйтьләрмен!» — ди. Әлегә бу шулай дип әйтә, гаризаларында исә барысы да бертөрле язалар: «Коммунизм төзүчеләр сафында булырга телим!» — дип.

Әйтерсең, партиягә кермичә генә, аны төзеп булмый!

Хәер, партиялеләр дә моңарчы аны төзи алмадылар. Халыксыз алар үзләре генә ни эшли алсыннар? Ә ул «коммунизм» дигәннәре офык сызыгы кебек, барган саен ераклаша бирә. Үзенә күрә матур хыял гына инде... Хыял булса да, ышанучан адәмне ымсындырырга ярап куя тагын...

Сөйләшмәсәк тә, аерым булса да, моңарчы бер бүлмәдә куна торган идек. Ләкин хәерсез кичләрнең берсендә Мәрзия күренмәде, кунарга да кайтмады. Кояш күрде, ай алды! Борчылуымнан тәмам аптырап киттем. Ни булган соң, берәр бәлагә тарымагандыр бит? Алла сакласын, мондый ыгы-зыгылы зур калада!.. Ни әйтсән дә, мин аның өчен җаваплы ич. Бернича көн белешеп, хәтта «скорый»ларга шалтыратып йөргәннән соң гына мин аның хуҗа хатын бүлмәсеннән исән-сау чыкканын күрдем. Шунда гына куныл йөри икән бит ул! Ә мин шул тәүлекләрдә ниләр генә уйлап бетермәдем, башым түнде хәтта! Ичмасам, бер сүз дә әйтмәгән! Шушы микәнни аерылуыбыз? Минем җаваплы чорымны да исәпкә алмаган, тапкан вакытын! Хәер, ул югары уку йортының ни икәнен дә белми. Ә академия югары уку йорты гына да түгел, үтә катлаулы нәрсә. Анда вакытны әрәм-шәрәм итәр өчен генә алмыйлар. Кәҗә маена хәтле сыгалар. Җанын-тәнең белән бирелеп укуың һәм хезмәт итүең таләп ителә ич! Андагы фәннәрнең очына хәтле ерып чыгар өчен, җан тынычлыгы һәм баш кирәк. Инде менә шушы тәмсезләнүебез генә җитмәгән икән — фән имтиханнарына тормыш имтиханы өстәлә!..

Икенче мәртәбә бит! Оят та, хурлык та...

Үз кешең белән дә тора алмагач, ни әйтергә?

«Болай булгач, гаеп Мәрзиядә генә түгел, үзем яраксыз, киребеткән бәндә, ахры!» — дип, әрнеп уйлап куйдым. Мондый ямьсез хәлне һич яшереп булмый. Туганнарыма, дус-ишләремә һәм командованиегә ничек аңлатырга? Ятлар исә, авызларын ерып, кеше керендә таплар эзләп актарынырга әзер. Беләм ич, сәбәпсез тырнак астыннан кер эзләүчеләр җитәрлек. Мәрзия, аптырагач, «яхшы» кешеләр өйрәтүенчә, академиянең парткомиссия рәисе полковник Төхфәтуллинга мөрәҗәгать иткән. Болай, икебезгә генә кагылышлы серләребезне әллә кемгә ачып-зарланып, тормышыбызны тагы да катлауландырмаска иде. Партия гаилә хәлләренә кысылса да, аларны төзәткәне юк әле. Чөнки мәхәббәт һәм гаилә тормышы партия кодрәтенә буйсынмый алар!..

Төхфәтуллин сыйныф начальнигы аша мине парткомиссия кабинетына чакырта. Бу «җылы» урынга нинди казанышлары аркасында эләккәндер ул. Чөгендердәй кызыл табак битле, базык гәүдәле ир, җайлап сөйләшү урынына, юан бармагы белән яный-яный, кызып мина җикерә. Татарча түгел, урысча инде. «Штубы хатыныңны тап һәм ялгышыңны төзәт!» — ди. Болай да көйсезләнеп сыртым кабарган чак. Ачы елмаеп: «Ник алай кычкырасыз, мин әле партия әгъзасы түгел ич!» — дим. Кулын гына селтәде. Шуның белән тәмам. Бер «җаваплы» эшен башкарып, бу кенәгәсенә чираттагы «галочкасын» сызып куйды инде. «Болай булгач, инде мина юньле хезмәт урынын күрсәтмәсләр!» — дип уйлыйм, парткомның кара дермантин кагылган ишеген ябып. Ишек алдында дистәдән артык партиягә керергә теләүче шәкертләрнең чираты тезелеп утыра иде. Парткомның нәүбәттәге «запаркасы»... Бу инде байтактан килгән формаль йола. Тегe, сугышка керер алдыннан «партия әгъзасы булырга телим» дигән күк, алар академияне тәмамлап, частьларга китәр алдыннан партияле булырга тырышалар. Ишеккә карашымны тагы бер ташлап: «Әй, төкерим лә, Ерак Көнчыгышка үз ихтыярым белән китәрмен. Украинада

житәрлек хезмәт ителгән, яшьрәк чагымда яна жирләрне күрергә кирәк!» — дип уйладым һәм тынычлана төштем. Куркытты, имеш! Әй, Мәрзия-Мәрзия, тапкан кая барырга! Арабыз бозыла гына төште. Тагы ачуым купты. Шуннан соң шүрләпме, ул минем күземә янә күренмәскә тырышты. Аның шикаятеннән һәм Төхфәтуллинның «өшкерүеннән» соң мин, үч иткәндәй, киресенчә кылырга булдым.

Инде күңелсез хәл турында атама-анама хәбәр итәргә кирәк. Анысы кыенрак әле. Ахырда: «Мәрзия белән аерылабыз бугай!» — дип өйгә хат яздым.

Бу хәбәрне алуга, минем халәтемне аңлап, атам шунда ук поезд белән юлга чыга. Ерак ара дип тормаган. Беләм ич, әни: «Бар, юатып-үгетләп кара, атасы!» — дигәндер... «Кайгысыннан бала үзенә берәр хәл кылмагае!» — дип уйлаганнардыр. Менә бит, ата булгач, авырсынмый икенче мәртәбә юләрләнгән улына килә! Күңелләре сизгән, белеп килгән икән! Атамны вокзалда күрүгә жинеләеп киткән күк булдым. «Менә әниең борчылып, бар да бар, улың янында бул, кайгысын күтәреш дигәч, тагын килдем!» — ди ул акланган кебек. Шатлыклы вакытта туган-тумачаларсыз да яшәп була. Михнәтле-кайгылы чакта кирәгрәк шул алар. Кызганыч, каенатасы килүен белсә дә, Мәрзия күрешеп әчен бушатырга янына чыкмады һәм әтигә күренмәскә тырышты. Татар гадәтендә булмаган хәл! Югыйсә каенатасы аны якын итә иде, какканы булмады, авырлыгы тимәде. Мәрзиянең мондый кыланышы оялуыннан яки акылсызлануыннан булдымы, анысын үзе генә беләдер. Әтинең хәтере калды. «Ник минем яныма, әти дип, исәнләшергә чыкмый икән? Минем аңарга бернинди усаллыгым тимәде. Син аны калдырып киткәч, икенче сменасында курыкмагае дип каршы алырга йөрдем, аяк киемен тазартып тордым. Югыйсә олы башым белән килештереп-татулаштырырга дип килгән идем. Болай булгач, булмый икән!» — дип зарланды әти. «Ярар, хажәтебез беткәндер!» — дигән булдым. Мәрзиягә ачуым тагын да кабара төште.

Әти берничә тәүлек мина үгет-нәсихәт биреп яшәде. Патша сараен карап, Чаткы бакчасына бергә чыгып йөрдек. Ни әйтсәң дә, янында якын кешең булганда рәхәт инде. Шатлыгымнан телефон аша аның килүе турында Валяга хәбәр иттем. Бераз тынып торганнан соң:

— Ярар, Чаткы бакчасында гына очрашыйк, вакытым чамалы! — диде ул тыныч кына. Күрәсен, беребезгә дә ачу тотмый. Татар каенатасы белән яхшы мөнәсәбәттә иде шул. Татарча «әти» дип ягымлы итеп эндәшә иде... Ул әйткән вакытында диярлек килде. Исәнләштек. Сизелә: кызыксыну хисе сүрелә башлаган... Ә бәлки, шулай сер бирмәскә тырышамы? — Әллә тагын кушылырга телисеңме, йөрмә хурга калып, киселгән телем ябышмый ул! — диде картайган атам. Дөрес әйтә бугай. Саташмыйк әле, Мәрзия белән ара өзелмәгән ич! Салкынча гына саубуллаштык. Шуннан соң Валяны бүтән очратмадым. Ә ул Чуриннарга бер килеп сорашкан. Авыр чагы булгандыр...

Әти белән вокзалда хушлашканда ул:

— Тынычлан, бер дә кайгырма, була торган хәл, — диде. — Моннан да авыррак сынаулар була ул, түзәргә кирәк. Башың яшь, исән-имин син әле яна тормыш та кора алырсың. Әнә, картлар да башларына төшкәч өйләнәләр!

— Анысы шулай, тик мин, әти, кешеләрдән оялам, яхшысынмыйм, гарьләнәм дә! — дим.

— Нишләмәк кирәк, сабыр бул, вөжданың булгач, оялырсың да, гарьләнерсең дә! Гомер моның белән генә бетми, дөнья, шөкер, жимерелми, яхшы тор, әниеңне тынычландырырмын» — дип, әти мине кочты һәм аркамны чәбәкли-чәбәкли сөйде. Аһ, бу хушлашулар, тепловозның кузгалу авазы үзәгемне өзә генә! Һәр хушлашуыбыз соңгы тапкыр сыман, шикләндерә. Бусы да соңгысы булмаса ярар иде!.. Инде шушы кырмыска оясыдай өзлексез хәрәкәтләнеп торган һәм халык белән тулган калада берүзем генә калам. Атам тагы: «Кайгы-хәсрәткә бирелмә, мондый хәлгә түзмәслек түгел. Академияне яхшырак тәмамларга

тырыш!» — дип, мина җан җылысын һәм куәтен биреп, кайтып китте. Тагын да исән-сау күрешергә насыйп булса иде!..

Түзәсен инде, түзми нишләмәк кирәк? Әҗәленнән алда кара җиргә кереп ятмассың ич!

Ә Мәрзия? Ул да шундый кызыкмаслык хәлдәдер, анарга да җинел түгелдер. Ә бәлки авыррактыр да әле. Ирләр сыкранган мәлләрдә хатын-кызлар елыйлар инде. Ләкин гыйбрәт алырга теләсәң, гыйбрәтләр бар ул. Тик үз туксаным туксан, минем күземә алар күренмиләр. Мин әле кеше хәленә керерлек түгел. Сайладым-сайландым, тик барыбер ялгыштым, бәхетем булмагач... Хәер, мина яраклысы, гомумән, бар микән ул? Үкенеп көрсенәм. Мәрзиянең шикаять бирүен кичерә алмыйм. Үзенең сөйдереп яраклаша алмавын җиде ят Төхфәтуллин гына булдыра алмас! Анда барганчы уйлыйсы иде!..

Бер фатирда торсак та, үҗәтләнеп аерым яшибез. Әмма төшенке хисләргә бирелеп балавыз сыгып утыра торган вакыт түгел. Инде клиникаларда гыйбрәтле һәм бай практикаларыбыз тәмамланды, укыласы тирән мәгънәле лекцияләр укылып бетте. Кыен һәм гасырдай озын алты елыбыз үтте. Әйтергә генә ансат. Аллага шөкер, укуыбызның очына барып чыктык! Бербөтен гомер узган диярсең. Мөгаен, бушка узмагандыр. Олыгайдык, күпне күреп, күпне белдек. Дәүләт имтиханнарын тапшыру вакыты җитте. Комиссия рәисе ЦВМУдан — медицина генералы Павловский. Гаять тә усал нәмәстә!

Байтак тынлаучыларыбыз имтиханнарга әзерләнер өчен Разливтагы ял йортына киттеләр. Миһербанлы якты җәй башы. Яшәгән саен яшисе генә! Мина монда да хәзер комачаулаучы кеше юк. Зиһенемне җыеп, күнелемне беркетеп эшкә керештем. Байтак кына калын-калын китапларны, бихисап конспектларны яңадан игътибар белән укып чыгасы бар. Түбәндәге биш фәннән имтиханнарын атна саен бирсен тотасы:

1. Диамат һәм истмат. Боларсыз СССРның бернинди ВУЗын тәмамлый алмыйсың. Алар хәтта «кандидатлык минимумына» да керәләр!
2. Хирургия. Бу фәнне хәрби табиблар бигрәк тә шәп белергә тиеш.
3. Эчке авырулар. Үтә кин колачлы фән бу.
4. Йогышлы чирләр вә эпидемиология.
5. ОТМС (Организация и тактика мед.службы).

Язмышымны хәл итәчәк бик җаваплы имтиханнар. Әлбәттә, бераз шүрлим. Ярар, монарчы башкарганны, шәт, бу юлы да җиренә җиткерермен!

Имтиханнарның теория якларыннан тыш, бүтән җитди яклары да бар. Билет вә өстәмә сорауларына җавап биргәннән соң, клиникалардан китерелгән авыруларга, комиссия әгъзалары алдында тикшереп, диагноз куярга һәм дәвалау чараларын әйтеп, башка махсус мәсьәләләргә дә кагылырга кирәк!

Хәстәрләнә торгач, «кыямәт» көннәре дә җитте. Имтиханнарны клуб бинасында тапшырачакбыз. «Газраилләр» янына тәвәккәлләп барабыз. Дәүләт имтихан комиссиясен, әйткәнемчә, ЦВМУ начальнигы урынбасары генерал-лейтенант Павловский җитәкли. Бигрәк кырыс зат. Менә актык имтиханнарны тапшырырга тотындык. Алар башта өркетеп торсалар да, бер-бер артлы, берсеннән гайре, гел «бишле»гә тапшырып киллем. Һәр зачёт-имтиханнан соң хәлсезләнәм, билем сызлый. Ятасы килә. Бу инде бөер өсте бизләренең йончыгу галәмәте. Кыен, киеренке һәм нык дулкынланган чакларда алар гормоннарын (адреналиннарын) канга күбрәк чыгарып, вакытлыча өзлегәләр. Менә шул инде Г.Сельеның «стресс» дигәне.

## Алда безне ни көтә?

Карасаң, барыбызның да битләре суырылган. Шундый җитди эшләрне уңышлы башкардык. Гомеребезнең төп максатына ирештек диярлек. Белем тупланган, алда гаскәр хезмәте көтә. Сигезенче июльдә язылган дипломнарны,

тужуркаларга тагасы академия «калканнарын» өләштеләр. Бу ромбларны хәрбиләр үзара «поплавок» диләр. Хезмәттә «батарга» ирек бирмиләр, имеш. Әйтмәсәң дә, армияне кыскартканда, «академиклар»ны калдыралар... Бер-беребезне ихластан котлыйбыз. Кояшлы матур көндә, нәкъ беренче курска кергәч, беренче тапкыр сафка тезелгән яшел бакчада, шанлы лейбмедик Виллие сыны янында янә тезеләбез. Барысы да элеккечә, тик үзебез генә бүтән. Ул заманнан бирле байтак сулар аккан шул. Кызганыч, атам-анам бу шатлыклы мәлне күрмиләр!

Яшьләр инде лейтенантлар. Бер елдан соң, яхшы хезмәт итсәләр, өлкән лейтенант булачаклар. Хәзер аларны яна формаларында танырлык та түгел.

Кешене акыл гына түгел, кием дә бизи шул. Офицерларның кайберләренә, сроклары чыгу сәбәпле, «капитан» дәрәҗәсе бирелде. Чурин Иван — капитан, бераз масаеп та киткән. Менә белештерми булыш син кешегә! Миңа да капитан булырга берничә ай гына калды. Стародумов, Чекалкин һәм Подолько майор булдылар, чөнки укырга кергәндә үк капитан иделәр.

«Балтика» рестораныңда тантаналы банкет уздырылды. Банкет алдыннан Герасютенконы начальник кисәтте һәм дежурныйларга аңарга күз-колак булып торырга кушты. Чөнки ул Яңа ел кичәсендә нык исереп, клубыбызның бәдрәфендә: «Без — Запорожье казаклары!» — дип, кергән бер кешене бергәләп кыйнаганнар иде. Аларны көчкә аннан сөйрәп чыгарганнар иде. Менә шул холыксыз «казак» ахырда РВның баш анестезиологы булачак...

Андый соңгы банкетларда үтә сак булуың зарури. Чөнки бәйләнеп үч алучылар булырга мөмкин. Шулай, бездән ике ел алда укып чыгучыларның берсен шул ук ресторанның дүртенче кат балконыннан ыргытып дөмектергәннәр. Ыргытучыларны таба алмаганнар.

Ленинградтан каядыр китәсе көнем якынлаша. Анысы да зур мәсьәлә. Белмәгәннәргә хәрби хезмәт кайда да бертөрле булып тоелса, чынбарлыкта алай түгел шул. Хәрби хезмәтләр гаскәрләренең (вид, род), урыннарына (дислокация), һавасына (климатик зона), азык-төлек белән тәэмин ителүенә карап, аермалары зур. Хезмәт итәсе ягын үземчә билгеләп куйсам, яна корылган стратегик ракета гаскәрләренең ни икәннәрен үз күзем белән күреп, татып карыйсы бар әле. Андый гаскәрне үзем сайлагач, ни булса да чыдарга туры килер инде. Адәм корыч чыдамаган җирдә дә түзә ул, түзим дисә! Корыч уттан суга салуга ныгый ич...

ЦВМУның кадрлар бүлегеннән комиссия, ә хәрби округлардан «сатып алучылар» килделәр. Безне (ике йөзгә якын кешене) исемлек буенча чакыртып сөйләшәләр, хезмәт урыннарын тәкъдим итәләр. Кайберәүләр тәкъдим иткән урыннарны ошатмый кәҗәләнеп-карышып маташалар. Һәркемнең гариза-подпискаларында: «Кайда хезмәт итәргә ризалыгымны бирәм!» — диелгән. Өлкән лейтенант Глушков бернинди тәкъдим белән килешми. Әнә комиссия барыбер үзенекен кылырга тырыша. Анда бигрәк хәйләкәр кешеләр. Округны атыйлар да урынны (должностьны) әйтәләр. Округлар зур ич. Кайда һәм ничек урнашкан ул часть — анысы сер булып кала. Ниһаять, мина да чират житә. Комиссия алдында басып торам. Язмышым аның кулында. Факультетның яна житәкчесе генерал Огурцов: «ЗабВОда хезмәт итәргә тәкъдим итәбез!» — ди. Байкал арты хәрби округы инде. Иң начар округ. Без үзара: «Забудь вернуться обратно!» — дип тәрҗемә итә идек. Анда эләккән кешене тиз генә ычкындырмыйлар. Шуңа күрә ул округны «безвозвратный клапан» дип тә әйтәләр иде. ЗабВО — ул элекке Даур казакларның җирләре, комлы даладан һәм сопкаларыннан гайре берни дә юк диярлек. Һавасы — кырыс континенталь. Азык-төлек ягы такы-токы. Житмәсә, вабалы төбәк, русчалатып әйткәндә, «природная очаговость чумы». Декабристларны тикмәгә генә шунда сөрмәгәннәрдер!

Укуны яхшы гына тәгәлләсәм дә, берданбер татарга юри шунда өлеш чыгаралар! Ләкин, бер дә исем китмәгәндәй, бераз дәшми торганнан соң: «Юк,

мин аннан да арырак, Хабаровск якларында хезмәт итәргә телим!» — дидем. Огурцовның гаҗәпләнүеннән тешләре ыржайды, чөнки монарчы берәү дә ул якны үзе сорамаган!

«Юк, кушкан җиргә барыгыз!» — дип җикерә бу. Миңа инде барыбер. Башым яшь, исән-имин. Намуслы декабристлар булган җирдә, әҗәлем җитмәсә, шәт, үлмәм әле!

Калинин әйтүенчә, быелгыдан да начаррак назначениеләр булмаган икән. Ә башта бөтенләй башкача планлаштырылган. Байтакларыбызны Мәскәүгә, Космик мединститутка алмакчы булганнар. Ләкин хәрби округ командующийлары моны белеп, хәрби министрга мөрәҗәгать иткәннәр: «Космос институтына граждан медикларын алсыннар, ә бу хәрбиләрне гаскәрләргә бирегез!» — дип. Министр килешә. Менә шулай, без өйләнгәч, төн кыскарды дигәндәй, юньле урынга эләкми калдык...

Инде көн дә сәгать унга Академия бакчасына сафка тезелергә йөрибез. Мәскәүдән киләчәк, язмышыбызны хәл итәсе министр боерыгын көтәбез. Олы Калинин безне барлагач карап чыга да, боерык килмәгән әле дип тарата. Хәл-әхвәлләрне белешкәннән, хәбәрләр алышканнан соң, кайсыбыз-кая китә шунда. Мондый хәл ун көнгә хәтле сузылды. Димәк, Ленинград белән саубуллашып йөрергә вакыт булды. Кайчан кабат күрергә туры килер әле бу гүзәл каланы?

Яшь чакта белештерми, әле вакыт бар, вакытыбыз күп, дибез. Юк шул, ваемсызлыктан шулай уйлыйбыз. Чынбарлыкта вакыт гел кысылганнан-кысыла бара, сыеп булмый, узганың күрми-сизми дә каласың. Аның җитми калуына соныннан бик үкенергә туры килә. Менә хәзер бигрәк тә якынайган Alma mater, дус-ишләр вә мөгаллимнәр белән хушлашыр вакыт җитте. Башта бу көн бик ерак, һич килеп җитмәс кебек тоела иде. Инде югары белемле хәрби белгеч дәрәҗәсенә ирештек, куанасы иде кана. Тик җаным тыныч түгел шул. Мәрзия өчен унайсызланам, аны шушында, адаштыргандай, ятлар арасында калдырасы бар... Югалмасмы? «Нык торса, көче җитсә, югалмас, нәни бала түгел!» — дип, яхшыга юрыйм. Мин андый сикәлтәле сынау юлын исән-имин үттем ич! — дип, тынычланырга тырышам. Ләкин Байкал аръягы да куандырмый.

Тормышымның чираттагы кискен борылышы, киләчәкнең билгесезлеге борчый...

Боерыклары килсә, тиешле юлламаларын, билет-багаж кәгазьләрен һәм тиешле акчаны алып, бер айга ялга һәм аннары гына билгеләнгән яна частька китәсе. Ялымны туганнарым белән үткәрергә булдым.

Миңа юл кәгазьләрен тәки Чита шәһәренә язганнар! Җыена башладым. Мәрзия, сизсә дә, сер бирми. Сөйләшкәнебез юк. Әләкләгәне өчен ачуым узмаган.

Артык кием-салымнарымны, урын-җиремне һәм байтак җыелган конспект-китапларны хезмәт итәсе урынга багажлата, үземнән алда җибәрмәкче булдым. Бар иде заман, ни багажлар, ни контейнерлар таланмый иде! Шикләнми тапшыра торган идек. Чакырмасам да, багаж тартмаларының тышларын тегешергә Мәрзия барды. Аны багаж адресы кызыксындырды бугай. Шулай булса да, эчемнән рәхмәтле идем. «Әллә акылга утыра башлаган инде?» — дип уйладым. Юридик яктан аерылмаганбыз ич әле. Сонарып булса да тормыш акылга утырта ул. Багажым ике урын, ә чемоданым үзем белән. Димәк, «omnid mea mecbm porto»! Артык сөйләшми саубуллаштык та, һәркайсыбыз үз ягыбызга киттек. Кем белә аны, тагы очрашырбызмы, тәкъдирдәниләр язылгандыр?

Мәрзиянең күңелендә ни булгандыр, ә минем балтам тирән Нева суына төшеп батты инде әллә! Китте башым Себергә! Бер үк мәлдә үкенеч тә, кызганыч та. Хуш, Ленинград, хуш Мәрзия, әлегә калып торыгыз! Поездда коелып утырам. Утыздан узганмын, ә тормышым һаман җайланмаган...

Күңелсез инде. Болай бүтән яклардан кимчелекләрем юк, уңган кеше кебек үзе, ләкин зәгыйфь, бичара сыман «ни башлы, ни күзле»!.. Буйдак булып

кайтуым атам-анама да күнелле түгел. Әнә яшьтәшләрем инде икешәр бала үстерәләр, кинәнеп үз гаиләләре белән гөрләшеп яшиләр, ә мин һаман да берүзем. Тормышның котылгысыз прозасы бар бит. Чит-ят җирдә ялгызым ничек хезмәт ителер, кем кайнар аш хәстәрләп ашатсын вә чәй эчерсен? Димәк, тагын өйләнергә кирәк булачак, гомерем бер генә ич!

Яраланган йөрәгемнең бер өлеше Ленинградта кала. Алда да әллә нинди куанычлар көтмидер сыман. Гомеремнең нәүбәттәге утә мөһим борылышы менә башланды инде. Мин утәсе юлны берәү дә үтмәс. Тагы асыл офык шәфәгенә таба омтылырга кирәк.

Өйгә кайтып керүгә куанышсак та, артык очынып йөрерлек сәбәпләр юк. Кайтуымны Мәрзия хатыннан белептер, агасы Мөхәммәтзыя килеп: «Сенлемне әрәм итеп, адаштырып ташлагансың икән!» — дип сукранды. «Ике кешенең мөнәсәбәтләре берсенә генә кагылмый. Сенлең дә әулия түгел!» — дидем. Шуның белән сүз бетте. Мәрзия белән мөнәсәбәтләребез икеле-микеле булса да, әнинең күнеле Хәдиягә тартыла. Аны да аңларга була. Кемнең генә анасы улына яхшылык теләмәс икән?! Үзем дә аптырашта, башым әйләнгән чак. «Хәдия исеңдәме? Син аны танымассың, ул хәзер менә дигән җиткән кыз. Госпитальда шәфкать туташы булып эшли һәм мединститутта укый, алтынчы курска күчкән. Ул инде монда берүзе генә. Атасы вафат булгач, әнисе икенче кызы Галия белән туганнары янына — Промстройга күчеп китте. Күптән түгел генә мунчада күргән идем, килешмәгән җире юк. Синең турыда бик сорашты!» — диде ул. Сүзен кай якка таба борганын тел төбеннән аңлыйм. Тормыш бит бу. Һәркем үзенә яхшыны тели... Хәдияне дә ачык хәтерлим. Бала чагыннан ук беләм. Мәктәпкә барганда, тәрәзә каршында утырган кечкенә Хәдиягә дәшеп уза торган идем. Тиз үсәләр шул кызлар!

Шулай, әни аның белән сөйләшеп тә караган икән. Хәдия синең белән очрашырга риза, ди. Җәһәннәмгә китәр алдыннан тилергән башымны кемгә иярргә соң? Ерак гарнизоннарда һөнәрле һәм булдыклы тормыш иптәше кирәк инде ул. Бер уйласаң, Хәдиянең бар ягы килгән.

Ни булса да булыр, очрашып, сынап карыйк. Бәлки, бер купкан җаным урынына утырып тынычланыр? Белмим шул, икеләнәм. Нигә генә болай берсеннән-берсенә сугылам соң әле? Әллә чын мәхәббәтнең ни икәнен моңарчы татымаганмын инде?.. Аннан, Мәрзия алдында да үземне гаепле һәм җаваплы кебек тоям. Ят шәһәрдә берүзе генә таянычсыз калды бит!.. Ләкин ирләрнең артык уйланмый, акылга буйсынмый торган чаклары була икән шул. Әллә инде безгә кыргыйлардан калган полигамия атавизмы уйнаклый?

Биредә аралашыр дус-ишләр булмагач, ялгызлыктан чарасыз димме, үзенә бертөрле күңел ачу булыр дип, ахырда Хәдия белән очрашып, уртак тел табып, ансат кына сөйләшеп киттем. Зифа буйлы Хәдия элекке кечкенә, кара бөдрә чәчле кызчык түгел инде. Житлеккән, күз карашларында тирән уй. Бөтен җире коеп куйган курчак! Тик чырае сүренке. Житди һәм бераз казакъларга тартым. Тавышы үзгәргән, ниндидер ят, еламсыраурак. Ул яклары ошап бетмәсә дә, очрашканнан ни зыян? Хәдиянең үзенең дә башы бар бит. Шулай очрашкалый торгач дуслашып та киттек, бер-беребезгә тартыла башладык.

Менә шулай, уеннан уймак чыга. Яшьләр бит, мавыгып, вакытында тыела белмибез. Эш тирәнгә киткәч, әти-әни: «Улым, болай ярамас, мөселман баласы бит, никах укытырга кирәк!» — диделәр. Гаебемне танып, карышмадым. Хәдия алдында бурычлы идем инде. «Аһ, Хәдия — Хэд, ничек болай булып чыкты соң әле бу? Нигә болай җинел генә хискә бирелдек? Хис бит ул үзгәрүчән!» Мин анарга шулай, инглизләрчә, исемен кыскартып «Хэд» дип дәшергә күнеккән идем. Ул мина ышанган иде. Ышанычын аклый алмадым. Кеше белән гомер буе яшәсәң дә, аны ахырына хәтле белеп булмыйдыр шул.

Хәдия шашынулы, чиксез хискә, шатлыклы вә төшенке халәткә бирелүчән булып

чыкты. Бүтән сүз белән әйткәндә, экзальтацияләнүчән. Баксан, сабыр вә житди тышкы кыяфәтенә туры килми, эчке яктан бөтенләй бүтән кеше икән ул.

Бер генә елмайганын да хәтерләмим аның. Мондый затлар тиз туйдыручан була. Гомер буе шундый булса, нишләрмен? Без ирләр шундый инде, менә дигән хатын-кызларның печтик кенә кимчелеге табылдымы — бетте-китте!

Әйтерсең, үзебез Йосыф кебек үтә камил затлар! Әллә кемнәрне сайлаган булабыз! Юк, тәүге гыйшыклар эзсез узмый ул. Таләпчән күңелнең түрендә аларның жылылыклары сүрелеп бетми саклана бирә. Сөю бер генә була, диләр. Әлбәттә, мондый матур фикергә кемнәрнеңдер ышанасы да киләдер. Романнарда һәм шигырьләрдә бу турыда бигрәк мавыктыргыч итеп языла әнә. Тик аларда хыял белән хис буталыша бит!.. Бәлки, бер сөюгә генә бирелеп яшәүчеләр дә бардыр. Ләкин минем «бердәнбер сөю» фикере белән килешәсем килми. Гомер булгач, сөю дә, сөйгәннәреңне күралмау халәтенә төшү дә берничә мәртәбә кабатланырга мөмкин. Сөю бер генә булса, кешеләрнең нәсел җепләре тиз арада өзелер иде... Кыскасы, әкренләп Хәдиядән бизә башладым. Кешенең «күңел» атлы бик нечкә кылы бар. Ул фальшьны сөйми һәм үзенә килешмәгән-ошамаганны якын итми. Күңел белән көрәшеп тә, аны алдалап та булмый. Ул акылга буйсынмый. Бусы укымышлы, кеше күзенә күренерлек булса да, нәфис Мәрзияне кызганып, аны сагына ук башладым.

Бусы белән дә эшем барып чыкмады, тагы абындым, аякларым ике генә шул! Тик ялгышуларым күпкә китте. Эш узганнан соң гына уйланучан шул яшьлек. Инде гөнаһларга билдән батып беттем, тукталып нокта куярга кирәк! Ни кылсаң да, яхшысы да, яманы да үзеңә кайтачак, диләр. Хәдия белән укмашып, уртак серләр белән яши алмаячагымны ачык аңлыйм.

«Кыйбласы-максаты бар, таза, аякларында нык басып тора, шәт, югалмас!» — дигән нәтиҗәгә килдем һәм, ялым узгач, үзем генә китәргә булдым. Хәтере калса калыр, инде күңелемне ул түгел, билгесезлек, киләчәк хезмәтем борчый. Анда нинди тишеккә тыгарлар икән? Ә атам-анам бигрәк Хәдия өчен, эшебез пешмәгән өчен борчылалар. «Кыз әрәм булмаган!» — диләр. Юкка гына әни белән башын әйләндердек, ә мин — тинтәк ник үз акылым белән яшәмим соң? Китәсе вакыт та житте. Килүләр, китүләр!.. Әйтерсең, жил куып арлы-бирле йөрибез... Китүләрнең дә төрлесе була. Урамда төксе, шомлы көз. Көн шактый сүрелгән. Халык плащлар, көзге бишмәтләр кигән. Саубуллашуларыбыз бу юлы бигрәк күңелсез. Хәдиянең ике күзендә сорау билгеләре. Үзем дә юньләп белмәгәнне ничек аңлатып әйтим? «Кичерә алсаң, кичер мине һәм каһәрләмә, Хэд, мин тилерүемнән айнадым!» — дим ишетелер-ишетелмәс кенә тынгысыз перронда һәм шуның белән вәссәлам! Ишетте микән? Хәдиягә туры карый алмыйм. Вөждан газабы бигрәк авыр. Әти, әни, Кәшифә һәм Нажия, хәлне аңлаган кук, дәшми генә көтеп торалар. Китәсе поезд да, сабырлыгымны сынагандай, һич кузгала алмады инде! Айга тиң мизгелләр...

Менә, ниһаять, электровоз вагоннарын йолкып кузгалды һәм тизлеген арттырып тәгәри башлады. Сагыш белән тулган күзләр ерагайганнан-ерагаялар...

«Хуш-сау булыгыз, мине гаеп итеп, нәфрәтләнеп калмагыз! Хәерле сәгатьтә — хәерле юл! Ходаем, хәвеф-хәтәрләрдән, бәла-казалардан туганнарымны һәм якыннарымны сакла! Изге ниятләребез белән аңга килгән идек, ләкин тимуг юлы да изге ниятләр белән түшәлгән, диләр... Дөньяда, нарасыйлардан гайре, гөнаһсыз адәм юктыр. Гомумән, мин гөнаһсыз!» — дип шапырынырга берәүнең дә хакы юк. Ләкин гөнаһлы гамәлләрен таныган кеше дөм өметсез түгел әле. Аһ, Аллам, мин гөнаһларга батып беттем, кичерә алсаң, кичер инде, моннан ары андый булмам!..»

Иреннәрем кыймылдап, тагы әллә нәрсәләрне әйтергә омтылалар. Инде хәзер хисләргә бирелеп кенә түгел, акыл белән дә яшәр вакыт.

Мине инде торасы яна урын да, хезмәтем дә кайгыга салмый. Кеше кайда да

эшләп, хезмәт итеп яши ала. Анысын булдырырмын. Аерып калдырган Валя да онытылган диярлек. Хәдия турында да артык борчылмыйм. Тик Мәрзия генә тынгылык бирми, Себер юлы буе аның турында уйлап барам. Юл күренешләре дә юатмый, күземә дөнья галәмәтләре күренми. Нишләп кенә аны япа-ялгыз шул зур калада башын әйләндереп адаштырып калдырдым?

Яман юлга басмаса ярар иде! Аздыручылар бихисап. Очсыз, бетмәс озын юл, кысан тынчу купе һәм җан газаплары тәмам алҗытып бетерделәр. Ахырда, барып урнашкач, хат язып җибәрергә булдым. Кеше ялгышырга мөмкин, ялгыша да. Ләкин хатасын таныгач, аны төзәтергә тиештер ич! Мәрзиянең күңеле бизеп, кире кайтмаган булса, аны яныма чакырырга кирәк. Яңадан бергә уртак тормыш корырбыз... Берәү дә бөтен эшләргә оста, маһир вә әүлия булып тумый. Белмәгәннәрен өйрәтермен, ярамаган гадәтләрен әйтеп төзәттерермен! Авыр булса да түзәрмен. Кыргый аюны да биергә өйрәтәләр ич, Пигмалион әсәрен дә хәтерләү җитә! Менә шулай, үземә-үзем сүз биргәндәй һәм сүземдә нык тормакчы булам. Андый карарга килгәч, бераз тынычланам сыман. Минем күңелсезләнеп баруымны сизептер инде, проводница, чәй керткәндә: «Кемегез булды ул читтәрәк басып торган күркәм кыз?» — дип сорады. Мин: «Барыбер түгелмени?» — дидем. Бүтән нәрсәләр турында уйларга тырышам. Корыч көпчәкләр дөбердәп, җелекләрне селкетеп тәгәриләр. Тимер дәвер! Үзәк төбәкләрдән ерагайганнан-ерагая барам. Кечкенә чагымдагы сөрелеп баруыбыз исемә төште. Вагон тәрәзәсеннән күземне алмыйм. Яфракларын коеп, чишенә башлаган урманнар, телеграф баганалары, шыксыз разъезд тораклары, чәнечкеле тимер чыбык белән уралган ниндидер зоналар артка чигенеп күздән югала торалар...

Уйланам. Уйлар, уйлар!.. Бер-берсен уза-уза чаба алар. Әллә инде зиһенем чуаламы? Нигәдер тагы йөрәгемне чеметеп Валя искә төшә. Юк, бөтенләй онытылмаган икән шул. Бигрәк ягымлы һәм шаян, көр күңелле иде. Югалтсам да, ул үзе югалмас инде. Крупская исемендәге институтның кичке факультетында укып эшли. Аның өчен кайгырмасам да була, ләкин менә, исемә төшкәч, йөрәгем нигәдер кысыла... Узган гомер кызгандыра һәм үкендерә. Тик аны кайтара алмассың инде. Валя табар әле үзенең ише урысны. Хәдия дә югалмас. Үзе таза, башы яшь, диплом алырга тора. Ә менә Мәрзия тынгысыз олы шәһәрдә югалмагае, саулыгы да чамалы гына!.. Йөрәгем дөпелдәп, поезд дөбердәве белән ярыша. Ул хәтле өзгәләнмәскә иде лә!.. Хаталарымның берсен инде төзәтергә мөмкин ич...

Ниһаять, менә ул үтә кырыс Байкал аръягы далалары. Җәй уртасында да кичләрендә вә төнлә сарык яки эт тиресеннән тегелгән «себер майкасыз» дер-дер калтырарлык тараф — борынгы төрки кардәшләребезнең җирләре... Берничә көн көпчәкле сандыкта кабыргаларны сындыра язып интеккәннән соң, Чита вокзалына килеп төштем. Багажым инде монда булырга тиеш. Вокзал комендантыннан кая сугыласын белешеп киттем. Штаб нәкъ шәһәр уртасында икән. Барам. Шәһәрнең үзәк урамнары гына шәһәрчә. Бераз арырак узып, кырыйгарак тайпылсаң, тузан-комлы шыксыз авылга әверелә дә куя!

Менә мина кирәк ике катлы кечкенә бина. Нинди күрәчәк көтә мине монда? Кизү торучы офицер язуларымны тикшерде дә кемгәдер шалтырата. Өстән, кадрлар начальнигы бугай, төшеп, мине дивизия командиры кабинетына ияртеп китә. Керәбез. Өстәл артында чибәр, яшь генерал утыра. Алдына кылт итеп үрә басам да, тиешенчә рапорт биреп, кем икәнемне әйтәм. Генерал утырырга тәкъдим итте. Шул арада сер бүлеге начальнигы ЗАС телеграммасын тотып керде һәм генерал алдына салды. Генерал аны укыды һәм башын күтәреп мина бакты. «Хәсәнов дигегез бугай?» «Әйе!» — дим. «Алай булгач, менә укыгыз, Мәскәүдән сезне Хабаровскига юлларга боералар. Монда хезмәт итәргә сезгә насыйп булмады!» Могҗиза бит бу! Мәскәү комиссиясе, кирәгем чыккач, Хабаровск краенда хезмәт итәргә таләвемне искә алган, димәк.

Генералга мөрәҗәгать итәм: «Иптәш генерал, багажымны яна жиргә күчертәсем бар!» — дим. Ул, анлап: «Өч көн житәме?» — дип сорый. Юмарт икән, «Житә!» — дим. «Ярый, килештек. Хәерле юл сезгә!»

«Рәхмәт!» — дидем дә борылып чыктым. Строевой бүлектә предписаниемне янартып, әлеге телеграмманы кыстырып һәм багаж таләбен юллап, бу штабтан подписка биреп ычкындым.

Инде түбәнге очка, сай гына, тавык та тәпиләп чыгарлык, вак соры комлы инеш аша кирпечләргә баса-баса чыгып, багаж пакгаузына юнәлдем. Бу инеш дигәнем бигрәк алдакчы икән. Ул еш кына янгырлардан соң һәм язын-көзен туфан суына әверелеп ярты шәһәрне баса икән! Мин Чиләбедә яткан арада әйберләрем килеп өлгергән. Багаж шактый таушалган. Бауларын тарттырып, теккәләп, адресларын кара белән буяп, яналарын язып, тагы тапшырдым. Инде каланы да янә бер әйләнеп карарга була. Кунакханәдә кунып чыкканнан соң, китәргә ниятләдем, чөнки Читада мине кызыктырырлык һәм тоткарларлык берни дә юк иде. Ике тәүлектән соң Хабаровск вокзалына килеп життем. Читага якынлашканда, поездда икешәр юрган бирүләренә карамастан, суыктан калтыранып кунган идек, ә монда, төн уртасы булса да, жылы бөркелеп тора! Ичмасам, бу яктан алдатмаганмын икән.

Менә таң атуын чиста вокзалда, юньле киенгән кешеләр арасында көтеп утырам. Берничә тапкыр вокзал мәйданына чыгып, казак Ерофей Хабаров һәйкәлен урап үттем. Менә ул татар качаклары токымыннан булган урысларның данлы «землепроходецы». Баскынчылар үзләренә атамаларны таба белгәннәр дә соң! Биек, зур һәйкәл. Чиләбенең «Сказ о Урале» һәйкәленә охшаган. Шәһәр Чита ише генә түгел! Күп катлы биналар, урамнары чиста, агачлары яфракларын әле коймаганнар. «Дальний Восток» дигәннәренең бер өлеше шушы инде.

Ерак Көнчыгышны килмешәкләр дөньясы дисәк тә була. Бу якларда аларга хатын-кызлар житмәгән. Ул мәсьәлә инде мина да кагыла. Тагы ялгызлыгым исемә төште. Бер риваятькә кагылмый булмас. Имеш, Әби-патша Екатерина II казакларга яулап алынган жир чикләрен сакларга боера (шушы Ерофей Хабаров төркеме кебекләргә). Ә аларны тиздән хатын-кыз юклыгы борчый башлый. Япан-ят якларда, сугыш булмаганда, ирләр хатын-кызларсыз ничек яшәсеннәр ди? Патша галижәнабына бу хакта ялварып хат язарга мәжбүр булалар. Хатның ин кирәк өлеше ике сүз була: «Пришлите бабсто!» Патша кәнсәсендә «бабсто» мәгънәсенә төшенә алмый аптырыйлар. Ләкин, баш вата торгач, анлыйлар һәм бөек хужалары белән рәхәтләнеп шаркылдап көләләр. Хат язучыларнын белемнәре чамалы булганга, казаклар «баб сто» сүзләрен кушып язганнар икән! Билгеле, әби-патша хәлләренә керә. Ул үзе дә сонгы көннәренә хәтле ирләрсез һич тора алмаган ич. Менә шуннан соң казаклар урнашкан урынны «Бабсто» дип атый башлыйлар.

Хатын-кызлар кытлыгы Сахалин каторгасында да үзен нык сиздергән. Хөкемгә тартылган хатыннарны анда, пароход белән китерүгә, каторжаннарга өләшкәннәр.

Егерменче гасырнын утызынчы елларында купкан «хетагуровкалар» шаукымы да әлеге дә баягы шул ук «бабсто» мәсьәләсе. Ерак Көнчыгышны шыплап совет хәрбиләре белән тутыргач, ирләргә хатын-кызлар кирәк була башлый. Һәм иргә чыга алмаган жилбәзәк-кәнтәй хатыннар, сөрсеп беткән кызлар Ерак Көнчыгышка агыла. Ә аларны кыстап-өндәп һәм озатып йөрүче Хетагурова Ленин ордены белән бүләкләнә.

Ярый, үз язмышыма күчим.

Иртән, комендант килүгә, кая барасын белештем. Яна гына оешкан ракетачыларнын корпус штабы Кызыл елга исемле жирдә, автотранспорт училищесы янында урнашкан икән. Автобус белән ун ягымнан дендропарк вә жиләк-жимеш совхоз бакчасын узам. Корпус табибы, Читадагысы күк,

чираттагы ялында икән. Аның кайтуын көтәргә туры килә. Монда төрле төбәк-округлардан күчерелгән офицерларга бер казармада вакытлыча ике катлы тимер сәкеләр тезеп куйганнар. Төрле хәрби частьларны кыскартканда, булдыклырак офицерларны ракетачылар частьларына юллаганнар. Н.Хрущёвның мотопехота вә башка частьларны кыскартуы ракета гаскәре файдасына булган икән! Монда инде халык күп җыелган, язмышларын хәл иткәнне көтәләр.

Аннары кайсы-кая китәсе. Биредә капитан Завгородный һәм лейтенант Александровны очраттым. Беренчесе, кайда нинди урыннар булуын белешсә дә, сер бирмәгән була. Кыек юл белән йөргәнем юк әле һәм йөрмәм дә! Бер тәүлектән соң мине кадрлар бүлегенә чакырттылар. Моннан 65 чакрымдагы частька мине өлкән табиб урынына Мәскәү боерыгы буенча билгеләгәннәр икән. Ләкин анда фатирлар әле төзеләсе генә. Юк, мәйтәм, фатирсыз иза чигеп туйдым, мина фатирлы урын бирегез, дим. «Менә Белогорск шәһәре артында, Возжаевка полустанкасында фатирлы, кечерәк хәрбиләр гарнизоны бар-барын, ләкин сез бит Мәскәү боерыгы белән өлкән табиб итеп билгеләнгәнсез инде! Түбәнрәк урынга төшерергә хакым юк. Аннары аларны да бер елдан соң тайгага күчерәбез!» — ди кадрлар бүлеге начальнигы. Ярар, мәйтәм, кечерәк, ләкин фатирлы урын булсын. Үгетләп карый, мин күнмим. Яна эшне кечкенәрәк урыннан башлап җибәрсәң, бәлки отышлырак та булыр дип уйлыйм. Ахырда Белогорск (искерәк исеме «Куйбышевка Восточная») дивизиясенә юлларга булдылар. Шулай итеп, майор урыныннан баш тартып, капитан урынына ризалаштым. Әле капитан мәртәбәсен аласы бар, аннары гына дүрт ел майор йолдызларын көтәсе. Вакыт бар. Анарчы ниләр булып бетмәс. Әрҗәсе тәмам какшап, төеннең баулары суырылып-бушап калган багажымны Возжаевкага юлладым. Бусы инде өченче мәртәбә адрес үзгәртүем! Менә ул хәрбиләрнең тормыш рәвеше!..

Буш вакытымны заяга уздырмыйча, өч көн шәһәрне, мәгърур Амур елгасын карап йөрдем. Ике үзәк «фирменный» ресторанннарында (берсе — «Уссури», икенчесе «Восток» исемле) сыйландым. Төрле дингез хәзинәләре пешереп салынган салатлары миңа тансык булгангадыр инде. Тәмле үзе.

Треплангалы борщлары да шәп иде. Тагы кайчан шундый юньле аш-ризыкларын ашарга туры килер, эләккәндә сыпыртып калырга кирәк.

Амур елгасы искиткеч киң һәм тирән икән. Менә ул борынгы вальска кергән һәм «Өч танкист» җырында яңгыраган дәрьялы як! Киноларда күргәнем һәм җырын байтак җырлаганым бар, әмма үз күзең белән күрүгә җитми инде. Академияне тәмамлаганчы, бу якларда булачагым башыма да килгәне юк иде. Амур елгасының вә мондый Ерак Көнчыгыш җирләренең тәэсирләре тирән булды. Бигрәк иркен як. Китәсе көнне «тайфун» исемле явымлы давыл башланды. Якты көне тәмам карангы төнгә әверелеп, шәһәрне туфан суы басты диярлек. Тыгыз вә куәтле җил аяктан егарлык!..

Инде Хабаровскидан кире көнбатыш ягына, тулы сулы Амур аша озын корыч күпердән дөберләп чыгып, поездда Белогорскига таба юл тотабыз. Уң яктан шактый биек текә тау өстендә «Волочаевка көннәренә» багышланган мемориалны ерактан күреп узабыз. Партизаннар төбәге... Аннары сул яктан бер-бер артлы Еврейлар автономия өлкәсенең Биробиджан, Бира, Кульдур вә Шмаковка станцияләрен үтәбез. Кульдур ул — Саки шифаханәсенә, ә Шмаковка Боржомига тиң курортлар. Хәрби округ шифаханәләре. Автономия өлкәсендә яһүдләр бик аз, диләр. Алар бу ярымонытылган, тормыш яклары юньләп көйләнмәгән җирләргә үз ихтыярлары белән килеп оялмаганнар шул, Мәскәү, Ленинград, Киев, Минск, Одесса, Ялта кебек калалар булганда! Шмаковкада элек ирләр монастыре булган. Шушында инде утызынчы елларда Мәскәүдән яһүд партократларын Сталин боерыгы буенча колхоз-совхозлар оештырырга юллаганнар. Хәрби частьларны һәм эшчеләрне азык-төлек белән тәэмин итәргә кирәк ич! Бер мәзәктә әйтелүенчә, тиздән Мәскәүгә

мондый телеграмма сукканнар, имеш: «Колхозлар оештырдык, колхозчыларны җибәрегез!» Булыр да ул яһүдләрдән! Хәзер исә: «Еврейлар автономиясенә еврейлар җибәрегез!» — дисән дә була...

Белогорск зур урыс авылын хәтерләтә. Калага архитектор тәтемәгән. Берничә ике катлы кечкенә таш биналары бар. Берсендә, гадәттәгечә, партия шәһәр комитеты, икенчесендә дивизия штабы, өченчесендә мәктәп, дүртенчесендә ресторан. Калганнары бер катлы гади агач өйләр. Урамнары пычрак, кибетләре ярлы. Шәһәрне бер яктан урап сай гына тонык инеш ага. Янгырлардан сон шактый зур елгага әверелә, диләр. Ә җәйге эссе көннәрдә бөтенләй кибеп, төбе калкып чыгып, ләмле җирләре барлыкка килә икән. Үзендә әрсез вә талымсыз ратан исемле, бичок сымак, балыклары да бар. Шунысы кызык: елга корыганда, ләмгә күмелеп исән калалар икән!.. Һәр як табигатьнен үзенчәлекләре була шул. Рестораннарында (гади генә ашханә) тамак туйдыргач, штабка киттем. Кадрлар бүлегендә капитан Малыгин «шәхси эш»емне карап гаҗәпләнде. Анда хезмәт урыным «өлкән табиб» дип билгеләнгән ич! Бирегә үзем теләп киллем, дидем. Ярый, ди бу һәм Возжаевкага шалтырата. РТБны сорый. Аны шулай сер итеп, «Ракетно-техническая бригада» урынына «Ремонтно-техническая бригада» дип атыйлар. Андый ысулны «легенда прикрытия», диләр. Чынбарлыкта стратегик ракеталар полклар карамагында, ә аларнын үтә хәтәр атом-төшле башлары («головная часть» — ГЧ) — РТБ кулында. РТБ хезмәткәрләре аларны тоташтырып, вакытлары җиткәндә тикшереп яки алмаштырып торалар һәм махсус залда («технологик зал») икенче залпка запасларын тоталар. Мин менә шул РТБ табибы инде. Ике сәгатьтән соң мине алырга җинел машина белән килделәр. Утырып киттем. Возжаевка үзе бәләкәй генә полустанок. Тиз йөрүче поездлар нибары ике минутка гына тукталалар. Шул арада офицерлар вагон-ресторанга тәм-томнар, аракы-сыра алырга керәләр. Тимер юлнын, көнбатышка таба барганда, сул ягында — шыксыз авыл. Авыл артында — алты моторлы Мясищев бомбалаучылар аэродромы һәм совхоз басулары. Анда яшелчә вә соя борчагын чәчеп үстерәләр. Соядан дүрт йөз төрле ашамлык хәстәрләргә була, диләр. Томат шулпасы әрчелгән соя кәнсирләрен байтак ашаганым бар, туклыклы һәм тәмле ризык. Тик әрчелмәгән борчагы онынннан күнелгә авыррак исе килә. Шуна күрә анын исен бетереп, «дезодорировать» итәләр. Анысын да крафт капчыклары белән Прилукига, хәрби ашханәләргә китерәләр һәм кыздырып соус-подливкаларын әзерлиләр иде. Сонрак соя маена да ирештек. Анысы да күнелгә авыррак иде.

Тимер юлнын ун ягында хәрбиләр шәһәрчеге сугышка хәтле корылган. Элек анда хәрби очучылар һәм техниклар яшәгән. Кечкенә җир аэродромы һәм ике моторлы самолётларны төзәтә торган хәрби завод бар. Янәшәдә мәхбүсләр колониясе... Шәһәрчектә дүрт-биш катлы биналар. Аларда хәзер полк һәм РТБ офицерлары яши. Бер урамны ике фатирлы таш коттеджлар тәшкил итә. Аларны да офицерлар өчен төзегәннәр. Кайберләре буш. Фатир кирәк, дигәч, берсенә мине илттеләр. Ике бүлмәле, чоланлы, мичле фатир. Ул мина бик суык һәм шыксыз булып күренде. Моны жылытыр өчен яга-яга эт булырсын! Ә ташкүмерен-утынын каян юнәтәсе? Юк, мәйтәм, барып чыкмас. Теге дүрт катлы, жылыткычлы йорттан сорарга кирәк, дим. Нәкъ берсенен каршында — ике катлы агач лазаретыбыз. Чемоданымны һәм түенчегемне тотып шунда юнәлдем. Төнне лазаретта уздырдым. Иртән РТБ штабына барып, командирга күрендем. Кызыл чырайлы, Орёл фамилияле полковник. Эчәргә ярата, ахры. Командирлар безне сыныйлар, ә без — аларны... Мангаенда кыйпылчык ярасынын җөе. Сугышта булган. «Атнын — артыннан, ишәкнен — алдыннан, ә командирнын һәр ягыннан саклан!» — дисәләр дә, Орёл ярыйсы кеше булып чыкты. Венгриядә, Балатон күле янында яраланган! Шунда чолганышка эләгеп, сазлыкта ятып, аяк бармакларын өшеткән. Бирегә Уссурийсктан (Элегрәк

Ворошиловск) — танклар төзәтүче заводтан килгән. Шул танклар заводында хезмәт итеп, аның начальнигы булып, папахасын да киеп алган. — Полковник начальник урынына ничек билгеләнүе турында кызык итеп сөйләгән иде.

Әлбәттә, башта берәү дә начальник булмый. Завод начальнигының урыны бушап калгач, моны Хабаровскка, Округ штабының Хәрби Советына чакырталар. Анда инде безнең братваны кинәшмәгә чакырткан булып, йә пешекләп чыгаралар, йә югарырак күтәрәләр... Бу яңа киемнәрен киеп бара. Хәрби совет утырышы башлана. Бер мәлне моны да чакырып кертәләр. Командующий һәм Совет әгъзалары моның белән сөйләшергә керешәләр. Дөресрәге, партия сәясәте турында, устав буенча сораулар яудыралар, завод хәлләрен төпченәләр. Полковник урынына ярауярамавын сыныйлар. Ахырда генерал (политбүлек начальнигы): «Пушкин кем ул?» — дип сорый. Бу, андый, хезмәткә кагылмаган һәм һич көтелмәгән сораудан бераз югалып кала да: «Бөек рус шагыйре!» — дип җавап бирә.

Җавабыннан соң үзе: «Хәзер әсәрләрен сораштыра башласалар, харап булам!» — дип уйлый. Ләкин шундый «авыр» сорауга җавап бирә алгач, тегеләр канәгать калалар. Һәм бушаган урынга утырталар. Менә шул Орёл белән сөйләшеп утырабыз. РТБда штат тупланып бетмәгән әле. Офицерлары һәм солдатлары да җитәрлек түгел. «Сездә теге хәтәр нәмәстәләр бармы?» — дип, ГЧларга ишарәләп сорыйм. «Булсалар да, аларның бер куркынычлары юк! Мин үзем Тоцкое полигонында чын атом бомбасын шартлаткан хәрби уенга катнашкан кеше. Үземә бер нейтроны эләксә-эләккәндер. Саулыгыма әле дә зарланмыйм!» — ди. Әллә шулай үзен юаткан буламы, әллә атом нурланышына сай акылы белән җиңелчә карыймы? Әлегә аның ни икәненә бик күпләр төшенеп бетмәгәннәр.

Ул әйткәнчә, алай ук «пүчтәк» булмаган шул. Оренбург өлкәсенең «Тоцк» полигонында маршал Г.Жуков җитәкчелегендә 1954 елның 14 сентябрендә үтә зарарлы хәтәр хәрби уен үткәрелә. Анда самолёттан 20 килотонналы атом бомбасы ташлана. Ул 500 метр биеклектә шартлый. Шуннан соң «кызыллар» «зәңгәрләргә» зарарланган җир аша «һөҗүмгә» ыргылалар. Шул хәрбиләрнең бик күбесе нурланып, тора-бара чирләп үләләр. Исән калганнары да саулыкка туймый. Бу — табигатькә вә адәмгә каршы кылынган тиңсез җинаять. Бернигә дә карамыйча, СССРның чын-чынлап атом сугышына хәстәрләнә башлаган чагы бу. Монарчы Яңа җирдә, Якутиядә, Новосибирск өлкәсендә, Уралда, Әстерхан өлкәсендә, Казакъстанда һ.б. җирләрдә — барлыгы ике йөзгә якын атом сынавы үткәрелә. Күбесен халык хуҗалыгы мәнфәгатенә сылтап шартлаталар. Шулай булгач, зарарланмаган җирләребез калмаган диярлек. Әле дә мондый аяныч серләрнең күбесе ачылмаган һәм картага төшерелмәгән! Нәфрәтләнеп уфтанырга гына кала. Мондый җирләрне халыктан яшерү — кылган җинаятьләрнең рецидивы. Инде без чирләми кем чирләсен? Җинаятьче сәясәтчеләр кул астында яшибез ич. «Салкын сугыш мәҗбүр итте!» — дип акланган булалар. Юк, КПССның акылсыз сәясәте бу!

Орёл миңа дүрт катлы йортта РТБның элекке табиб бүлмәсен билгеләде. Шуннан соң яңа вазифамны үтәргә керештем. Миннән бер ел алданрак укып чыккан Зайцев медпунктны да оештырып ачмаган, санинструкторларның да хәстәренә тотынмаган, офицерларның һәм солдатларның медицина кенәгәләрен дә җыеп алмаган. Ә аларның саулыкларын тикшереп, шул кенәгәләргә язып куярга кирәк ич.

Чирләүчеләр була калса, лазаретка гына ияртеп китә икән! Әйтерсең, алты ел буена аны шуның өчен генә укытканнар! Булдыксыз лыгырдык нәмәстә үзен эре тоткан була тагы! «Яшь белгеч хатыныма монда эш юк, дипломы югала, бүтән урынга күчерегез!» — дип колак итләрен ашап, командованиене йөдәтеп бетергән. Инде аны менә Кызыл елгага күчерәләр. Тик ул киткәнче миңа тагы да яхшырагы — икенче каттагы иркенрәк бүлмә бушады. Анысын Уссурийскига китәсе Баландин бушатты. Диваннары кыйбатка төшсә дә, шунда ук сатып

алдым, ә Зайцевтан — керогазын һәм чиләген. Өстәлне һәм табуреткаларны частьтан китерттем дә багажымны алдым. Шулай итеп торыр урынлы булдым. Фатир үзе — өч бүлмәле, икесендә майор Мызников хатыны һәм ике малае белән яши. Аш бүлмәсе уртак. Ванна һәм бәдрәф бүлмәләре бар, ләкин сантехникасы корылмаган, канализациясе юк. Жиренә житкереп эшләргә куллары һәм акчалары житмәгән! Су урам колонкасында. Гомуми бәдрәф тә урамда. Бу хакта бер чит ил дипломатының сүзләрен гәжиттә укырга туры килгән иде. Ул, бездән ачы көлеп: «СССР ул — космик ракеталар вә жир бәдрәфләре иле!» — дигән. Бик дөрес әйткән, чукынчык! Мондый контраст адәм файдасына түгел инде. СССРда кешенең кадере булмады, аның шәхси мәнфәгатьләре беркайчан да артык санга сугылмады. Әнә шул такталардан әмәлләнгән бәдрәфтә кырык градуслы суыкта ыштаныңны төшереп утырып кара! Без ирләр чыдарбыз да ди, ә хатын-кызлар ничек түзсеннәр?! Ярый әле мич ягасы түгел, батарейлары бар. Аш-суны керогазда хәстәрләргә була. Миче бар барын, тик әлегә аның беребезгә дә кирәге юк.

Бүлмәм жылы һәм якты, түшәме биек, идәне такталы, тәрәзәсе лазаретка карый. Беренче катта кечкенә китап кибете. Эшкә, кибеткә, клубка, мунчага һәм ашханәгә йөрергә якын. Яна урынга иялэшеп өлгермәстән, көннәрнең берсендә без — өч офицер һәм ике старшина — Владивостокка рекрутларны алырга киттек. Мина Владивосток, андагы Алтын Мөгез култыгы, баш урамнары, яр буйлары, кибет-рестораннары, вокзалы һәм һәйкәлләре бик ошады. Ресторанга кереп ашап чыктык. Кит итеннән пешерелгән котлетлар һәм гарнирга пешерелгән дингез кәбестәсен бик ошатып бетермәсәк тә, талымлап торырлык ара юк. Тын океан камбаласы монда тавык ите урынына кулланыла икән. Ризык кытлыгы үзен сиздерә башлаган чак. Пешекчеләр һәм аш ташучылар масаеп, хәрбиләрнең кесәләрен селкетергә остарып беткәннәр. Сүз әйтер хәл юк икән. «Хәзер үк патруль-милицияне чакыртабыз!» — дияргә күнеккәннәр. Мондый урынсыз тәкәбберлекләре хакында бередә әле дә бер вакыйга турында риваять итеп менә ни сөйлиләр. Имеш, «Алтын мөгез» ресторанына бер төркем ирләр кереп утыралар, берничәсе кара тутлы кавказлы икән. Байтак көтеп утыра болар, әмма яннарына килүче күренми. Ниһаять, ак алъяпкычлы бер капкорсак алларына меню салып китә. Кыскасы, бездә — ресторан, маңгай бетләре — аракы-шәраб теләмәгәннәрне чүпкә дә санамыйлар һәм боларны да шактый изалыйлар. Ахырда болар шикаять кенәгәсен таләп итәләр. Анысын да киреләнеп бирми маташалар. Менә кечерәк, кәкре борынлы бер әрмән нидер яза һәм мөдирне чакырта. Анысы чыкмый. «Чыкмаса, прокурорга чакыртабыз!» — дигәч кенә чыга теге. «Укыгыз!» — диләр. Теге укымый. «Язгансыз икән, инде сыпыртыгыз!» — ди һаваланып. Тегене култыклап: «Юк, укыгыз!» — диләр төшемле итеп. Теге укый: «Весь обслуживающий персонал во главе с директором уволить! Микоян», дип. Директорның күзе акаеп, атылып чыгарга житә. Микоян ул чакта — наркомпищепром. Шуннан соң бүтән рестораннарны да кем икәннәрен онытканнардан әрчиләр. Хәзер исә мондый эш бер Микоян хәленнән генә килмәс иде.

Шулай, бередә табигать матур булса да, тормыш шартлары бик камил түгел икән. Һавасы бик дымлы, шкафлар да, хәтта кием-салым күгәрә, диләр. Бәяләр кыйбат. Монда барысын да ерактан китерәләр бит.

Владивостокның өлкә военкоматыннан безне Уссурийскига юлладылар. Уссурийск яшел бакчалы, күбесенчә бер катлы иске, тыныч кала. Кояшлы жылы көн иде. Тирә-юньдә күмер шахталары һәм терриконнар күренеп тора. Безгә шахта бистәсенең малайларын бирделәр. Мин кайберләренең саулыкларын тикшереп, кире кактым. Кайтканда алар белән шактый чиләндек.

Старшиналар калтыранып аракылы шешәләрен рельсларга бәргәләделәр. Хәер, мунча кертеп, чәчләрен китәреп, хәрби киемнәрен кидергәннән соң, аларны тиз кулга алдылар. Һәркайсын карап, медкенәгәләрен яздым. Казарманың

бер бүлмәсендә медпункт ачтым. Кирәк-яраклар белән җиһазландырдым һәм аптекадан дарулар китердем. Офицерларга һәм солдатларга тиешле ун сәгатьлек ВМП (военно-медицинская подготовка) дәресләрен укытырга керештем. Өйләдән соң авыруларны кабул итәм.

Орёлнын гаҗәпләнүеннән күзе дүрт булды. «Менә ничек эшләргә кирәк икән!» — дип ычкындырып җибәрмәсенме! Ялкау, кулын кесәгә тыгып йөргән Зайцевтан ул моны күрмәгән шул. Дивизия табибы подполковник Братаненкодан санинструкторлар сорый. Миңа алар дүртәү тиеш. Ләкин ул махы биреп, дивизиядән бер генә солдатны да Уссурийскига — санинструкторлар мәктәбенә юлламаган икән! Инде аларны үзебезгә әзерләргә туры килә. Әлегә булышырга үземә ике солдат алдым. Орёлга медпунктка тиешле сан. Машинасы — «УАЗ-451 А»сын югарыдан сораткан кәгазь яздырдым. Лазарет вә полк табиблары белән танышып, уртак тел таптым. Атнасына бер тәүлек лазаретта кизү торам. Анысы үземә тәҗрибә өчен кирәк. Шулай, барысына да тиз ияләштем. Әйтерсен, гаскәрдән алты ел аерылып тормаганмын! Шунысы мөһим: гарнизонда офицер гаиләләре үзара тату, бер-берсен якын итеп яшиләр. Үзенчәлекле зур бер гаилә булып дисәң дә була. Шуна күрә бирелгәге тормыш җинелрәк тоела. Тик менә үземнеке тулы түгел шул. Кайбер яшь хатыннар мина күз салгалыйлар үзе. Ә берсе, ире өлкән лейтенант Добрынин командировкада чакта, чиргә сабышкан булып, мине чакыртты. Һәр гарнизонда андый дәртле җилбәзәкләр табыла инде ул. Добрынин — моның икенче ире, беренчесе — очучы, һәлак булган. Керсәм, ул шәрә килеш елмаеп җәелеп ята! Әйтерсен, Рембрандтнын Данаясы Зевсны көтеп ята! Ак кабарынкы тәнен җентекләп тикшергәннән соң, билгеле, бернинди чирен дә тапмадым, «воспаление хитрости»дан гайре. Мине әллә хатын-кыз күрмәгән дип белә инде?

Тормыш якларына килгәндә, военторг кибетендә сайлап алырлык әлләни ризык юк. Ни китерәләр — халык шуны сыпыртып ала. Пешереп йөрисем килми инде. Чәй генә кайнатып, Болгария конфитюры белән ак майлы күмәч ашыйм. Күбесенчә ашханәдә пешерелгән ашларын тикшереп тукланам. Ә кайчакларда Возжаевка ашханәсенә барып киләм. Анда рәтләре юк, шакшы. Даими тикшереп торучы, күз-колак юк чөнки. Әй, ул Рәсәйнең «гражданка»дагы гади ашханәләре! Ярты халкыбызның ашказаннарын яраксыз ашамлыклары белән бозып бетерделәр. Аларда җыен угрылар һәм ялкау йолкышлар эшлиләр бугай.

Менә кинәт карлы, салкын җил-буранлы кыш бөтен мохитне яулап алды. Күз яшьләрен сыгып, колак-борын-янакларны өшетә. Төнлә саргылт вә зәңгәрсу йолдызлар чекерәеп калкалар һәм күз кысышкандай җемелдәшеп торалар. Калкурак аэродром тирәсендә җил каршы себереп, җирне шартлаганчы туңдырды. Бу аэродромга сирәк кенә кечерәк һәм ике моторлы таушалган самолётлар янартылырга килеп төшә. Тимер юлдан моторларын да китергәлиләр.

Монда тормыш бертөрлерәк. Буш вә озын кичләрдә клубка кино карарга йөрим. Фатирда үземә генә күңелсез. Клуб шыгрым тулы була. Офицер хатыннары киенешеп, үзләрен күрсәтергә һәм башкаларны күрергә ирләре белән шунда килми, кая барсыннар? Телевизорлар әле берсенең дә юк диярлек. Ял көннәрендә вагон-рестораннарны каршыларга җыелышып чыгалар. Автобус белән Белогорск кибетләрен дә айкап кайталар. Хәтта Благовещенск каласына да поездга утырып баргалыйлар. Минем андый йомышларым юк.

**Энәс ХӘСӘН.**
*Кырым*

*Дәвамы киләсе санда*

# «ӘХМӘТ ГАЛИ, ГӨЛЧӘЧӘК ГАЛИ...»

## 1. Ул пәһлеван җитәкче иде

24 гыйнварда дөньядан Әхмәт Галиев китеп барды. Кем соң ул Әхмәт Мөхетдин улы Галиев? Күпләрнен хәтеренә ул Казандагы элекке завод директорларының берсе буларак кына кереп калды шикелле. Онытy томаны мәрхүмнәрне тиз сарып ала. Әхмәт абый исә онытылырга тиешле кеше түгел. Әллә кем булып түш киереп йөрүчеләр күп ул, ә менә тормышны бераз гына булса да әйбәт якка үзгәртә алган милләттәшләребезне ике кул бармаклары белән генә дә санап бетереп буладыр.

Әхмәт абыйны мин беренче тапкыр «Татарстан яшьләре»ндә эшләгәндә, Компрессор заводындагы комсомол җыелышына баргач күрдем. Чын совет чоры әле бу. Комсомол өлкә комитеты секретаре заводның комсомол комитетына карата ялгыш фикер әйткәч, директор бу түрәне тулы зал алдында пыр туздырып атты. Соныннан белдем: партия түрәләренә һәм тулаем партия линиясенә дә бик исе китмәгән аның. Мондый хөрлек инде Казан Авиация техникумында укыганда ук сеңә башлаган (соңыннан ул Авиация институтын да тәмамлый). Казанга Мәскәү вузларыннан сөрелгән укытучылар да эшләп алган икән анда. Үзенә Сталинның чынлыкта кем икәнлегенә кадәр анлатып биргән (Сталин исән чакта!) керәшен татары Смолинны Әхмәт абый аерып атады. Миллият дәресләрен исә ул 5нче класстан Иске Чүрилегә йөреп укый башлагач, сабакташларыннан алган. Алар аны бик тә Алексейга әйләндерергә маташканнар. Гел шулай дип дәшә торган булганнар. Ләкин мона бер тапкыр да җавап алмагач, яна исемне йодрыклап кушмакчы булганнар. Уку беткәч, ике сыйныфташы аңа ияреп киткән. Ләкин бу юлы да барып чыкмаган. «Үзләренә күбрәк эләкте», — диде миңа Әхмәт абый. Болай дип тә өстәде:

— Заводта мин, баш инженер чакта да, директор булгач та, татар кешесе белән беркайчан да урысча сөйләшмәдем, бары татарча гына сөйләшә торган идем. Янымда торганнарның моны өнәмәвен сизгән хәлдә дә.

Әхмәт Галиев Суверенитет турында декларация кабул ителүне бик сөенеп каршы ала. Пассив күзәтүче генә булмый ул. 30 август көнне Ирек мәйданында анын йогынтысын тойган Компрессор заводы егетләре-кызлары да суверенитет даулый. Әхмәт Мөхетдин улының иң олы эше – Татарстандагы завод-фабрикаларны Татарстан юрисдикциясенә күчерүне башлап җибәрү. Ул чакта Татарстандагы предприятиеләрнең нибары ике проценты, район промкомбинаты, сөт заводы кебекләре генә Татарстанга караган.

— Ни уйлап алындыгыз сез бу эшкә? – 2006 елны үткәргән әңгәмәдә[1] Әхмәт абыйдан шулай дип сорадым мин.

— Икътисадның ни икәнен аңлаганнан килеп чыкты бу, — диде ул. – Байлыгын, милкең юк икән, синең бер хокукың да юк. Декларация кабул ителгән елны безнен заводтан СССРга биш миллион сумга якын[2] акча китә иде. Татарстанга күп булса шунын ун проценты гына калгандыр.

Союз белән, Рәсәй белән нык бәйләнгән завод бит бу. Шуңа завод коллективын беркайда үрнәге булмаган бу үтә тәвәккәл эшкә күндерүнең четереклелек кимәлен әйтеп бетерерлек кенә түгел. Бигрәк тә партком секретаре мона теш-тырнагы белән каршы торган хәлдә. Әхмәт абыебызның абруе һәм зирәк акылы гына җиңүгә китерә монда. Шуннан соң ул Татарстан премьер-министры Мөхәммәт Сабиров янына килә һәм «Мөхәммәт Галләмович, безнен бөтен байлык СССРга һәм Россиягә күчеп бара, безнен үзебезгә берни дә калмый, мин менә шушындый нәрсә оештырмакчы булам, сез мона каршы түгелме?» – ди. Сабиров исә: «Бик әйбәт булыр», — ди.

[1] Кара: Р.Юныс. Татар гаме. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2013.
[2] Иске акча белән бу.



Мондый диалог мине шаккатырды. Мин бит Әхмәт абый бу эшкә дәүләт житәкчеләребез тәкъдиме белән тотынган дип уйлап йөргән идем. Декларация кабул ителгәннән соң, бер елдан артык вакыт үтеп тә икътисад жәһәтеннән кыл да кыймылдатылмаган булып чыга түгелме соң инде, алайса?

Бу юлда икенче һәм өченче адымнарны да шул ук Әхмәт Галиев ясый: Казандагы «Вакуммаш» һәм Бөгелмәдәге Батырма насослар заводлары житәкчеләрен дә күндерә ул. Шуннан соң гына бу эшкә хөкүмәтебез алына. Татарстан юрисдикциясенә күчү, шөкер, ике-өч ел буена әйбәт кенә барып, азакта Татарстан карамагындагы предприятиеләрнең өлеше 92 процентка житә! Әгәр дә шунда Компрессор заводының директор кәнәфиендә бүтән бер кеше утырган булса?

Моңа охшаш тагын бер мисал бар. Референдумыбызга бик тә, бик тә халыкара күзәтүчеләр кирәк булачак дигән уй төн йокыларын качырган Илдус Садыйков атлы милләттәшебез Америкага китеп бара. Үз акчасына — машина алырга дип жыйган акчага! Һәм референдумга бик тә абруйлы күзәтүчеләр чакырып кайта. Әгәр дә шушы халыкара күзәтүчеләр булмаса, референдумны үткәртерләр иде микән? Үткән хәлдә дә, резонансы һәм юридик куәте күп өлеш кимрәк булачак иде бит. Нигә бу эш шәп кенә окладлар алып утырган дәүләт түрәләреннән берәрсенең тәкъдиме белән эшләнмәгән соң? Аларның барысы да диярлек татар язмышына да, Татарстан язмышына да битараф булганлыктандыр, бәлкем? Моңа шактыеның гыйлем һәм булдыклылык жәһәтеннән сайрак булуын да өстәргә кирәктер әле. Америкадан кайткач, Илдус абый кабаланып Шәймиев янына китә. Ике көннән приёмный аша үтә дә ала. Һәм, идея хуплангач, күзәтүчеләргә рәсми чакыру кирәклеген әйтә. Шәймиев: «Әйдә, хәзер чакыру да язып алып кил инде», — ди. Икенче көнне үк алып килә Илдус абый текстны. 25 февральдә, ягъни. Ул тинтерәтеп торуга карамастан, Шәймиев хуплаган текстны инглизчәгә тәржемә итеп жибәрү 9 мартка кадәр сузыла! «Менә бит, тәржемәче юк әле», — президент аппаратындагы берәүнең жавабы гел шул була! Үзем тәржемә иттертеп китерәм дигәнгә дә күнми ул. (Ярый әле Шәймиев текстны Илдус абыйның үзеннән яздырган! Янында кемнәр утырганлыгын чамалаган, күрәсең). Нәтижәдә күзәтүчеләрнең өчесе сонарыбрак — референдум алдыннан гына килеп житә. Америка татарлары исә бөтенләй килми кала — бу күзәтүчеләргә визалар әзерләнеп өлгерми. Ярый әле Илдус абый алга карап эш иткән. Татарстан Югары Советының референдум үткәрү турында карар чыгаруын (21 февраль) көтеп ятмаган, Америкага 13 гыйнварда ук килеп төшкән.

Түрәләр-түрәчекләрнең «гамьлелеге һәм булдыклылыгына» тагын бер мисал китерик әле. Тегесеннән ике-өч ел элек булган хәл бу. Сугыш башлангач ябылган татар яшьләр журналын ачар өчен Комсомол Үзәк комитетына хат язу кирәк була. Бу эш комсомол Өлкә комитетының бүлек мөдиренә йөкләнә. Туктаусыз бимазалап торган килеш тә ярты ел буена яза ул аны һәм тәки язып бетерә алмый! Бу эш өчен жан аткан Мансур Вәлиев белән Ринат Закиров үзләре тотынып, ярты сәгать эчендә язып ташлыйлар моны.

Туксанынчы елларга бөтен яклап мач килгән бердәнбер дәүләт чиновнигы Рафаэль Хәкимов булды шикелле[3]. Менә аңарда гакыл-белем дә, милли гамь белән фидакарьлек тә житәрлек иде инде. Нәкъ менә шуңа күрә Мәскәү басым ясап, аны эшеннән читләштереп тә тордылар хәтта. Менә шушы Хәкимов икътисад турындагы сүзен дә кистереп әйтте. «Без икътисадта үз сәясәтебезне кора алмадык,

[3] 1991 елдан – Татарстан Президентының фән, мәгариф, мәдәният һәм сәламәтлек, 1996 елдан сәяси мәсьәләләр буенча киңәшчесе.

уртак икътисади кыр дип мавыктык. Тоталар да Мәскәүгә чабалар, ни табалардыр анда», — диде ул.

Хәзер без йөзләрчә дәүләт түрәсе шәп кабинетларда шулай тыныч-мәнсез генә оклад арты оклад алып утырганда, Компрессор заводы директорының иненә өелгән гасаби йөкнең авырлыгын чамалап карыйк әле. Башта — сөенечле ягы. Элек табышның 35 проценты Союз бюджетына күчерелсә, моның 25 проценты Татарстан бюджетына керә инде, 10 проценты исә заводның үзендә кала башлый. Икенче айда ук заводта эшләүчеләрнең эш хакы арта. Ләкин шундук заводны икътисади буу башлана. Житештерелгән компрессорлар өчен акча элек дүрт көн эчендә килеп торган булса, акчаны инде Үзәк банк аша күчерә башлап, ул өчәр, дүртәр, бишәр ай йөри башлый. Димәк, эш хакын да, материаллар һәм электр өчен дә түләп булмый. Ник шартламыйсың шунда! Әхмәт абый нишли? Прокурор янына китә. Бу урында кайбер укучылар көлеп тә куяр әле. Тот капчыгыңны кинрәк итеп, янәсе, — хәзер, прокурор ана Мәскәүдән акча тутыртыр! Юкка көлерләр, тутырта шул! Кем янына барганын белә Әхмәт Галиев — 1992 елда Татарстан прокуроры ук ителгән Казан прокуроры Сәйфихан Нәфиев бит бу! Татарстан референдумын үткәртмәскә дип Мәскәүдән килгән прокурорлар бригадасыннан Татарстан прокуроры урынбасары Марсель Мусин белән бергәләп аны фидакарьләрчә саклап кала алган чын ир-егет! Ул, запрослар жибәртеп, гаепләнә таба һәм акча терәлгән жиреннән кузгалып китә торган була.

Татарстан карамагына күчеп ярты ел да үтми, хәрби заказларны да бер тәүлек эчендә туктаталар. Ягъни бөтен эшләп чыгару күләменең 38 процентын! Бер мең биш йөз житмеш кеше эшсез торып кала! Монда инде бөтен заводлар да, «Бирелэм!» дип, ике кулын күтәрер иде. Ләкин башында Әхмәт Галиев торган завод түгел. Аның житәкче буларак искиткеч булдыклылыгы совет чорында ук өч орден белән бәяләнә («Хезмәт Кызыл Байрагы», «Халыклар Дуслыгы» һәм «Почёт Билгесе»). Гыйлем, техник әзерлек ягы да бар бит әле. Әхмәт абыйны озату мәрасимендә (ул заводның ишегалдында үткәрелде) Татарстан предприятиеләре һәм эшмәкәрләре ассоциациясе президенты, күп еллар Вертолёт заводына житәкчелек иткән Александр Лаврентьев Әхмәт Галиевнең фәннең иң яңа казанышларын, иң шәп техник һәм технологик алымнарны гамәлгә кертеп эшләгәнлеген әйтте. Кешене теге дөньяга озатканда әйтелә торган төче сүзләр генә түгел инде бу. Административ житәкчелектән узмаган күп кенә башка директорлардан, бигрәк тә бу эшнең хикмәтен бөтенләй белмәгән килеш — танышлык-кардәшлек буенча гына куелганнардан аермалы буларак, бөтен нәрсәнең төбенә төшәргә яраткан Әхмәт абый үзләре ясый торган компрессор машиналарын да нечкәләп өйрәнә. Техник фәннәр кандидаты, аннары хәтта техник фәннәр докторы була! Бөтен Советлар Союзында ничә генә иде икән мондый завод директорлары? Моның нәтижәсе дә саллы. 120 градуска кадәр суыклык биргән суыткыч машина өчен 1981 елны Лейпцигта үткән халыкара күргәзмәдә завод алтын медаль белән бүләкләнә. Әхмәт абый үзе исә соңрак СССРның хөкүмәт премиясен ала.

Мәскәү, заводны аяктан егарга теләп, аннан хәрби заказларын алгач та югалып калмый Әхмәт Галиев. Яңа төр техниканы үтә тиз эшләү ысулларын таба алар. Һәм нибары ике-өч ай эчендә бөтен эшсезләр дә шуларны житештерә башлый. Аларга эшсез торган айлары өчен дә түлиләр хәтта. Алай гына да түгел, завод ныгытып экспортка эшләргә керешә, экспорт өлеше 38 процентка житә. Югары сыйфатлы машиналарны 44 илгә чыгара башлыйлар! 1993-1995 елларда завод Парижда (ике тапкыр), Мадридта, Копенгагенда, Женевада халыкара конкурс жиңүчеләре арасында була. Призларны алганда, Әхмәт Галиев татарча чыгыш ясый, чыгыш инглиз теленә тәржемә ителеп бара.

1996 елны исә, 65 яшендә, Әхмәт абыебыз эштән китте.

— Эшче белән завод директорының эш хаклары арасында аерма зур идеме элек? — шуннан соң ун ел үткәч гәпләшкәндә Әхмәт абыйга әнә шундый сорау да бирдем.

— Зур иде. Мин, беренче категорияле завод директоры булгач, өч йөз утыз сум ала идем, — диде ул. — Эшчеләр ике йөз сум тирәсе ала иде.

— Шул аерма зурмы? Ә хәзер директорлар күпме ала?

— Монысын мин әйтә алмыйм инде. Хәзер хезмәт хакын директорлар үзләре белгелиләр һәм сер итеп саклыйлар. Күп алалар дисәк, ялгышмабыз.

— Әхмәт абый, к-ү-ү-ү-ү-ү-үп алалар дисәк, бигрәк тә ялгышмабыз.

— Шулайдыр, эшчеләрдән йөзләрчә тапкыр күбрәк алучылары да бардыр дип уйлыйм.

— Татарстан җитәкчеләренең иң зур хатасы ни булды?

— Мөстәкыйльлекне якламау. Чигендек. Нык чигендек. Төп гаеп – хөкүмәттә, югарыда утырганнарда. Яуланган бөтен нәрсәне дә диярлек җуйдык.

Соңгы соравым шундый булды:

— Сез башлаган теге олы эштән ни калды, Әхмәт абый?

— Берни дә калмады. Янә бар да Россия кулында хәзер.

Заводның әле берничә генә ай эшләгән хәзерге директоры (Әхмәт абыйдан соңгы икенче директор бу), аны зиратка заводтан озатыйк дигәч, башта риза булмаган. Мәскәүдәге «Гидравлик машиналар системасы» дигән компанияләр төркеменең Казандагы компрессор машиналары җитештерү предприятиесе директоры була инде бу!

Озатучылар арасында эшчеләр дә күп иде. Берсе Әхмәт абый турында бик җылы сүзләр әйтте. Сөйләгәндә тавышы да калтырап куйгалады. Калтырамый ни. Татарстанлы һәм Әхмәт Галиевле шул 15 елда кинәт үсеп чыккан Сосновка бистәсендә ике йөз йортның яртысы завод исәбенә салына бит. Шәп проект буенча 18 катлы ике йорт төзелә. Җәмгысе өч меңнән артык гаилә фатирлы була! Заманча бик шәп итеп төзеп, биш балалар бакчасы ачалар. Эш хакы да шәп кенә арта. Әхмәт абыйның мәдәниятебезгә күрсәткән ярдәмен исә санап бетерерлек кенә түгел. Мин үзем 13 ел эшләгән «Идел» журналын да (шулай ук «Шәһри Казан» газетасын да), саллы матди ярдәм күрсәтеп, ул да ачышкан.

Әхмәт абый җәсәде белән бергә Сеҗе зиратына бер венок та барды: кабергә Татарстан Президенты, Дәүләт Советы һәм Татарстан хөкүмәте исеменнән салыначак венок.

## 2. «Сөйдем, сөелдем, әле дә сөям!»

Укучыларыбызның шактые түземсезләнеп тагын бер исем аталганны көтәдер. Бу – Әхмәт абыйның хатыны Гөлчәчәк Галиева. Ул да – гаҗәеп шәхес. Тотынган эшен бөтен күнелен биреп, онытылып-йотылып эшли торган кеше. Аны, әйтик, пионервожатый итеп куялар. Һәм ничәдер елдан ул СССРның иң шәп пионервожатые булып табыла! Казандагы 18нче кечке мәктәпнең шәптин-шәп директоры була. Житмеше тулгач, әдәби иҗатка тотына һәм... «Тулгак» дигән бәяны «Ел китабы – 2001» конкурсында икенче урынны ала! Аннан соң аның «Өзелгән өмет» дигән бәяны (2003) һәм «Газзәбану» романы да (2010) китап булып басылып чыкты (әсәрләренең өчесе дә әүвәл «Казан утлары»нда дөнья күрде). «Газзәбану»ның популярлыгы «Тулгак»ныкын да уздырды. Егылыплар укыды аны халык. Тулы килеш «Матбугат. ру»га куелып, компьютердан да укыдылар хәтта. Сыйфат ягы да әйбәт һәм анда татар тормышының ачылмаган катламы тасвирлана. Бу романы өчен апабызга Татарстан Язучылар берлегенең Сажидә Сөләйманова премиясе бирелде. Боларга тагын «Күнелемә якын затлар» дигән документаль китап та өстәлде (2007).

Мөхәммәт Мәһдиевнең беренче әсәре 39 яшендә генә басылу татар әдәбиятындагы гаҗәеп хәл дип саналса, Гөлчәчәк Галиеванын иҗади тыны җитмеш яшьтән соң шулай киң ачылып китүне ни дип бәяләргә кирәк?

Язмыш дигән режиссёр шушы ике гаҗәеп затны Мирхәйдәр Фәйзи ярдәмендә очраштыра. Арча районының Сеҗе авылында. Авылның драмтүгәрәк җитәкчесе – 19 яшьлек кызый! – «Галиябану»ны куймакчы. Үзе Галиябану була инде. Һәм ул, өйләренә килеп, гармун да уйныйсың, җырлыйсың да икән, Хәлил бул, дип... 16 яшьлек Әхмәт атлы үсмергә әйтә. Хәер, буй-сыны «жегетлярский» була инде үзенең! Шуннан аларның... үз «Галиябану»лары да башланып китә. Бер генә тапкыр куелмый «Галиябану». Сәхнәдә ике катлы драма барганны авылдашлары да тоя башлый. «Сеҗе Исмәгыйле» – завуч малае, Казан Елга техникумы студенты да гашыйк

була Гөлчәчәк-Галиябануга. «Өстәвенә чибәрлеге дә бар, буе-сыны матур, үзен интеллигентларча тота», дип язды аның турында Әхмәт абыебыз. Репетицияләр барганда Гөлчәчәкнең дә сокланулы карашы күбрәк «Исмәгыйль»гә тама. Ләкин үсмер «Хәлил» дә төшеп калганнардан түгел. Спектакльдә ул тәрәзәдән керүгә гармунын идәнгә куя да Галиябануны үбеп ала. Пьесада әйтелмәгән килеш бит бу! Уйнаган саен шулай итә «Хәлил». Һәм Галиябану Гөлчәчәк тә, режиссёр Гөлчәчәк тә моңа каршы килмиләр.



*«Хәлил» Әхмәт белән «Галиябану» Гөлчәчәк бу фотода мәңге яшь калырлар...*

Тагын дүрт елдан «Галиябану» белән «Хәлил» өйләнешәләр...

Шушы юлларны язганнан соң күтмәгәндә башка шундый бер уй килде: Әхмәт абый белән Гөлчәчәк апа кешелекнең меңнәрчә еллык тарихы фонында караганда да ин-иң шәп парларның берсе түгел микән? Фәрһәт һәм Ширин, Ромео һәм Джульетта, Ләйлә һәм Мәҗнүннәр, әйтик, тормышта чыннан да булдылар ди. Һәм алар, кавышып, уртак тормыш кичерә башладылар ди. Ун елдан, егерме, утыз, кырык елдан ничек яшәрләр иде икән алар? Үлепләр яратып өйләнешеп тә өч-дүрт елдан аерылышучылар юк мәллә? Култыклашып алсу болытлар эчендә йөргәндә йомылып торган «холыклар пар килмәү», эгоизм кебек нәрсәләр бергәләп дөнья күтә башлагач пылт итеп калкып килеп чыга бит алар!

Әхмәт абый белән Гөлчәчәк апа яратышып... 63 ел гомер кичерделәр!

Аларның, шөкер, кәгазьгә дә төшеп калган үз сүзләренә колак салыйк әле.

*Гөлчәчәк апа:*

— Без Мирхәйдәр Фәйзинең саф мәхәббәткә гомер буе тугры калыгыз дигән васыятен үтәдек.

*Әхмәт абый:*

— Кайбер кешеләр: «Картлыкта мәхәббәт була алмый. Ул бер-береңә ияләшүдән генә тора», — диләр. Ышанмыйм! Мәхәббәт бит ул күңелнең иң тәмле җимеше. Йөрәк, күңел беркайчан да картаюны белми!!!

*Ул ук:*

— Минем бәхетем муллан булды: сөйдем, сөелдем, әле дә сөям.

*Гөлчәчәк апа:*

— Яшьлектәге мәхәббәтне тапландырмыйча саклый белергә дә кирәк бит. Әхмәтнең бу самими хисләргә үзенең аңлатмасы бар: «Мәхәббәт ул — сөйгән кешең өчен яшәү, гомереңне ана багышлау. Аны бәхетле итәргә тырышу...»

Мәхәббәтнең нәфис тукымасын тиз арада умырып ташлый алган теге хәтәр сыйфатлар, шөкер, аларда бөтенләй булмаган да кебек. Әйтик, эгоизм, үзеңне алга кую, саранлык, вакчыллык, көнчелек. «Ул йомшак күңелле. Шәфкатьле», — ди Гөлчәчәк апа Әхмәт абый турында. Үзе тагын! Йә, кайсы Джульетта аз акча алып эшләгән ире һәм ике бәбкәче белән баракның 7 квадрат метрлы бүлмәсендә ачлы-туклы килеш елмаеп-көлеп-җырлап яши алыр иде икән? «Бөтен авырлыкны үз өстенә алып, мина Авиация институтының кичке бүлеген тәмамларга мөмкинлек бирде, — ди Әхмәт абый. — Ул чордагы безнең ярлылыкны, тормышның шәфкатьсез изүен фәкать бер-береңә булган олы, саф мәхәббәт һәм ихтирам белән генә җиңә алганбыздыр дип уйлыйм... Соңгы 17 ел гомерен минем әнием дә бездә яшәде. Гөлчәчәкнең ана булган ихтирамын, хөрмәтен улларым күреп үсте». Сәламәтлеге дә какшаган була бит әле әбекәйнең.

Көнчелеккә килсәк, бер хатын-кыз телефоннан шалтыратып, Әхмәт абый турында котлы сүз сөйли башлагач, Әхмәтен «кемдер белән бүлешмәс өчен үләргә дә



*Гөлчәчәк һәм Әхмәт Галиевләр журналда «Тулгак» бәяны басылу уңаеннан «Казан утлары» редакциясендә. Икенче рәттә уңнан сулга: Р.Фәйзуллин (баш мөхәррир) һәм редакция хезмәткәрләре Л.Гатауллина, М.Вәлиев, Э.Камалова, Ф.Латыйфи, Т.Шиһабиева. Астагы рәттә сулдан Г.Бәйрәмова һәм А.Рәхимова. 2000 елгы фото.*

әзер» (апабызның үз сүзе) Гөлчәчәк апаның җавабы мондый була: «Күрәм, сез дә аңа гашыйк. Аңа гашыйк булмау мөмкин түгел, мин сезне аңлыйм, әмма берничек тә ярдәм итә алмыйм».

— Кер уганда күлмәген битемә китереп: «Бу бит Әхмәтемнең күлмәге, бу бит Әхмәтемнең исе!» — ди торган идем, — журналыбызда эшләүче кызларга Гөлчәчәк апа бер тапкыр шулай дип сөйләгән... Гөлчәчәк апа редакциядә икешәрөчәр сәгать корректура укыганда да Әхмәт абый сөенеп тын гына көтә торган булган.

Ир — баш, хатын муен булганмы соң бу гаиләдә? Начар түгелдер бу, әмма мәхәббәтне, хәтта гап-гади татулыкны да кайчакта шул нәрсә юкка чыгара бит. Алар белән ун еллап аралашкан кеше буларак, бөтен нәрсә киңәшеп эшләнгән дип беләм. Юкса Әхмәт абый зур түрә бит инде. Аннары ул пенсионер булып кала, Гөлчәчәк апа исә шунда үзен меңнәрчә кеше белгән, яраткан бик популяр язучыга әйләнә. Әллә нинди психологик кытыршылыклар (ким дигәндә!) килеп чыга алыр иде мондый җирлектә. Бу гаиләдә исә — киресенчә.

Күптән түгел мина завод житәкчеләренең берсе белән сөйләшергә туры килде. Теге елларда Гөлчәчәк апаны көн саен диярлек иртәнге якта заводта күргәнлеген әйтте ул. Әхмәт абыйга күп вакытын ала һәм алҗыта торган кәгазь эшләрен эшләшкәндер дип фаразларга кала инде хәзер. Мәктәп директорлыгыннан китеп бит бу! Өйгә дә кайткан инде бу эш. Өйдә тагын авыру каенана да бар бит әле... Әхмәт абый үзе исә болай дип язган: «Ул инде үзенең бөтен көчен миңа багышлады. Әгәр дә бу «югалтулар»га бармаган булса, мин техник фәннәр буенча кандидатлык һәм докторлык дәрәҗәләренә ирешә алмаган булыр идем. Мин житәкләгән Компрессор фәнни-производство берләшмәсендә ел саен дистәләгән яна типтагы компрессор машиналары житештерелмәгән булыр иде». *(«Сөембикә». — 2000, №8).*

Бу урында Гөлчәчәк апаның күнеленә иң якын затларның берсе булган Рәфыйк Шәрәфиев сөйләгән хәл бик тә мач килер. Галиевләр Балтач районының Шода авылына, үзләрен кавыштырган Мирхәйдәр Фәйзи музеена юл тоталар. Гөлчәчәк апабыз Компрессор заводы турында сөйләп бара. Юлдашлары Мәдинә һәм Бакый Зыятдиновлар, барын да шулай нечкәләп белүенә шаккатып: «Сез анда баш инженер идегез мәллә?» — дип сорыйлар. (Галиевләр музейга күп кенә китаплар һәм ун мең сум акча да биреп калдыралар). Мәктәп директорлыгыннан китеп, 15 ел буе «заводлашуын» Гөлчәчәк апа: «Үз карьерама караганда ир хакын хаклауны кирәгрәк санадым», — дип аңлата. Ире пенсиягә киткәч ул, ниһаять, иҗатка тотына һәм... Гөлчәчәк апабыз моны үзе әйтеп бирсен әле:

— Әдәбиятка, шигъри сүзгә игътибарлы, нечкә җанлы Әхмәтем дә иҗат эшемне хуплап, көч биреп торды. «Әллә никадәр ачылмаган хәзинә бар күнеленда, гел мине кайгыртып талантың хакында уйларга вакытың юк,» —дип бик тә борчыла иде... *(Роза Камалетдинова. «Сөембикә» — 2010, №7).* Акча түләп китапларын чыгарыша, уңышлары өчен үзеннән дә ныграк сөенеп тора Әхмәт абый.

Биредә саналган китапларның барысы да аларның үз акчасына чыгарылган. Мона тагын «Иҗат көзгесе» дигән, Гөлчәчәк апаның иҗаты һәм тормышы

турындагы, тиражы нибары 200 данә булган бүләк китапны да өстәргә кирәк. Һәм... шаккатмалы хәл: Татарстан китап нәшрияты үзе, үз теләге белән «Әсәрләр» дигән китап чыгарды. Анда шул ук «Газзәбану», «Тулгак», «Өзелгән өмет» һәм тагын бәләкәй Әхмәт турындагы «Барсам» дигән хикәя кергән. 430 битле ин зур китабы бу Гөлчәчәк апанын. Бизәлеше дә бик матур. Язучыга моннан да шәп «комплимент» әйтеп була микән: нәшрият үзе сайлап, яратып анын китабын чыгарган! Гөлчәчәк апанын ничекләр сөенүен белсәгез икән. 2013 елнын октябрьләрендә була инде бу. Апабызнын вафатына нибары 6-7 ай калган, димәк. Шунын ничәдер ае, бәлкем, сихәтле дару кебек шушы китап өлешенә тиядер әле...

Хатын-кызда бик сирәк була торган нәрсәдер бу – нечкә күнеллелек, йомшаклык белән катгый туры сүзнен сыешуы. Гөлчәчәк апабызнын 80 еллык юбилей кичәсендә укылган шигыремнән бер өзек китерим әле.

*... Хаксызлыкка йоны тырпаядыр,*
*Мәкерне ул күрә утәли.*
*Теле нисез аның... каптырмасыз –*
*Дошми калмас Гөлчәчәк Гали!*

*Төн йокламый чыга ала, җәлләп*
*Занзибарда үлгән атларны.*
*Колагыннан тартып үстермәкче*
*Күңеленә якын затларны.*

Анын туры сүзе матбугат аша да әйтелде. «Күнелемә якын затлар» китабы исә – матбугат аша эшләгән игелеге... Минем дә колактан тартты ул. Башта «Казан утлары»нда, аннары шул китабында минем турыда зур мәкалә чыгарды. Язар өчен сораштыра, китапларымны таптыра башлагач, «Кирәкми, башлаган повестегызны гына язгыз әнә», – дигән идем юкса. «Идел»дә баш мөхәррир урынбасары чак бу минем. Көтмәгәндә, безне сөендереп, «Шәһри Казан»да журналга күзәтүләр чыгара башлады апабыз. Ун еллап вакыт үткәч, Алсу Хәсәнованын Гөлчәчәк апа белән «Ватаным Татарстан»да (2008, 22 февраль) чыккан әңгәмәсеннән генә белдем: мин киренен «күнеленә ачкыч табар өчен» язган икән бит ул аларны!

2014 елнын 11 мае. Хатыным Дания белән Нагорный посёлогынын Ельня урамыннан килабез. Менә килеп тә җиттек. Ундагы өйдә әдәбиятны да, сәнгатьне дә шәп кенә белгән Зирәк атлы зирәк ир-егет яши – хатыны, Жыр һәм бию ансамблебезнен элекке җитәкчесе Лима Кустабаева белән. Сулда – Әхмәт абыйлар капкасы. Эчтәге келәне гадәттәгечә кул тыгып кына ачабыз да ишек алдыннан болдырга таба атлыйбыз. Килеп җитәрәк гаҗәпсендек: тәрәзәдән ир-ат тавышлары ишетелеп тора иде. Кунаклар килгән микәнни? Юк, Әхмәт абый тавышы бу. Борчулы тавыш. Чире көчәйгәннән сон анын йөрү «метражы» кимегәннән-кими барып, инде бу як бүлмәгә чыкканы да юк иде кебек, көнен дә, төнен дә караватта ятып үткәрә иде бугай бит ул. Ни булган сон?!

Бүлмә ишеген ача башлауга, Әхмәт абыйнын сүзләре аермачык булып ишетелде:

– Ничек итеп сине, бәгърем, салкын җир куеннарына салыйм?

Кергәч, гел елмаеп йөргән Гөлчәчәк апанын тынсыз гәүдәсен күреп, тетрәнепләр киттем. Махсус шушы бүлмәгә чыгарылган – Гөлчәчәк апабызнын җәсәде бит инде бу! Әхмәт абый урындыкка утырган, куллары хатынынын тәнендә, янда уллары Шамил, киленнәре Мәрзия һәм оныклары Шамилә басып торалар.

– Нигә мине шулай калдырып киттен инде?!

– Култык асларын җылы бит әле! Китмә, бәгърем, китмә!..

Өзгәләнеп әйтелгән, ачы газап һәм сөю-ярату тулы шундый сүзләрне бәгыреннән берөзлексез бушата торды Әхмәт абый. Сөеклесен җир куенына үзе индерә алмаячагын да, башка күп нәрсәләрне дә анларлык хәлдә түгел иде ул...

Юк, Әхмәт абыйны калдырып киту түгел Гөлчәчәк апабызнын үлеме. Башта мин үлсәм, Әхмәтемә авыр булачак, дигән сүзне әйткән иде инде ул...

Гөлчәчәк апаны озату мәрасиме аларнын ишегалларында узды. Сеже зиратында

жирләдек аны. Зиратның кырый өлешендә. Унда-сулда бер кабер дә юк... Гөлчәчәк апа үз янында Әхмәтенә дә урын алып калды менә...

*Кулымдагы йөзегемнең*
*Исемнәре Гөлчәчәк.*
*Сиңа булган мәхәббәтем*
*Гүремә кадәр җитәчәк, —*

дип язган иде Әхмәт абый. Шулай булды, җитте.

Аларга килгәч, Әхмәт абыйның бөтен сүзе дә Гөлчәчәк апага ялгана торган иде. Телендә гел ул, тавышында исә сагыш — мәхәббәт сагышы иде... Гөлчәчәк апасыз ул бары 258 көн генә яши алды. Менә Әхмәт абый да зиратта Гөлчәчәк апа алып куйган урынга килеп ятты. Алар тагын янәшә... Урыннары җәннәттә булсын... Болай дип әйтергә ярамыйдыр да инде, ләкин Гөлчәчәк Кәрим кызы белән Әхмәт Мөхетдин улы оҗмах бакчаларында да бергә, җитәкләшеп йөрерләр кебек тоела миңа...

Язманы теге шигыремнең ахыргы өлеше белән төгәллисем килә:

*...Чү, онытма, юкса татырсың син*
*Аның бөтен ачу-зәхмәтен,*
*Әгәр... әгәр ошбу шигырьгә син*
*Кертми калсаң аның Әхмәтен.*

*Әхмәт Гали – мәгърур татар улы,*
*Зифа буйлы асыл ир-егет.*
*Хыялының нарат матчасы ул,*
*Бәхетенең имән өрлеге.*

*Сыңар шатлык монда яши алмый,*
*Ялгыз яну, ялгыз көю юк.*
*Әйтсәм-әйтим, алар... ике башлы,*
*Куш йөрәкле әйбәт дию кук!*

*Ул мәхәббәт – ярты гасыр кичкән –*
*Һаман садә, һаман фидаи.*
*Безнең мескен, фани каләм моны*
*Яза алмас – кайда Кол Гали?..*

*Ике гали бергә! Бу галилек*
*Җылы, тыйнак, гадидән-гади.*
*Булды алар, шөкер, булыр алар –*
*Әхмәт Гали, Гөлчәчәк Гали!*

Булырлар, әйе. Әгәр башыбызда – акыл, күнелебездә мән табылып, бу исемнәрне онытмасак. Һәм – оныттырмасак...

**Рәфикъ ЮНЫС**

**Өр-яңа хәбәр:** Ельня урамына Әхмәт Галиев исеме бирелгән. Афәрин!



# УЕНЫ-ЧЫНЫ БЕРГӘ

**Зариф БӘШИРИ**

## Истәлекләрдән

...Мин беренче тапкыр Галимҗан Ибраһимов фатирына бардым. Өстәле өстендә бармак төртерлек тә ачык-буш җир күренми, ике башына китаплар, кулъязмалар өелгән. Урталыкта эреле-ваклы төрле кәгазьләр чәчелеп ята. Нинди кәгазь туры килсә, шуңа язылган кулъязмаларны күргәч, минем исемә бер хәл килеп төште: Оренбургта чагымда «Шура» журналында бастыру өчен Риза Казыйга бер нәрсә биргән идем. Ул, кулына алгач та, көлеп куйды:

— Үзең, Америка язучылары шикелле, нинди кәгазь туры килсә, шуңа язгансың икән, — диде.

Мин Риза Казыйның әлеге сүзләрен искә төшереп:

— Чынлап та, әллә син дә шуларга иярәсеңме? — дидем.

— Мин Америка язучыларының нинди кәгазь туры килсә, шуңа язулары турында бернәрсә дә белмим, — диде Галимҗан Ибраһимов. — Әмма мин шуны әйтергә телим: төрле язучыда төрле гадәт бар. Мәсәлән, Көнчыгыш сарай шагыйрьләреннән берсендә шундый гадәт булган диләр: ул, бераз язган саен, иягендәге сакал бөртеген йолкып ала икән. Хан моның белән кызыксына да аңа боерык бирә. «Менә шул турыда бер шигырь яз, ләкин сакалыңа кагылма!» — ди. Шагыйрь утыра да утыра, ләкин барып чыкмый, башы эшләми. Бармакларын сакалга таба суза башлады исә, хан боерыгы җибәрми. Иң азагында шагыйрь хан катына килә: «Юк, ханым-солтаным, башымны киссәң дә булмый, мин сакал бөртеген йолкымыйча бер юл да яза алмыйм», — ди.

**Туфан МИҢНУЛЛИН**

## Булган хәл

Тәтеш районының бер авылында бер мулла абзый болай дип зарланган:

— Ульяновскида ясин чыккан өчен 100 сум түлиләр икән. Без монда 10 тәнкәгә эшереләбез, анасын саткыры!

## Кеше шундый ул

— Бүләк ул, Туфан Абдулович, шундый нәрсә — аны бүлешкәндә, ничаклы тырышсаң да, низаг чыга. Әллә нинди, бер дә кирәкмәгән бүләк булса да. Мәсәлән, тимерче Садыйк абзый тимердән ясап ун кешегә медаль бирсең, унберенчегә бирми калдырсың, барыбер тавыш чыгачак.

## Им-том

— Безнең авылда бер әбигә: «Әби, «Им-Том» дигән гәҗиткә языласыңмы?» — дигәч: «Язылам, бәбкәм, им-том булгач, безгә яраклы гәҗиттер», — дигән. Сүз «Интим» газетасы турында барганын авыл почтальоны да, әби дә аңламаган. Газета килә башлагач кына, мәсьәлә ачыкланган.

## Ачыш булмады

Мәскәүдә, Югары әдәби курсларда укыганда, рус язучысы Алексеев бер яшь язучының табышы турында шаккатып сөйләде:

— Надо же, — диде ул, — у него человеческий голос имеет окраску. Он пишет: «Синим голосом закричал». Это же здорово, замечательно!

Зөлфәт белән безнең исебез дә китмәде.

— У нас даже старушки так говорят, — дидек. — Только у нас говорят еще лучше — «иссиня-зелёным» голосом. «Күкле-яшелле тавыш белән кычкырды» дип бот буе малайлар да әйтә, — дидек.

Алексеевның кәефе китте, чөнки бөек ачышы әрәм булды.

## Лаеклы бүләк

— Кайбер эшлексез кешенең эш турында сөйләгәнен тыңлап торгач, теленә Ленин ордены кадап куясы килә.

**Разил ВӘЛИЕВ**

## «Рәхмәт инде...»

Композитор Заһид Хәбибуллинны мәктәп укучылары белән очрашуга чакырып, Композиторлар берлегенә хат килеп төшә. Очрашуга барыр алдыннан берлекнең партия оешмасы җитәкчесе Заһид агайга үгет-нәсихәт бирә.

— Заһид ага, үзең бик шәп композитор булсаң да, синең гел кирегә сөреп, тормышны каралтып, яманлап сөйли торган гадәтең бар. Күрәсең бит, тормышыбыз көннән-көн яхшыра бара, моның өчен хөкүмәтебезгә, партиягә рәхмәтле булырга кирәк, — ди ул.

Мәктәпнең шыгрым тулы залында укучылар мәшһүр композиторны, аягүрә басып, алкышлап каршы алалар.

— Мин бик тә борынгы кеше бит, балалар. 1910 елда туганмын, — дип сөйләп китә ул. — Минем баштан бик күп фаҗигале хәлләр узды. Унҗиденче елгы революциядән соң дөньялар буталып бетте бит. Бар булган мөлкәтебез юкка чыкты, кешеләр меңәрләп кырылды. Тугыз яшемнән мин шыр ятим калдым — рәхмәт инде Совет властена!

— Аннары илдә гражданнар сугышы башланды. Халык капма-каршы фронтка бүленеп, сугышырга, кан коярга тотынды. Кешеләр ачлыктан кырылды — рәхмәт инде Совет властена!

— Аннары Сталин дәвере, колхозлашу еллары башланды. Хәлле, булдыклы кешеләрнең бар байлыгын талап, йорт-җирләрен яндырып, җыен ярлы-ябагай авылларда мәхшәр куптарды. Шул әтрәк-әләм, ялкау-хөрәсән, тинтәк-наданнар түрә булып алдылар — рәхмәт инде Совет властена.

— Күп тә узмады, Бөек Ватан сугышы башланды. Мәскәү язучылары Казанга, Чистайга яшәргә килделәр ул вакытта. Ә татарның бөтен зыялы затларын: язучыларын, композиторларын, рәссамнарын, галимнәрен фронтка озаттылар. Аларның күбесе сугыш кырларында мәңгегә ятып калды — рәхмәт инде Совет властена.

— Ә сугыштан соң — тагын ачлык, ялангачлык. Алабутасын да, кычытканын да, черек бәрәңгесен дә ашарга туры килде. Безнең буын меңә шундый гыйбрәтле язмыш кичерде — рәхмәт инде Совет властена! — дип Заһид ага сүзен тәмамлый.

**Мәхмүт ХӨСӘЕН**

## Сонет аккордлары

***

Юк, көрәшеп булмый гимнсыз,
Яши алмый дөнья Ленинсыз!

***

Кан короле булсын чын дуслык,
Таң пароле булсын тынычлык!

***

Ибраһимов, Тукай — россиян,
Акыллары белән — океан!

***

Карьерага хирыс түрәләр
Үргә менеп тирес түгәләр.

***

Тигәнәктәй әрсез сырышып,
Әй имәсең илне, сорыкорт!

***

Феодаллар күптән бетсә дә,
Рухы яши кайбер бетчәдә.

***

Әй кешелек, бүген күр менә:
Татар театры үр менә!

**ҮЗЕ**

## Сүз куәте

Язучыларның идарә утырышында Марсель Галиевне Тукай премиясенә кандидатлар исемлегенә кертәләр. Аның дус дип йөргән каләмдәшләре яклап сүз әйтергә озаклап җыенган арада драматург Данил Салихов, дәррәү урыныннан кубып, сүз ала. Бәрхет-баритон тавыш белән, актанышларча кайнар хисләнеп, сөйләп китә бу... Ул — Марсель Галинең шигырьләренә язылган җырларның мәңгелеге, ул — аның тел-сурәтләвендәге могҗизаи образлар дисеңме!

— Укымаган килеш шулай сөйли, укыса ничек сөйләмәс иде! — дип пышылдый Ркаил Зәйдулла күршесенә.

Теле телгә йокмый Данил Салиховның, артист буларак, Станиславский алымы буенча, һәммә кешегә бармагын төбәп, аерым мөрәҗәгать иткән кебек сөйли, чукынчык. Аның сүз куәсенә бирелеп, Марсель Галиев тә үзенең бөеклегенә отыры ышанганнан ышана бара, хәтта дулкынланудан күзенә яшь килә. Аның ышануы бер хәл (кайсы язучы эчтән генә үзен бөек дип санамый инде), бүтәннәрнең дә бит аның иҗатына сокланудан күз төпләре дымланып чыкты әнә.

Ниһаять, идарә әгъзаларын сәхнәви карашы белән тагын бер кистереп алганнан соң, Данил Салихов нотыгын тәмамлый. Бер мәлгә хәлиткеч тынлык урнаша.

Шул мәлдә Равил Фәйзуллин маңгай аланына шытып чыккан суык тир бөртекләрен кулъяулыгына җыеп ала да, тамак кыргандай шикелле ютәлләгән сыман алагаем көрсенеп:

— Җәмәгать, мона бит Тукай премиясе генә аз... Тәкъдим итү уңайсыз хәтта, — ди. — Әллә соң турыдан-туры Нобель премиясенә юллыйкмы үзен?!

*Сәхифәне* **Марсель ГАЛИЕВ** *әзерләде.*



*Ак җилкән*

Балачак белән яшьлек арасындагы
гүзәл дөньяда яшәүчеләр, бу — безнен сәхифә!

## ХИКӘЯ ЯЗА АЛАСЫЗМЫ?

### Мин ялгызым түгел хәзер

**Мин аны йөрәгемнән мәңгегә алып атарга, ә баламны саклап калырга ант иттем.**

**Язның ярсулы бер көне иде ул...** Мин, гадәттәгечә, салмак кына атлап, эштән кайтып киләм. Ашыгасы җирем юк, өйдә көтүчем дә юк. Тик шулай да бүген озак йөрмәскә исәп: аякларым мин торган йортка юнәлделәр. Һәм юкка түгел икән. Ишек төбендә Ахирәт апам басып тора иде.

— Әминә, мин синең янга олы йомыш белән килдем бит әле, — диде ул, мин ишекне ачканны да көтмичә.Тупсадан ук сөйли башлаган ханымны өйгә үтеп кергәч туктатам димә инде.

— Әминә, балакаем, әйдәле, утырыйк әле, сөйләшик...

Ул мине җитәкләп диярлек диванга китереп утыртты да тиз генә дога кылды һәм сүзен дәвам итте:

— Менә инде ничәнче ел шәһәрдә яшисең, эшләп йөрисең, ә гаилә корырдай кешеңне һич очрата алганың юк әле! Яшең дә бара, бала табарга да вакытың узып китеп бара инде хәтта. Мин сине шуңа күрә бер егет белән таныштырырга булдым әле. Егете бик ипле, бик укымышлы, дөнья көтәрдәй, аңа чыккан хатын-кызга бернәрсә хакында да уйларга урын калмаячак.

— Мин ...

— Тукта, каршы төшәргә ашыкма. Башта күр, сөйләшегез... — Ул минем кулны ычкындырмыйча җайлап кына сыпырып утыра бирде.

Башка вакытны, димләүченең кем булуына карамастан, кырт кисеп «юк» дип әйтсәм дә, бу юлы әллә назлы тавышы сихерләде, әллә кулларны берөзлексез сыпырып тору ялгызлыктан тәмам туңып беткән йөрәгемне эреттеме, «юк» димәдем, танышырга ризалыгымны бирдем.

Иртәгәсе көнне ишек төбендә кичәге таныш ханым белән булачак кияү мине көтеп торалар иде инде.

Аннары соң бар да төш кебек кенә булды. Танышу, чәчәкле-кәнфитле кичләр, һәм, ниһаять, никах... Ах, бу никах дигәннәре шулай тиз булмаса, мин, бәлки, миңа җибәрелгән сихерле йогынтыдан айныган да булыр идем, тик буласы булган, үкенүдән эшләр узган иде инде...

Аны үлеп яраттым дип әйтә алмыйм, әмма тәз, горур гәүдәле ир-егет мине үзенә буйсынырга мәҗбүр итте. Көннәрдән бер көнне ул, хатын-кыз ир йортында торырга тиеш дип, мине үз өенә алып кайтып китте. Таныш булмаган өйнең тупсасын атлап керү белән, үземне төрбәгә (мавзолей) килеп кергән кебек хис иттем. Күзне иркәләрлек берни юк иде бүлмәләрдә, хәтта тәрәзә төбендә үсеп утырган гөлләр дә каберлек өстенә салынган җансыз чәчәкләрне хәтерләтә иде.

— Менә, хатын, шушы өйдә син хуҗабикә буласың! — диде ул. — Әйдә, нигә катып торасың, эшкә кереш, сиңа эш күп монда, — дип, үзе алып килгән әйберләрне ташый башлады.

Өй миңа ошамады. «Мал иясенә охшый» диләрме әле, минем ирем дә игътибарлы, ягымлыдан шушы тәрбә төсле өйгә әверелде: шундый ук салкынлык исә башлады аңардан. Пешергән ризыктан — кимчелек, эшләгән эштән гаеп эзләп тинтерәтер булды. Өстәвенә аз-маз гына салгалый да башлады, имеш, ул стресс кичергән, шуны шул рәвешле юкка чыгара. Ә син, хатын-кыз булып тугансың икән, димәк, синең бәхетең шуннан, түз барысына да!

Рәнҗегәннәрне күрсәтмәскә тырышып яшәдем, йөрәк астында, ни дисәң дә, аның сабыен йөртәм ич. Балага ата кеше кирәк кирәген, тик аның анасын шулай һәрвакыт кимсетеп яшәүче ата кеше нәрсәгә өйрәтеп үстерә алыр икән аны? Эшләр шуңа барып җитте ки, хәтта телефоннан сөйләшкәндә дә мин ансыз гына сөйләшә алмадым. Кесә телефонын йә яшереп куя, йә тулы тавышына ачып куя да текәлеп сиңа карап утыра башлый, янәсе, берәр артык сүз әйтеп кара... Тәнемнең генә түгел, җанымның, күңелемнең сакчысына да әверелде ул.

Ялгызлыгымнан качып, шундый ук ялгызлык тозагына килеп эләктем бит мин... Элекке иркен тормышымны сагына башладым. Әйе, анда да мин ялгыз идем, тик бу ялгызлыкны үтә тыныч күңел белән кичерә идем. Ә монда үземне тагын да ялгызрак тоя башладым. Ә мин тормышта эзләгәне — ул күңел берлеге белән бер тын алып яшәрлек затны табу иде. Йөрәк астымдагы баламның беренче кат тибеп куюы әнә шундый затның минем тормышыма килүен исбатлаган шикелле булды. Мин ялгызым түгел! Минем балам булачак! Димәк, мине үз җаена ватарга, кимсетергә тырышучыдан мөмкин кадәр ераккарак китәргә кирәк, балам хакына, аның язмышын минеке кебек ваттырмас өчен, китәргә! Һәм мин аны йөрәгемнән мәңгегә алып атарга, ә баламны саклап калырга ант иттем!

**Әлфия АРСЛАНОВА,**
*татар теле һәм әдәбияты укытучысы.*
*Башкортстан, Кушнаренко районы,*
*Карача-Елга авылы*

## Ләйсән яңгыры

**«Там, там, там, тамуыңны яратам», — яңгыр астында шулай дип җырлап барганда, ул... уянып китте. Кайдадыр чалкан ята икән бит, ә аның өстенә ниндидер кыз иелгән. Теге җылы тамчылар шуның күзеннән тама икән ул!**

Илгиз, керфекләрен көч-хәл белән күтәреп, тирә-якка күз салды, шактый вакыт үзенең кайда ятканын абайлый алмый торды. Соңыннан гына, әче спирт исен тоеп, ап-ак түшәм һәм стеналарны күреп алганнан соң,тирәсендәге ятакларда берничә кешенең шәүләсен күргәч, хастаханәдә ятканын аңлады. Ә салкын бит очларына йөрәк түреннән, бәгыреннән сытылып чыккан кайнар яшьләрен тамызучы — ул аның сөйгәне Ләйсән иде.

Ильяс ни булганын исенә төшерергә тырышып карады. Ләкин бар хәтерләгәне: әллә нинди усал җанварлар тавышы чыгарып бәрелешкән ике тимер ат та, тән буразналары аша аккан сыек кан инеше һәм шул инешнең башы булган җәрәхәтләрнең сулкылдап сызлавы иде.

Ә бу мөлаем кыз? Ә бу коңгырт күзле, килешеп торган нәзек кашлы кыз белән ничек танышып, очраша башладылар соң әле алар?

Ләйсән яңгырның шыбырдап койган мәле иде. Кызык. Ничек туры килгән бит, ә! Аларның очрашып йөри башлаганнарына атна-ун көн генә булгандыр әле. Ләйлә белән Мәҗнүндәй бер-берсенә бер күрүдә гашыйк булган ике яшь йөрәк Кабан күле буендагы төсле фонтаннарның «җырлаганын» тыңлап йөриләр иде. Фонтандагы су тамчылары «Әдрән диңгез» көе белән гаҗәеп төсләр чыгарып агыла. Шул вакытта кинәт беренче, күптән көттереп килгән яңгыр, ләйсән яңгыры башланмасынмы?! Барысы да тизрәк яңгырдан качу ягын карый. Озак та үтмәде, мәйданда мәхәббәттән тилергән ошбу пардан башка беркем дә калмады. Чалбар балакларын сыксаң, бер чиләк су чыгар инде, ә алар һаман уйныйлар, шаяралар. Казан уртасында мондый мөмкинлек тагын кайчан булыр?

— Ләйсән ләйсәнне ярата! — дип, шатлык тулы тавышы белән кулларын күккә күтәреп аваз салды Ләйсән.

— Илгиз Ләйсәнне ярата! — дип җавап бирергә кирәк тапты Илгиз.

— Там, там, там, тамыуыңны ярата-а-ам! — дип шатлык яшьләре аша яңадан җавап бирергә ашыкты Ләйсән.

**Алинә ЮНЫСОВА.**
*Мамадыш*

## Кычкырып укылган хат

**«Күк-күк, күк-күк, күк-күк...» — ә күке санады да санады. Айгөлнең аны нәрсәгә юрап санатканын белә иде микән ул?**

Әле ярый җәйге матур көннәрдә күкеләр күкелди, алар бит Айгөлнең зур өмете. Айгөл күкенең мөмкин кадәр әзрәк күкелдәвен тели, чөнки ул әнисе кайтасы көнне күкегә ышанып саный. Әнә бит, күке дә ишеткән, ахрысы, 3-4 көн элек сигез яки тугыз тапкыр күкелдәсә, хәзер биш-алты тапкыр гына күкелди. Димәк, әнисе, һичшиксез, тиздән кайтачак, күке алдамас! Бу кошка чын күңеленнән ышанды шул Айгөл. Иртән бәбкәләрне су буена алып барганда, Айгөл белән әнисе гел күке тавышы ишетәләр иде. Соңгы арада әнисе күке тавышын ишетүгә туктап кала да, нидер саный да, авыр сулап куя. Нәрсә санады икән аның әнисе? Айгөл бу турыда белми иде. Ләкин күке әнисе санаганда кыскарак, әзрәк күкелдәгән сыман тоелды аңа. Әллә әнисе күкенең әз күкелдәвенә үпкәләп кәефсезләнде микән?.. «И, күке, нигә тавышыңны кызганасың, әнинең күңеле булыр иде, күкелдә әле озак итеп», — дия торган иде кыз шулчакта. Ләкин әнисе генә: «Алай димә, кызым, күке ялгышмас, үзем дә шулай сизәм...» — дип, кызын кочагына алып һәм карынындагы бәбиен сыйпап үксеп елый да таралыша башлаган бәбкәләрне җыя — су буена юлларын дәвам итәләр иде алар. Никтер Айгөл әнисенең олылар сөйләшә торган җитди сүзләр сөйләвен өнәп бетерә алмый, әнә әле дә әллә нинди сәер сүзләр әйтеп куйды, аңа әнисе назлы, йомшак итеп әйткән сүзләр күбрәк ошый.

Хәзер урамнан үткән чагында күрше-тирә апалар никтер Айгөлдән гел хәлен сорыйлар, бәби еламыймы дип тә белешкәлиләр. Кайберләре берничә сум акча яки кәнфит бирәләр дә, Айгөлнең башыннан сыйпап: «Тәүфигың белән исән-сау үсә күр, балакай, без дә кулдан килгәнчә булышырбыз», — диләр. «Ни булган соң бу апаларга, элек бер дә болай эшләмиләр иде бит?» — дип аптырашта да калгалады Айгөл. Мөгаен, аның энесе туу шатлыгын шулай бүлешәләрдер, ул бит хәзер дәү апа булды! Шушы уйлардан соң сөенеп, очынып китә дә өй түрендә бишектә яткан энесе Аязның бит очыннан үбеп ала.

Ничек рәхәт бит алар өендә хәзер! Әтисе белән әбисе Аязны бик яраталар, бер генә минутка да янында китмиләр. Әле тиздән әниләре дә кайтып житсә, тормышлары түм-түгәрәк булыр! Айгөлнең исәпләвенчә, әнисе тагын өч-дүрт көннән кайтып житәргә тиеш. Их, ничек сагынды бит ул әнисен! «Бәбиләр өләшә торган жир»гә Аязны алырга дип киткән иде әнисе, Аяз кайтты, тик әнисе генә күренми әле. Аяз да кайтканнан бирле көйсез, гел елыйсы килеп тора, ул да әнине сагынадыр инде дип уйлады Айгөл. Ә әби нигә Аязны кочаклап елый икән? Әтинең дә кәефе юк. Алар да, мөгаен, әнине сагынганнардыр... Ә әнисе Аяз белән бергә кайта алмаган, чөнки бәби алган жирдә Аязның киемнәре, уенчыклары тузгып ята икән, әнисе шуны жыештырырга калган, әбисе шулай дип аңлатты. «Энемнең ул уенчыкларын әни монда алып кайтса, рәхәтләнеп уйнар идек. Әни шактый озак торды, мөгаен, Аязның уенчыклары ике сумкалык булгандыр! Хәер, юк, ике сумка гына түгел, бер атна буе жыелган уенчык тагын да күбрәк, дәү бер тау кадәр булгандыр инде...» — дип уйлады Айгөл.

Көннәр шулай үтә торды. Айгөл беркөнне йокы булмәсендә ниндидер тавыш ишетте. Әкрен генә ишекне ачып караса, аның әтисе әнисенең Айгөл төнлә кочаклап йоклый торган киемнәрен кулына кысып тоткан да үксеп-үксеп елап утыра. Бу хәлдән соң Айгөл түзмәде, әнисенә хат язарга булды. Дөрес, ул әле беренче класста гына, шулай да яза белә инде. Хаталары булса, әбисе белән әтисе төзәтер әле, төзәтмәсә, аның әнисе акыллы бит, болай да аңлар ул аны. Хаталарын төзәтеп укыганда, менә мондый иде хат:

«Сәлам, әнием! Әни, Аязның киемнәрен, уенчыкларын жыеп бетердеңме әле? Инде күке кычкырмый да башлады, димәк, сиңа кайтырга вакыт, ә син һаман күренмисең. Әни, жыелган әйберләреңне ал да кайт син, калганы андагы бәбиләргә калсын. Сумкаларыңа сыймаса, безгә әйт, әти күрше Салих абыйның дәү машинасы белән апкайтыр. Анда бәби бирүче апаларга әйт инде, мине көтәләр, диген, тизрәк кайт, әни, без сагындык. Аязның, әтинең, әбинең сине бигрәк тә күрәселәре килә, аларны елатма, кайт, яме, әни! Көтәм. Кызың Айгөл».

Әлеге хатны кыз әтисе кулына тапшырды, чөнки аның әтисе бу дөньяда Айгөл өчен барысын да эшли, бу хатны да, һичшиксез, әнисенә тапшырыр.

– Әниең безне күзәтеп тора ул, кызым, еламаска куша. Бу хатны аңа кычкырып укырбыз, ул ишетер, — диде әтисе калтыраулы тавыш белән...

**Гөлшат ЗӘЙНИ**

---

## ХАЛЫК ӘЙТСӘ, ХАК ӘЙТӘ

- Ат башында нукта, кызлар күзе чукта.
- Кыз бала — өй зиннәте.
- Кызлар бүрәнә ярыгындагы таракан ботыннан да көләләр.
- Егет кыз алгач тәүфыйк таба.
- Кыз акыллы егет эзли, егет матур кыз эзли.

# «ТАНЫМЫШ» ДӘРЕСЕ

*Җаваплар (№3)*

①

②

③

④

⑤


***1. Равил Гайнетдин***
Гает житсә намаз укый,
Урам тулы мөселман.
«Путин» мәчете кирәк шул,
Тырыш син, Равил туган.

***2. Илдус Гыйләҗев***
Бердәнбер язучыдыр син —
Жирдән аерылмаган.
«Жир китабы» – җыр китабын
Шәп язгансың бит, туган.

***3. Искәндәр Гыйләҗев***
Туры Аязның улы син,
Шул дәрәҗәңне сакла.
Татар теленең атасы
Дигән исемне якла!

***4. Зәки Зәйнуллин***
Көрәш уртасында булдың,
Кайда гына торсаң да.
«Чын полковник», әлбәттә, син,
Сүз дә юктыр бу хакта.

***5. Салават Фәтхетдинов***
Зур талант иясе бит син.
Шуны аңлый халкыбыз.
Син бит безнең иң кадерле
Икенче Илһамыбыз!

**Рушания НИЗАМОВА.**
*Аксубай районы, Яңа Дума авылы*

①

②

③


④


⑤

*Сездән Зөлфәт Хәйруллинның бу шаржларына да эпиграммалы яки гади җаваплар көтәбез. Рушания Низамовага исә ике санга да эпиграммалы дәрес җаваплары өчен биш плюслы ике зур «бишле» куябыз!*

# МӘКАЛЬ ӨМӘСЕ

- Иелгән башта таҗ тормас.
- Салкын сугышлардан сәясәтчеләр җылына.
- Иманасын саткан салым түләр, Ил-анасын саткан калым даулар.
- Кансызлар кан түгүчән.
- Үлеп ярату гомерне озайта.
- Кәфенгә кесә текмиләр.
- Гамәл дәфтәренә әләк карасы йокмас.
- Учак та җырлый, пычак та җылый.
- Су кушып сөйләшүче судан коры чыга.
- Соңгы юлга сәфәрдәш кирәкми.
- Оҗмахта ачык ишекләр көне үткәрелми.

**Зиннур МАНСУРОВ**

- Әләкче белән гайбәтче — игезәкләр.
- Тел — кылыч, кынында тотарга тырыш.
- Эчендәге ялкын белән өй җылынмый.
- Карчыгың «карт» дип дәшсә дә күңелле.

**Фарук НӘФИЕВ.**
*Тәтеш*

- Ялган дан ялган яманаттан яманрак.
- Авыз чайкаган һәрнәрсә пычрана.
- Аяксызга — ката, хак сүзгә хата кидереп булмый.
- Инквизиторга һәйкәл салып, булмый тарихта калып.

**Нәҗибә САФИНА**

- Түрдә озак утырган түрә дәүләт кесәсенә керә.
- Авырлыктан курыкма, авырудан курык.
- Атынны мактасаң да, хатынынны мактама, ялгышың үзенә кайта.

**Мөнир АБДУЛЛИН.**
*Казан*

- Ашына күрә табагы, эшенә күрә тамагы.
- Ялкауга йомыш кушсаң, артыннан үзең бар.
- Агачны бөкмичә дуга ясалмый.

**Госман ГОМӘР**

- Мулланың кесә телефоны да «Бир-р!»-«Бир-р!» дип чылтырый.
- Гайбәткә ишек ачсаң, йортыңа кот кунмас.
- Бака сазлыкта батмас, гайбәт кесәдә ятмас.
- Чын мәхәббәткә ант кирәкми.
- Шүре — җепне, сүз сүзне тартып чыгара.

**Рашат НИЗАМИ**

*Сәхифәне* **Рәфикъ ЮНЫС** *әзерләде.*

# Ictimagi-mədəni tormışıbızdan
# Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан

### РӨСТӘМ МИҢНЕХАНОВ ТАТАРСТАН ПРЕЗИДЕНТЫ ВАЗИФАЛАРЫН БАШКАРУЧЫ ИТЕП БИЛГЕЛӘНДЕ

Россия Федерациясе Президенты Владимир Путин Кремльдә Рөстәм Миңнеханов белән очрашты.

Владимир Путин очрашу барышында Татарстан Республикасының соңгы биш елдагы үсешен югары бәяләде. «Төбәк житәкчесе вазифаларын 2015 елның сентябрендә Татарстан Республикасы Президенты сайлауларына кадәр үтәвегезне сорыйм», — диде, Рөстәм Миңнехановка мөрәҗәгать итеп. Үз чиратында Рөстәм Миңнеханов Владимир Путинга ышанычы өчен рәхмәт белдерде.

Россия Президенты Владимир Путин «Татарстан Республикасы Президенты вазифаларын башкаручы турында»гы Указны имзалады, дип хәбәр итә Кремльнең матбугат хезмәте. Дәүләт башлыгы сайтында урнаштырылган документ тексты нигезендә, Рөстәм Миңнеханов вәкаләтләре вакыты чыгуга бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Президенты итеп сайланган зат үз вазифасына керешкәнче, вакытлыча Татарстан Республикасы Президенты вазифаларын башкаручы итеп билгеләнә.

### ПРЕЗИДЕНТ УКАЗЫ

Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнехановның 2015 елда Татарстан АССР оешуга — 95 һәм Татарстан Республикасының яна дәүләтчелегенә 25 ел тулуны бәйрәм итү турында Указы игълан ителде.

### ЮБИЛЕЙ

ТР Президенты Рөстәм Миңнеханов Кремльдә Россиянең һәм Татарстанның халык артисты, республикабызның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Әзһәр Шакировны 75 яшьлек юбилее белән котлады, аңа «Татарстан Республикасы алдында казанышлары өчен» орденын тапшырды һәм машина бүләк итте. Тантанада Президент Аппараты житәкчесе Әсгать Сәфәров, Президент ярдәмчесе Ләйлә Фазлыева һ.б. катнашты.

Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында Әзһәр Шакировның 75 яшьлеге уңаеннан тантаналы кичә булды. Юбилярны республикабызның Премьер-министры урынбасары Васыйл Шәйхразиев, Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Римма Ратникова, республикабыз театрлары, сәнгать әһелләре, якташлары котлады.

### ТАТАР КИТАПЛАРЫ ЕВРОПАДА

Германиянең Лейпциг шәһәрендә узган халыкара китап ярминкәсендә Татарстаннан «Мәгариф-Вакыт» нәшрияты да катнашты. XVII гасырдан ук килүче иң борынгы китап күргәзмәсе быел 251 мең кешене жыйды. Нәшрият стендыннан дүрт көн буе халык өзелмәде. Берничә язучы һәм галим «Мәгариф-Вакыт»та үз китабын бастырырга теләк белдерде, Германиянең «Райнхардт» нәшрияты үзара хезмәттәшлек тәкъдим итте.

### ГАБДУЛЛА ТУКАЙ БҮЛӘГЕНӘ КАНДИДАТЛАР

2015 елда Татарстан Республикасының Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә кандидатлар исемлеге игълан ителде.

**Булатова Клара Гариф кызы.** «Келәү». Шигырьләр, повесть, хикәя» (Казан: Татар.кит.нәшр., 2013), «Сәяхәтнамәләр». Шигырьләр (Казан: Татар.кит.нәшр., 2013), «К солнцу лицом» (Казан: «Рухият» нәшр., 2013) китаплары өчен.

**Кәримов Камил Әдһәм улы.** «Уен». Роман, хикәяләр һәм юморескалар (Казан: Татар.кит.нәшр., 2010), «Игезәкләр йолдызлыгы». Роман-фарс («Казан утлары», 2010: №9, Б.5-62, №10, Б.6-50), «Ком сәгате». Роман, повестьлар (Казан: Татар. кит.нәшр., 2000), «Сакау күке». Роман, повесть (Казан: Татар.кит.нәшр., 2005) китаплары өчен.

**Колмогорцева Ирина Константиновна.** «Казан һәм Габдулла Тукай» график эшләнмәләр сериясе өчен.

**Корбанов Рафис Харис улы.** «Рафис Корбан шигырьләре» (Казан: Татар.кит. нәшр., 2013) китабы өчен.

**Леронов Лемон Лерон улы.** «Бәхеткә биш минут кала». Пьесалар (Казан: Татар.кит.нәшр., 2012), «Сөяксез тел». Пародияләр, эпиграммалар (Казан: Татар.кит.нәшр., 2008), «Жил көймәсе». Шигырьләр (Казан: «Мәгариф» нәшр., 2008) китаплары өчен.

**Матуров Илдар Заһир улы.** «Моя линия фронта» (2010), «Туфан — Туфан инде ул» (2013) фильмнары өчен.

**Салихов Харис Салих улы.** «Религия и наука (основы мировых религиозных и свет-

ских культур)» («Дин вә фән» (дөньякүләм дини һәм мәдәни этика нигезләре) (Казан: «Идел-Пресс», 2012), «А.Пушкин, Г.Тукай иҗатында Коръән вә бүгенге рухи тәрбиянен бер мәсьәләсе» (Казан: «Идел-Пресс», 2008) хезмәтләре өчен.

**Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрының иҗат коллективы.** Мөхәммәтҗанов Рәүфәл Сабир улы, Ковтун Георгий Анатольевич, Андреева Кристина Андреевна, Тимаев Михаил Иванович. «Алтын Урда» спектаклен куйган өчен.

## «ТАНТАНА» ПРЕМИЯЛӘРЕН ТАПШЫРУ

Казанда Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында «Тантана» театр премияләрен тапшырдылар. Быел бу чара бишенче тапкыр үткәрелде. Анда К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма театрында куелган «Кара пулат» белән Г.Камал театрының «Хуҗа Насретдин» спектакльләре «Ел вакыйгасы» дип бәяләнде. «Намус һәм тугрылык» номинациясендә призга Казандагы яшь тамашачылар театрыннан Александр Купцов лаек булды. Г.Камал театрыннан артистлар Рамил Вәҗиев, Илнур Закиров, Эмиль Талипов, Алмаз Сабирҗанов «Минем исемем Кызыл» спектаклендә «Пластик образ тудырган өчен» бүләкләнделәр. Чаллы Татар дәүләт драма театрыннан Разил Фәхретдинов — «Ирләр ролен иң яхшы башкаручы» номинациясендә җиңүче. Шул ук театрдан Чулпан Арсланова «Иҗади үсеш өчен» махсус приз белән бүләкләнде. С.Өметбаев исемендәге Минзәлә татар дәүләт драма театры артисты Ленар Миннемуллин — «Иң яхшы эпизодик роль өчен» бүләк алды. Г.Камал театры артисты Илдар Хәйруллин «Хуҗа Насретдин» спектаклендә Җиһангир роле өчен ТР Президентының мәдәниятне үстерүгә ярдәм фонды призына лаек булды.

Быел премияләрне (һәркайсы 50шәр мең сум) 20ләп артист алды. Бәйрәм Әдәбият елында үткәрелү уңаеннан бүләкләрне язучылар тапшырды.

## НӘҮРҮЗ БӘЙРӘМЕНЕҢ ХӘЙРИЯ ЯРДӘМЕ

Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында Нәүрүз бәйрәменә багышланган концерт булды. Анда «Адмирал» Сәүдә йортында зур янгын чыгу аркасында зыян күрүчеләргә Хәйрия фонды тарафыннан акча җыю да оештырылды.

## ИҖАДИ ДУСЛЫКНЫ НЫГЫТУ

Татарстан Язучылар берлегенең 80 еллыгы уңаеннан Тукай клубында уздырылган әдәби кичәдә төрки халыкларның иҗади дуслыгын ныгыту, иң яхшы әдәби әсәр үрнәкләрен тарату, алмашу турында зур сөйләшү булды. Кичәдә Азәрбайҗан Язучылар берлеге рәисе Анар Рзаев та катнашты һәм чыгыш ясады. Аның чыгышына караганда, «Азәрбайҗан» әдәби-нәфис журналында язучы-прозаик, публицист Тәүфикъ Әйдинең «Ватансыз» хикәясе һәм Татарстанның халык язучысы Марсель Галиевнең «Рух» әсәреннән «Атилла рухы» дигән эссе Азәр Абдулла тәрҗемәсендә дөнья күргән.

## «КАЗАН УТЛАРЫ» БӘЙРӘМЕ

Чаллы шәһәрендәге «Энергетик» мәдәният сараенда «Казан утлары» журналының бәйрәме булды. Кичәдә журналның баш мөхәррире Илфак Ибраһимов, Татарстан Республикасының халык шагыйре, «Татмедиа» акционерлык җәмгыятенең генераль директор кинәшчесе Равил Фәйзуллин, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, «Чаллы икмәге» ябык акционерлык җәмгыятенең генераль директоры Рафаэль Юнисов, Чаллы дәүләт педагогия институты ректоры Фәйрүзә Мостафина, «Агросила групп» ябык акционерлык җәмгыяте генераль директоры Фәнис Газетдинов, Тукай муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге җитәкчесе Рамил Исаев, Чаллы шәһәре мәгариф идарәсенең баш белгече Наилә Миначова, Татарстан Республикасының халык язучылары Рабит Батулла, Марсель Галиев, журналның баш мөхәррир урынбасары Рамил Ханнанов, бүлек мөхәррирләре Камил Кәримов, Айгөл Әхмәтгалиева, шагыйрь Газинур Морат, Татарстан Язучылар берлегенең Чаллы бүлеге җитәкчесе Факил Сафин, Чаллыдан язучылар Айдар Хәлим, Әлфия Ситдыйкова, Сирень Якупова, Айрат Суфиянов, «Татмедиа» акционерлык җәмгыятенең корпоратив үсеш буенча баш белгече, шагыйрә Сиринә Мөхәммәтҗанова, Татарстан Республикасының халык артисты Рөстәм Маликов һәм башкалар катнашты, чыгыш ясады. Кичәне «Энергетик» мәдәният сараеның директор урынбасары Гөлзада Рзаева алып барды.

## БӘЙГЕ

Ижау шәһәренең «Спартак» мәдәният сараенда Удмуртия Республикасы мәктәпләрендә укучыларның иҗади бәйгесенә йомгак ясалды. Җиңүчеләрне Татарстан Республикасы Язучылар берлеге рәисе урынбасары Данил Салихов, «Казан утлары» журналының җаваплы сәркатибе Вакыйф Нуриев, шагыйрь Рифат Җамал, җирле шагыйрьләр Ринат Баттал, Ибраһим Биектаулы, Әлфирә Низамова, Татарстан Язучылар берлегенең шәрәфле әгъзасы Зәкуан Нуретдин һ.б. котлады.

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

«Проза и поэзия»: исторический рассказ С.ШАМСИ «Отец и ханбикэ»; рассказ Р.ЗАРИПОВА
«Иным путём»; сонет Ф.САФИНА, стихи З.МАНСУРОВА, А.СИТДИКОВОЙ, Ф.ГИЛЯЗОВА, Р.ВАЛИЕВА.
«Драматургия»: драма Д.САЛИХОВА «Баязит».
«Конкурс на повесть малого формата»: Н.АМИНОВ. «Гость из Сибири».
«Искусство»: беседа Р.БАТУЛЛЫ с Ф.БИКЧАНТАЕВЫМ; М.АРСЛАНОВ «Прощай, Хаджа Насретдин».
«100-я страница»: Р.БАТУЛЛА. «Тукай, Тукай...»
«Публицистика»: Я.ШАФИКОВ. «Кто первым водрузил Знамя Победы над Рейхстагом?»
«Наука»: И.БАШИРОВА. «Писал ли Тукай на турецком языке?..»
«Кандидаты Государственной премии РТ им. Г.Тукая»: статьи Р.ШАГИЕВА о творчестве К.БУЛАТОВОЙ, БАТУЛЛЫ о творчестве К.КАРИМОВА, Р.РАХМАНИ о творчестве Р.КУРБАНА.
«Литературная критика»: Н.ЮСУПОВА «Мир поэзии: 2014 год».
«Наши юбиляры»: статья М.ВАЛИЕВА, посвящённая 80-летию со дня рождения Роберта Ахметзянова; стихи Р.АХМЕТЗЯНОВА.
«Память»: А.ШАМОВА. «Ваши судьбы связаны с огнём войны»; воспоминания А.ХАСАНА
«Наша судьба»; Р.ЮНУС. «Ахмет Гали, Гулчачак Гали...»
«Страницы юмора»: рубрику ведёт М.ГАЛИЕВ.
«Белый парус»: рассказы А.АРСЛАНОВОЙ, А.ЮНУСОВОЙ, Г.ЗАЙНИ; «Узнавайка».
Из фотоархива журнала. Рубрику ведёт Р.ФАЙЗУЛЛИН.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: памятник Г.Тукаю в деревне Новый Кырлай Арского района. Автор проекта — Б.Урманче, скульптор — И.Новосельцев; скульптура «Загадки Шурале» на площади перед театром Г.Камала. Автор — А.Миннуллина.

## IN THIS ISSUE:

«Prose and poetry»: historical narrative by S.SHAMSI «Father and hanbika»; story by R.ZARIPOV
«By other way»; sonnet by F.SAFIN; poems by Z.MANSUROV, A.SITDIKOVA, F.GILYAZOV, R.VALIEV.
«Dramaturgy»: drama by D.SALIHOV «Bayazit».
«Competition for the small-format novel»: N.AMINOV. «Visitor from Siberia».
«Art»: conversation of R.BATULLA with F.BIKCHANTAEV; M.ARSLANOV «Goodbye, Haja Nasretdin».
«100th page»: R.BATULLA. «Tukay, Tukay...»
«Publicism»: Ya.SHAFIKOV. «Who was the first hoisted the Victory Flag over the Reichstag?»
«Science»: I.BASHIROVA. «Did Tukay write in Turkish?..»
«Candidates of the State Prize of the Republic of Tatarstan named after G.Tukay»: articles by R.SHAGIEV about K.BULATOVA's creativity, by BATULLA about K.KARIMOV's creativity, by R.RAHMANI about R.KURBAN's creativity.
«Literary criticism»: N.YUSUPOVA «World of poetry: 2014».
«Our heroes of the day»: article by M.VALIEV dedicated to 80th anniversary of Robert Akhmetzyanov; poems by R.AHMETZYANOV.
«Memory»: A.SHAMOVA. «Your fates are linked with the fire of war»; memories by A.HASAN
«Our fate»; R.YUNUS. «Ahmet Gali, Gulchachak Gali...»
«Pages of humor»: section is led by M.GALIEV.
«White Sail»: stories by A.ARSLANOVA, A.YUNUSOVA, G.ZAYNI; «Let's find out».
From photo archives of the magazine. Section is led by R.FAYZULLIN.
Diary of the social-cultural life.
On our covers: G.Tukayu monument in the village of New Kyrlay, Arsky region. Author of the project: B.Urmanche, sculptor: I.Novoseltsev; sculpture «Shurale's mysteries» on the square in front of the G.Kamal theater. Author: A.Minnullina.

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Габдулла Тукайның Арча районы Яңа Кырлайдагы һәйкәле. *Проект авторы — **Бакый Урманче**, скульптор — **И.Новосельцев**.*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* Г.Камал театры каршындагы мәйданда «Шүрәле табышмаклары» скульптурасы. *Авторы — **Асия Миңнуллина**.*

# БАТЫРЛЫК ЕЛЪЯЗМАСЫ

## *Абдулла Алиш – каһарман шагыйрь*



*Абдулла Алиш «Пионер каләме» (хәзерге «Ялкын») журналының хезмәткәре. 1938 ел.*



Charlottenburg ... 26. August ...

25. August 1944 ...

Der Standesbeamte

*1944 елның 25 августында Абдулла Алишның җәзаланып үтерелүе турында немец хәрби суд администрациясенең таныклык белешмәсе.*



*Әдипнең туган авылы Көектә (Спас районы) бюст-һәйкәле.*

## *Мәхмүт Хөсәен – шагыйрь, фронтта тупчы, командир*



*Сугышчан орден-медальләр иясе офицер Мәхмүт Хөсәеновка 24 яшь. 1947 ел.*



*Шагыйрь Мәхмүт Хөсәенгә 60 яшь. 1983 ел.*

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

2015
Парклар һәм
Скверлар елы



Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)